КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Разил ВӘЛИЕВ. Мин бәхетле – ил бәхетле булса... *Шигырьләр.* ....3
Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Буа. *Роман.* ....7
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Гел яхшыга юрасын тик кошлар... *Шигырьләр.* ....69
Айдар ХӘЛИМ. Моң кайтты. *Повесть.* ....74
Нәҗибә САФИНА. Мәңгелек белән элемтә. *Шигырьләр.* ....103
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Лаләләр. *Хикәя.* ....107
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. Табылсын якуты вакытның... *Шигырьләр.* ....125

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Камил КӘРИМОВ. Йөзгә-йөз. ....129
*«Казан утлары» – минем язмышымда:* Фоат САДРИЕВ. Иҗат казаны. ....132

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Рафис КОРБАН. Соңгы Сабантуй. *Хикәя.* ....134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Лилия ГАЛИТЗУЛЛИНА. Хикәя җегәре *(Айдар Хәлимгә – 80 яшь).* ....143
Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Дөньяны бары тик яхшы якка үзгәртүче *(Разил Вәлиевкә – 75 яшь).* ....147
Зиннур МАНСУРОВ. Ваемлы йөрәк авазы. *(Ркаил Зәйдуллага – 60 яшь).* ....157

*Фотоархив:* Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе,
Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә – 85 яшь. ....168

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Тәнзилә ЗУМАКУЛОВА. Сез килегез миңа кунак булып... *Шигырьләр.* ....170
Муталип БЕППАЕВ. Тауларым – минем очар кошларым... *Шигырьләр.* ....172
Әскәр ДОДУЕВ. Җәһәннәм белән куркытма мине... *Шигырьләр.*
*(Балкарчадан Рафис КОРБАН тәрҗемәләре).* ....173

ИДЕЛ БУЕНДА ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Идел-Чулман төбәгендә ислам дине: Идел буе Болгар дәүләте. ....174
*Сәнгать:* Юныс САФИУЛЛИН. Әлки әллә әллүкиме? ....179
*Әдәби берләшмәләрдә:* Р.Гыймадиева, А.Сәгыева, Г.Гыйниятов, Д.Әхмәдуллина, Г.Ибраһимова, Р.Сабирҗанов, М.Сибгатуллина, Ф.Абдуллина, З.Хәкимуллина *шигырьләре*.... 185
*Газиз тавышлар:* Аны әле һаман яраталар *(шагыйрь Зөлфәтнең туына – 75 ел).* ....188
Балаларның якын дусты *(Дания Гайнетдиновага – 70 яшь).Сәхифәне*
*Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 1 (1191) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан, Рамил Ханнанов.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2021, график буенча 29.12.2021, басылып чыгу вакыты 11.01.2022.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-0070. Тираж 8507.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Разил Вәлиев

# МИН БӘХЕТЛЕ – ИЛ БӘХЕТЛЕ БУЛСА...

## Яңарасы иде, агарасы...

Ак карларда эри төн карасы,
Төзәлә күк Җирнең җан ярасы.
Ак карларга охшап, безгә дә бит
Агарасы иде, яңарасы.

Яңарасы иде, арынасы
Күңелләрне сарган сагышлардан –
Моңа кадәр һәрбер туар көнгә
Бәхет юрап, күпме ялгышкан бар...

Офыклар да бер ачылыр әле,
Көн яктырыр, болыт бер таралса.
Тик әлегә илдә буран дулый,
Без барасы юлны карлар баса.

Шул карларны ерып, еллар кичик,
Карамыйча юллар уравына.
Кыйбла – туры, Иман тулы булса,
Адашмабыз язмыш буранында.

Яңа елда хәсрәт-кайгылар да
Әверелсен карга – ак тузанга.
Хыял кебек ымсындырып безне,
Болытлардан өстә йолдыз яна.

Күчсен аклык һәммә күңелләргә,
Килсен шатлык һәммә кешегә дә!
Ходай кушып, Яңа елда күктән
Бәхет иңсен безнең ишегә дә!

Бәхет иңсен барча кешеләргә!

---

Разил ВӘЛИЕВ (1947) – *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә чыккан күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

## Мең яшә!

*Йөзьяшәр «Казан утлары» журналына*

Син мәңгегә килгәнсеңдер, – татарның үзе сыман.
Синең асыл битләреңә халкымның җаны сыйган.

Гарәп, латин, кириллны да хәтереңбелә, таный...
Бер гасырлык аксакал син, йөз яшь тутырган сабый.

Тәүге саның чыккан көнне әйткәннәрдер: «Йөз яшә!»
Син элек тә, син бүген дә безнең белән янәшә.

Уздың каралмый, таралмый караңгы еллар аша.
Синең аша безнең язмыш чорлар белән тоташа.

Халкым сиңа үткәннәрдән, киләчәктән эндәшә:
«Йөзең саклап, Йөз яшәдең, хәзер инде Мең яшә!»

## Өмет

Хастаханә... Ап-ак диварлары...
Ничәнче кат керде төшемә.
...Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?

Яктыра да тәрәз, тагын сүнә...
(Ник сүнәсең? Сүнмә, гел яшә!)
Хастаханә шушы тәрәз аша
Җиһан белән гүя сөйләшә.

Янәшәдә генә Идел ага,
Болыт йөзә күктә агарып.
Бер кайгысыз кошлар агачларда
Уйный әле һаман, шаярып.

Яр буеннан парлар үтеп бара,
Бала-чага таган атына.
Тәрәз аша хәбәр җибәргәндәй,
Төпсез күктә йолдыз атыла.

...Ә палата ап-ак... чиста, тынлык...
Оҗмахы да шундый булмасын...
«Сәгатең бор. Туктамасын, улым...
Ә аннан соң... дару юлларсың...»

Хастаханә... Ап-ак диварлары...
Бүген тагын керде төшемә.
Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?!

## Женева күлендә

Кай илдә, кай җирдә булмадым! –
Һәммәсе уелган күңелгә.
Сагышлы җанымны чайкадым
Саф сулы Женева күлендә.

Бу илнең җире саф, суы саф, –
Ләкин ул минеке түгел лә...

Язмышым язылган Казанда,
Иделдә һәм Кабан күлендә.

Болакның болганчык сулары,
Иделнең каралган ак ташы...
Женева күленең саф суы
Җанымда Иделгә тоташты.

## Рәссам

Әйдә рәсем ясыйм әле –
Булсын бер кызык.
Томаны ак кәгазь булыр,
Яңгыры – сызык.

Аннары сине ясармын
Яңгыр эчендә,
Ә күлмәгең яшел булыр –
Урман төсендә.

Күз ясармын, зәңгәр буяу
Табалсам әгәр, –
Чөнки синең күзләрең бит
Сагыштай зәңгәр.

Тын калырмын, күзләреңдә
Күренгәч яшьләр.
Шул чагында йөрәгемдә
Яшеннәр яшьнәр.

## Татар мөһаҗире

Күпме татар, чит җирләргә китеп,
Тирләр түккән, даннар казанган...
Канатларым канап каерылса да,
Аерылмады җаным Казаннан.

Төп Ватаным чөнки шушы җирдә,
Яшәсәм дә әллә кайларда...
Татар булып пешеп җитәр өчен
Казаннарда кирәк кайнарга.

Адашмадык язмыш юлларында,
Давылларда сынып аумадык.
Без яңадан илле, җирле булдык,
Без Казанны кабат яуладык.

Мин бәхетле – ил бәхетле булса,
Халкым булса азат, тәхетле.
Мин милләтем – татарларым белән
Бергә чакта гына бәхетле!

## Тегермән

Илем хаста, телем аста...
Ни калыр оныгыма?
Тегермән ташы әйләнә,
Тик чыкмый оны гына.

## «Әтисез» бала

Көтелмәгән бер дәвамы булып
Мәхәббәтсез корган чатырның,
Карында ук йодрык төя-төя
Ул әтисен, гүя, чакырды.

## Соңгы сүзем...

Мин дөньяга татар булып килдем,
Татар булып яшим, яшәрмен!
Газраилем миңа сүз катканда,
Туган телдә аңа дәшәрмен...

## Мәҗүси

Мин, кыйбламны эзли-эзли,
Берүзем җир буйлап барам.
Язлар белән яшелләнәм,
Кышлар белән чал агарам.

Оҗмахым да – бу тормышым,
Тәмугым да – бу тормышым...
Әкиятләргә ышанырга,
Табынырга күп тырыштым.

Барып кердем урманнарга,
Килеп чыктым киң кырларга...
Сызгырмадым урманнарда,
Ашыкмадым җыр җырларга.

Оста барда телең тый, ди...
Телем тыйдым тургай барда.
Бәхет керсә төшләремә,
Куркып яттым уянырга.

Сокландым мин имәннәргә,
Сокландым мин усакларга...
Агачларны бергә җыеп,
Их, бер кысып кочакларга!

Мин нарасый бала бугай...
Шаман кебек шашып көлдем,
Барып чыктым җир читенә...
Очрамады миңа үлем.

Очсам – күгем, йөзсәм – күлем,
Иярләнгән атым көтә...
Бер мәҗүси бала кебек –
Табынам гел табигатькә.

## Көз офыгы

Көз әле алтынсу биләүдә –
Мин инде җәйләрне сагынам.
Сагышның мәйданы киңәя –
Офыклар киңәйгән чагында.

Соңгы кат сөенеп калыйм, дип,
Каеннар таң белән торганнар.
Күңелгә көз моңын иңдереп,
Каңгылдый һавада торналар.

Яңгырый хушлашу авазы
Күкләрдән, таулардан – бар яктан;
...Йөрәгең өзелер бер мәлдә –
Агачтан өзелгән яфрактай.

Тик һаман кошларга ияреп,
Талпына күңелем югары.
Бәхетнең үзенә илтә күк
Күктәге кошларның юллары.

## Бәхетле булсыннар җырларым

*Җырчы Хәния Фәрхи истәлегенә*

Мин җиргә яз белән килгәнмен,
Елыйсы урында көлгәнмен.
Күз яшен йөрәккә яшереп
Яшисен алдан ук белгәнмен.

Мин җирдә моң эзләп яшәдем,
Яшеннәр сукса да, дәшмәдем.
Елларым чабудан тартканда,
Алкышлар шавыннан яшәрдем.

Дөньяда килү бар, китү бар...
Газаплы ул көнне көтүләр.
Мин сезгә мең кабат бурычлы, –
Мин киткәч, бурычым җыр түләр.

Мин китәм мәңгелек иленә,
Хушыгыз, урманнар, кырларым.
Мин китәм язмышка ияреп,
Калдырып иң газиз моңнарым.

Мин китәм мәңгелек иленә,
Бәхетле булсыннар җырларым.

## Хушлашу

*Җырчы Рафаэль Сәхәбиев истәлегенә*

Син сәхнәгә чыгып җыр башласаң,
Китә иде дөньям яктырып...
Каян килгән синә бу якты моң,
Каян килгән мондый затлылык?!
Синең белән күпме юллар кичтек,
Учак ягып, таңнар аттырдык...
Җырың белән илләр яуладың син...
Каян килгән мондый батырлык –
Илаһилык, рухи матурлык?!
Китеп бардың, җыр калдырып илгә,
Җир уллары отып ятларлык.
«Мин татар» дип, оран салмасаң да,
Ташып торды синдә татарлык.

Дуслар өчен жаның фида иде,
Ихлас иде һәрчак күңелең.
Шатлык чәчеп җирдә яшәдең дә
Якты сагыш булып түгелдең.
Һәр көн саен хәзер көтәрмен мин
Гарешләрдән синең тавышны.
Ташлап киттең. Юкса, безнең дә бит
Гомеребез көзгә авышты.
Кара җирнең кайгыларын күмеп,
Озакламый килер ак кышы...
Изге җаның Җомга иртәсендә
Фәрештәләр белән кавышты.

*Яңа исемнәр*



*1980 елның 18 апрелендә Буа районының Югары Лашчы авылында туган. 2005 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. 1998 елдан «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең яңалыклар хезмәтендә корреспондент, 2002 елдан «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясендә тапшырулар алып баручы. 2005 елда «Татарстан яшьләре» газетасында авыл хуҗалыгы бүлеге мөхәррире булып эшләп ала, шул ук елны телевидениегә алып баручы вазифасына кайта. 2011 елда Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясенең Татарстандагы филиалы директоры итеп билгеләнә.*

*Беренче язмалары мәктәп елларында «Яшь ленинчы» газетасында дөнья күрә. 1997 елдан «Татарстан яшьләре» газетасы белән хезмәттәшлек итә, анда мәкаләләре, фельетоннары урнаштырыла. 2005 елда «Идел» журналында «Хәтер корбаны» дигән кечкенә генә хикәясе басылып чыга. 2010 елда «Безнең гәҗит» газетасында «Иблис утары» хикәясе дөнья күрә.*

Фирдүс Гыймалтдинов

# БУА

РОМАН

*Кырмыскалар да буаны ерып җибәрә ала.*
Япон халык әйтеме

Әле таң беленеп кенә килә иде. Тимерхановларның биек капкасы төбендә купшы тарантас туктады. Ике яхшы ат җигелгән тарантас үзе дә елкылдап тора. Өстенә кунган тузан гына юлчыларның еракта килүенә ишарәли.

Тарантас туктарга өлгермәде, аннан озын буйлы чибәр егет – Сәгыйдулла сикереп төште. Бер генә мизгелгә туган нигезен күздән кичерде дә капканы ачты. Бикле түгел иде. Ишегалдыннан җил-җил атлап, болдырга күтәрелде. Ишек катында аны абыйсының хатыны Нәсимә каршылады.

– Исәнме, Матур апа, – диде Сәгыйдулла, кул биреп күрешеп.

– Саумы, Сәгыйдулла! Ничек кайтып җиттегез?

– Әйбәт кенә, рәхмәт... Абый кайда?

– Абыең мәчеттә... – Нәсимә чак кына уңайсызланган төсле булды.

– Әни ничек?

– Әни уянды инде. Сине көтә ул, йокысы качты...

Сәгыйдулла, туфлиләрен салып, сак кына басып, әнисенең бүлмәсенә юнәлде.

Әнисе Шәмсекамәр остабикә урын өстендә ята иде. Иркен бүлмәсенә кояш иртәнге нурларын сирпегән. Ире Хәбибрахман исән чакта бергә йоклаган сәкедә ул хәзер ялгызы. Әнисе кечерәеп калган сыман. Өстендә юрган, баш астына берничә мендәр өелгән, ул ярым утырган килеш улын көтә.

– Балакаем... – диде әнисе, Сәгыйдулла бусагадан атлап кергәч тә. Күзләреннән яшь тамчылары атылып чыкты. Баласы сак кына сәкегә, әнисе янына утырды, аның шыр сөяккә калган көчсез кулларын учына алды. Сәгыйдулланың да, тыела алмыйча, битеннән яшьләр тәгәрәде.

Алар шулай, берара сүзсез генә бер-берсенә карашып утырдылар. Акрын гына бер кулын улының учыннан алып, ана кеше сабыеның битеннән яшьләрне сыпырды.

– Ябыгып киткәнсең, балам, – диде ул, Сәгыйдулланы беренче мәртәбә күргән сыман дикъкать белән өйрәнеп. – Ашарыңа начардыр инде ят җирләрдә.

– Юк, әни, ашау әйбәт, эшем күп.

– Дөнья куганда, үзеңне онытырга ярамый. Мал ул бер көнлек кенә, аның артыннан чабып, тормыш мәгънәсен җуя күрмә, улым.

– Җуймыйм, әни. Петроградта мәчет тә бар, шунда йөреп торам, мәхәлләгә булышам.

– Сәдакаларыңны, догаларыңны Ходай кабул итеп алсын. – Шәмсекамәр остабикә кинәт моңсуланып китте, карашын улыннан аерып, тәрәзәгә күз салды. – Мин нык бетештем инде, улым. Кайтканыңа рәхмәт, үлеп киткәнче сине исән-имин килеш күрәсем килде. Күп калмады миңа, гомерем үтә. – Әнисе авыр көрсенеп мышкылдап куйды, аннан кинәт елмаерга көч тапты, янә баласына таба борылды. – Аллаһы боерса, әтиең Хәбибрахман белән очрашырбыз. Ходай җәннәт рәхәтлекләрен бирә күрсен инде, булган гөнаһларыбызны ярлыкасын...

– Амин, әни. Тик син алай начарга юрама әле. Бик матур күренәсең, Аллага шөкер...

Шәмсекамәр остабикә рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

– Кеше үләр алдыннан шулай матурая ул, балам. Син кайту шатлыгыннан гына шулай матур мин. Урыннан тора алмыйм, киленебезгә Ходай түземлеген бирсен. Өрмәгән урынга да утыртмый, ни теләсәм, шул бар, тамак кына бернинди дә ризык сорамый...

– Ашарга кирәк, әни. Үзең тагын миңа әйткән буласың. – Сәгыйдулла, елмаеп, шаяртырга тырышты.

Ишек катында тавышлар ишетелде, аннан бүлмәгә Хәмидулла мулла килеп керде.

– Әни, саумы, хәлләрең ничек? – дип, башта ул Шәмсекамәр остабикәгә эндәште, аннан соң ике кулын энекәшенә сузды: – Әссәламегаләйкүм, Сәгыйдулла, исән-имин кайтып җиттеңме?

– Кайттым, абый.

– Ярый, әйдәгез, бер дога. – Хәмидулла мулла урындыкка утырды, ике кулын догага күтәрде. Ана кеше белән энекәше дә аңа кушылды. Амин иткәч, Хәмидулла Сәгыйдуллага борылды: – Озакка кайттыңмы?

– Озакка дип... Ничек килеп чыгар инде.

– Бераз торсаң зыян итмәс. Урын күп, кучерыңа да почмак табарбыз. Эшләрең әйбәт кенә барамы?

– Бара, Аллага шөкер. Мәхәллә ничек?

– Бездә дә шөкер. – Хәмидулла мулла урыныннан торды. – Әйдә, юлдан алҗыгансыңдыр, Матур апаң табын хәстәрләде, чәйләп алыйк.

Олы якка чыккач та, Сәгыйдулла, кулларын юып, табынга утырды. Түр башында урын алган Хәмидулла дога кылды, шуннан соң гына ашауга керештеләр.

– Петроградта хәлләр ничек? – дип сорады Хәмидулла.

– Катлаулы...

– Бер яктан сугыш, икенче яктан большевиклар, меньшевиклар, эсерлар, тагын әллә кемнәр... Дөнья бик нык болганчыкка әйләнде, ни булып бетәр... Бәлки, Петроградтагы кибетләреңне сатып, авылга кире кайтырсың?

Сәгыйдулла җавап бирергә өлгермәде, мулла бүлмәсе ягыннан бала елаган тавыш ишетелде. Нәсимә, сикереп торып, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, нарасые янына ашыкты.

– Күпме булды инде Зөбәйдәгә? – Сәгыйдулла Нәсимә киткән якка ымлады.

– Яшь ярымны тутырырга җыенабыз, Алла бирсә.

– Бәхетле-тәүфыйклы бала булып үссен!

– Амин... Сәгыйдулла, син минем сорауга җавап бирмәдең. Кире туган җиргә кайтырга уйламыйсыңмы? Авылга димим, Сембергә, әйтик...

– Юк, абый, минем эшләрем Финляндиядә яшәүче татарлар белән бәйле, сәүдә әйбәт кенә бара, сугыш афәте безгә берничек тә тәэсир итми. Шуңа күрә Петроградтан мөмкин кадәресен алып калырга кирәк. – Сәгыйдулла берара уйланып, дәшми торды. Аннан кинәт аңына килгәндәй булды. – Әни ничек соң, аның сәламәтлеге ни хәлдә?!

– Күрдең бит инде әнине... – Хәмидулла көрсенеп куйды. – Син кайтасын белгәч, төн йокысы качты, сине көтте. Ничек кенә аяныч яңгырамасын – язмыштан узмыш юк, яшь үзенекен итә, әнигә бакыйлыкка күчәргә озак калмагандыр, энекәш. Шуңа күрә кайтканың өчен рәхмәт сиңа.

– Рәхмәт дип... Минем дә әни бит инде ул. Ә бәлки, аны Казанга, йә булмаса Сембергә алып барып, табибларга күрсәтеп карарга кирәктер?!

– Картлыктан дәва юк, энем. Ул урын өстендә ята, юлга чыксаң, хәле авыраерга гына мөмкин.

Әниләре яткан бүлмә ягыннан «Балаларым, килегез әле!» – дигән аваз ишетелде. Икесе дә сикереп торып Шәмсекамәр остабикә янына ашыктылар. Моңарчы остабикә яртылаш утырган шикелле булса, хәзер инде яткан, мендәрләре як-якка күчерелгән. Йөзе дә баягыдай балкымый, тагын да картаеп, каралып калган төсле. Шәмсекамәр остабикәнең хәле киткәнлеге бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Ул ике улына янәшәсендә урын күрсәтте. Сәгыйдулла әнисе янына сәкегә, Хәмидулла исә урындыкка утырды. Шәмсекамәр остабикә еш-еш сулыш ала, тыны кысыла, күрәсең. Ләкин ул үзендә сөйләшергә көч тапты.

– Улларым, җанкисәкләрем, мине игътибар белән тыңлагыз. Әтиегез Хәбибрахман белән безгә өй тутырып, бала үстерергә насып булмады. Сез икәү

генә. Мин Ходайдан бирәр кыз бирүен ялварсам да, теләгем чынга ашмады. Картлык көнендә булса да, бераз сөенсен дип, Аллаһы Тәгалә миңа кызым шикелле ихтирам күрсәтүче Нәсимәне биргәндер, күрәсең, – Шәмсекамәр остабикә күз читләрендәге яшьләрне яулык очы белән сөртеп куйды. – Шөкер, икегезне дә таза-сау, укымышлы итеп үстердек. Икегезнең дә үз юлыгыз, үз кыйблагыз бар. Сиңа, улым Хәмидулла, төп йорттагы бала буларак зур рәхмәт. Миңа күрсәткән тәрбиягез өчен, муллалыкта Тимерхановлар нәселенең йөзләрчә еллык эшен дәвам иткәнең өчен. Син ышанычлы ирегет, сиңа гаиләң дә, мәхәллә дә курыкмыйча таяна ала. Синнән дә, хатының Нәсимәдән дә риза-бәхил. Әтиең васыятен үтәп, туган нигезне саклыйсың. Улым Сәгыйдулла, синең үз тормышың. Ул да Ходай язган язмыш. Ят җирләргә китеп, бер ялгызың көн күрү рәхәт түгелдер. Еракта булсаң да, безгә яхшы хәбәрләрең генә ишетелә, нәселебезнең данын арттырасың, хәләл малыңны безнең мәхәлләгә дә биреп торасың. Синнән дә риза-бәхил, улым. Минем көннәрем күп калмады. Балаларым, нәзер итеп әйтеп калдырам – беркайчан да араларны өзмәгез, ызгышмагыз, мал бүлешмәгез. Ерактамы, якындамы – аралашып, туган булып яшәгез. Әтиегез Хәбибрахман белән безгә шуннан артыгы кирәкми. Улым Сәгыйдулла, туган нигезеңне онытма, кайткалап тор. Хәмидулла, синең ишекләр һәрвакыт ачык булсын, табының корылып торсын.

Әниләре сөйләгәндә, уллары, башларын иеп, пышылдап кына «ярар, әни» дип кабатлый тордылар. Шәмсекамәр остабикә тынып калды. Ул еш-еш сулый, күзләре йомылган, йөзенә сихри бер тынычлык нуры иңгән.

– И әни, онытып та торам, сиңа күчтәнәчкә яулык алып кайткан идем бит! – дип, Сәгыйдулла урыныннан торып, олы якка чыгып китте.

Кучер алып кергән саквояж-чемоданнарны актарып, әнисенә дип сайлап алган яулыкны тапты да кире бүлмәгә керде. Ләкин яулыкны әнисенә тапшырырга язмаган икән. Хәмидулла сәке янында тезләнгән. Бер кулында әнисенә иреннәрен чылатырга биргән чәшкә. Икенчесе белән остабикәнең җансыз кулын тоткан да дога укый. Аякларыннан көче китүне тоеп, Сәгыйдулла да тезләнде, башын түбән иеп, догага кереште. Тик фикерләр чуала, күкрәк сулкылдый, яшь тамчылары ага. Еларга ярамаганны белсә дә, туктый алмый. Абыйсы ни дияр? Ул кыяр-кыймас кына Хәмидулла муллага күз салды. Аның да яшьләре чыккан, ул да тыела алмый...

– Энекәш, шуның белән тәмам, – диде, ниһаять, Хәмидулла. Әнисенең күзләрен йомдыргач, алар икәүләп идәннән тордылар. – Нәсимәгә әйтергә кирәк. Мәет юуучыларны да чакырасы, зират өстенә казучылар белән син барырсың. Әти янәшәсенә күмәрбез, әнинең васыяте шундый иде...

Ишектә Нәсимә күренде. Ул, иренең кыяфәтеннән барысын да аңлап, «әни-и» дип ачыргаланып пышылдады да елап җибәрде. Хәмидулла хәзрәт аны кочаклап алды.

– Елама, Нәсимә, түз. Үлгәндә дә, соңгы сүзләре сиңа рәхмәт әйтүе иде. Әниебезне шулай тәрбияләп торганың өчен сиңа мин гомерлек бурычлымын...

Шәмсекамәр остабикәне озатырга бөтен авыл гына түгел, күрше-тирәдән дә бик күп халык җыелды. Араларында чуваш кешеләре дә бар иде. Милләтенә, диненә карамый, мәрхүмә янына чирләрне өшкертергә йөрделәр. Күзгә чыккан арпадан алып, теле ачылмаган балаларга кадәр дәва таба иде

Шәмсекамәр остабикә – дога белән чирләрне куа торган сәләте бар иде. Балаларын да ул әнә шулай өшкереп, төрле авырулардан аралап торды. 1916 елның җәендә данлыклы остабикәне зар елап, җир куенына салып куйдылар...

Остабикәнең өчесе белән җидесен укытканда да, табынга шактый кеше җыярга туры килде. Авылдагыларны чакырмау турында сүз дә юк инде ул, ләкин алардан тыш аның әле таныш-белешләре, ахирәтләре күрше авылларда да җитәрлек. Берсен дәшсәң, икенчесен калдырырга ярамый. Ләкин бу мәшәкатьләрдән Хәмидулла да, Нәсимә дә курыкмады. Ярдәмләшергә күршеләре керде, азык-төлекләре исә җитәрлек. Сарыклар суеп, үз түтәлләреннән яңа бәрәңге алып, үз умарталарыннан хуш исле бал аертып, мул табын җәйделәр.

Җидесен укытканның кичендә Хәмидулла белән Сәгыйдулла капка төбенә чыгып утырды. Көннең эссесе беткән, урамда һава рәхәт, көне буе булган мәшәкатьләрдән бераз ял итү өчен менә дигән.

– Мин иртәгә юлга кузгалырмын инде, абый, – диде Сәгыйдулла. – Сәүдә эшен озакка ташлап булмый, ачуланма, зинһар.

– Ачуланмыйм, энем. Әнинең васыятен онытма. Теләсә кайчан безнең өйгә кайтып керә аласың.

– Беләм, рәхмәт. Матур апа да кочак җәеп каршы ала.

– Сиңа да өйләнергә вакыт инде...

– Вакыт та бит... Петроградта татар кызларын табуы авыр. Кайвакыт эш буенча төрле мәҗлесләргә чакыралар, ләкин андагылар байлыкка гына кызыга. Имана җирләрең күпме, биләмләрең зурмы, дип төпченә башлыйлар да гади бер сәүдәгәр-алыпсатар икәнлекне белгәч югалалар. – Сәгыйдулла көлеп куйды. – Акчага корылган дөньядан нәрсә көтәсең?!

– Анысы хак. Сиңа да хатын табылыр анысы, табылмый калмас. Вакыт бит ул җиткән булырга да, җитмәскә дә мөмкин. Сабырлык белән көтәргә кирәк.

– Гомер буе нидер көтәбез, нидер эзлибез, нидер куабыз... – Сәгыйдулла өйләре яныннан күренеп торган кыйгач айга текәлде. Кичке шәфәкъ нурларында аңа йөгертелгән алтын күз камаштырырлык төсләргә кергән иде. – Бу мәчет аен безнең бабай эшләткән бит?

– Тимерхан бабайның әтисе Вәлиулла...

– Чын алтыннан эшләнгән дигәннәре дөресме икән?

– Алтыны тышкы ягына йөгертелгән, анысы хак.

– Бигрәк матур итеп уйнаклап тора.

– Миңа менә шул иман нурын сүндерми-сүрелтмичә саклап, үземнән соң киләсе яңа буын муллага тапшырасы инде, энекәш. Ходай бу изге бурычны намус белән башкарырга көч бирсен иде.

– Амин...

Икенче көнне Сәгыйдулла тарантасына утырып, Казанга юл алды. Авылдан чыгып киткәндә, зират янына туктап, әтисе белән әнисе каберләре янында дога укыды, аларның рухларыннан бәхиллек һәм ярдәм сорады.

Казаннан поезд аны башта Мәскәүгә алып килде. Биредәге вак-төяк эшләре берничә көнгә тоткарланырга мәҗбүр итте. Аннан Петроградка.

Петроградта Сәгыйдулла затлы бер бинаның мебельле бүлмәләрендә яши иде. Бөтен йорт тулысы белән аның эше вакытлыча торак алып торучыларга бирелгән. Бүлмәләр чиста, аларны җыештырып торырга

аерым бер кеше бар. Ишегалды да ялт итеп тора. Төрле кеше яши бередә, әлбәттә. Имениеләреннән Петроградка кәеф-сафа корырга килеп йөрүчеләр дә бар. Аларын шау-шудан, бокаллар зыңгылдавы, патефон акыртуыннан чамалап була. Авылларында «тир түгеп» алҗыганнан соң, бирегә килеп пар чыгаралар. Помещиклар, гадәттә, бер көтү дусларын, карап торышка ук бик үк тәртипле юлда йөрмәгәнлеге ярылып яткан хатын-кызларны ияртеп кайталар. Бүлмәләрнең берсендә полициядә эшләүче зур гына түрәнең сөяркәсе яши. Милләте белән полька булган туташны пани Ковальская дип йөртәләр. Аның кечкенә генә маэмае бар. Пани бик купшы киенеп йөрергә ярата, опера белән балетны да якын итә икән. Полиция түрәсе соңгы вакытларда еш килә алмый, күрәсең, илдәге болганышлар аркасында эше күптер. Сәгыйдулла берничә тапкыр очратканда, пани Ковальсканың үзенә нык кызыксынып, текәлеп каравын абайлады. Әлбәттә, яшь егеткә үзенә шундый затлы хатынның күз төшерүен белеп тору рәхәт иде, тик андыйлардан ерак торуың хәерлерәк. Шуңа да эшләпәсен күтәреп, чак кына иелә төшеп исәнләшүдән ары китмәде.

Бирегә Урал аръягы промышленникларын да, ялга кайткан хәрбиләрне дә, тагын әллә кемнәрне очратырга мөмкин. Нинди генә затлы күренмәсен, йортның эче серләр, түбән мөнәсәбәтләр, эчкечелек, фахишәлек белән тулган.

Үзе яши торган йортка кайтып җиткәндә, вакыт инде төшкә авышып бара иде. Сәгыйдулла, кулына чемоданын тотып, гомуми бүлмәгә керде. Баскыч буйлап икенче катка, үзенә менәм дигәндә, кинәт колагына татарча җырлаган тавыш ишетелде. Кем булыр бу?! Кем бирегә татар көйләрен сузар?! Сәгыйдулла сак кына көй килгән тарафка юнәлде. Ашханәдә ниндидер кызый җырлый. Сәгыйдулла ишек катыннан үрелеп карады. Бу бүлмәләрне җыештыручы кыз булып чыкты.

– «Карурманны чыккан чакта кисеп алдым пар каен...» – дип сузды кызый, идән юуудан туктамый гына.

Сәгыйдулланың: «Ай, аерылмаек, дускаем», – дип кушылуыннан теге кыз һуштан язар дәрәҗәгә җитте, чиләге авып китеп суы идәнгә түгелде. Сәгыйдулла шундук, чемоданын бер читкә куеп, ярдәмгә ашыкты, кызның кулындагы чүпрәкне алып, идәнгә түгелгән суны җыярга һәм кире чиләккә сыгарга керешә. Бу мәрәкәне кыз шаккатып, уң кулын күкрәгенә куеп, дәшми генә авызын ачып күзәтеп торды. Идән күпмедер дәрәҗәдә судан арынгач, Сәгыйдулла, елмаеп, теге кызга борылды.

– Бирегә татар кешесен очратырмын дип уйламаган идем, – диде ул, чүпрәкне идәнгә куйгач та. – Кул биреп тора алмыйм, туташ, гафу итегез, мин Сәгыйдулла булам. Сезнең исемегез ничек?

– Мин?! Мин... Мин Сәкинә исемле.

– Минем сезне бер дә куркытасым килмәгән иде. Шулкадәр матур җырлыйсыз ки, кушылмый кала алмадым... Гафу итәрсез дип өметләнәм.

– Нәрсә?! Гафу?! Ә... Әйе, әлбәттә. – Сәкинә инде аңына килгән иде. Ул идәндә аунап яткан чүпрәкне күтәреп алды, чиләккә үрелде. – Гафу итегез, суны алмаштырырга кирәк, мин китим инде.

Сәгыйдулла аны карашы белән озатып калды. Ничек шушы көнгә кадәр игътибар итмәгән! Сылу буй, тулышкан алсу иреннәр, зур, якты

күзләр. Озын толымы ипләп үрелгән. Күлмәге гади, ләкин буй-сынына килешле. Үзе дә бик гади кыз кебек. Юк ла, гади түгел, ә ихлас, чиста күңелле. Андыйларны хәзер сирәк очратасың. Бигрәк тә Сәгыйдулла чуалган тирәлектә. Сәүдә дөньясы кырыс, ул керем алуга, кемне дә булса алдауга корылган. Андагыларның күзләре төпсез упкын. Ә Сәкинәнеке... Сәкинәнеке шулкадәр ачык, якты, алардан нур сибелеп тора сыман!

Сәгыйдулла төне буе уйланып чыкты. Көндезге күрешү башыннан чыкмады. Бәлки, Сәкинә – аның язмышыдыр? Авылдан әнисе белән бәхилләшеп килгәннән соң очрашуы да очраклы түгелдер. Кем белә, бәлки, әнисе аның ялгыз яшәүдән интегүен күреп, улына соңгы догасында аңа тиң кәләш теләгәндер? Татар кызы булуы да, бер күрүдә гашыйк итә алуы да шуңа ишарәли. Ә идән юуучы булуы бөтенләй дә мөһим түгел. Анысы төзәтелә торган әйбер, Сәгыйдулланың гына эшләре әйбәт барсын! Авыр эшнең ни икәнен дә белмәс Сәкинәсе. Йокыга киткәндә, ул инде Сәкинәне бары тик үзенеке итеп уйлый, бергә булачакларына бераз гына да шиге юк иде...

Сәгыйдулла мөмкинлек тапкан саен көндезләрен үзе яшәгән йортка сугылып чыга торган булды. Сәкинә күпчелек бүлмәләр бушап калгач җыештыруга керешә. Егет, вакытын туры китереп, кызый белән күрешү, исәнләшү җаен эзләде. Аны күргәч тә, Сәкинә югалып кала, ни әйтергә белми, тавышы чак кына ишетелерлек итеп чыга.

Көннәрнең берендә Сәгыйдулла аңа кичен очрашырга тәкъдим ясады. Сәкинә, гадәттәгечә, эшкә чумган. Сәгыйдулла, бүлмәгә кергәч тә, акрын гына тамак кырды. Сәкинә дерт итеп куйды, аннан егеткә таба борылды.

– Исәнмесез, – диде ул, кулындагы чүпрәген әле тегеләй, әле болай әйләндергәләп.

– Исәнмесез, Сәкинә! – Сәгыйдулла аркасына яшергән чәчәк бәйләмен кызга сузды.

Сәкинәгә беркемнең дә беркайчан да чәчәкләр бүләк иткәне юк иде. Ул тагын да ныграк каушады, чүпрәге шап итеп идәнгә барып төште. Вакыйгаларны аңларлык халәткә килгәнче Сәкинәгә бераз вакыт кирәк булды, ләкин Сәгыйдулла кулындагы чәчкәләрне сузган көе тыныч кына көтә бирде. Кыз алъяпкыч кесәсеннән зур кулъяулык чыгарып, кулларын яхшылап сөртте. Шуннан соң гына ул егетнең кулындагы бәйләмне алды. Чәчәкләр шулкадәр хуш исле иде! Оялуын да онытып, бәйләмне борынына якын китерде һәм тулы күкрәк белән сулыш алды.

– Рәхмәт сезгә, – диде ул, елмаеп. – Әллә бүген берәр төрле бәйрәмме?

– Әйе, бәйрәм. Мин сезне кичен һава сулап керергә паркка чакырам.

Кызның йөзендәге елмаюы юк булды. Бүген җомга, ял көннәренә ул җомга киченнән үк Петроград читендә ялгызы яшәүче әтисе янына кайтып китә. Юк, әтисен борчырга ярамый.

– Гафу итегез, ләкин мин бүген кич буш түгел. – Сәгыйдулланың кәефе кырылуын күргәч, Сәкинә егетнең әллә ниләр уйларга мөмкин икәнлеген чамалады, шуңа аңлатырга ашыкты: – Минем әтием авыру, ял көннәренә мин аның янына кайтам, ә без моннан шактый еракта, шәһәр читендә яшибез...

– Ә, алаймыни? – Сәгыйдулла «жу» иткән йөрәгенең тынычлануын

тойды. Ул Сәкинәнең кемедер бар дип уйлап алган иде, ялгышкан, димәк.
– Зыян юк. Адресны әйтәсез дә, мин сезне экипаж белән кая кирәк шунда илтеп куярмын.

– Әллә ничек...

– Шәп була! Алай-болай миннән качарга уйласагыз, кайдан эзләргә икәнлеген белеп торырмын. – Сәгыйдулла киң итеп елмайды.

Ишектән кемнәрнеңдер кергәне ишетелде. Сәкинә бу рәвештә басып торулары сәер тоелуын аңлап, тизрәк әйтергә ашыкты:

– Яхшы алайса, ничәдә?

– Сез ничәдә бушыйсыз?

– Биштә... Алтыда очрашсак буламы?

– Бик шәп! Димәк, мин сезне кичке алтыда холлда көтәм!

Сәкинәнең башында бүлмәләрне җыештыру кайгысы калмады. Моңарчы аны очрашуларга чакыручы булмады, игътибар иткән егетләр исә майлы күзләрен ялтыратып, кызыйга икеле-микеле тәкъдимнәр генә ясыйлар иде. Ә бусы... Бусы чын очрашу булырга тора. Чәчәкләр дә бирде бит, кичке якта күрешергә дә дәшә. Ничек киенергә? Кершәннәр ягынырга мы? Бизәнү әйберләре дә берән-сәрән генә. Мәрхүм әнисеннән калган яшел ташлы бакыр балдак, шуңа килешле колак алкалары. Артык иске димәсме, артта калган кешегә санамасмы? Кияргә рәтле күлмәге дә юк. Ә Сәгыйдуллага карасаң! Кәчтүмнәре, чалбарлары ничек килешеп тора, кап-кара, аның астыннан һәрвакыт ап-ак күлмәк якасы, галстук! Ә пирчәткәләре? Ахыр чиктә Сәкинә, ни булса шул булыр дип, үзе уйлаганча иң матур дигән күлмәген киде, чама белән генә бизәнде.

Сәгыйдулла аны паркка чакырды. Биредә алар кебек үк парлар, яшьләр йөри.

– Туңасыз бугай, – дип, рөхсәт сорап тормый-нитми, кызның иңнәренә кәчтүмен япты. Кәчтүмнән егетнең җылысы белән бергә баш әйләндергеч татлы исе килә иде. – Әтиегез белән икәү генә яшисез, димәк?

– Әйе...

– Әтиегез ни атлы?

– Барый.

– Сезнең нәсел кай яклардан соң?

– Нижгардан. Ә сез?

– Мин Казан ягыннан, Сембер губерниясеннән.

– Казан да, Сембер дә берьюлы буламыни? – Сәкинәнең күңелен ялганлый дигән шик кытыклап үтте.

– Безнең авыл чикләре буенча Сембер губерниясенә керә, ләкин күңелебез белән Казанда, татарлар ватанында.

– Аңлашылды алайса...

– Әйдәгез, каһвәханәгә кереп, бераз җылынып чыгыйк.

Алар, каһвәханәгә кереп, тагын бераз сөйләшеп утырдылар. Сәкинәгә егет янәшәсендә рәхәт тә, шомлы да иде. Сәгыйдулла кем дә, ул кем?! Алдарга гына йөрмиме?

– Ник сез минем белән очрашуны холлда билгеләдегез?

– Ә кайда билгелисе иде?

– Белмим тагын... Урамда, мәсәлән, яисә берәр мәйданда.

– Бер йортта яшәгәч, нигә андый яшертен юллар белән йөрергә тагын?! – Сәгыйдулла көлеп җибәрде.

– Йортта яшәүчеләр безне күрде бит...

– Күрсәләр, шуннан ни?

– Мин, үзегез беләсез, гади идән юуучы, җыештыручы гына...

– Алай икән. – Сәгыйдулла җитдиләнде. – Миңа сезнең һөнәрегез мөһим түгел. Күңелегез... Ә ул чиста һәм керсез кебек тоелды миңа. Ә безнең йортта яшәүчеләр башта үзләрен белсеннәр, аннан кешене тикшерсеннәр!

Сәкинәгә аның сүзләре ошады. Чыннан да, бүлмәләрне җыештырганда, кайберләре дуңгыз абзарын хәтерләтә, шулкадәр әшәке кыланучылар бар ки, җирәнгеч булып китә.

Беренче очрашуда сөйләшү авыррак барды. Сәкинә Сәгыйдулла өчен әлегә ябык иде. Егет ике арадагы бозлы диварны эретү, кызның ышанычын яулап алу өчен шактый вакыт кирәклеген яхшы аңлый. Ләкин үзендә моның өчен җитәрлек көч барлыгына чынлап торып ышана.

Сәкинәне ул, вәгъдә иткәнчә, экипаж белән кайтарып куйды. Алар әтисе белән Петроградның бөтенләй читендә, караңгы почмакта яшәп яталар икән. Кызның моңа да нык кыенсынуы сизелде. Тик очрашуга ризалашкан икән, димәк, Сәкинәдә дә ниндидер хис кабынган. Ә бу мәхәббәтнең бер дә җавапсыз түгеллегенә бик зур дәлил...

Әтисе Сәкинәне борчылып көтеп торган. Кызының болай караңгыга калганы юк иде. Әллә ниләр уйлап бетерсә дә, кызының исән-имин килеш кайтып керүен кергәч, картның ачуы да, хафасы да басылды. Җитмәсә, Сәкинәсенең йөзе шатлыктан балкый.

– Кызым, ник болай соңладың? – дип кенә әйтә алды ул, очрашкач та Сәкинәгә яудырасы тозлы-борычлы сүзләренең барысын да берочтан онытып.

– Эштә озаграк тоттылар, әти.

– Тоткан, ди, эштә. Кыяфәтең бер дә чиләнеп эшләгәнгә охшамаган. Әниеңнең алкаларын да таккансың.

– Болай гына ул, әти, һаман да боегып йөрергә ярамый бит, – диде кыз, үзе кечкенә бүлмәсенә өстен алмаштырырга кереп китте.

– Боегып йөрмә инде алайса... – дип, үз-үзенә мыгырданды Барый карт. Аннан кызы ишетелерлек итеп кычкырып ук әйтте: – Алдана гына күрмә, кызым, алдыңны-артыңны карап йөр!

Өйләрендәге сөйләшү шуның белән тәмам булды.

Россиядәге олы болганышлар чорында, шул зилзиләнең нәкъ үзәгендә Сәгыйдулла белән Сәкинәнең мәхәббәт тарихы башланды. Алданрак Сәкинәнең күңеле тулы шик булса, ул, вакыт узу белән, егеткә күбрәк ияләшә, аның ихлас хисләренә ышана төште. Менә нинди икәнсең син, чын ярату! Әйтерсең, яшьләр тирә-юньдәге вакыйгаларны күрмиләр, Петроград урамнары буйлап арлы-бирле йөрүче хәрбиләрне, фронттан кайткан олау-олау яралыларны, ачлыкны, үзгәрешләргә өндәүче листовкаларны бар дип тә белмиләр. Тик бу беренче карашка гына шулай иде. Сәкинә шәһәргә ачлык килүен бөтен барлыгы белән тойды. Хезмәт хакы болай да кечкенә, анысының да бәрәкәте китте. Ризык көннән-көн кыйммәтләнә, озакламый бөтенләй дә талонга гына калды. Әгәр янәшәсендә Сәгыйдулласы булмаса, әтисе белән икесенә туклану мөмкин булмас иде.

Сәгыйдулланың да хәлләре шәптән түгел. Ул элек җыелган малы хисабына азмы-күпме тормышны тарта. Финляндия татарлары белән товар алмашу өзелде. Складларда булганын сатарга мөмкин түгел, алырга кеше юк, барысында да ашау кайгысы гына. Большевикларның көчәюен, ахыр чиктә, дөньяның асты өскә киләчәген яхшы тойды ул. Булган акчаларын акрынлап, алтын, бизәнү әйберләренә алмаштырырга кереште. Анысы да җиңел түгел, «кара базарда» кытлык, шуңа бар нәрсәнең дә бәясе яман күтәрелгән. Большевикларның алай да бер ярдәме тиде – танышлары аша тегеләрнең яшерен оешмаларының берсенә чыгып, үзенә һәм Сәкинәсенә ялган документлар эшләтте, алар буенча икесе дә Финляндиядә яшәп, вакытлыча Петроградка килгән татарларга әйләнеп куйдылар. Әлеге документларны складындагы ышанычлы урынга яшерде. Бу гамәлләр хакында ул Сәкинәгә бер сүз дә әйтмәде.

1917 елның март ае башында Петроградны яман хәбәр тетрәндерде. Патша Николай Икенче үз теләге белән тәхеттән ваз кичкән! Сәгыйдулла танышбелешләре белән аралашкан вакытта моның Россиядә самодержавиенең тәмам бетүенә китерәчәген аңлады. Шактый гына данлыклы фамилия әһелләре Петроградтан Кырым якларына, аннан чит илләргә качу хәстәрен күргән иде инде. Купшы мәҗлесләр тынып калды, аның урынына шәһәр урамнарында мәхшәр урнашты. Көпә-көндез кибетләрне, йөк төялгән олауларны талау гадәти күренешкә әверелде. Бүтән сузарга ярамый иде.

Петроградка яз якынлаша, көннәр шыксыз, аяк асты пычрак. Шулай да, гадәттәгечә, Сәгыйдулла белән Сәкинә икәүләшеп, паркка йөрергә чыктылар. Анысын сөйләштеләр, монысын, кинәт, аулаграк урын табып, Сәгыйдулла туктады һәм кызга туп-туры текәлеп карады. Сәкинә гаҗәпләнде, ләкин егет дәшмәде. Ул ашыкмый гына, вакытны суза-суза кесәсеннән кечкенә генә тартмачык чыгарды. Аны ачып, кызга эчендәге алтын балдакны күрсәтте.

– Син миңа кияүгә чыгарга ризамы, Сәкинә?! – Егетнең иреннәрендә елмаю уйный иде.

Сәкинә каушап калды. Бу вакыйга булырга тиешлеген тойды, хәтта көтте дә, ләкин менә болай, капылт кына килеп чыгар дип башына да китермәде.

– Һай Аллам, белмим тагын... Мондый вакытта... Әти ни дияр?!

– Әйдә, әтиең янына киттек! Үзем ярәшәм.

– Юк ла инде, анда бит...

Егет, башка тарткалашып тормыйча, кызның бармагына балдакны кидерде дә, экипаж яллап, Сәкинәне утыртып, аларның өенә таба юнәлде. Сәкинә оялуыннан ни эшләргә белмәде. Сәләмә фатирларын, күбрәк вакытын урын өстендә яткан әтисен егетенә күрсәтмәс өчен ул һаман да төрле сәбәпләр уйлап чыгара иде, ә монда менә сиңа мә!

Фатирга кергәч тә, Сәкинә әтисе янына беренче булып ашыкты.

– Әти, исәнме... Монда ни, мин үзем генә түгел...

Ятагында утырган Барый абзый бер Сәгыйдуллага, бер кызына караш ташлады.

– Исәнмесез, балалар, – диде ул, бернигә дә исе китмәгән кыяфәт белән. Аннан күрешер өчен Сәгыйдуллага ике кулын сузды. – Барый абзый булам.

– Сәгыйдулла Тимерханов.

– Утыр, энем. Исемең дә матур, фамилияң дә. Кызым, чәй куеп җибәр әле. – Сәгыйдулла утыргач та, Барый абзый аннан кемлеген, тумышы белән кайдан икәнлеген, ниләр белән шөгыльләнүен бик төпченеп сораштырды. Ялгызы өйдә утыргач, сөйләшергә кеше дә юк, шуңа Сәгыйдулла аңа бер юаныч төсле иде.

Үзенә дә берәр сүз кыстырырга мөмкинлек тугач, Сәгыйдулла монда килүенең төп сәбәбен әйтеп калырга ашыкты.

– Барый абзый, сезнең кызыгызны сорарга килдем. Без никах укытырга телибез...

Кырыс Барый ага ихтыярсыз килеп чыккан яшьләрен сөртеп куйды, борынын мышкылдатты. Аннан читтәрәк әтисенең җавабын көтеп, уңайсызланып басып торган кызына эндәште:

– Кил, кызым, син дә каршыма утыр. – Балалар утырышкач, кызының кулын алып, Сәгыйдулланың учына салды. – Миннән ризалык, балалар. Кызымны ныклап, кысып тот, ычкындырма! Заманалар әллә нишләде, Сәкинәгә дә терәк кирәк. Бер-берегезне аңлап, яклап яшәгез, бу катлаулы чорларны исән-имин килеш үтегез!

Никахны икенче көнне Петроградтагы мәчеттә укыттылар. Бернинди мәҗлес тә оештырылмады, икәү генә бардылар, аннан соң Сәгыйдулланың бүлмәсенә кайттылар. Бу – аларның очраша башлаганнан бирле беренче кайнар төннәре иде...

Назлы төннәр озакка сузылмады. Петроградта киеренкелек көннән-көн арта торды. Сәяси каршылыкка сугыштагы вакыйгалар, башкалада азык-төлек җитмәү дә өстәлде.

Бер төнне Сәкинә белән йокларга ятканнар иде инде, өйләрендә тавышгауга купты. Кемнәрдер авыр итекләре белән дөмбердәп, коридорлар буенча йөгерешә, бераздан ишекләрне каты итеп кагарга керештеләр. Аларныкына да кактылар. Сәгыйдулла ишекне ачып җибәрде. Бусага төбендә ике кораллы матрос басып тора, түшләренә кызыл чүпрәкләр бәйләгәннәр. Матросның берсе Сәгыйдулланы баштанаяк өйрәнеп чыкты да, аның артында халаттан басып торучы Сәкинәгә текәлде.

– Сезме, Ковальская?! – дип сорады ул. Матрос авызыннан Сәгыйдулланың битенә хәмер исе бәрде.

– Юк, ул Ковальская түгел... – Сәгыйдулла мөмкин булганча тынычрак сөйләшергә тырышты.

– Документларын күрсәтегез.

Сәгыйдулла, ярар дип борылырга өлгермәде, Ковальская яшәгән бүлмә ягыннан чыр-чулы тавыш яңгырады:

– Таптык, егетләр, монда ул, – дип кычкырды икенче бер хәрби.

Матрослар шунда ук Сәгыйдулла белән Сәкинәне оныттылар, тавышка таба йөгерделәр.

Сәкинәне бүлмәдә калдырып, Сәгыйдулла коридорга чыкты. Чыр-чу, кычкырыш тынды. Кемнеңдер елаганы гына ишетелде. Озак та үтми кораллы матрослар озатуында пани Ковальская күренде. Ул, кыска вакыт эчендә аннан-моннан гына җыенса да, өсте барыбер пөхтә, пирчәткәләренә кадәр кигән. Йөзендәге макияжы гына бозылган – анысы елаудан. Тик пани инде тыныч, башын югары тота, бер кулына кечкенә генә букчасын

да аскан. Матрослар да тынып калганнар, бу кодрәтле панининың йогынтысы аларга тәэсир иткән сыман.

Сәгыйдулла яныннан үткәндә, Ковальская егеткә бер генә караш ташлады. Ул караштa Сәгыйдуллага карата нииндидер үпкә бар төсле тоелды. Пани Ковальскаяның менә шулай мәсхәрәләнеп, кара төндә алып чыгып кителүендә, әйтерсең, Сәгыйдулланың да гаебе бар.

Матросларның берсе егеткә таба борылып ысылдады:

– Монысын эләктердек, озакламый чират сезгә дә җитәр!

Бүлмәгә кергәч тә, ул коты алынган Сәкинәсен кочаклап алды.

– Пани Ковальскаяны алырга килгәннәр... – Сәгыйдулла хәзер сүз башлар өчен иң кулай вакыт дип уйлады. – Кадерлем, миңа синең белән бик җитди итеп сөйләшергә кирәк.

– Ни турында? – Сәкинә моңарчы матрослардан бер-бер хәтәр чыгар дип курыккан иде. Хәзер исә Сәгыйдулласыннан яман хәбәр ишетер төсле тоелды, ул сагаеп калды.

– Кадерлем, син барысын да үз күзең белән күреп торасың. Дөньялар әллә нәрсәгә әйләнде. Күңелем сизә, бүген пани Ковальская, иртәгә аның урынында синең белән без булачакбыз...

– Бездән кемгә зыян тигән?!

– Болар аны-моны уйлап торучы кавем түгел. Мин – сәүдәгәр, аларга каршы класс кешесе. Син – минем хатыным...

– Ни эшлик?!

– Качыйк моннан. Документлар бар. Поездга билет кына аласы калды. Икәү бу илдән китик әйдә!

Сәкинә тораташтай катып калды. Аннан Сәгыйдулланың кочагыннан аерылды.

– Әтине нишләтәбез?! Аның белән бергә юлга чыгып булмый бит?!

Сәгыйдулла өчен бу иң авыр, күпме уйлап та чишелеш таба алмаган сорау иде.

– Кадерлем, – диде ул, тавышына мөмкин кадәр җылылык чыгарырга тырышып. – Әтиеңә беркем дә тимәс, ул да пролетариат вәкиле. Без аңа җитәрлек акча калдырырбыз, ә дөньялар тынычлангач, кире кайтып алырбыз...

Ничек кенә тырышмасын, Сәгыйдулла кызны инандырырлык сүзләр таба алмады. Ул әйткәненә үзе дә ышанмый иде. Ләкин бүгенге вазгыятьтә тагын нишли алсын?! Исән калу өчен башка мөмкинлек юк.

– Миңа бу хакта уйлап карарга кирәк, – диде кинәт салкынайган тавыш белән Сәкинә һәм Сәгыйдуллага аркасы белән борылып, урынга барып ятты.

Алар иртән дә бик салкын сөйләштеләр. Сәгыйдулла өстенә гадирәк киемнәрен киде, аннан-моннан капкалап, кибетенә йөгерде.

Купшы киенмәве дөрес карар булган икән – аның кибетен талап маташалар иде. Ишек, тәрәзәләр ватылган, эчтәге малның төп өлешен инде чыгарып бетергәннәр. Кибет ягына артык текәлеп карамаска тырышып, Сәгыйдулла бөтен ихтыярын бер йодрыкка җыйды, кан саркыган йөрәгенә Ходайдан тынычлык сорады.

Кибеттән ерактарак урнашкан складка әле куллары җитмәгән. Эчкә кереп, ул ишекне бикләде һәм утны кабызды. Яшерен урынны ачты.

Алтыннар, банкноталар үз урынында. Ул акча санарга кереште. Поездга билет алырга, юл чыгымнарына кирәкле күләмне аерып куйды. Аннан соң, озак кына уйланып торгачтын, Барый абзый өлешенә калдырыласын исәпләде. Болай да чикле булган акчалардан колак кагасы килмәсә дә, карт кешене бер тиенсез калдырырга ярамый. Сәкинә этисен ач килеш ташлап китү белән килешмәячәк, кичәдән бирле рәтле-юньле сөйләшми.

Акчалар белән бергә яшерен урындагы документларны да алды. Алтыннар, банкноталар салынган саквояжны биредә калдырып торырга туры килер. Урам буйлап байлыкларыңны күтәреп йөрү куркыныч.

Фин вокзалыннан поезд кичке унбердә китәсе иде. Ул кулындагы ялган документлар буенча ике билет алды. Шәһәрдә күрәсе берничә кешесе бар иде, алар янына да сугылып чыгарга туры килде. Эшне бетергәч, абыйсы Хәмидулла исеменә хат җибәрде, анда үзенә куркыныч янавы, хатыны белән Финляндиягә китүе турында хәбәр итте. «Абый, күңелем сизә, бу кабахәт большевиклар минем башыма җитәчәк, – дип язды ул. – Кибетемне таладылар, иртәгә үземне дә алып китәчәкләр. Башка Россиядә калырга җаем юк, гафу ит. Матур апага, Зөбәйдәгә миннән күп сәламнәр әйт, бу давыллар тынгач та, беренче эш итеп, сезнең янга кайтырмын».

Үзе яшәгән өйгә кайтып җиткәндә, караңгы төшкән иде инде. Йорт эченә кергәч тә, ул гомуми бүлмәдә ватылып беткән өстәл-урындыкларга, җимерелгән буфетка тап булды. Күңеле белән ниндидер куркыныч тоеп, Сәгыйдулла сак кына икенче катка күтәрелде. Барлык бүлмәләрнең дә ишекләре йә каерып алынган, йә шыр ачык. Үзенең бүлмәсендә дә шул ук хәл. Эчкә кергәч тә, ул биредә дә идәндә таралып ятучы җиһаз, пыяла кисәкләрен, киемнәрен күреп алды. Урамнан кергән саран яктылыкта ул кайбер өс киемнәрен җыештыргалап, ниндидер бер могҗиза белән исән калган чемоданына тутырды.

Сәкинәсе кайда соң?! Чемоданын эләктереп, бинаның ярымподвал өлешенә, элек хатыны яшәгән бүлмәгә йөгерде.

Йөрәге ялгышмаган – Сәкинәсе биредә. Ул югалып калган кыяфәт белән бер почмакка текәлеп утыра. Өстәлдә тонык кына лампа яна. Сәгыйдулланы күреп алу белән ул, йөгереп килеп, аны кочаклап алды һәм үкереп елап җибәрде.

– Алар сине эзләп килде, сәүдәгәр Тимерхановны! – диде ул, үкси-үкси. – Миңа тимәделәр, синең хатының булуын әйтмәдем...

– Тынычлан, бәгърем, тынычлан. – Хатынының аркасыннан сөйгәндә, Сәгыйдулланың үзенең дә куллары калтырана башлады. – Моннан качып китәргә кирәклеген аңладыңмы инде хәзер?!

– Аңладым, җаным! Сине интектергән өчен, зинһар, гафу итә күр...

– Зыян юк, кадерлем! Мин билетлар алдым, бүген кичке унбердә безгә поездда кузгаласы...

Сәкинәнең янә күңел халәте үзгәрде, ул елаудан туктап җитдиләнде.

– Миңа әти белән бәхилләшергә кирәк...

– Әлбәттә, җаным, әлбәттә! – Сәгыйдулла түш кесәсеннән банкноталар тутырылган купшы төргәк чыгарды. – Менә, акча да алып килдем. Хәзер, экипажлар тотабыз да юлга кузгалабыз. Миңа бер урынга кереп, кайбер әйберләрне алып чыгасы булыр. – Сәгыйдулла кул сәгатенә күз салды. Әгәр

башта ул да Барый абзый янына, аннан соң байлыкларын алырга складка кереп йөрсә, поездга өлгермәячәк. – Син этиең белән саубуллаш та, туры вокзалга кил, мин шунда көтәчәкмен. Минем исемнән гафу үтен, эшләрен көйләп бетерәсе бар, шуңа килә алмады диген. Экипаж көтеп торсын, беркая да җибәрмә. Тиз булыйк, вакыт бик кысан! Менә билетың белән документларың!

Экипажлар тотканчы, Петроградның кысан урамнары буйлап боргаланып йөргәнче шактый вакыт узды. Сәгыйдулла, бер кулына чемодан, икенчесенә байлыклары салынган саквояжны тотып, Фин вокзалына килгәндә, ун тулып килә иде. Ул вокзалны, аңа янәшә урыннарны айкап чыкты. Сәкинә беркайда да күренмәде. Вагон янында көтеп басып торды. Сөйгәне килмәде. Поезд кузгалгач та, ул әле бик озак кына тәрәзәдән күзен алмады.

Бу вакытта Сәкинә исә этисенең өендә, урын өстенә капланган килеш, сулкылдый-сулкылдый елап ятты. Әтисенә ул китү турында бер генә сүз дә әйтмәде. Ташлап китә алмый иде ул аны. Барый абзый Сәкинәгә җиде яшь тулгач та тол калды, ул Сәкинә өчен этисе дә, әнисе дә булды. Картлык көнендә урын өстендә ятарга калган кешене хәзер калдырып китү бик зур хыянәт сыман тоелды.

...1918 елга чыкканда, дөньяга сабый бала – Сәгыйдулла белән Сәкинәнең уллары аваз салды. Әтисе киңәше белән аның туу турындагы таныклыгында хакыйкатьне бераз гына үзгәрттеләр. Малайга Хәмит дип куштылар, таныклыкка ул Хәмит Сәйдулла улы Тимерханов буларак яздырылды. Улы үсә төшкәч тә, Сәкинә аңа этисе Сәйдулла Тимерхановның пролетариат бәхете өчен көрәштә 1917 елны Петроград баррикадаларының берсендә һәлак булуы турында озын-озын бәяннәр сөйләргә гадәтләнде...

***

Хәмидулла хәзрәт энекәшенең хатын алганнан соң, бик озак моңсу йөрде. Иренең бу хәлен күреп, Нәсимә дә хафага калды, ләкин хәзрәт аңа берни турында да әйтмәде.

Әнисенең соңгы әманәте исендә бит. Аралашып, туган якка кайткалап яшәргә кушты ул кече улына. Хәзер ничек кайтыр? Дөньялар тынычланыр дип, кем әйтә ала? Тынычлана икән, кайчан?! Аннан соң, Сәгыйдулланың хатыны белән бергә туган ягына хәзер кайту мөмкинлеге дә булгандыр бит. Монда урын җитәрлек, шау-шу, гауга да ишетелми...

Соңарып булса да, авылда да сәвит власте урнашты. Буадан килгән комиссарлар авыл белән идарә итүче итеп ялкаулыгы, куштанлыгы һәм усаллыгы белән аерылып торган Фазылҗанны билгеләделәр. Аның янәшәсенә тагын берничә активист кушылды, ләкин күпчелек халык үзгәрешләргә сагаеп карады. Хәер, Фазылҗан да әллә ни эш майтара алмады. Үзенә тоттырылган кызыл әләмне эләрлек аерым идарә бинасы да булмагач, аны үзенең кечкенә генә алачыгы башына кадаклап куйды. Фазылҗанга файдасы булды тагын – ул, ничәмә еллар буе буйдак булып йөреп, күптән егетләр яшеннән чыккан иде, властька килгәч, шунда ук күрше авылдан хатын да табылды. Никахны кыз ягында укыдылар, Хәмидулла хәзрәткә «яшьләрне» кавыштыру насыйп булмады...

Фазылҗанның бәхете озакка бармады. 1919 елның кызу июль ае көнендә авылга атларга атланган аклар төркеме килеп төште. Хәмидулла

ат пошкырган, урысча кычкырган тавышларны ишетеп, мәчеттән чыкты. Төркемдә утызлап кеше, барысы да кораллы. Бер солдат, атылып барып, Фазылҗан йортына беркетелгән кызыл әләмнең сабына төбәп, мылтыгыннан атып җибәрде. Әләм җиргә мәтәлеп төште. Фазылҗан бер мәлгә генә ишектән башын тыгып карады да кире өенә ашыкты. Акларны җитәкләгән офицер әмер бирүгә, өч солдат Фазылҗан йортына таба йөгереп китте, идарә башлыгын алар арткы тәрәзәдән чыгып качарга маташкан вакытта эләктереп алдылар.

Мәчет янындагы мәйданда янгын-фәлән чыкканда кагып, халык җыя торган авыр тимер кисәге бар иде. Бер солдат чаң кага башлады. Мәйданга куркынган авыл кешеләре агылырга тотынды.

Төркемне җитәкләгән офицер атыннан төшеп, мәчет болдырында торган мулла янына килде.

– Исәнме, хәзрәт! – диде ул, киң итеп елмаеп.

– Саумысыз!

– Урысча да беләсезмени?! – дип гаҗәпләнде офицер.

– Сукалыйм шунда аз-маз...

– Болар урысча аңламыйдыр инде? – Офицер мәйданга җыелучы халыкка таба ымлады.

– Алар да аз-маз беләдер шикелле. Нәрсә әйтүегезгә бәйле инде...

– Яхшы, сез минем тәрҗемәче булырсыз, – диде офицер, катгый карарга килеп.

– Гафу итегез, ләкин мин тәрҗемәче була алмыйм. Мин бу халыкка Аллаһы сүзен сөйләүче генә, мин сәясәт белән шөгыльләнмим...

Офицерның йөзендәге елмаю юк булды. Ул усал итеп тамак кырды, ләкин башка карышып тормады.

Ул арада мәйданга, кулларын артка бәйләп, Фазылҗанны китерделәр. Аның артыннан елый-елый, көмәнле хатыны йөгерә. Фазылҗан үзе дә елаган бугай, бөтен бите пычранып беткән, тузанга баткан. Аны халык каршына бастырдылар.

– Урысчага тәрҗемә итәрлек кеше бармы?! – дип сорады офицер.

– Бар! – Заһидулла байның улы Нигъмәтҗан алга атлады.

– Булса, бик әйбәт, бире кил. Исемең ничек?

– Нигъмәтҗан.

– Минем әйткәннәрне сүзен сүзгә тәрҗемә итеп торасы. – Офицер халыкка борылды, һәрбер җөмләдән соң туктап, Нигъмәтҗанның татарчалап әйткәнен көтеп торды. – Хөрмәтле ватандашлар! Без сезгә большевиклар афәтеннән коткару алып килдек. Аларның котырынулары озакка бармады, без моңа чик куячакбыз, яраткан илебезгә самодержавиене кайтарачакбыз! Сезнең арада советлар властенә хезмәт иткән кешеләр бармы? Булса, күрсәтегез аларны! – Халык дәшмәде.

– Барысы да диярлек урманга качып киттеләр, – диде Нигъмәтҗан офицерга.

– Аңлашылды... – диде офицер, аннан янә халыкка мөрәҗәгать итте. – Сезнең арада безнең белән бергә большевикларга каршы көрәшергә теләге булган кешеләр бармы? Булса, бер адым алга атлагыз. Бөтен кием-салымны, коралны, азык-төлекне үзебез бирәчәкбез.

Халык янә дәшмәде. Нигъмәтҗан бу юлы да офицерны коткарды:

– Мин сезнең армиягә керергә телим, – диде ул. Алгы рәтләрдә торган әтисе Заһидулла бай сер бирмәде, ә менә әнисе Бибинур агарынып чыкты, калтырана башлады. Заһидулла аны кочаклап алды, тынычландырырга кереште. Алар икәүләшеп, алгы рәтләрдән чыгып киттеләр.

Фазылҗанны бәйләнгән килеш тоткынлыкка, Нигъмәтҗанны кораллы көчләренә алырга дип ияртеп, аклар авылдан китеп барды. Авыл тормышының үзендә берни дә үзгәрмәде, барысы да элеккеге җай белән дәвам итте.

Кичке намазны тәмамлагач, инде кайтыйм дигәндә, Хәмидулла хәзрәт мәчеткә кереп баручы Гөлнисаны күреп алды.

– Әссәламегаләйкүм, Гөлниса, ни йомыш белән килүең?

– Вәгаләйкемәссәлам, Хәмидулла хәзрәт. – Гөлнисаның тавышы карлыккан, елаудан бөтен йөзе шешенеп беткән. – Зур бәла төште башыма, нишләргә дә белгәнем юк. Улым Таһир кызыллар яклы сугышырга дип, урманга китеп барды...

– Әстагъфирулла! Аңа ничә яшь соң әле?!

– Унсигезен тутырып бара инде... Хәзрәт, шул балага зиһен бирүен сорап, дога кыл әле, зинһар!

Хәмидулла хәзрәт дога укырга кереште. Таһирны Гөлниса карчык бер ялгызы үстерә. Аның әтисе әле Хәмидулла Бохарада укыган вакытта ук мәрхүм булган иде. Явыз телләрне тыңласаң, күрше авылдагы чувашлардан алган яман көмешкә белән агуланып үлгән. Ләкин Хәмидуллага монысы караңгы, кеше гөнаһысы аңа кирәк түгел. Гөлниса карчык кына кызганыч, улы азгын, явыз булып үсте. Күрәсең, әтисенең каны. Авылда ул да беренче сугыш чукмары булган.

Шулай да Хәмидулла догасының тәртибен бозмады, Ходайдан балага карата рәхим-шәфкать, үзенә акылга килүен сорады. Дога тәмам булгач та, Гөлниса ахылдый-ухылдый, өенә юнәлде.

Аклар авылга бүтән килмәде. Күрәсең, үз хәлләре хәл иде. Тирә-юньдә шактый зур партизан төркеме туплаган Космовский аларга тыныч көн дә, төн дә калдырмады. Ату тавышлары авылга кадәр ишетелеп торган чаклар да булды.

Гөлнисаның борчылуы юкка булып чыкты. Сентябрь уртасы дигәндә, акларны Буадан куып чыгардылар. Таһир авылга яхшы атта кайтып төште. Өстендә күн куртка, галифе чалбар, ялтырап торган күн итек. Портупеяда пистолет, фуражкасында кызыл йолдыз ялтырый. Улын күргәч тә, Гөлниса аның янына йөгереп барып, аттан төшкәнен дә көтми, күн итегендәге аягын кысып тотты.

– Йә, җитәр инде, әни, – дип, баласы әнисенең читкәрәк китүен сорады, аннан җиргә сикереп төште. Гөлнисалар каршыннан үтеп барганга, Хәмидулла да халык төркеме янына туктады.

Гөлниса янә улын кочаклап алды, аның битен сыйпый, пышылдап кына нидер сөйли. Таһир масаюлы караш белән авылдашларын күзләп чыкты.

– Куып җибәрдек акларны! Артларыннан тузан гына тузып калды. Беренче булып чабучылар арасында Заһидулла байның улы Нигъмәтҗанны да күрдем, – диде ул, лачт иттереп җиргә төкереп.

– Улым, син исән-сау кайтсын дип, бөтен авыл белән дога кылдык, менә, Хәмидулла хәзрәт тә биредә, ул да догасыннан калдырмады.

Таһир Хәмидулла хәзрәткә борылды.

– Догаларың өчен рәхмәт, хәзрәт! – диде ул, кәкре тешләрен күрсәтеп елмаеп. – Болай булгач, кызыңа өйләнәсе була инде, үстер, әйдә, тизрәк.

Хәмидулла моңа шатланырга да, кайгырырга да, ни әйтергә дә белмәде. Ул тагын бераз сүзсез генә басып торды да өенә кузгалды.

Озакламый урманда качып яткан активистлар да, Буадагы тоткынлыктан азат ителгән Фазылҗан да кайттылар. Фазылҗан беренче эш итеп, әләмне төзәтеп, кире йорт түбәсенә кадаклап куйды. Җае чыккан саен хак эш өчен тоткынлыкта күргән михнәтләре турында сөйли торган булды. «Сезнең ирек өчен канымны койдым», – ди торган иде ул, ике айлык тоткынлыгы тарихын кабаттан сөйләгәннән соң.

Тик Фазылҗанның идарә эшендә бәхете булмады. Янә озак эшли алмады ул – районнан килгән карар буенча аның урынына яшь-яшь, ләкин бик булдыклы Таһир Солтановны билгеләделәр. Гөлниса, улым кеше булды дип, урам буйлап күкрәк киереп йөрергә күнекте. Дөрес, имеш-мимешләргә ышансаң, кызыллар төркемендә чакта Таһир әтисе кебек үк хәмер эчәргә һәм хәтта тәмәке тартырга да өйрәнгән. Авыл өчен бу ике нәрсә бик гаҗәп һәм гайре табигый иде. Акрынлап, егетнең күрше авылларда тол хатыннар белән чуалуы турында да хәбәрләр чыккалады. Яңа хакимиятнең яңа кешесе, ни эшләтәсең, аңа сүз әйтә торган түгел...

Заһидулла белән Бибинурның гына тормышлары үз урынында түгел иде. Уллары Нигъмәтҗан, чыннан да, акларга ияреп китеп барган, аларны кызыллар туган җирләреннән еракка, киң далаларга таба куалар иде...

Еллар арты еллар уза торды. Хәмидулланың кызы да буйга җитеп үсте. Таһир авылда коммуна оештырды. Ләкин зур үзгәрешләр, коточкыч афәтләр әле алда иде...

***

1931 елның гыйнвар иртәсе. Сәгыйдулла пәлтәсенең барлык төймәләрен төймәләп, якасын күтәрде һәм Берлинның таш җәелгән кысан урамы буйлап юлга кузгалды. Германиянең җепшек карлы кышларына күнегә алмады ул. Гәрчә, биредә уналтынчы кышын каршылаcа да. Сәгыйдулла авылдан киткәндә, туганнары белән хушлашканда, бу хушлашуның, бәлки, мәңгелеккә булачагын башына да китермәгән иде. Ә язмыш үзенекен итте. Петроградтан көч-хәл белән чыгып качып, башта Финляндиягә, аннан Даниягә, ниһаять, Берлинга килеп төпләнергә насыйп булган икән. Болай да ачлык-ялангачлыктан интеккән Германиядә мескен татар эмигрантына якты чырай да, җылы почмак та табылмады. Туктаусыз күченеп йөрүләр, байлыкларын ризыкка алмаштырулар, ачлык, ялангачлык – боларның барысы да башыннан үтте. Германия беренче Бөтендөнья сугышында җиңелгәч, хәлләр тагын да мөшкелләнде. Россиядән качкан кешеләрне сискәндереп, Европада да коммунизм өрәге калкып чыкты. Сәгыйдуллага Франциягә күченеп китәргә тәкъдим итүчеләр дә булды, ләкин ул ризалашмады. Тишекне ертыкка алмаштырганчы, бер урында төпләнү хәерлерәк тоелды аңа. Аннан соң, коммунизм идеяләре Германия генә түгел, Европаның бөтен илләренә үтеп керергә өлгерде.

Интегеп йөри-йөри, елдан артык вакыт узып китте. Көч-хәл белән Сәгыйдулла, ниһаять, үзенә яраклы эш таба алды. Эмигрант танышлары

Берлинның үзәгеннән ерак түгел бер сыраханәгә савыт-саба юучы кирәклеген әйттеләр. Күптән көткән эш урыны чит-ятка китмәсен дип, Сәгыйдулла үзенә хәбәр ителгән адрес буенча ашыкты. Аны симез гәүдәле нимес каршылады. Сәгыйдулланың вата-җимерә немесчә үзе турында сөйләгәннәрен дәшми генә тыңлап торгач, Фридрих сорауларга күчте:

– Сез биргә савыт-саба юарга яллануыгызны аңлыйсызмы?

– Әлбәттә, һерр Фридрих, бик яхшы аңлыйм. Мин теләсә нинди эшкә әзер!

– Түләүне дә күп куя алмыйм. Аның каравы ашау бушлай. Россиядә сез купшылыкка күнеккәнсездер, биредә гади кеше булачаксыз, аңлыйсызмы? – Фридрих Сәгыйдуллага бораулап карады.

– Беләсезме, һерр Фридрих, туган илемнән чыгып киткәч, миңа күп нәрсәне күрергә туры килде. Ачлыкны да, сырхауны да, салкынны да. Минем өчен күп нәрсә үзгәрде бу тормышта. Шуңа мин карусыз хезмәткә әзермен.

Фридрих берара дәшми торды, аннан, килештек, дип ымлап куйды. Соңрак Сәгыйдулла Фридрихның беренче Бөтендөнья сугышында Көнбатыш фронтта булуын, аннан нык яраланып кайтуын белде. Фридрих беркайчан да күп сөйләшмәс, хәлгә керә белүчән нимес булып чыкты. Саранлыгы бар барын, ләкин сыраханәдә эшләүче Сәгыйдулла, Ганс һәм Вильгельмны кимсетмәде. Хезмәт хакын вакытында түли, ашаудан аермый. Бер ел дигәндә, Сәгыйдулла савыт-саба юучыдан пешерүчегә күтәрелде. Нимес ризыгы әллә ни катлаулы түгел үзе, дуңгыз ите булу гына күңелгә тия. Ләкин яшисең килсә кайбер нәрсәләргә күзеңне йомарга туры килә. Гомумән алганда, шул көннән Сәгыйдулланың тормышы азмы-күпме көйләнде. Сыраханәдән ерак түгел бер нимес әбисенең фатирында бүлмә яллап яши, анда йокларга гына кайта. Сыраханәгә кеше шактый йөри, шуңа күрә тәңкәләр шалтырап тора. Дөрес, ул тәңкәләргә сыра салып торучы Ганс якынрак, тик нишләтәсең, һәркем үз язмышын тарта инде...

Берлин урамының пычрагын ерып, ул, ниһаять, сыраханәгә килеп җитте. Вакыт әле иртә булуга карамастан, ишек ачык иде. Ганс өстәл артында маташа, кухня ягыннан Вильгельмның савыт-саба шалтыратканы ишетелә.

– Хәерле иртә, Ганс! – диде Сәгыйдулла, эчкә узып.

– Хәерле иртә, Сагди! – Нимесләр, аның исемен әйткәндә, басымны һәрвакыт а хәрефенә төшерәләр. – Шыксыз көн, әйеме?

– Әйтәсе юк. Җылынырга керүчеләр күбрәк булыр дип өметләник.

– Бүген күп булачак, менә күрерсез. – Ганс, ниндидер сер белгәндәй, елмаеп куйды.

– Кайдан чамаладың аны?

– Бүген национал-социалистлар хакимияткә киләчәк.

Кухня ягыннан Вильгельм башын тыкты. Бер кулына ул сосискалар бәйләмен ураган иде.

– Исәнме, Сагди! Ганс әнә нәрсә сөйли бит – бүген Гитлер хакимияткә киләчәк, ди. Канцлер булып.

– Ә Гинденбургны кая куясы?

– Гинденбургның урыны зиратта, – диде Ганс күзен дә йоммыйча. – Җитәр инде картлачка. Национал-социалистларга юл бирергә вакыт.

– Ярый, куйдылар да ди. Сыра эчәргә халык җыелыр, дисеңме?

– Германиянең төрле якларыннан киләләр, Сагди. Мюнхеннан бик зур төркем килде. СА, штурм отрядлары вәкилләре җыела Берлинга, бүген зур бәйрәм булачак. – Ганс әлеге вакыйгага чиксез шатлануын яшерми иде. – Мин әле генә Гитлерның китабын укып чыктым. Ул безнең илебезгә байлык, тынычлык, куәт алып киләчәк. Тормышның матур чаклары алда әле, әйтте диярсез!

Сәгыйдулла кухня ягына узды, өстен алмаштырды һәм күнегелгән эшкә кереште. Суган, кәбестә, сосискалар, ит кисәкләре... Алар белән маташканда, ничектер күңеле тынычлана, авыр хатирәләр читкә китә төсле. Ә хатирәләр бихисап... Әнисенең соңгы сүзләре. Алар мәңгелеккә аның өстендә, ул йокыга ятса да, уянса да. шуны уйлый. Кайчан да булса аның васыятен үтәп, туган җиренә әйләнеп кайта алырмы? Әллә инде, улының ни хәлдә икәнлеген күреп, әнисе аны күптән кичергәнме? Бихисап уйлары Сәкинә турында. Аның үзе белән китә алмаячагын аңлады бит ул. Ничек итеп әтисен урын өстендә яткан килеш ташлап китсен?! Күңеле белән аңлады, акылы белән карышты. Сәкинә әтисен Сәгыйдуллага алмаштырмады. Бәлки, ул вакытта китмәгән булса, Сәгыйдулла да вөҗдан газабыннан интекмәс, тыныч кына яшәр иде? Шул ук Барый абзый алачыгында көн күрерләр иде. Авылына да кайтып килергә була, сөйгән яры да янында. Тик Россиядән чыгып качканда, байлыклары белән чит җирдә матур мул тормыш корып җибәрермен дип өметләнде. Язмаган икән. Байлыклары тиз таралды. Алдаучылар да шактый очрады аның юлында. Менә хәзер ул ярык тагарак алдында, бер ялгызы.

Мондый тормыш Сәгыйдулланы эчтән дә, тыштан да үзгәртте. Ул аякларын көчкә сөйрәп йөри, башы һәрвакыт түбән иелгән, чәчләре коелып бара, үзе карачкы сыман ябык. Кайчандыр пани Ковальскаяларны кызыктырган егеттән берни дә калмады...

Аның уйларын шаян Вильгельм бүлдерде:

– Сагди, ә коммунистлар нинди алар?

Сәгыйдулла каушап калды. Нинди икән алар, коммунистлар? Бу сорауны аның үз-үзенә дә биргәне юк бит...

– Алар куркыныч, Вилли... Уйларында бары тик талау, үтерү, кешеләрне изү. Әгәр мин алардан курыкмасам, бүген монда басып тормас идем...

– Ә кемнәр куркынычрак – коммунистлармы, әллә национал-социалистлармы?

Сәгыйдулла беренче тапкыр күргәндәй шаккатып, Вильгельмгә текәлде. Тегесе сары башын да күтәрми, бүкән өстенә утырып, бәрәңге әрчи бирә.

– Белмим, Вилли, белмим... Баштарак коммунистлар куркыныч түгел кебек иде. Хакимиятне үз кулларына алгач кына, хәшәрәткә әйләнде алар... Хакимият ул теләсә кемне боза шул...

***

Бу көн – 1931 елның 30 гыйнвары, чыннан да, Германия генә түгел, бөтен дөнья тарихына кереп каласы иде. Берлинның Рейхсканцлерплацында урнашкан «Кайзерһоф» кунакханәсендә шырпы сызсаң, шартлау яңгырарлык мохит хөкем сөрә иде. Бирегә зур өстәл янына нацистлар партиясенең лидерлары

җыелган. Табын түрендә – Адольф Гитлер. Ул үзен кая куярга белми, куллары калтырана, күзләре арлы-бирле йөгерә, өстәл артындагы сөйләшүләрне ул ишетми, ишетсә дә, аңламый, башаяк үз уйларына чумган. Аның янәшәсендә, урындыкка ятып диярлек, Герман Геринг утыра. Парламентта җылы урын биләгәнгә, ул әлегә биредәгеләр арасында Германиянең иң югары җитәкчесе. Ләкин нәкъ менә Геринг бу хәл озакламый үзгәрәчәген тәгаен белә, әлеге шатлыклы хәбәрне ул кичә төнлә Гитлерның үзенә җиткерде. Хакимлек инде бик якын, Геринг Гитлерның болай борчылуын аңлый да, аңламый да кебек. Гитлер янәшәсендә шулай ук Эрнст Ганфштенгель, фюрерның якын дусты, сердәшчесе, киңәшчесе. Читтәрәк авыру кыяфәтле, ябык гәүдәле Йозеф Геббельс; симез чучкага охшаган, бит тиресе майланып торучы Эрнст Рём; күптән түгел генә нацистларга килеп кушылган, ләкин 30 гыйнвар вакыйгаларында өлеше зур булган Иоахим фон Риббентроп; Гитлерга нимес гражданлыгы алуда ярдәм иткән Вильгельм Фрик; Гитлерның шәхси сак хезмәте ССны җитәкләүче Генрих Гиммлер. Бүлмәдә нацистлар партиясенең өске эшелонына кергән башка кешеләр да шактый.

Адольф Гитлер сәгатькә күз салды һәм кинәт сикереп торды.

– Кузгалырга вакыт, – диде ул усал эт өргән тавыш белән.

Урындыклар дөбердәде, бүлмәдәгеләр аягүрә бастылар. Көрән формага киенгән СС егетләре килеп чыкты. Алар, Адольф Гитлерны бар яктан да әйләндереп алып, урамга юнәлделәр. «Кайзерһоф» каршына инде шактый халык җыелырга өлгергән. Гитлер, аларны күргәч, ничектер уңайсызланган төсле елмаеп, уң кулын иңенә кадәр генә күтәреп сәламләде. Төрле яклардан фотокамералар черт-черт итә торды. СС егетләре озатуында Адольф Гитлер автомобильгә утырды һәм машина, акрын гына кузгалып китеп, кунакханәдән ерак түгел урнашкан рейхсканцеляриягә юнәлде. Халык ташкыны, репортерлар машина артыннан кузгалды. Кунакханә эчендәгеләр исә, тәрәзә каршына басып, тынлыкта үзләренең юлбашчыларын көтә калдылар.

– Бередән барысы да бик яхшы күренә, – диде Йозеф Геббельс, тәрәзәдән күзен алмый. – Сәфәре уңышлымы-юкмы икәнлеген моннан ук чыраеннан аңлап булачак.

– Борчылма әле, әллә ниләр юрама, без җиңәчәкбез. – Геринг симез корсагын сыйпап куйды. – Әйтте диярсез.

Бу вакыт мәңгелеккә сузылды төсле. Ә моңарчы нацистларның күргәне күпме! Төрмәләр дә, урам бәрелешләре дә, үтерешләр дә, куркыту-өркетүләр, сатлыкҗанлык та күп булды. Хәзер алар барлык югалту-борчулары өчен бурыч кайтаруны көтә. Ниһаять, рейхсканцелярия ишегендә Адольф Гитлер күренде. Аның йөзенә барысы да аермачык итеп язылган иде. Бүлмәдәгеләр, кычкырыша-кычкырыша, бер-берсе белән кочаклаша, бер-берсен котлый башладылар. Шау-шу урамда да башланды. Гитлер утырган машинаны СС, СА вәкилләре, партия әгъзалары, нацистларны яклаган нимесләр урап алды.

Адольф Гитлер бүлмәгә килеп кергәндә, андагылар инде тынычланырга өлгергән иде. Яңа гына Президент каршында ант иткән рейхсканцлерның күзендә яшьләр, бөтен тәне калтырана, күзләре ут булып яна. Ул, әйтерсең, ничектер кечерәеп калган, ләкин аларның барысыннан да өстен, әйтерсең, фани дөньядан бакыйлыкка күчкән, гүя үлеп яңадан терелгән.

– Әле генә без... – диде ул, елап җибәрер хәлгә җитеп. – Барысы да хәл ителде...

Бүлмәдәгеләр – купшы киемле Герингтан башлап, официантларга кадәр – Гитлерны котларга, кулын кысарга ашыкты. Кайдандыр шәраб, кабымлыклар чыкты. Гитлер, әйтерсең, югалып калган, шатлыклы, шул ук вакытта ниндидер сәер елмаю белән һәркемгә караш ташлый, күзләре анда-монда йөгерә. Зур бүлмә бокаллар чыңлавына күмелде. Берара Гитлер белән Вильгельм Фрик каядыр югалып тордылар. Озакламый Фрик Рёмны чакырып алып, аның колагына нидер пышылдады. Минут та үтмәде, көрән форма кигән СА вәкилләре олы бүлмәдән партиягә катнашы булмаганнарны, официантларны коридорга озатты. Тынып калган җәмәгать каршына Адольф Гитлер чыкты. Ул тынычланган, йөзе торараштай каткан.

– Бүген, – диде ул, бүлмәдәгеләрнең баш очыннан караш ташлап, – сез барыгыз да тарихи вакыйга шаһитлары! Бөек Германия – безнең иң зур максатыбыз. Тапталган, таланган немес халкы тезләнеп түгел, күкрәк киереп яшәргә тиеш. Немес халкына тормыш мәйданын тәэмин итү – безнең изге бурычыбыз! Коммунистлар, яһүдләр – безнең дошманнарыбыз! Яһүдләр бөек немес халкын ничәмә гасырлар буе буып, мыскыл итеп яши – без моңа чик куярга тиеш! Бүген зур тырышлык белән алынган хакимлек – беренче адымыбыз гына. Ләкин бер нәрсәне онытмагыз – хакимлекне алу бер хәл, аны әле ныклап, кулда да тотарга кирәк. Бары тик барыбыз да бердәм йодрык булганда гына, моңа ирешергә мөмкин. Сатлыкҗаннар, явызлар безнең арага да үтеп керәләр, аларны тамырлары белән йолкырга вакыт. Бөек Германия өчен!

Шау-шу белән нацистлар бокалларга үрелде, бүлмәне янә көлгән тавышлар, җанлы сөйләшү күмеп китте. Урамда инде караңгы төшкән. Адольф Гитлерны Эрнст Рём балконга дәште. Урамда салкынча булса да, Гитлер күлмәкчән генә чыкты. «Кайзерһоф» янәшәсендә – халык ташкыны. Утлы факеллар күтәргән СА отрядлары, яңа билгеләнгән канцлерны сәламләп, Вильгельмштрасседан кунакханәгә таба агыла. Моны күреп, Адольф Гитлер, нацистларны сәламләп, уң кулын алга ташлады. Тигез рәтләргә тезелгән немесләр үтеп киткәндә, ул әле аларны сәламли, әле бии, әле рәхәтләнеп көлә иде. Ахыр чиктә, хисләргә түзә алмый елый башлагач, Эрнст Ганфштенгель аны иңнәреннән кочаклап алып, бүлмәгә алып керде.

«Кайзерһоф»ка җыенган нацистлар барчасына да министр кәнәфие эләкмәгәнлеген беләләр иде инде. Кайберәүләрнең кәефе кырылса да, моны күрсәтмәде. Хакимиятне кулына алгач, ычкындырмас өчен барысын да эшләргә, хәтта янәшәдә булганнарны да аямаска әзер булуын Адольф Гитлер ачыктан-ачык әйтте. Аның кылычы кемнең башын кисәр? Адольф Гитлер беренчеләрдән булып, Рёмның башына җитәчәк. Моны әлегә Гитлер белән Гиммлер гына белә. Рёмны үтерү дусларга кисәтү, дошманнарга уйлану өчен кирәк... Әлегә исә национал-социалистлар бәйрәм итә, Берлин урамнарында утлы йөрешләр төне буе тынмады.

Бу вакыйгалардан Адольф Гитлер калтырана, тәне чемерди, башында меӊ төрле уй кабына да сүнә. Менә язмыш ничек итеп борылды бит! Хәзер барысы да аның бу дөньяга олы бер миссия белән килүен, тыштан күренмәгән илаһи бер көчкә ия булуын аңлар! Бөтен дөнья аның каршында

тезләнәчәк, башыннан үткән барча җәбер-золымнар өчен гафу үтенәчәк. Кирәк булса, кан белән үзләренең ялгышларын юачаклар!

...Аны балачактан яратмадылар. Мәктәптә укыганда да, һәрчак кыерсыттылар, кимсеттеләр. Хәер, үзе дә кимен куя торган бала түгел. Ул киребеткән, үзсүзле, үчле булып үсте. Мөгаен, җир йөзендә аны чынлап торып ярата алган бер генә кеше – әнисе булгандыр. Әни кеше һәркемгә дә якын, ләкин Адольфның бөтен дөньясында әнисеннән кала беркеме дә юк иде. Кырыс холыклы әтисе Алоисның каһәрле сүзләреннән, каты кулыннан да һәрвакыт әнисе Клара яклап чыкты. Алоис улының үзе кебек чиновник хезмәтен үзләштерүен теләсә, Адольф рәссам булырга хыялланды. Әлеге мәсьәләдәге бәхәс аркасында гаиләдә шактый гына гауга да чыккалады. Ләкин әтисен тыңламау бер дә файда китермәде – Венадагы академиягә ике тапкыр укырга керергә маташса да, Адольф Гитлерның рәсемнәрен икесендә дә чүпкә дә яраксыз дип таптылар һәм студентлар эскәмиясенә утыртмадылар.

Адольф башта әтисен югалтты – ул алтмыш биш яшендә якты дөнья белән хушлашты. Ул вакытта Адольфка унөч яшь кенә иде. Алоис Гитлер бер танышы янына кунакханәгә баргач, шунда җан бирде. Мәрхүмнең үпкәләре авыру икәнлеген барысы да белә, кинәт ул идәнгә мәтәлгән, авызыннан кан агып чыккан. Идәндә кан эчендә аунап яткан әтисен күргәч, Адольф, ирексездән, елап ук җибәрде. Бу кешедән, аның каты кулларыннан, әшәке сүгенү, кимсетүләреннән тәмам гарык. Әмма әтисенең мондый мәсхәрәле хәлдә җан тәслим кылуы бөтен нәселенә түбәнчелек төсле тоелды аңа.

Клара кулында ике бала – Адольф белән Паула калды. Адольф әнисенең тырышлыгын, аларга белем бирер өчен бөтен көчен куюын бик яхшы күрсә дә, балачактан күңеленә сеңгән кирелек аркасында укуда әллә ни зур уңышларга ирешә алмады. Кызыксынса, шул тарих белән генә аз-маз кызыксынды. Гомумән, үзләре яшәгән урамда да, мәктәптә дә Адольфның дәрәҗәсе дә, тотып мактанырлык исеме дә булмады. Ничек теләсә шулай яшәде, озакламый укуын да ташлады. Әнисе Клара болай да күкрәгендәге яман чирдән интегә. Улының мәгънәсез үсүе гомерен кыскарткан тагын бер сәбәп булгандыр, күрәсең. Адольфка унтугыз тулды дигәндә, әнисе мәрхүм булды. Аны Австриядәге Леондинге зиратына Алоис Гитлер янәшәсенә җирләделәр.

Адольф өчен бу – тормышында иң авыр мизгелләрнең берсе иде. Әйтерсең, дөнья шушы урында бетте. Алда ни көтә – билгесез. Хәер, көтмәсә дә ярый төсле. Әнисе киткәч, ул дөньяда ятим, беркемгә дә кирәкмәс бәндә булып калды.

Ябык, картлар төсле зарланучан, коры, усал Адольфны хатын-кыз өммәте кабул итмәде. Туганнары, балачактан ук рәт чыкмаячагы күренгәч, аннан йөз чөерде. Венадагы академия ишеген борыны төбендә шартлатып ябып куйдылар... Адольфның күңелендә бөтен дөньяга нәфрәт, ачу уянды. Балачактан ук үчле егет йөрәгендә үзен кимсеткән, кыерсытканнарны кайчан да булса җәзага тарту хыялы дөрләп кабынды.

Вена урамнарында теләсә нинди акчага булса да, картиналарын сатарга маташкан Адольф бигрәк тә зур ачу белән тук кыяфәтле яһүдләргә карап кала иде. Тегеләре дә моның картиналарын әле алай, әле болай

әйләндергәләп карыйлар да борыннарын ямьсез җыерып кире киштәгә куялар һәм юлларын дәвам итәләр. Менә кемнәр кулында байлык! Менә кемнәр аркасында мескен Адольф ачлык-ялангачлыктан интегә!

Күпне күрде үз тормышында Адольф. 1914 елда үз теләге белән фронтка китте. Франциядәге сугышта ул ике тапкыр яраланып, ефрейторлыкка күтәрелде, түшен беренче дәрәҗә Тимер тәре белән бизәп куйды. Әлеге бүләкне аеруча батырлык күрсәткән өчен солдатларга гына бирәләр иде. Адольф Гитлер гомеренең соңгы көненә кадәр кителенә шул Тимер тәресен тагып йөрде, шуның белән теге дөньяга да китеп барды...

Германиянең беренче Бөтендөнья сугышында җиңелүе Гитлерның тормышында әнисе үлеменә тиң кара көнгә әйләнде. Фронттан кайтып, анда-монда бәрелеп-сугылып йөреп, ниһаять, национал-социалистлар янына килеп эләкте. Тынгысызлыгы бәрабәренә тиз арада партиянең югары катламнарына үтеп керде.

Сөйли белә иде Адольф. Дөньясын онытып, карлыкканчы кычкырып, төкерек чәчә-чәчә сөйли иде. Шуның белән сыраханәләрдә дан казанды, нацистларның күренекле лидерына әверелде. Дошманнарны да таба белә – яһүдләр, сугышта солдатларны мәсхәрәләгән генералитет. Генераллар да яһүдләр сыман үз җаен гына карый, солдатларны иттарткычка илтеп тыга да капитуляцияли. Мюнхенның сыраханәләренә кереп, озын кичләрдә аны тыңлаган немесләрнең күңеленә бу ефрейтор фикерләре хуш килде. Җитмәсә, ветеран, алар шикелле үк кимсетелгән, ярык тагарак каршында калган мескен бер кеше...

Ләкин партия эшчәнлегендә дә барысы да матур гына бармады шул. Төрмәдә дә утырып чыкты. Анда Адольф Гитлер вакытын бушка әрәм итмәде, нацистларның төп әсбабына әйләнгән хезмәтне – «Минем көрәш» китабын язды. Бүген әлеге китап көннән-көн киңрәк таралып, меңнәрчә немесләрнең миен агулый, шуның белән бергә Адольфның кесәсен дә калынайта.

Китап гонорарына гына яшәп булмый, әлбәттә. Шөкер, Гитлерны акчалы кешеләр, кайбер эре промышленниклар күреп алды. Алар Гитлерда шәп ораторданбигрәк коммунизм афәтенә каршы торырдай идеология вәкилен таптылар. Эре промышленниклар ике явызлыкның берсен сайлады. Халыкны дәррәү күтәрә торган коммунизм бик куркыныч тоелды аларга. Ә нацистлар милеккә, капитализмга каршы чыкмый, башка төрдәрәк идеология, мисал өчен, Ватанны ярату кебек хисләрне күтәрмәкче. Ә яһүдләр... Гомер буе куылган инде алар, кешелек яратылганнан бирле анда-монда йөргәннәр, аларга хәзер генә зыян тимәс, дигәнрәк уйлар иде Германиянең бай эшмәкәрләре башында.

Нацистлар партиясе эшчәнлегенә акча бирүчеләр бүген шактый күбәйде. Кайберләре белән шулай ук беренче Бөтендөнья сугышы ветераны, очкычында дошманнарны дер селкетеп торган Герман Геринг таныштырды. Адольф аны бүлмәдәгеләр арасыннан карашы белән эзләп тапты. Чиксез симергән, циркта чыгыш ясарга яраклы күлмәк-кәчтүм кигән бу кешене хәзер самолёт штурвалы артында күз алдына китерү авыррак... Күпме генә дәваланса да, Геринг әфьюн белән мавыгудан туктый алмый. Хәзер дә, әнә, калын иреннәре кыйшайган, күзләре кып-кызыл...

Адольф Гитлер, шау-шудан качып, икенче бүлмәгә кереп китте. Аны Йозеф Геббельс дәшсә дә, аптыратма әле дигән кыяфәт белән кулын селтәде. Бөтен нәрсә дә бар, бөтен нәрсә дә урында кебек. Тик бер генә әйбер күңеленә тынгылык бирми бүген. Янәшәсендә чынлап торып яраткан кешесе юк. Гели Раубаль, ул аны бүген дә сагынып яши...

Адольф – хатын-кызларга, хатын-кызлар Адольфка салкын булды дигән идек. Ачу, үпкә, нәфрәт, тагын әллә ниләр белән чүпләнгән башында мәхәббәт кебек юк-бар хискә урын табылмады.

Кесәсендә, партия резолюцияләре белән беррәттән акча да шыгырдый башлагач, Гитлер Оберзальцбергта үзе өчен вилла сатып алды. Зур хуҗалыкны карап, ашарга пешереп торырга кеше кирәк. Исәнлек-иминлеген, сәламәтлеген, хәтта гомерен кемгә ышанып тапшырырга? Дошман тулы дөньяда ышанычлы кешене кайдан табарга? Эзли торгач, Венадагы туганы – этисенең икенче хатыныннан туган кызы Ангела Раубальны эзләп тапты. Кулында ике кызы – Гели һәм Фридл калган хатынның хәлләре шәптән түгел, ә Оберзальцбергта җылы почмак, тәмле ризык тәкъдим итәләр. Ангела ике дә уйлап тормый ризалашты һәм, озакка сузмый, кызларын ияртеп, виллага күченеп тә килде.

Адольф Гелины моңарчы күргәне бар иде инде. Ләкин ул чакта кызчык артык яшь иде. Оберзальцбергка исә буйга җиткән, мул күкрәкле, яше егермедән узган менә дигән туташ килеп төште. Беренче тапкыр табынга утыргач, Адольф аңа оялып кына, караш ташлады. Гели бу игътибарга каршы түгел иде кебек. Акрынлап, алар аралаша башладылар. Гели, читтән чибәр туташ, эчтән исә шактый һавалы, вакыты белән әче телле, ир-ат тәмен татырга өлгергән кыз булып чыкты. Аларның икәүдән-икәү калулары озакламый интим мөнәсәбәтләргә күчте. Оберзальцбергта Адольф белән Гели беркемнән дә тартынмый, бер бүлмәдә йоклый башладылар.

Сәеррәк иде бу. Адольф белән Гели ерак туганнар бит. Икенче яктан, нәрсәдән сәерсенәсе? Адольфның әти-әниләре дә ерак туганнар булган, шуңа күрә бу алма да агачыннан ерак тәгәрәмәде...

Адольф белән Гелиның интим тормышын бу китап битләре күтәрерлек түгел. Түбән дәрәҗәдә әшәке, хайваннарча пычрак иде ул төннәр. Ләкин халык арасында Адольф белән Гели бер-берсенә үлеп гашыйк пар булып йөрделәр. Тик бу төче, ясалма гыйшык иде.

Көннәрнең берендә Адольф Гелидан үзенә җырлап бирүен үтенде. Гели каршы килмәде. Җыр тәмамлангач, Адольф үзенә генә хас кыяфәттә тирән уйга калды, аннан сикереп торып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

– Беләсеңме, сөйгәнем Гели, сине тыңлаганда, мин үземне Вена операсында утыргандай хис иттем! – диде ул, йодрыкларын агарып чыкканчы йомарлап. – Сиңа, һичшиксез, сәхнәгә менәргә кирәк! Син нимес операсын бөтен дөньяга танытачаксың!

– Һай Адольф, бу бит минем күптәнге хыялым! – Гели саташкан ефрейторының кочагына ташланды. – Син миңа ярдәм итсәң, без сәхнәне дер селкетәчәкбез!

– Сәхнәне түгел, дөньяны! – Гитлерның күзләре уттай яна иде бу мизгелдә.

Икенче көнне үк алар икәүләшеп машинага утырып, юлга кузгалдылар. Өйдән чыкканда, каршыларына алъяпкычы белән тәлинкә сөртүче Ангела очрады.

– Кая җыендыгыз болай? – диде ул, тәлинкә ышкуыннан туктамыйча гына.

– Әни, без музыка укытучысы янына киттек. Мин операда җырлаячакмын! – Чиксез шатлыгыннан елмаеп, ул Адольфка төбәлде.

– Чыккан ди синнән җырчы. – Ангела җирәнүен яшермәде. Адольфның чигәләрендә кан тамырлары шартлардай булып күперсә дә, ул тыелып калды һәм тыныч кына җавап кайтарды:

– Фрау Ангела, сез Гелиның мөмкинлекләрен, талантын белеп бетермисез. Мин аны иң шәп музыка белгечләрендә тәрбияләп, исемен бөтен дөньяга танытачакмын.

Яшьләр артыннан Ангела йөзен чытып карап калды. Кызының төннәренниләр кыланганын яхшы белә иде ул. Аристократ каны белән аерылып тормаганга, әледән-әле бүлмә ишеге төбендә дә тыңлап торгалады. Ләкин бу шакшы мөнәсәбәтләргә каршы чыгарга көч таба алмады. Тамак кайгысы үзенекен итте...

Гитлерның «иң шәп музыка белгече» дигәне инде шактый өлкән яшьтәге, нацистлар партиясе әгъзасы Адольф Фогель иде. Гитлерга бигрәк тә аның карт булуы ошады – димәк, Гелига бәйләнмәячәк. Гитлер үзе партия эшләре белән еш кына юлда, ә Гелиның азгын холкын белеп булмый. Аннан соң, Гитлер интим мөнәсәбәтләрдән үзе өчен канәгатьлек алса да, Гели канәгать каламы-юкмы икәнлеге дә билгесез бит. Чөнки Адольф бик сирәк көннәрдә генә аны ирлек көче белән шатландыра ала иде...

Фогель Гелины музыкаль яктан булдыксыз дип тапты. Ләкин Адольф әлеге булдыксызлыкта, киресенчә, Фогельның үзен генә гаепләде. Партиядәш дуслары шунда ук Фогельның үткәненнән кара таплар таптылар: аның бер укучысы Берта Морена, шактый танылган опера җырчысы – яһүд кызы икән! Әлбәттә, партия җитәкчесенең туганы яһүдләр белән аралашкан, алардан акча алган, аларның вәкилен сәнгать югарылыгына күтәргән бәндәдә укый алмый иде!

Икенче укытучысы – Ганс Штрек – Фогельгә караганда акыллырак, хәйләкәррәк булып чыкты. Гелины укыткан өчен Гитлер партия казнасыннан вакытында һәм күп итеп акча түләп бара, нигә әле туташны музыка серләренә төшендермәскә? Хәер, Гитлер партия эшләре белән чыгып киткәндә, Гели дәрес алырга кирәк санамый, өйдә шөгыльләнми, җырчылык таланты ягыннан да исерек табын артында чыгыш ясарга гына яраклы. Кызның үз-үзен тотышы да авыл гыйбадларыныкы сыман, каты гына итеп сүгенеп куярга да күп сорамый. Әмма Штрек боларның барысына да түзеп, Гелиның «музыка укытучысы» булып йөри башлады.

Адольф белән Гелиның мөнәсәбәтләре, әлбәттә, җырдагыча көйле генә бармады. Нык бәдәнле бу кызга үзен кочагында кысып, төннәрен хәлдән тайдырганчы иркәләрлек ир кирәк иде. Адольф Германиянең төрле почмакларында булган чакта Гели бер дә ноталар өйрәнеп ятмады, очраклы танышкан дәртле ирләр белән үз күңелен үзе күрде. Бу хакта сизенгән Адольф еш кына Гели белән каты гына сүзгә керә, хәтта кызны кыйный

да башлады. Андый вакытларда Гели Гитлерны «импотент», «булдыксыз», «чүпрәк» дигән сүзләр белән яшь аралаш түбәнсетә иде.

1931 елның 18 сентябрь иртәсендә алар чираттагы төнге талаштан соң, табын артына утырдылар. Гели Адольфка карамый, Адольф берни дә ашамый, чәнечкесе белән тәлинкәсендә казына. Ангела киеренкелек зыңгылдап торган бүлмәдә ни әйтергә дә белми, яшьләр янына табынга утырды.

– Каһвә эчәсеңме? – дип сорады ул Гелидан.

– Эчәм. Сөт белән. – Әнисенең чәйнекләргә сузылуын күзәтеп, ул әллә аңа, әллә Гитлерга мөрәҗәгать итте. – Мин бүген Венага китәм. Бөтенләйгә.

Адольф бер мәлгә тынсыз калды. Аннан каршында торган тәлинкәне тотып алып, стенага бәреп ватты да һушыннан язар чиккә җиткән Ангеланы урап, Гелига ташланды.

– Венага?! Кем, фахишә булыпмы?! Җибәрермен мин сине Венага! – Һәм чәчләреннән тотып алып, Гелины бите белән тәлинкәгә сукты. Гелиның борыныннан кан китте, ул, уң кул учы белән борынын сөртеп, бер мизгел генә кып-кызыл канга карап торды. Аннан сикереп торып, Адольф өстенә сикерде. Чыгырыннан чыккан хатын-кыз дулаган биядән дә яман. Алар әүмәкләшеп, кухняда сугыша башладылар. Савыт-саба дөбердәве, стаканнарның чәлпәрәмә килеп ватылган тавышы аша бер-берсенә яудырган әшәке сүзләр ишетелә иде. Ангела аңына килеп аермаса, бу көрәшнең ни белән тәмамланачагын күз алдына китерүе дә авыр. Икесе дә калтыраналар, Гели баштанаяк канга баткан.

– Хәзер үк бүлмәңә кереп кит! – дип кычкырды Адольф. Ангела аңа нәфрәт тулы карашын ташлады. Ләкин тормыш алып баруны кайгырту ана хисеннән көчлерәк булып чыкты. Тынычландырып, борыннарын сөртеп, ул кызын бүлмәгә таба алып китте. Озакламый алар янына ертылган күлмәген алмаштырып, Адольф та керде.

– Ангела, чыгыгыз биредән, – диде ул. Гитлерның куллары артында, борыны өскә чөерелгән, йөзендә ник бер кан тамчысы булсын. Ангела бүлмәдән чыкса да, ерак китмәскә карар кылды. Гитлер Гели янына килде, кулын аның иңенә куйды. – Болай ярамый, Гели.

– Мин арыдым, бүтән түзәр хәлем юк, – дип, Гели үксеп елый башлады.

– Мин бүген Нюрнбергта. Кайткач сөйләшербез.

Урын өстендә үксеп утыручы Гелины калдырып, Адольф бүлмәдән чыкты.

Урамда аны инде машина көтеп тора иде.

– Кая юл тотабыз? – дип сорады исәнләшкәч тә Юлиус Шрек.

– Нюрнбергка, Юлиус.

Икенче көннең иртәсендә Ангела Оберзальцбергтагы йортларына хезмәт күрсәтүче Винтерны чакырып алды. Гелиның бүлмәсе эчтән бикле иде. Винтер ишекне җимереп ачты. Бүлмәдә алар кан эчендә яткан Гелины табып алдылар. Кызның кулында – Гитлерның револьверы. Гели пычракка баткан тормышка бүтән түзә алмый, үз теләге белән дөньядан китеп барды...

– Адольф, – дигән тавыш Гитлерны хатирәләреннән бүлдерде. Ишектә Геринг тора иде.

– Ни бар, Герман?

– Фройляйн Ева килде.

– Ева?! Ә, Ева, әйе, чыгам. – Һәм ул иренено елмаю элеп, Ева Браунны каршыларга ашыкты...

***

Кичке якта, Ганс вәгъдә иткәнчә, сыраханә халык белән тулды. Төнгә таба кунаклар тагын да күбәйделәр. Зур залдан кухняга аларның шаулашып утырулары, сыра тулы бокаллар зыңгылдавы төн буе яңгырап торды. Аннан соң нимес җырларын суза башладылар. Халык инде таңга да күп калмады дигәндә генә таралышты. Фридрих вакыт соң, дөресрәге иртә булса да, көндәге гадәт буенча кассадагы акчаларны санады.

– Егетләр, бүген сезгә премия! – диде ул, эш тәмам булгач һәм башта Ганс, аннан Сәгыйдулла, аннан Вильгельмгә акча суздык. – Чыннан да, шәп эшләдек бүген.

– Гитлер тулысы белән хакимияткә кереп беткәч, безнең эшләр тагын да әйбәтләнәчәк әле, – дип елмайды Ганс.

– Барысын да каян беләсең син? – Вильгельм иптәшенең сүзләренә ышанырга ашыкмаса да, Ганс аңа үпкә белдермәде.

– Эх, Вилли, Вилли! Менә син һаман минем белән бәхәсләшәсең, ә?! Әйбәтләнә дим икән, димәк, әйбәтләнәчәк. Менә, бүген Гитлер Рейхсканцлер була дидем – өстенә бастым бит, күрдеңме? Син аның «Минем көрәш» китабын укымагансыңдыр, шәт?

– Юк...

– Ә мин укыдым, анда...

– Мин дә укыдым, – диде тәмәкесен көйрәтеп Фридрих. Хуҗа буларак, аның кемне дә бүлдерергә хакы бар иде. – Кызык китап. Син, Ганс, партия әгъзасымы?

– Керергә исәп бар...

– Ә син, Вилли?

– Әти әйтә...

– Әтиең әйтсә, хак әйтә инде. Укыдым мин ул китапны. Кызык китап. – Фридрих көрсенеп куйды, аннан Сәгыйдуллага караш ташлады. – Менә мин үзем сугышта булдым, Сагди. Тик без урыслар белән сугышмадык. Без французлар һәм инглизләр белән сугыштык. Сез теге яктан кыстыгыз кысуын, ләкин мин ул якта булмадым, мин көнбатыш фронтта идем. Ә Гитлер хәзер нимес өчен яхшы тормыш көнчыгышта, шул җирләрне барып басып алырга кирәк, ди. Ул синең туган як, урыс җире булып чыга түгелме соң?

Дүртесе дә тынып калды. Фридрих ни турындадыр уйлана иде.

– Нимескә яшәр өчен урын кирәк, ди Гитлер. Тик ул җирдә башка кеше яши икән, аны ничек тартып аласы соң? Ничек икәне билгеле – корал белән. Сугыш булачак дигән сүзме бу? – Сөйләшү тәмамланганына ишарәләп, Фридрих урыныннан торды. – Ә минем өчен сугыш тәмам, җитәр...

Сәгыйдулла, Ганс, Вильгельм Берлин урамнары буйлап өйләренә таралыштылар. Дөресрәге, Ганс белән Вильгельм үз өйләренә, ә Сәгыйдулла кеше почмагына кайта иде. Кайткач та, ул әле озак кына боргаланып, Фридрихның сүзләрен кабат күңелендә яңартып ятты. Ә чыннан да сугыш чыкса, нишлисе? Кем булачак ул бу сугышта? Берлинда яшәгән татарлар белән очрашып, гәп

корасы булыр дип, Сәгыйдулла йокыга талды. Тагын берничә сәгатьтән аңа янәдән сыраханәгә, нимесләр өчен чучка сосискалары пешерергә барасы иде...

...Әхмәдия мәчетенә Сәгыйдулла берничә көннән соң гына килә алды. Берлинның Вильмерсдорф дигән өлешендә урнашкан әлеге мәчеткә төрле милләттән булган мөселманнар йөри. Араларында татарлар да бар. Күбесе беренче Бөтендөнья сугышы вакытында Россия империясе яклы сугышып, әсирлеккә төшкән кешеләр. Хәзер инде алар әсир түгел, Германияне яңа ватаннары итеп кабул иткән халык. Сәгыйдулла шундыйларның берсе – Гыйльмулла белән әледән-әле аралашып тора. Гади, нечкә күңелле, түзем һәм тырыш Гыйльмулла, алдан сөйләшкән төсле, Сәгыйдулла килгән көнне мәчеттә булып чыкты. Өйләдән соң алар ерак түгел урнашкан каһвәханәгә кереп, бераз гәпләшеп утырырга карар кылдылар.

– Гыйльми, син безнең татарлар белән күп аралашасың, алар соңгы яңалыклар турында ни уйлый?

– Нинди яңалыклар ул, Сәгыйдулла?

– Национал-социалистларның хакимияткә килүен әйтүем...

– Укымышлы кешеләр әйткәнчә, татарларга аларның зыяны тимәячәк, Сәгыйдулла. Алар бит коммунистларга каршы, ә без коммунист түгел. Без яһүд тә түгелбез. Ләкин, минем кайбер танышлар Франциягә күченү хәстәрен күрә башлады. Нидәндер куркалар бугай.

– Франциядә тынычракмы икән?

– Франциядә һәрвакыт тыныч, Сәгыйдулла, анда булып кайткан кешеләр мондагыдай хәерчелек тә юк дип сөйли. Үзең ни уйлыйсың?

– Ни уйларга да белгән юк. Нимесләр үзләре дә аны-моны аңышып бетермәгән бугай, аларда да бертөрле генә фикер юк шикелле.

– Анысы хак... Ә бездә, Россиядә, хәлләр мөшкелләнә дип сөйлиләр. Җирләрне талыйлар, мулла-попларны атып үтерәләр, имеш...

Гыйльмулла көрсенеп куйды. Сәгыйдулла да уйга батты. Димәк, аның абыйсының да башына җитәчәкләр...

Алар әле бик озак сөйләшеп утырдылар, үткәннәрне искә төшерделәр. Теге якта калган Ватан турында килгән сирәк яңалыкларны ишетү Сәгыйдулланы бер дә шатландырмады. Гыйльмулла татарлар күпләп яшәгән Вюнсдорфта тора, шуңа күрә аның аралашу мөмкинлеге дә күбрәк, рус телендәге эмигрант газеталары да кулларына еш эләгә икән. Гыйльмидән Сәгыйдулла туган ягы турында бер генә яхшы хәбәр дә ишетмәде. Унҗиденче елда ук башланган канкоеш, күрәсең, туктарга да уйламый, каршылык уты дөрләп янып, йөзләрчә мең кешенең башына җитә. Ул утта аның якыннары, ул яраткан кешеләр дә булмас дип, кем генә әйтер?!

Гыйльми белән аерылышкач та, Сәгыйдулла Франциягә күченү турында алай да уйлап карады, болай да. Ләкин, ахыр чиктә, кайда яшәсә дә, бөтен җирдә дә хәерче килмешәк булачакмын дип, инде бер төпләнгән урында – салкын, шыксыз, нацизм чиреннән бәргәләнә башлаган Берлинда калырга карар кылды...

***

Европаның бер почмагында булачак диктатор хакимияткә килеп маташканда, Советлар илендә икенче диктатор инде тулы көчен җыйган иде. Күпмедер дәрәҗәдә язмышлары, дөньяга карашларында уртаклык булган

ике җитәкченең бер-берсенә ябышуларына санаулы еллар калып бара. Бу еллар эчендә сәер дуслык та, кан дошманлык та булачак...

Иосиф Сталин Зубаловодагы дачасында уянып китте. Гадәттәгечә, өстенә шинель ябынып йоклый иде ул. Диван янәшәсендәге итекләрен киде, кулына «Герцоговина Флор» пачкасын алып, папирос тәмәкесен төрепкәсенә тутырды, тартып җибәрде. Тарту аны тынычландыра да, уйларга да ярдәм итә иде. Иртә баштан тәмәке тарту авыррак анысы, ләкин җанга барыбер рәхәт тоела. Ул янәдән кичә төне буе йокы бирмәгән уйларына әйләнеп кайтты.

Күптән түгел узган Пленум әле дә хәтерендә. Быел ул югары трибунага чыгып, Советлар иленең, димәк, үзенең ирешкән уңышлары турында күкрәк тутырып әйтә алды.

– Бездә илне индустриализацияләүнең нигезе – кара металлургия юк иде. Хәзер ул бар! – Зал алкышларга күмелә, Сталин, Пленум вәкилләренең шатлыклы алкышларын бүлмичә, трибунадан читкәрәк китеп, рәхәтләнеп елмая. Аннан кулы белән җитәр дип ишарәләп дәвам итә: – Бездә тракторлар промышленносте юк иде. Хәзер ул бездә бар. – Янә алкышлар. Сталин, алкышларга күмелеп, залдагыларга һәм бөтен илгә, ниһаять, автомобиль промышленносте, станоклар төзү, химия промышленносте, авиатөзелеш булдырылуын исләренә төшерә. Зал экстазда Юлбашчыны сәламли, һәр җөмлә саен урыннарыннан сикереп торган делегатлар артында, мылтыктан аткан тавышлар чыгарып, урындыклар дөберди. Пленум Сталинның тулы триумфы белән тәмамланды.

Докладын әзерләгәндә, Сталин һәрбер бүлеккә мул итеп, Ленин хезмәтләреннән цитаталар тутырды. Картлач Иосифны яратмады, үлеме алдыннан Сталинны кырыслык, кешелексезлектә гаепләп васыять тә язып калдырды. Дөрес, ул васыять турында сирәк кешеләр генә белә. Сталин күңелендә Ленинга карата мәңгелек үпкә урын алды. Әмма үлекләр белән сугышмыйлар. Ленинның инде мавзолейдан торып чыгасы юк. Шуңа күрә хезмәт ияләренең иң нечкә күңел кылларына да үтеп керер өчен Сталин Ленин лозунгларын үз кулына алып, байрак итеп күтәрде.

Мәетләрдән түгел, исәннәрдән куркырга кирәк. Иң зур дошманы – Троцкий исән. Чит илдә Сталин өстеннән рәхәтләнеп, әшәке эчтәлекле мәкаләләр язып ята. Хәзерге акылы булса, Иосиф, әлбәттә, Троцкийга Төркиягә чыгып китү җаен бирмәс иде. Ләкин ул вакытта партиядә фикер төрлелеге артык зур иде шул. Троцкийга әлегә куллары җитми, ләкин иртәме-соңмы, ул чүпне тамыры белән йолкырга кирәк. Җитмәсә, Сталинның янәшәсендә үк дошманнар күп. Алар Троцкийга тиңдәш түгел, әлбәттә, тик шулай да... Зиновьев, Бухарин, Каменев элеккеге гөнаһларын танып, тугрылыкка ант эчсәләр дә, теләсә кайсы вакытта аңа Юлбашчыга каршы борылырга мөмкиннәр...

Сталин ванна бүлмәсенә кереп юынып чыкканда, табында инде иртәнге аш пәйда булган иде. Юлбашчы өстәл артына утырды. Чәйгә җиттем дигәндә, ишектә Власик күренде.

– Хәерле иртә, иптәш Сталин, – диде ул.

– Хәерле иртә, Николай. – Сталин тән сакчысына мыек астыннан гына елмайды. – Нәрсә, Николай, урамда салкынмы?

– Салкын, иптәш Сталин, ат катмалы суык.

– Утыр, чәй эч. – Власик, шинелен дә салмый, урындык читенә утырып, икенче чәшкәгә чәй ясады.

– Нәрсә, Николай, Кунцевода эшләр ничек бара?

– Сезнең якын дачагыз төзелешендә барысы да планлаштырылганча, иптәш Сталин. Барлык эшләр дә тәүлек буе күзәтү астында...

– Совет кешеләренә ышанычыгыз юк, димәк, иптәш Власик? – Сталин тән сакчысына сөзеп карады. – Ә нәрсә, совет төзүчеләре иптәш Сталин дачасының нигезенә бомба куеп калдырыр дип куркасызмы?

Сталин янә төрепкәсен кабызып җибәрде, урыныннан торып, бүлмә буйлап атлап китте.

– Тәртип булырга тиеш дип уйлыйм, иптәш Сталин.

– Нәрсә соң ул – тәртип, иптәш Власик? Мылтык көпшәсе астында иптәш Сталинга дача төзү – тәртипмени? Генрихның солдатлары булмаса, эш бармыймы? – Власик үзе дә Генрих Ягодага буйсынганга, тән сакчысына уңайсыз булып китте.

– Дошман бит ул эчтә генә түгел, тышта да булырга мөмкин... – Власикның солдат миендә шушыннан да шәбрәк җавап табылмады.

Сталин шаркылдап көлеп җибәрде.

– Читтәге дошманнар – алар да совет кешеләредер бит, Николай, ә?

– Анысы шулай инде, иптәш Сталин.

– Фәлсәфәче түгел син, Николай.

– Солдат мин, иптәш Сталин.

– Әйе, солдат. – Сталин, сүзсез калып, бәс каплаган агачларга текәлде. – Кунцеводагы дачаны тизрәк төзеп бетерергә кирәк. Монда һава юк, буылам мин. Һәм, иптәш Власик, күрәсеңме теге агачларны?

Власик Сталин янына килеп, ул күрсәткән якка күз салды.

– Менә аларны сирәкләргә кирәк. Җәйгә шаулап үсәчәк алар, анда берәр дошман кереп, мине сагалап тормас дип кем әйтә ала? Ә мин сезнең ише солдатлар төзелеш алып барганда, Кунцевога тиз генә күчә алмам бугай...

Өстенә тунын, киез итеген, колакчынлы бүреген киеп, Сталин Власик озатуында урамга чыкты. Ишек төбендә аларны машина көтә иде. Сталин, утырырга ашыкмады, шофёр белән исәнләште.

– Менә, иптәш Власик, халык миннән көләдер инде, – диде ул, шофёр да ишетерлек итеп. Аннан шофёрның үзенә үк эндәште. – Син дә көләсеңдер әле, иптәш Соловьев.

– Нигә алай дисез, иптәш Сталин?! – Власикның куркудан йөзе үк үзгәрде, Хуҗаның болай сүз башлавы, гадәттә, бер дә хәерлегә түгел.

– Менә мин, иптәш Власик, съездда үзебезнең промышленность, шул исәптән автомобиль җитештерү барлыкка килүе хакында сөйләдем, миңа зал аягүрә басып, кул чапты. Шул ук вакытта иптәш Сталинның чит ил машинасында йөрүен совет кешеләре бик әйбәт беләләр бит. – Иосиф Виссарионович, җирәнгән кыяфәт чыгарып, үзен көтеп торган Паккард машинасын күздән кичерде. – Совет иле Политбюро өчен машина җитештерә алмыймыни?

– Әзерлибез, иптәш Сталин, Ленинградта...

– Кайчан әзер булачак соң ул?

– Быел сезнең хозурга тәкъдим итәчәкбез, иптәш Сталин.

Сталин төрепкәсен кабызып, Власикны бераз йөреп килергә өндәде.

– Василий турында тагын начар хәбәрләр ишеттем, Николай...

– Тәртибе белән бераз проблемалар килеп чыккан шул, мин кичә мәктәп директорында булдым, сөйләштек, Василий белән дә сөйләштем.

– Катырак сөйләшергә кирәк, Николай. Юкса, иптәш Сталинның улы тәртипсез үсә дигән сүзләр чыгачак бит. – Бераз дәшми торып, Сталин янә дәвам итте. – Укуда да бик әллә кем түгел ул... Светанка да үсеп җитә, быел җиде яшь тулачак, – диде ул, кинәт кенә кызы Светланага күчеп. Үзенчә яратып, аны Сталин Светанка дип йөртә иде. – Светанка мәктәпкә дачадан йөреп укый алмаячак. Шуңа күрә Мәскәүгә күчәргә туры килер, бирегә ялларга гына килә торган итеп. Дөресен әйтим, минем үземнең Кремльдәге фатирга кайтасы килми. – Янә тынлык урнашты, аяк астында кар шыгырдаганы гына ишетелә. – Ә Кунцевоны тизләтергә кирәк, юкса, Зубаловода тынчу... Һава җитми монда, кешеләр артык күп...

Власик берни дәшмәде, салдофон булса да, ул тормышчан, кешелеклелек мәсьәләләрен бик төптән аңлый иде. Алар машинага утырдылар.

– Ә мәктәпкә, иптәш Власик, иртәгә үземә кереп чыгарга кирәк булыр, – диде Сталин әллә Власикка, әллә үз-үзенә һәм янә уйларына кереп чумды...

...Надежда Аллилуева белән Иосиф революциягә кадәр үк танышты. Беренче күрүендә әле Надежда мәктәпне дә тәмамламаган кызчык кына иде. Иосиф исә аннан 23 яшькә олырак. Ул инде беренче хатыны Екатеринаны җирләргә өлгергән, тормышның ачысын-төчесен, төрмә-сөргенлекне узган революционер.

Беренче хатыныннан яшьли ятим калган Яковны мәрхүмәнең туганнары тәрбиягә алды, ә Иосиф исә үзенең бөтен вакытын, уй-фикерләрен большевиклар эшенә багышлады. Екатерина җан тәслим кылганнан соң инде бүтән гаилә кормам дип уйлаган иде Иосиф. Тормышында хатын-кызлар булмады түгел, әлбәттә. Ләкин гаиләле килеш көрәш алып бару, патша шымчыларыннан качып йөрү авыррак. Гаилә аның идеологик эшенә комачаулый гына. Әмма Надеждага күзе төште, күңеленә дә кереп калды бугай. Надежданың әтисе дә революционер, шуңа Иосиф аларның Петроградтагы фатирларында еш кунакка әйләнде, берара яшәп тә алды. Надежда Иосифка соклануын яшермәде, кайвакыт кичләрен табынга утыргач, Иосифның Туруханск өлкәсендә сөргенлектә күргәннәрен сөйләгәнен авызын ачып тыңлап утыра. Күзләрендә башта чиксез хөрмәт һәм ихтирам тоемланса, соңрак кайнар хис чаткылары да күренә башлады. Акрынлап, алар якынайдылар, еш кына кичләрен икәүләп, урамга һава суларга чыгып китә торган булдылар. Надежданың әти-әниләре Сергей һәм Ольга алдында исә хисләрен күрсәтмәскә тырыштылар. Хәер, холкы белән кырыс Иосиф хатын-кызлар белән мөнәсәбәтләрдә дә артык җебеп китә торган кеше түгел, үзен үтә җитди, Надеждадан өстенрәк тотты. Бусы – Кавказ тәэсире дә, Иосифның үз гаиләсендәге тәртипләр нәтиҗәсе дә. Әтисе Виссарион салган баштан әнисен кыйнаганнары әле дә исендә. Виссарионның ничек итеп үлгәнен дә тәгаен белүче юк, усал телләр генә аның исерек баштан килеп чыккан чәкәлештә җан тәслим кылганын әйтә. Ә әнисе бүген дә исән...

1918 елда Иосиф, ниһаять, Надеждага тәкъдим ясады. Бу хәбәрне

Сергей белән Ольга чиксез шатланып кабул иттеләр. Рәсми язылышып, гөрләп, туйлар үткәрер чак түгел иде. Аллилуевларның Петроградтагы фатирларында гаилә әгъзалары гына җыелды. Ольга табынны мул итеп, Кавказ гадәтләре буенча әзерләгән. Өстәлгә итле ризыклар, шәраблар чыкты. Беренче тапкыр әнә шул көнне Надежда Иосифның җырлаганын ишетте. Көр, нык тавыш һәм шул ук вакытта тирән сагыш белән башкара иде Иосиф грузин җырларын...

Иосифны партия Царицынга юллагач, Надежда да аның белән бергә китте. Ул инде, яшьлегенә карамастан, партия эшләренә аз-мазлап төшенә башлаган иде. Царицындагы тормыш балдан-майдан гына тормады. Гражданнар сугышының иң авыр чаклары. Иосиф көне-төне эштә. Аннан арып, йончылып кайта. Җитмәсә, бу – Совет власте өчен катлаулы чорларның берсе. Иосиф усал, ә Надежданың исә назланасы килә. Иосифның кәефе юклыгын күреп, Надежда кайвакыт чыгырыннан чыга торган булды. Баштарак Иосиф моны кызның яшьлегенә сылтаса да, соңрак характер үзенчәлеге, ә бәлки, авыру ук булуын аңлады.

Чыгырыннан чыккан вакытта Надежда бөтенләй үзгә кешегә әйләнә, теләсә нәрсә кычкыра, савыт-саба, йорт әсбапларын тар-мар итәргә керешә. Нәкъ менә Царицында Иосиф беренче тапкыр хатыны авызыннан үзенә карата әйтелгән «үтерүче» сүзен ишетте...

Надежда гаилә эшләрендә шактый булдыксыз икәнлеген күрсәтте. Еллар узу белән дә, ул гаилә учагын саклаучы тырыш хатынга әйләнмәде. Бер-бер артлы туган Василий белән Светланага карата да әни кеше салкын иде. Сөйләшүләре тәмле тоелса да, чынында күңеле коры булып чыкты. Шул ук вакытта Надежданы каты күңелле дип әйтергә дә тел әйләнми. Аларның өендә Иосифның беренче хатыныннан туган улы Яков яши башлагач, Надежда күтәрелеп, бер авыр сүз әйтмәде. Әле сабый чагында ук ятим калып, Политбюро карары белән Иосифка беркетелгән, аның үги малаена әверелгән Артем да Надеждадан караңгы чырай күрмәде. Дөрес, ул вакытта аңа инде өй мәшәкатьләре, бала тәрбияләү белән чикләнергә туры килмәде. Сталиннарның гаиләсендә хезмәтчеләр барлыкка килде. Балалар белән тәрбияче шөгыльләнә, аш-суны аерым кеше пешерә.

Надежданың институтка укырга керүен Сталин яратып бетермәде. Аның фикеренчә, әни кеше гаилә белән маташырга, өй буенча хезмәт күрсәтергә тиеш, ә Надежда исә иренең эшенә тыкшына, ил белән идарә итүгә кысылырга да күп сорап тормый.

Абхазиягә ялга баргач, аларга кунакка Лаврентий Берия килде. Ул кичне матур гына утырдылар, Бериядән кала табынга Абхазия җитәкчесе Нестор Лакоба да чакырылган иде. Надеждага бу өч чын Кавказ ир-аты янында баштарак кызык кебек тоелды. Ләкин берәр сәгать табында утырганнан соң, ул кинәт сикереп торып, бүлмәдән атылып чыгып китте.

– Ни булды, Коба? – дип сорады Нестор Лакоба.

– Зыян юк, хатын-кыз бит, аңламассың аларны, – дип, сүзне шаяртуга борырга маташса да, Иосиф гарьлек һәм ояттан җир тишегенә кереп китәргә әзер иде. Ләкин түзде, сер бирмәде.

Кунаклар соң гына таралышты, шактый күп шәраб эчелгәнгә, өчесе дә нык кәефле иде. Лакоба белән Берия киткәч, Сталин йокы бүлмәсенә

күтәрелде. Надежда табында нинди киемнән булса, шулай йөзе белән мендәргә капланып, җәелмәгән урын өстендә ята. Иосиф сәкегә утырып, хатынының чәчләрен сыйпарга үрелде, ләкин тегесе кинәт сикереп торып, аның кулын читкә алып ташлады. Надежда бу мизгелдә куркыныч иде. Кып-кызыл күзләре акайган, йөзе шешенеп беткән.

– Татька, – диде Иосиф. Надежданы яратып, икәүдән-икәү калганда, ул шулай атый иде. – Татька, сиңа ни булды?

– Миңамы? Миңа берни булмады, ә менә син ни эшлисең?! – Надежда, тәмам чыгырыннан чыгып кычкыра ук башлады.

– Аңламадым...

– Берия! Кемең ул синең?! Нигә ул миңа шундый майлы күзләре белән карап утырды? – дип ябырылды хатыны. Дөресен әйткәндә, Сталинның бер генә тапкыр да хатынын Бериягә карата көнләшү турында уйлап та караганы булмады. Лаврентийның Сталин хатынына күз төшерүе аның башына да килми иде.

– Татька, син ни сөйлисең?! Лаврентий – Кавказда минем иң ышанычлы кешеләремнең берсе!

– Әһә, иң ышанычлы, димәк! Син бирегә миннән башка ял итәргә килгәндә, ул ышанычлы кешең сиңа нинди себеркеләр ташый соң? Миңа охшаганнарнымы, әллә миннән яхшыракларнымы?!

Надежда, тәмам дулап, бөтен тирә-юньгә яңгырап торырлык итеп кычкырырга тотынды. Шау-шуга сак хезмәткәрләре үк йөгереп килде, ләкин Сталин аларны бүлмәгә кертмәде, барысы да яхшы дип, кире борып җибәрде. Бу кичтә ул икенче тапкыр оятыннан кызарды.

– Надежда, син акылыңнан шаштыңмы әллә? Ниләр сөйлисең, ни кыланасың? Сакчыларны аякка бастырдың, иртәгә аларның күзләренә ничек күренербез? – Хәзер инде чыгырыннан чыгу чираты Сталинда иде. – Син миңа кай яктан килеп бәйләнергә белмисең, һәрбер итәккә көнчелегең белән бөтен тормыш көчен аласың, җанымны суырасың!

– Син ил җитәкчесе булгач та, хатыныңны алдаларга ярый дип уйлыйсыңмы? Йә, әйт, бу Берияң белән ничә себеркене үз кулыгыз аша үткәрдегез?!

Ул мәлне Сталинның беренче тапкыр нервлары түзмәде һәм ул чалт итеп, хатынының яңагына сукты. Башта Надежда тынып калды, аннан соң акырып елап җибәрде. Икенче мизгелдә ул, әллә ниләр кычкыра-кычкыра Иосиф өстенә ташланды. Әгәр кулларын вакытында эләктереп алмаса, Надежда, һичшиксез, Иосифның битен тырнап бетерәчәк иде. Көчле куллар кысып алгач, куркынган Надежда беразга тынсыз калды. Сталин аның яшь тулы күзләренә текәлеп карап торды да бар көченнән сәкегә таба төртеп җибәрде. Шунда ук капылт кына борылып, бүлмәдән чыкты, ишекне тыштан ачкыч белән бикләде һәм ял дачасындагы китапханәгә төшеп китте.

Биредә ул төнге икеләргә кадәр китаплар укыды, туктаусыз тәрепкә тартты, һәм инде офыкта кояшның беренче нурлары күренә башлагач кына, шундагы диванга бөгәрләнеп ятып йоклап китте.

Әлбәттә, алар икенче көнне дуслаштылар, бер-берсеннән гафу да үтенделәр шикелле. Дөресрәге, Надежда гафу үтенде. Ул инде тынычланган һәм, әйтерсең, кичәге хәлләрне оныткан. Иосиф онытмады.

Соңрак мондый хәлләр бик еш кабатлана торган булды. Мәскәүдәге фатирларында да, Зубаловодагы дачада да, Надежда, балалар, туганнар, чит-ят кешеләр, хезмәтчеләр һәм сакчылар ишетә дип уйлап тормый, олы тавышлы гаугаларны ешрак куптара башлады. Берничә тапкыр моңа чик куяр өчен аерылышырга уйласа да, Иосиф, ахыр чиктә, түзәргә карар кылды. Вакыт узар, акыл керер, тынычланыр.

Соңгы гауга узган елның көзендә, 7 ноябрь демонстрациясеннән соң килеп чыкты. Бәйрәмнең икенче көнендә аларны Климент Ворошилов үзләренә кунакка чакырды. Бирегә шулай ук хатыннары белән Вячеслав Молотов, Сергей Киров, Михаил Калинин да килгән иде.

Ул көнне Надежда иртәдән үк үзен сәер тотты. Бернинди сәбәпсез башта Василийга бәйләнде, имештер, ул начар укый, аларның гаиләсен мәсхәрә итә. Василий мондый бәйләнүләргә күнеккән, чынлап та начар укый, шуңа шелтәләргә әллә ни исе китмәде. Аннан соң чират Иосифка күчте. Күптән түгел Иосифның үзе генә Кара диңгез буена ялга баруын исенә төшерде.

– Син бит үзең барырга теләмәдең, – дип гаҗәпләнде Иосиф.

– Мин барырга теләмәү ул әле синең теләсә нәрсә эшләргә хакың бар дигән сүз түгел!

– Һәм нәрсә эшләдем инде мин?

– Әйттеләр, сөйләделәр, борчылма.

Сталин кырысланды, хатынын каты итеп, кулыннан тотып алды:

– Ниләр уйлап таптың тагын? Кем, нәрсә сөйләде?!

Надежда авызын кыйшайтып, чыннан да нидер белгән кыяфәт белән усал елмайды гына:

– Мин барысын да белеп торам, миңа синең турында барысын да сөйләп торучылар бар, кадерлем. Шуңа күрә алдыңны-артыңны карап йөр.

Сталин бар көченнән Надежданы этеп җибәрде, аннан көзгегә таба борылды:

– Климент янына мин үзем генә барам.

– Ничек үзең генә?

Сталин хатынына усал караш ташлады.

– Мондый халәттә мин сине кеше арасына алып чыга алмыйм...

Кинәт Надежда елап җибәрде. Сталин кымшанмады. Иренең салкынлыгын күреп, ул үзе аны килеп кочаклады:

– Гафу ит мине, Иосиф, мин үзем белән ни булганлыгын белештермим. Минем башым бик нык авырта, кайвакыт чыдап булмый. Мин сине бик нык яратам, сине беркем белән дә бүлешергә теләмим!

– Син мине беркем белән дә бүлешмисең. Ә бу туктаусыз гаугалардан мин туйдым. Үзең беләсең, минем өстә зур йөк, мин аны үзем генә тартам. Тирә-яктан мине күпме дошман әйләндереп алган, син дә әледән-әле өсти торасың. – Ул хатынын үзенең кочагыннан аерып, күзләренә текәлеп карады. – Моның чиге булырга тиеш, аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм, – диде Надежда, мышкылдап. – Бәйрәмнәрдән соң миңа табибка күренергә кирәк, бу баш авыртуларын үзем генә җиңә алмаячакмын... Ә син мине яратасыңмы?

Сталин хатынын кочаклап үпте.

– Яратам, әлбәттә, Татька! – Аннан кул сәгатенә күз салды. – Болай

елашып торсак, Климентка соңга калабыз. Әйдә, тиз генә битләреңне ю да киен.

Ворошиловларның өендә барысы да тынычланган төсле тоелды. Табындагы ир-атлар үзара сөйләшүгә кереп чумды. Надежда кич буе Молотовның хатыны Полина Жемчужнаядан аерылгысыз булды, алар үзара көлешә-көлешә гәп кора бирделәр. Молотовны Сталин хөрмәт итсә дә, Полинаны бик үк өнәп бетермәде. Әллә тегесенең кире холыклы яһүд хатыны булганга, әллә үзенең хатыны Надежда белән артык якынлыгы өчен яратмады.

Чираттагы тост әйтелгәндә, инде шактый шәраб эчелгән иде. Табындагылар бокалларын күтәрделәр, Полина белән Надежда гына сөйләшүдән туктамады. Сталинга, әлбәттә, бу хәл ошамады.

– Әй, син, эч әйдә, – диде ул, хатыны ягына мандарин кабыгы тондырып. Бу граната ташлау белән бер булды. Надежда урыныннан сикереп торды. Күзләре ут кебек яна, алар нәфрәт белән Иосифка текәлгән. Иосиф айнып китте – әлеге карашның ни аңлатканын ул яхшы белә, хәзер гауга чыгачак. Табындагылар, әле Сталинга, әле Надеждага карап катып калдылар.

– Мин сиңа әй түгел! – дип кычкырды Надежда һәм, өстәлдәге бокалны алып, идәнгә томырды. Бокал чәлпәрәмә килде, Надежда җил-җил атлап, бүлмәдән чыгып китте. Полина Жемчужная «Наденька!» дип кычкыра-кычкыра, аны туктатырга ашыкты.

Табында бер мизгелгә тынлык урнашты. Иосиф берара нишләргә дә белмәде. Аннан үзен кулга алып, бокалын югары күтәрде:

– Бөек Революциянең 15 еллыгы өчен!

Табындагылар әлеге сүзләргә дәррәү кушылды, бераздан күңелсез вакыйга онытылды кебек. Сталин гына аз сүзлегә әйләнде, ул бертуктаусыз нидер уйлый, кашлары җыерылган, һәм бер-бер артлы тостлар әйтә-әйтә, шәраб эчә бирде.

Өйгә ул төнге уникедән соң гына кайтты. Надежда йокы бүлмәсендә иде. Аягын да салып тормыйча, Сталин аның янына үтте. Хатыны җәелмәгән урын өстендә бер ноктага текәлеп утыра.

– Надежда, бу ни дигән сүз? – диде Иосиф кырыс тавыш белән. Хатыны урыныннан сикереп торып, күзләрен акайтып, Сталинга таба атлады.

– Мин синең хезмәтчең түгел. Мин – коммунист. Синең мине кыерсытырга хакың юк, ишеттеңме?!

– Әгәр син болай...

– ...Нишләтәсең? Төрмәгә ташлыйсыңмы?! Бәлки, стенага терәп аттырырсың?! Синең кулларыңнан кан исе килә бит, беләсеңме син шуны, юкмы?! Син мине дә, бөтен илне дә кыерсытып, интектереп яшисең! Синең өчен син үзең генә бар, башкаларны теләсә нишләтергә, сытып үтерергә дә ярый дип уйлыйсың!

– Җитәр, Надежда...

– Ә, җитәрмени?! Бәлки, сиңа да җитәр?! Менә хәзер кара төнгә кадәр син кайда йөрдең?!

– Мин Климентларда идем.

– Климентлардан син унбердә чыгып киттең, миңа Полина әйтте. Йә, кайда йөрдең, дим?!

– Булды, Надежда!

Ләкин Надежда тынычланырга уйламады да. Ул, каһәр сүзләрен кычкыра-кычкыра, иренә ташланды. Тик Иосиф аны эләктереп алып, сәкегә таба җилтерәтте һәм тиз генә бүлмәдән чыгып та китте. Надежда аның артыннан ташланды, әмма Иосиф инде кабинетына кереп бикләнергә өлгергән иде.

Ул төндә Иосиф, гадәттәгечә диярлек, кабинетындагы каты диванда йоклады. Иртән исә аларның бүлмәсендә Надежданың мәетен табып алдылар. Ул абыйсы чит илдән алып кайтып биргән пистолеттан үзен-үзе атып үтергән иде...

Надежданы югалткач, Иосифның күңеленең бер кыйпылчыгы кителеп төшкән төсле булды. Хатынын соңгы юлга ул кешеләрдән тартынмыйча, елап озатты. Һәм аның җәсәде каршында бүтән беркайчан да гаилә кормаска сүз бирде...

Татьканы сагынып искә алса да, вакыт-вакыт хәтеренә өйдә булган гаугалар әйләнеп кайткалый. Бигрәк тә соңгы төнне әйткән сүзләре йөрәгенә шырпы булып кадалды. Надежданың башы авыртуын да белә, ләкин бу барыбер аны аклый алмый. Надежда – хатыны, димәк, терәк, аңлаучы буласы кеше. Аеруча авыр чакларда, бүлмәсенә бикләнеп, ялгызлыкта шәраб эчкәндә, ул Надежданы онытырга, аның хатирәсен тапларга маташты. Инде тәмам исергәч, кулына төрепкәсен тотып, көзге каршына килеп, ул мыек астыннан елмаеп, үз-үзенә:

– Иосиф, Надежданы яклама, ул сине сталыкҗан төсле ташлап китте, – дип әйтә торган булды. Надежданың абыйсы Павелны да күңелендә гаеплеләр рәтенә кертте. Чөнки нәкъ менә Павел сеңлесенә чит илдән пистолет алып кайтып бүләк иткән, ә Иосиф бу хакта берни дә белмәгән. Бер яктан, хатын-кызларда кечкенә пистолетның булуы гадәти хәл. Икенче яктан, Павел сеңлесенең бераз сәеррәк икәнлеген белә бит. Пистолеттан Иосифка аткан булса? Йә булмаса балаларга?! Фаҗигадә гаепле кешеләр исемлегенә Сталин Полина Жемчужнаяны да кертте. Полина Ворошиловлардан Надежда белән чыгып китте бит, алар озак кына сөйләшеп йөргәннәр.Ниләр әйткән икән Полина Надеждага? Бәлки, нәкъ менә Полинаның сүзләре соңгы этәргеч булгандыр? Сораулар, сораулар, сораулар...

Иосифның якыннары гына артык сораулар бирмәде. Надежданың туганнары хәтта кияүләрен акларга да тырыштылар бугай, һәрхәлдә, гаепләмәделәр. Хәзер дә алар зур гаилә булып, Зубаловода бергә яшәп яталар. Һәм шуңа күрә Кунцеводагы дачаны тизрәк төзеп бетерергә, Надежданы хәтерләтүче диварлардан, бүлмәләрдән, кешеләрдән качарга кирәк...

Поскребышев, гадәттәгечә, эштә иде. Әйтерсең, ул Сталинның кабул итү бүлмәсендә төн кунып яши.

– Ничек хәлләр, иптәш Поскребышев? – дип, кул биреп исәнләште Сталин.

– Рәхмәт, иптәш Сталин, барысы да әйбәт.

Сталин кул сәгатенә күз салды:

– Иптәш Ягода керсен.

– Яхшы, иптәш Сталин.

Генрих Ягода тәбәнәк буйлы, авыру йөзле, борыны астында тар гына мыеклы бәндә иде. Бүлмәгә керү белән ишекне япты һәм пышылдап диярлек Сталин белән исәнләште. Сталин аның белән үзе килеп күреште һәм киңәшмәләр өстәле янына чакырды. Ярты сәгатьләп сөйләшкәннән соң Сталин, урыныннан торып, төрепкәсен кабызды һәм кабинет буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

– Беломорканал төзелеше сезнең системада бит, иптәш Ягода? – диде ул, тәрәзә аша каядыр еракка текәлеп.

– Әйе, иптәш Сталин.

– Быел әзер буламы инде ул?

– Әзер була, иптәш Сталин.

– Зур төзелеш инде бу, әйеме, иптәш Ягода?

– Бик зур, иптәш Сталин. Каналның озынлыгы 227 чакрым. Сезнең исемне йөртер өчен лаеклы объект дип саныйм.

– Минем исемне йөртер дә, ләкин чит илләрдә аның аркасында минем исемнең дәрәҗәсе төшә. Советлар Союзы көчле дәүләт, әмма халыкара сәхнәдә дә безнең ил дәрәҗәле, мәртәбәле булырга тиеш. Юкса, кайбер матбугат чаралары язуынча, Сталин исемендәге каналны көчләп куып китерелгән тоткыннар төзиләр икән. Тоткыннар гына түгел, коллар дип тә өстиләр. Безгә бу ялгыш фикерне төзәтергә, чын күңелдән хезмәт итүче совет халкының батырлыгын бөтен дөньяга күрсәтергә кирәк. Мин менә ничек уйлыйм. – Сталин, бер мәлгә тынып калып, төрепкәсенә тәмәке өстәде. – Менә мин ничек уйлыйм, иптәш Ягода. Көннәр җылынгач, Беломорканал төзелешенә язучылардан торган экспедиция оештырырга кирәк. Бездә әйбәт язучылар күп. Максим Горькийны гына алыйк. Аның халыкара мәйданда дәрәҗәсе зур. Аннан башкалар да җитәрлек. Толстой, Зощенко, Катаев. Минемчә, бу мәсьәләне Политбюро утырышына чыгарып, язучылар исемлеген раслап, берничә көнгә аларны төзүчеләр белән яшәтергә, Беломорканалның уңай якларын күрсәтергә кирәк. Аннан соң без матур гына итеп җыентык чыгарып, аны башка телләргә дә тәрҗемә итә алыр идек. Ничек уйлыйсыз, иптәш Ягода?!

– Әйбәт фикер, иптәш Сталин.

– Әйбәт фикерләрне ычкындырмагыз, иптәш Ягода. Әйбәт фикер – Троцкий шикелле, хәзер чыгып ычкынырга мөмкин. – Ягода куырылып килде. Лев Троцкийның Төркиягә китүен Сталин кичерә алмый, һәм, күрәсең, әле дә гаепне аңарда – Ягодада күрә.

Сөйләшү тәмамлануын аңлап, Ягода Сталинның кабинетыннан тиз генә тавыш-тынсыз чыгып китте.

***

Иртәнге тынлыкны бозып, тау башыннан ат тояклары шокырдаган тавыш ишетелде. Атлылар бик кызу киләләр иде – кайбер айгырлар, артык каты чабыштан арып, пошкырып куялар, каты итеп кешнәп җибәрәләр. Тавышка уянган халык, урамга чыгып, авылга төшә торган юлны күзәтә башлады. Зират тирәсендә тузан өермәсе купкан. Әледән-әле кемнәрнеңдер «Нооо» дип кычкырып җибәрүе колакны ярып уза.

Бу – районга махсус җибәрелгән хәрбиләр төркеме иде. Алар күн киемнәргә киенгән, аркаларына мылтык асканнар, билләрендә кылыч. Якыная төшкәч тә, башларындагы картузларында кызыл йолдызлар ялтыраганы шәйләнде. Унлап хәрбидән торган отряд җитәкчесенең башында папаха.

Атлылар мәчет янындагы мәйданга килеп төштеләр. Атлары, кызу чабудан айнып бетмичә, урында биеп тора бирделәр. Хәрбиләрнең берсе, ияреннән сикереп төшеп, мәчет янындагы мәйдандагы баганада асылынып торган тимер кисәгенә бертуктаусыз кага башлады. Кайвакыт бу тавыш күрше чуваш авылында зур бәйрәмнәрдә уйный торган чиркәү чаңын хәтерләтеп куя иде. Тик чиркәүдән бәйрәм моңы агылса, моннан хәтәр көе ишетелә...

Халык эшнең хәерлегә бармаганлыгын тиз аңлады. Олылар төрле почмаклардан йөгерешә-йөгерешә, мәчет мәйданына ашыктылар. Тимер кагу туктатылды. Мәйдандагы калкулыкка папаха кигән хәрби белән авылдагы коммуна башлыгы, коммунистларны әйдәп йөрүче Таһир күтәрелде. Таһирның бүген авылда кунмавы турында имеш-мимешләр йөргән иде инде, шушы хәрбиләрне ияртеп кайтырга киткән икән...

Авыл өстендә таң алына. Шәфәкъ кып-кызыл, әйтерсең, кан түсенә кергән. Үзара пышылдашкан халыкка дәшмәскә өндәп, Таһир уң кулын күтәрде.

– Иптәшләр! – диде ул, усал күзләрен кешеләргә төбәп. Күрәсең, төне буе йокламаган, эчеп чыккан, күзләре тонган. – Безнең авылда коммуна урнашканга инде беренче генә ел түгел. Без бу вакыт эчендә матур гына итеп, эш рәвешен көйли алдык. Һәркемнең үз шөгыле, үзенә җитәрлек икмәге бар. Акрынлап булса да, Ленин-Сталин күрсәткән юлдан алга таба барабыз, дошманнар белән аяусыз көрәштә безнең никадәр хаклы икәнлегебез бүген көн кебек ачык. Сез беләсез, безнең авылда өч гаилә байлар бар. Аларның бер өлеш малларын үгетләп, ялына-ялвара дисәң дә, дөрес булыр, без коммунага җәлеп итә алдык. Ләкин алар барыбер безнең юлны сайламады, үз тормышлары белән, аерым хуҗалык булып яшәп ятарга телиләр. Мине мондагы һәммә кеше яхшы белә. Мин беркем белән дә каты бәрелеп, янап сөйләшмәдем. Тик эшче халыкның көтәргә вакыты юк. Безгә матур ил, якты киләчәк төзергә кирәк. Ә моның өчен безне артка сөйрәүче элементлардан арыну хаҗәт. Алда безне зур эш көтә – коммунаны колхоз итеп оештыру, күмәк хуҗалык булып, бергә яшәргә һәм эшләргә кирәк. Моңа аяк чалучылар – үзебезнең янәшәдә үк. Иптәшләр! Безнең байларның кем икәнлеге сезгә мәгълүм. Сез аларга гомер-гомергә бил бөктегез, башкарган хезмәтегез өчен тиешле әҗерен ала алмый ачлыкта яшәдәгез. Менә бу иптәшләр, – дип, Таһир янәшәсендә торган папахалы хәрбигә, аннан атлыларга ымлады: – бу иптәшләр безнең совет хакимиятенең җаваплы бурычын үтәргә килделәр. Безнең янәшәдә яшәп яткан байларыбыз, берни булмаган төсле йөреп, илебезгә, халкыбызга, Сталинга каршы яшерен эшчәнлек алып барган.

Халык «аһ!» итте. Бер читтәрәк басып торган Заһидулла, йөрәген тотып, җиргә чүгәләде, янәшәсендәге хатыны Бибинур, елап җибәреп, аңа ярдәмгә ашыкты. Алар – шул өч бай гаиләсе дигәннәренең берсе иде.

– Күрәсезме, дөрес сүз ярамады, – дип ыржайды Таһир. – Ә хәзер сүзне мин безнең районнан килгән ихтирамлы кешегә бирәм. Ул безнең арадагы яшерен дошман элементларның исемлеген атап, аларга карата совет хакимияте чыгарган карарны җиткерәчәк.

– Атып үтерәләр икән, – диде бер хатын, күз яшен яулык очы белән сөртеп.

– Атмыйлар, әле суд булмаган бит, – диде икенче бер агай.

– Шул кирәк, күп кыландылар инде, – диде кемдер.

– Себер җибәрәләр байларны, советлар аларга пуляны да кызгана, имеш...

Халык шулай үзара сөйләшкән арада, папаха кигән хәрби кеше, билендәге күн офицер сумкасыннан ниндидер кәгазь чыгарып, анда язылганны кычкырып укырга кереште. Мәйданга җыелган халык, урысчаны аңлап бетермәсә дә, бераз сукалаганнар тәрҗемә итә торды. Аларның авылларыннан хәлле саналган өч гаилә, колхозлашуга каршы чыккан, халык арасында коткы, Троцкий яклы мәгълүмат тараткан өчен, иң кирәкле әйберләрен генә алып, сөргенгә озатылачак. Авыл халкы янә дулкын булып шаулашып алды. Байларны районга сорау алуга берничә мәртәбә чакыртуларын һәммәсе белә, менә хәзер сәбәбе дә ачыкланды.

Таһир, хәрбиләрне үзе белән ияртеп, байлар яшәгән йортларга таба юнәлде. Аңа коммунада актив катнашып йөрүче тагын берничә кеше кушылды. Ике хәрби йөрәген тотып торган Заһидулла байны ике яктан эләктереп, өенә җилтерәтеп алып киттеләр. Калган солдатлар аттан төшмәде.

Өч ат олавы җигелде. Өчесе өч бай йортының капка төбенә берәм-берәм килеп туктады. Байларның өйләре эчендә кычкырышкан, елашкан тавышлар ишетелде. Авыл халкы моны дәшми генә, тамаша караган төсле читтән күзәтеп торды.

Беренче булып, Заһидулла бай белән Бибинур, төенчекләрен җыеп, арбага чыгып утырды. Алар икәү генә калган иде инде. Бердәнбер уллары Нигъмәтҗан әле унтугызынчы елда ук бу якларга килеп чыккан ак чехларга ияреп, совет властена каршы көрәшеп карады да кызыл армиячеләр басымы астында аклар белән бергә көньякка китеп югалды. Әледән-әле аны йә Кара диңгез буенда пароходка төялгән вакытта күргәннәр дигән хәбәр килеп ирешә иде, йә казакъ далаларында басмачылар ягында сугышып йөри дигән сүзләр ишетелде. Заһидулла бай улының исән калуына ышанмады, аңа күптән ясин чыккан иде, Бибинуры гына туктаусыз елаудан шартлап кипкән күзләрен тәрәзәдән алмый, улын көтте. Хәзер инде икесе дә могҗизага өметләрен өзеп, кирәк-яракларын гына җыеп, хөкүмәт кайгырткан арбага менеп утырдылар. Авыл кешеләренә алар борылып та карамады – Бибинуры кинәт йөрәгенә тотып алган Заһидулласын тынычландырырга маташа иде...

Аннан Касыйм байга чират җитте. Усал, нык гәүдәле Касыйм бай, бугазы төбенә штык килеп төртелгәч, бер мизгелдә умыртка баганасы сынган кешегә охшап калды. Хатыны Кәшифә һуштан язып ук егылды, шактый вакыт аны аңга китерер өчен маташтылар. Касыймнар байлар арасында иң ишле гаиләле иде – кирәк-ярак әйберләре дә күп җыелды. Ике кызы, мәктәп яшеннән дә чыкмаган улы әти-әниләре янына арбага менеп утырды...

Заһидулла белән Касыйм олауларын сакларга җирле активистлар

калды, Таһир хәрбиләр озатуында Сафа бай утарына юл алды. Сафа бай авылның чыннан да иң хәлле кешесе иде. Абзар-каралтыларын таштан күтәргән, төп йорты ялтырап торган сап-сары нарат бүрәнәләрдән салынган. Йорт үзе алма бакчасы белән уратып алынган. Ишегалдына биек ярыс капкасы аша керәсе. Сафа бай заманында Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан кеше, аннан түшенә Георгий тәресен тагып кайтты. Сафаның булдыклылыгы да, усаллыгы да бар иде. Улы белән кызы, революция зилзиләсе башланганчы ук, гаиләләрен җыеп, Төркиягә чыгып киттеләр. Сафа исә төп йортта ялгызы калды. Туган нигезен ташламыйм, диде. Биредә аның әти-әниләре җирләнгән, күптән түгел генә зиратка үзенә генә мәгълүм кырыс мәхәббәт белән яраткан Сафурасын да илтеп урнаштырды.

Таһир биек ярыс капкага бар көченә китереп типте, аннан урам якка чыккан тәрәзәне таш атып, чәлпәрәмә китереп ватып төшерде.

– Чык, Сафа абый, вакытың җитте, – дип кычкырды Таһир.

– Хәзер, чыгып барам инде менә, – дигән тавыш әллә кайдан киләме, дисә, амбар тәрәзеннән икән. Ләкин аннан Сафа түгел, мылтык көпшәсе күренде.

Ату тавышы яңгырады. Таһирның башындагы комиссар картузы, мәтәлеп китеп, каядыр очты, колакларын ут белән өтеп алган төсле тоелды. Ул, алны-артны карамый, «үтерәләр!» дип кычкыра-кычкыра, капка төбеннән читкә йөгерде, абынып егылып, ниндидер канауга барып төште.

Халык арасында чыр-чу чыкты, кем кая тизрәк качарга, балаларны алып китәргә ашыктылар. Хәрбиләр дә тиз генә урам чатына ышыкландылар.

Папаха кигәне солдатларга урыс телендә ниндидер әмерләр бирде. Ике атлы солдат шунда ук, урыннарыннан җәһәт кенә кузгалып, урамның түбән очына йөгерделәр – күрәсең, аларга, йортны урап чыгып, бакча башыннан төшергә кушылгандыр. Өчесе исә, мылтыкларын күкрәкләренә кысып, шуышып, йорт каршынарак юнәлделәр. Алардан егермеләп адым ераклыкта канауда Таһир ята иде.

Үз ягына солдатлар шуышканны күргәч, Таһирга бераз җан керде.

– Сафа абый, чык яхшы чагында, башың сау булыр ичмасам! – диде ул, башын канаудан күтәрмичә.

– Чыгармын мин сиңа, тәмуг кисәве, көтеп тор! Тизәк арасында тудың, тизәк арасында йөрисең, хәзер дә тизәк янәшәсендә аунап ятасың! – Сафа бай тагын атып җибәрде. Таһирның янында гына балчык өере күтәрелеп, җилкәсенә үк кереп тулды.

Ләкин солдатлар да тик тормадылар. Амбарның кечкенә тәрәзәсенә төбәп, яткан төштән ата башладылар. Сафа бай бер-ике мәртәбә җавапка атып карады да бүтән дәшмәс булды. Озак та үтми, Сафа байның утары ягыннан «Атмагыз» дип, урысча кычкырган тавыш ишетелде. Тагын пуляләр шатырдавы яңгырады. Ул да булмады, биек ярыс капкасы ачылып китте, аннан ике кызылармияче күренде. Алар Сафа байны аякларыннан сөйрәп чыгарып, капка төбенә ташладылар. Сафа байның күзләре акайган, чалкан яткан җиреннән аркасыннан кан ага, ә түшендә Георгий тәресе ялтырый иде...

Таһир, өсләрен каккалап, канаудан торып басты, Сафа мәете янына йөгереп килеп, билендәге наганын тартып чыгарды һәм мәрхүмнең маңгаена төбәде. Ашыга-ашыга килеп җиткән папахалы хәрби аның кулыннан наганын тартып алды.

– Ярамый, – дип, кырт кисте ул, һәм, наганга бер генә күз төшереп, хуҗасына кире кайтарды.

Өч арба бер-бер артлы тезелеп басты. Беренче арбада хатыны белән Заһидулла бай, икенчесендә куркудан тәмам һушсыз калган балаларын кочып утырган Касыйм бай белән хатыны Кәшифә, өченчесендә – пыяла булып катып калган күзләрен күккә төбәгән Сафа бай мәете...

Өч олауны атлы солдатлар як-яктан әйләндереп алып, юлга кузгалдылар. Иң алдан яхшы кара атына атланган Таһир бара – ул башына комиссар картузын кигән, аның читләре чак кына тиеп үткән пулядан өтелеп калган, үзенең куркуы бетмәгәнлеге тышкы кыяфәтеннән сизелеп тора. Таһир янәшәсендә папахалы хәрби – йөзендә бернинди хис тә юк, әйтерсең, гадәти, көндәлек эш башкарылды. Кемдер татлы йокысын бүлеп, сабый булуына да карамастан, өстендә ни бар шуны киеп сөргенгә китәме, әллә инде берәрсен амбарына кереп, аркасына атып үтерәләрме – бернинди сәер нәрсә дә юк, әйтерсең, дөнья элек тә шулай барган, бүген дә шулай бара...

Олауларны озатып калган авыл халкы арасында сирәгенең күзеннән яшь чыкты. Кызгансалар, шул Кәшифә кызларын гына кызганганнардыр. Калганнарында халыкның әллә ни кайгысы юк иде. Артык әйбәт яшәделәр, җәзасын да алдылар. Авыз ачып, «шул кирәк» дип әйтүчеләре дә табылды. Иң аянычы – бу Таһирга яисә коммунистларга ярау өчен түгел, ә ихлас күңелдән әйтелгән сүзләр иде.

...Бары тик бер генә кеше бу вакытта күз яшьләрен ихластан түгә иде. Бары тик бер генә кеше бу котырынган, акылдан шашкан кавемнең аңга килүен сорап, Ходайга ялвара иде. Бары тик бер генә кеше бу мизгелдә гомере өзелгән мәрхүмнең рухына дога кыла иде. Ул – авыл мулласы Хәмидулла. Ул халык белән бергә мәйданга чыкмады, байларны мәсхәрәләгәнне карап тормады. Хатыны белән кызын да беркая да җибәрмәде. Шыпырт кына бакча артлатып, мәчетенә керде дә, авылда гаугалы вакыйгалар булып ятуына да карамастан, бертуктаусыз дога укыды. Укыганда еламаска тырышса да, булдыра алмады. Әйтерсең, авылдашларыннан чыкмаган күз яшьләре, кая барырга белми бәргәләнеп йөргәннән соң, аның күзләре аша дөньяга сибелделәр.

Революция Хәмидулланың да тормышын астын өскә китерде. Бертуганы Сәгыйдулланың Петроградтан чыгып качканнан бирле бернинди хат-хәбәре юк. Үзенә дә авырга туры килә. Нәселләре белән гомер-гомергә шушында мулла булып торган кешеләр бит, төшеп калганнардан түгел. Йорт та зур, каралты-куралар да, умарталар да, җире дә бар. Әтисе үләр алдыннан байлыгын ике улына тигез васыять итте, икесенә дә җитәрлек мал калдырды. Хезмәт белән тир түгеп җыелган байлык, бер дә хәрәм нәрсә юк.

Әтисе Хәбибрахман мулла бик укымышлы кеше иде. Хаҗ кылган, күп белем эстәгән. Дин эше белән бергә сәүдәне дә оештырырлык сәләте ачылды. Аның мәрхүменнән соң сәүдә эше кечкенә улы Сәгыйдуллага, ә мәчет-муллалык, төп нигез Хәмидуллага күчте. Якты дөнья белән бәхилләшкәндә, Хәбибрахман мулла туган иле өстенә мондый гарасат киләсен чамаламагандыр да...

Хәмидулла хәзрәт өенә өйләдән соң гына кайтты. Хатыны Нәсимә белән кызлары Зөбәйдә табын әзерләп көтеп торалар иде.

Сүзсез генә табынга утырдылар, дога кылып, ашка керештеләр.

– Сафа абыйны атып үтергәннәр, – диде, ниһаять, хатыны.

– Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун...

– Амин! Бакчадан төшеп аркасына атканнар. Хәмидулла, безне ни көтә инде?!

– Алла ни кушса, шул көтә, Нәсимә, син дә, мин дә артыгын белмибез.

– Ничек бу гарасаттан котылып булыр икән?!

– Белмим, Нәсимә. Алладан яклау сорап кына. Аннан артыгын мин белмим.

– Без дә байлар исәбендә йөрибездер бит.

– Безгә дә килерләр, ник аны хәзердән үк сорап аласың? Вакыты җиткәч, безгә дә килерләр, килми калмаслар.

– Килсәләр, нишлибез?

– Һәрхәлдә, Сафа абый төсле атышып булмас инде, Нәсимә. Яшәргә тырышырбыз. Ходай кушып, бу заманалар да узар. Ачлыкны үттек, аклар килде, кызыллар килде, исән калдык. Моннан да исән калырбыз, насыйбыбыз булса... – Аннан соң Хәмидулла, елмаерга тырышып, хатынына карады. – Сиңа борчылырга ярамый, Нәсимә, үзең генә түгел бит хәзер. Бер дә борчылма, янәшәңдә без бар, бергәләп, ул авырлыкны күтәрербез.

Нәсимәсе корсакка узганга өченче ай бара иде. Хәмидулла хәзрәт Алладан көн саен үзләренә малай бирүен сорады. Исемен дә сайлап куйды – Хәбибулла дип атыйсыларын Нәсимәсе белән килештерде. Хәбибулла – Аллаһының яраткан бәндәсе дигәнне аңлата. Хәмидулла хәзрәт, аны исән-имин үстереп, нәселләрендәге муллалык хезмәтен дәвам итүче булыр дип хыялланды. Көмәнлелек мондый ызгышлар чорына туры килү генә аны борчый, Нәсимәсенә бигрәк тә җиңел түгел. Аның борчылулары балага тәэсир итә күрмәсен өчен Хәмидулла хәзрәт хатынын һәрвакыт тынычландырырга, авыр эштән араларга тырыша. Моңарчы да талпынышлары бар иде, ләкин көмәнлек озакка бара алмады, нindидер сәбәпләр аркасында өзелә торды. Хәзер Нәсимәнең корсакка узуы өйдәгеләр өчен аерым бер вакыйгага әйләнде...

Икенче көнне Таһир җитәкчелегендә авылда зур эш башланды. Авыл янәшәсендәге инешнең аргы ягына колхоз корылмалары төзергә кушылды. Кайчандыр өч байныкы булган милек тулысы белән колхоз карамагына күчте. Сүтә алган каралтыларны, нык йортларны шунда күчерә башладылар. Әкренләп, сыер, сарык абзарлары оешып чыкты, иген келәтләре калыкты. Колхоз малы җыйналган утарны нык читән белән әйләндереп алдылар, керү шәбендә Сафа байның шәп имән йортыннан бригада конторасы җиткереп куйдылар. Таһир шунда колхозга керүчеләрдән гаризалар алырга утырды.

Колхозга керү акрын булса да, бара иде. Халык, кая бәрелергә белмәгәнлектән, кем сыерын, кем атын ияртеп, кем сукасын сөйрәп, күмәк хуҗалыкның уртак малын тулыландыра, Таһир кушкан эшләрне үти. Таһирның уң кулы итеп яше илледән узган Фазылҗанны сайлап куйдылар. Фазылҗанны сайлатучы Таһир үзе иде. Чөнки Фазылҗан – бердән, куркак, икенчедән, куштан, өченчедән, Таһирның сүзеннән чыкмый торган кеше. Колхозчылар ярдәме белән Фазылҗанның йорт-җирләрен дә төзәттеләр, күмәк хуҗалык исәбеннән үзенә бер кәҗә бүлеп бирелде

– соңарып өйләнгәнгә балалары әле кечкенә, җитмәсә күбәү дә – җиде бөртек. Фазылҗанның күрше авылдан революциядән соң ияртеп кайткан хатыны бик үрчемле булып чыкты – сабыйларны ел саен диярлек табып тора иде. Аларны ашатырга кирәк, колхоз үзенекеләрне ташламый дип, Таһир бу карарны җыелыш җыеп, зур итеп күпертеп кабул итте. Тагын азмаз кеше колхозга тартылды. Шулай үгетләү, хәйлә, куркыту белән авылда колхозлашу эше бара иде. Озакламый авылда колхозга кермәгән бер генә гаилә – Хәмидулла муллалар гына калды...

Караңгы төшеп килә иде. Хәмидулла, йокларга ятар алдыннан һава сулыйм дип капка төбенә чыкты. Урамнан аңа таба кара айгырына атланган Таһир борылды. Капка төбенә килеп җитү белән атыннан сикереп төшеп, ул аны ашыкмый гына читәнгә бәйләп куйды да, Хәмидуллага кулын сузды.

– Исәнме, Хәмидулла абый!

– Исән генә әле, Таһир энем, – диде коры гына сәламләп Хәмидулла.

– Синең белән сөйләшәсе бар иде.

– Соң, сөйләш, менә бит ул мин, каршыңда утырып торам.

Таһир да эскәмиягә утырды.

– Дөньялар үзгәргәнне сизәсең бит, Хәмидулла абый, – диде Таһир, муллага карамый, караңгыда нидер күзләп.

– Сизмәгән кая инде монда.

– Исән каласың киләме?

– Әстәгъфирулла, бу нәрсә, янаумы?!

– Янау түгел, солых.

– Солых?! Ниткән солых тагын?! Мин беркем белән дә сугышмыйм!

– Сугышасың шул. Совет власте белән сугышасың, Хәмидулла абый.

– Мин...

Таһирның тавышы кинәт кырысланды:

– Тыңлап бетер. Бу минем генә сүзләр түгел бит. Өстән килә торган фикер. Сез – муллалар, поплар халыкны бутыйсыз, властька каршы котыртасыз дигәнне бик еш ишетәм мин. Урман артындагы чуваш авылының побын кичә гаиләсе белән төяп, сөргенгә җибәрделәр. Ул да синең кебек колхозга керми карышкан, чиркәве белән генә көн күрмәкче булган... Аннан соң, ни, син белеп тор. Мин бүгеннән мәчет ишегенә йозак салдым.

Таһир кесәсеннән ачкыч чыгарып күрсәтте.

– Ачкычы миндә генә. Кеше җыеп, намазлар укытып йөрмисең. Белдерүне иртәгә эләбез, халык бүтән килеп йөрмәс.

– Әстәгы, әллә денсез калдырмакчы буласыңмы?!

Таһир көрсенеп куйды:

– Нәрсә аңлыйсың соң син, Хәмидулла абый! Мин уйлап чыгараммыни боларны? Күрше авыл побын алып киткәннәр дип, әле генә әйттем бит, ышанмасаң, ерак түгел, барып белешеп кайт! Аларда поп, бездә мулла. Иртәгә чират сиңа да килеп җитәргә мөмкин, Хәмидулла абый...

– Миңа нишләргә кушасың?

Таһир үҗәт мулланы үз ягына аудара алганына ышанды бугай, тавышы ышанычлырак яңгырый башлады:

– Чалмаңны салып, гаиләң белән колхозга керәсең. Бусы бер. Йортҗирләреңне, умарталарыңны, мал-туарыңны колхозга бирәсең. Бусы ике.

һәм иң соңгысы. Мин синең кызың Зөбәйдәгә ярәшергә телим, Нәсимә апа белән синнән ризалык, Зөбәйдәдән – миңа яхшы хатын булу шарты.

Хәмидулла торып басты. Караңгыда да ачудан күзләре ут булып януын Таһир бик аермачык күрде.

– Син нәрсә, энем, минем белән сатулашырга килдеңмени?

– Сатулашырга түгел, коткарырга, Хәмидулла абый!

– Нәрсәдән коткарырга?!

– Хәтәрдән коткарырга, сине дә, Нәсимә апаны да, Зөбәйдәне дә. – Таһир да урыныннан торды. – Үзең уйлап кара – авылның барча халкы хәзер колхозда. Алар кем сүзен тыңлар? Мондый зур йорт бер синдә генә калды, шулай озак барыр дип уйлыйсыңмы? Кечерәк бура сайлап алырбыз да, шунда күчәрсез. Сезне авыр эштә эшләтмәм. Зөбәйдәгә беркем дә бармак белән дә тимәячәк...

– Ә, алай икән... Беркем дә... Синнән башка... Ул әле сабый гына, аның белән алыш-биреш итәсем юк.

– Мин көтәргә әзер, Хәмидулла абый.

– Мин уйлап карармын, – диде Хәмидулла, сөйләшүнең тәмам икәнлегенә ишарәләп, капкага таба борылып. «Имансыз», диде ул әллә кычкырып, әллә үз-үзенә.

Өйгә кергәч тә, Нәсимә аның йөзенә күз салу белән бер-бер хәл булуын аңлады.

– Ат пошкырган тавыш ишетелде, кем йөри анда? – дип сорарга җөрьәт итте ул иреннән.

– Таһир.

– Ни кирәк аңа?!

– Зөбәйдә белән кирәк-ярак әйберләрегезне җыя торыгыз, – диде кинәт тавышы үзгәргән Хәмидулла. – Өс-баш әйберләрен, минем китапларны. Малларны, каралтыларны колхозга тапшырабыз.

– Ә үзебез?!

– Авыл читенә күченербез. Амбарны йорт итеп корып, шунда яшәрбез, аның бүрәнәләре нык. Ачтан үлмәбез.

– Колхозга керәбезмени?

– Колхозга да керергә туры килер, җанкисәгем. Барча малны аларга бирәбез. Баш сау булсын. Ә хәзер йокла.

Анык кына фикергә килсә дә, Хәмидулла хәзрәт аны Таһирга барып әйтергә ашыкмады.

Мәчет ишегенә чыннан да йозак салынган иде. Ишек яңагына беркетелгән кәгазьдә әлеге карарның колхоз җитәкчелеге тарафыннан кабул ителүе һәм мәчеткә йөрергә ярамаганлыгы әйтелгән.

Алар бөтен гаиләсе белән акрынлап, әйберләрен җыярга керештеләр.

Җылы җәйге кичләрнең берсе иде. Зөбәйдә, көянтәләрен алып, чишмәгә суга төшеп китте. Чишмә инеш чокырының төбендә үк, аңа кадәр әрәмәлек эченнән үтүче тар сукмак аша менәсе. Чиләкләрен тутырып, чокырдан өскә менеп кенә җиттем дигәндә, Зөбәйдә күзгә-күз Таһир белән очрашты. Таһир, күрәсең, бераз салмыш, йөзләре кызарып чыккан. Зөбәйдәне дә биредә сагалап торган, ахрысы – аты ерак түгел үлән утлап йөри.

– Саумы, Зөбәйдә, – диде Таһир, чүгәләгән җиреннән торып басып. Күн тужуркадан, күн картуздан, аякта күн итек, галифе чалбар, билдә

наган, күкрәктә портупея – мондый килеш-килбәт авылда бары тик колхоз рәисенеке генә.

– Исәнмесез, Таһир абый...

– Сез димә инде, Зөбәйдә, аннан соң, ниткән абый булыйм ди мин сиңа? Куй әле чиләкләреңне, бер утырып сөйләшик.

– Әти белән әни көтә, озак торсам борчылырлар.

Таһир аңа якынрак килде, Зөбәйдәнең йөзенә хәмер исе килеп бәрелде. Ул йөзен читкә борды.

– Бөтенләй буйга җиткән кыз булып үскәнсең, Зөбәйдә, – Таһир елмайган кыяфәт чыгарды, никтер ул калтырана иде. – Синең белән кайчан бер утырып тынычлап сөйләшеп булыр икән? Бүген кич чыга аласыңмы?

– Юк, Таһир абый, миңа ярамый, – диде кызый, үзен кая куярга белмичә.

– Ник ярамый? Кем комачаулый? Әйдә, әтиең белән үзем сөйләшәм.

Таһир калтыранган бармаклары белән Зөбәйдәнең иягеннән тотып, башын үзенә таба күтәрде. Хәмер исеннән җирәнеп, Зөбәйдә шунда ук артка чигенде, чиләкләрендә су чайпалып, җиргә түгелде.

– Нәрсә, җирәнәсеңмени? – Таһирның елмаюы качты. – Юкка болай кыланасың, Зөбәйдә, син дә, әтиең дә. Минем белән сиңа да, аларга да яхшырак булачак. Аңлыйсыңмы шуны?

Кызыйны кызыктырырга маташып, Таһир йомшара төште.

– Таһир абый, кайтыйм инде, – диде тегесе, мондый игътибардан кая качарга белмичә.

– Әллә соң мин башкалардан кимме? – дип, янә кызга таба килә башлады Таһир. – Ким түгел, күпкә артык! Авылда күкрәк киереп йөриячәксең, аңлыйсыңмы?!

Зөбәйдә кинәт көянтәсен-чиләкләрен күтәреп бәрде дә, әрәмәлек аша авылга таба йөгерде. Йөрәге дөп-дөп тибә иде.

– Үзеңне дә, әти-әниеңне дә коткара аласың, Зөбәйдә, юкка качасың! – дип, Таһирның кычкырган тавышы аның колакларында әле озак яңгырап торды.

Зөбәйдә авыл башына җиткәч, инеш ягына борылып карады. Таһир кара айгырына атланып, бригада утары ягына китеп бара иде. Нык куркынган булса да, кире килеп, көянтә-чиләкләрен алды, ләкин суга төшеп тормады. Өйгә кайткач та, әнисенә юлда абынып егылдым, суым шунда түгелде дип кенә әйтте. Әти-әнисен бу очрашу турында сөйләп хафаландырасы килмәде, аларның болай да бик киеренке чорлары. Әтисе мәчетсез калуны аеруча авыр кичерә, әнисенең көмәнлек белән үз хәле хәл...

Кичен ул каралты артына чыкты. Аны биредә Вакыйфы көтә иде. Алар умарталар янындагы куаклыкка барып елыштылар. Шушы мизгелдә, сөйгән егете җылысында гына Зөбәйдә күңелен бушатырга ирек бирде. Ул, мышык-мышык елый-елый, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләде.

– Үтерәм мин аны, – дип, йодрыкларын кысты Вакыйф.

– Кирәкми, Вакыйф, башыңа бәла алма. Мин барыбер синеке генә булачакмын. Аның миңа зыян китерергә хәленнән килмәячәк. Урында эшләгәч, бигрәк тә. Алдагысын тормыш күрсәтер.

Вакыйф та уйга калды.

– Сине сорарга әнине җибәрсәм?! – диде кинәт Вакыйф. – Күченергә җыенасыз, сиңа да мәшәкате азрак булыр.

– Вакыйф, мин бик риза да бит, ләкин бүгенге хәлләрендә эти-әниләр никах мәшәкатьләре, мине кияүгә бирү хәстәре белән йөрерлек түгел. Аннан бигрәк Таһирдан куркам, берәр зыян салып куймагае! Тынычланыр, онытыр, көтәргә кирәк. Дөньялар һаман да болай хәтәр булмас, афәт озакка бармас. Бераз гына сабыр ит инде, җаным!

Алар әле бик озак сөйләшеп утырдылар, киләчәкне әле алай, әле болай фараз кылдылар. Зөбәйдәне озатып, кайтыр юлга чыкканда, күк йөзе тәмам караңгыланып, анда йолдызлар сибелгән иде. Болытлар артыннан ай калкып чыкты, дөнья көмеш нурларга күмелде. Ике урам арасындагы сукмак уртасында Вакыйф кара атка атланган кешене шәйләп алды. Ул, атын ашыкмый гына атлатып, аңа таба килә иде. Нишләргә дә белми туктап калды Вакыйф. Аны Таһирның тавышы айнытып җибәрде.

– Кая бардың, Вакыйф?! – диде ул һәм аңа берничә адым кала атыннан сикереп төште. – Кара төндә нишләп йөрисең, иртәгә эшкә чыгасың юкмыни?

Вакыйф дәшмәде. Ул Зөбәйдәнең Таһир белән очрашуын искә төшереп, колхоз рәисенә ташланыр хәлгә җитсә дә, сабырлыгын җыеп тыелып калды.

– Нәрсә, әллә мулла кызы янына йөрисеңме?! – Таһир шаркылдап көлеп җибәрде. Аннан кинәт Вакыйфны ике куллап, якасыннан эләктереп алды да үзенә таба тартты. Алар йөзгә-йөз очраштылар. Таһирның авызыннан авыр ис килсә дә, Вакыйф түзде. – Хәзер мине тыңла, контра. Әгәр дә мулла кызына бармак белән генә кагылсаң да, үзеңне дә, әниеңне дә бер арбага төяп, Себергә озатам. Әби патша юлы нык, сезне генә күтәрерлек җае бар аның. Әгәр син аңа өйләнергә уйласаң, мин, совет власте вәкиле буларак, моңа бернинди ризалык та, рәсми документ та бирмәячәкмен. Ул чагында инде әниең белән сине генә түгел, син бозган Зөбәйдәңне дә янәшәгезгә утыртып олактырырмын, аңладыңмы?! Тагын бер генә тапкыр Зөбәйдә тирәсендә чуалганыңны күрсәм, беттең, егетем. Үзеңне уйламасаң, әниеңне уйла, аның юл газабын күтәрерлек көче калмагандыр.

Таһир бар көчтән Вакыйфны төртеп җибәрде. Вакыйф әйтер сүз тапмады. Ул берни дә дәшмәде. Күлмәкләрен рәтләде дә Таһир аша туп-турыга текәлеп, үз юлы белән китеп барды.

Икенче көнне Таһирны районга чакыртып алдылар. Беренче секретарь бүлмәсендә җирле НКВД вәкиле утыра иде. Ул Таһир белән коры гына исәнләште.

– Иптәш Фәтхуллин, менә сезне иптәш Фролов күрергә теләгән иде, – диде беренче секретарь.

– Әйе, тыңлыйм... – Таһир коелып төшсә дә, сер бирмәде, тәкъдим ителгән урынга утырды.

– Сезнең авылдан өч гаилә сөргенгә җибәрелде, алар бүген моннан еракта, белүемчә, малларын колхозга җәлеп иткәнсез. – НКВД вәкиле кулындагы кәгазьләрендә казына-казына, Таһирга карамый гына сөйләшә иде. Аннан кинәт күтәрелеп, пыяладай салкын, чем-кара күзләрен колхоз рәисенә төбәде. – Ләкин бер гаилә исемлеккә керми калган. Тимерхановлар. Безнең мәгълүмат буенча, алар да хәлле кешеләр, җитмәсә, муллалык белән шөгыльләнәләр. Мондый аерым мөнәсәбәтнең сәбәбе нидә?

– Аерым мөнәсәбәт юк, иптәш Фролов... – Таһир, ни әйтергә дә белми,

каушап ук калды. Үзенә янарга торган куркынычны тоюдан тәненә эсселек йөгерде. – Без колхоз идарәсе карары белән мәчетне яптык инде. Мулла гаиләсе дә колхозга керәчәк.

– Ләкин бүгенгә кадәр кермәгән булып чыга?

– Аңлыйсызмы, аңа капылт кына муллалыктан күчү авыррак, бераз вакыт кирәк.

– Безнең вакытыбыз юк. Бәлки, ишеткәнсездер, безнең көчләр белән бу тирәләрдә эш иткән кулак-мулла оешмасы тар-мар ителде. Алар, җыелышлар үткәреп, совет властена каршы мәкерле планнар корганнар, хакимиятне бәреп төшерү юлларын эзләгәннәр. Хәмидулла Тимерханов шул төркемдә катнашмаган дип, кем әйтә ала?!

– Юк, булмас. Авылдан китеп йөрми ул, һәрвакыт өендә.

– Иптәш Фәтхуллин, өендә утырган көе нәрсә хисабына яши соң ул?

– Белмим дә инде. Бәлки, элек җыйган маллары калгандыр...

Фроловның тавышы кырыслана төште:

– Шулкадәр мал җыйган элементны сез ник яклыйсыз?!

– Якламыйм, сез нәрсә?! – Таһирның тамагы кипте, ләкин өстәлдәге графиннан су салып эчәргә җөрьәт итмәде. – Без аны катгый игътибар үзәгендә тотабыз, колхозга керергә, малларын безгә тапшырырга күндерербез кебек...

– Күндерерсез кебек?!

– Әйе. Аңлыйсызмы, мулланың барыбер авыл халкы арасында дәрәҗәсе зур, сүзе үтә. – Таһир аклану өчен сәбәп табуына шатланып куйды, үз-үзенә ышанычы кайтты. – Колхоз әле аякка гына басып килә, халыкны котыртмасын, фетнә чыгармасын дип ашыкмыйча, акрынлап сөйләшү алып барабыз.

– Алай икән... – Фролов беренче секретарьга борылды. – Андый дәрәҗәле кеше булгач, Фәтхуллин урынына Тимерхановны колхоз рәисе итеп куярга кирәк.

Таһир янә шабыр тиргә батты, ул үзен якларга ашыкты:

– Юк, сез мине дөрес аңламадагыз! Кеше котыртырга мөмкин дип кенә әйтүем...

– Иптәш Фәтхуллин, Тимерхановларның язмышы хәл ителгән инде, юкка сүз көрәштереп утырасыз, – диде Фролов, кулындагы папканы ябып куеп.

– Минем бер генә үтенечем бар, иптәш өлкән лейтенант.

– Тыңлап карыйк.

– Мулланың гаиләсенә тимәсәк иде. Аның хатыны белән кызының гаебе юк дип беләм. Алар мулла сүзеннән чыга алмый, шуңа гына колхозга керми торалар. – Таһир алдашуга күчүен үзе дә сизми калды. – Мин аерым-аерым хатыны белән дә, кызы белән дә сөйләштем, икесе дә колхозга керергә риза. Мулланың нинди кырын эшләрдә катнашуын белмиләр. Әгәр алар колхозга керсә, икесен дә калдырып булырмы икән?

Фролов янә папканы ачып, бер андагы кәгазьләргә, бер Таһирга карады. Аның карашыннан Таһир куырылып килде. НКВД вәкиле янә беренче секретарьгә борылды.

– Мулланың кызына унбиш яшь. – Фролов та, беренче секретарь дә нәрсәдер белгән төсле елмайдылар.

– Иптәш Фәтхуллин – безнең ышанычлы кешебез. Үзенең совет властена тугры булуын канлы бәрелешләрдә, революциянең беренче елларында ук раслаган кеше, – диде беренче секретарь. – Шуңа күрә аның бу зур үтенечен мөмкин булганча исәпкә алып, мулланың хатыны белән кызын калдырырга тәкъдим итәм. Иптәш Фәтхуллин җаваплылыгында, әлбәттә.

Фролов дәшмәде, папканы өстәлдән алды да:

– Иптәш Фәтхуллин, иртәгә сигездә сезне үземдә көтәм, – дип саубуллашып чыгып китте. Таһир исә беренче секретарь белән хуҗалык эшләре турында сөйләшергә калды.

Таһир авылга кайткач та, төне буе йоклый алмый чыкты. Иртәгә НКВД вәкиле янына барасы, анда тагын ниләр сорарлар? Мулла гаиләсе, җавапсыз хисләре колхоз рәисен авыр таш сыман куркыныч чоңгыл төбенә өстери. Йокыга киткәч, сәер бер төш күрде.

Караңгы базда утыра, имеш, Таһир. Баз тирән һәм салкын. Ул, торып басып, аның җир диварларын капшады. Чыгарлык түгел, кул белән тотынырлык та урын юк. Шулай капшана торгач, Таһир артында гына кыштырдаган тавыш ишетте. Борылып карагач, биредә ялгызы түгеллеген аңлады. Базның икенче читендә кемдер чүгәләгән. Йөрәге куркудан ярылырга җитсә дә, Таһир:

– Син кем?! – дип сорарга көч тапты.

– Исәнме, Таһир! – Теге бәндә тәмәке кабызып җибәрде. Шырпы яктылыгында аның иңнәренә кадәр төшеп торган озын кара чәчләре, уттай янып торган күзләре абайланды. – Мин – ул син.

– Ничек инде алай?!

– Менә шулай.

– Без кайда соң?!

– Базда. Әлегә тирән түгел ул баз, ләкин тирәнәя бара.

Аның сүзләрен раслап, урта бер төштән җир каядыр түбәнгә убыла башлады. Таһир, коты чыгып, баз диварына елышты.

– Моннан ничек чыгабыз соң? – диде калтыранган Таһир.

– Әлегә баз авызы капланмаган.

Чыннан да, өстә яктылык күренде.

– Миңа нишләргә кирәк?!

– Моннан кеше өстенә менеп кенә күтәрелергә мөмкин, Таһир...

– Нинди кеше? Синнән башка беркем дә юк бит?!

– Мин сиңа ярдәм итә алмыйм, чөнки син ул мин дип әйттем бит. Башка кешене табарга кирәк, юкса икебез дә упкын төбенә очабыз.

Теге бәндә юк булды. Җир убылудан туктамады. Таһир, каты кычкырып уянып китте.

Икенче көнне иртән НКВД вәкиленә килгәндә, бөтен тәне авырта иде. Йокысызлык галәмәте, башы да шаулап авырта. Ятканчы салган да иде...

НКВД хезмәткәре озак сөйләшеп тормады. Ул аңа документ сузды. «Мин, Таһир Солтан улы Фәтхуллин...» дип башланган кәгазьдә Хәмидулла мулланың явызлыклары тасвирланган. Ул фетнә әзерләгән, өендә кулак-мулла калдыкларын җыеп котыртып яткан, кораллар сатып алырга керешкән. Ике кәгазь биткә тузга язмаган нәрсәләр теркәлгән иде.

– Миңа нишлисе? – диде Таһир, тәмам куркуга калып.

– Кул куегыз, иптәш Фәтхуллин. Калганы безнең эш.

– Ләкин бит...

– Нәрсә ләкин?! – Фроловның тавышына яман ачу чыккан иде.

– Юк. Каләм бирегез. – Таһир калтыранган куллары белән кәгазьне имзалады.

– Бүгенге числоны куегыз.

Таһир карышмады. Фролов яныннан чыгып киткән чакта ул инде тынычланган, хәле кайткан иде. Бөтен мулла-поплар сөрелгәндә, Хәмидулла гына калмас. Монда Таһирның бер генә гаебе дә юк. Заманага яраклашмасаң, үзең дә бетәсең. Хәмидулла үзгәрергә теләмәде. Таһир бу системадагы вак бөртек кенә. Шулай уйлап, ул үзенең намусы чисталыгында акланып, МТСтагы танышлары янына аракы эчәргә китеп барды.

Авыл читенә күченүне Хәмидуллага күрергә насыйп булмады. Көннәрнең берендә аларның йорты каршына кара машина килеп туктады. Аның эченнән өч хәрби һәм Таһир чыкты. Таһир югалып калган кыяфәттә, бу вакыйгада катнашу аңа ошап бетмәве сизелә иде. Шулай да ул хәрбиләрдән калышмады.

Тегеләр өйгә ишекне шакымый гына керделәр.

– Тимерханов! – дигән тавышка өйдәгеләр сискәнеп куйды. Хәмидулла мулла керүчеләрне каршыларга ашыкты.

– Мин булам, исәнмесез, – диде ул, формадагы кешеләрне күргәннән эсселе-суыклы булып.

– Җыеныгыз, сезгә безнең белән бергә китәргә туры киләчәк.

Ишек катында күзләре чыланган Нәсимә, янәшәсендә менә-менә елап җибәрергә әзер Зөбәйдә күренде. Хәмидулла аларның икесенә дә күз кысты, мөмкин кадәренчә елмайган итте.

– Борчылмагыз, тиздән кайтам, гаебем юклыгын беләсез бит... Нәсимә, зинһар, үзеңне сакла, көчле бул. Кызым, син әниеңә булыша күр.

Ике хәрби, ишектәге хатын белән кызны чак кына төртеп җибәреп, олы якка атладылар, өстәл тартмаларын, китап киштәләрен актарырга керештеләр. Урын-җирләрнең дә асты өскә килде. Аерым бер чемоданга кайбер китаплар, ниндидер кәгазьләр салына барды.

Нәсимә, кызына урамга чыгып торырга кушып, иренә юлга җыенырга ярдәмгә ашыкты. Хәмидулла янына иелгәч, тегесе хатынының калтыранган кулын тотып алды.

– Сиңа дулкынланырга ярамый, тынычрак бул...

– Бибисара карчык малай булыр диде. – Нәсимә пышылдап әйтте дә, янә тыела алмый еларга кереште.

– Бар, үзең дә урамга чыгып һава сулап ал, мин һичшиксез кайтырмын, яме?! Зөбәйдәне, туачак улыбызны сакла.

– Җәһәтрәк кыланыгыз! – дип кычкырды хәрбиләрнең башлыгы.

Өйдә табылган кайбер китапларны җыештырып, ике хәрби ике яктан озаткан килеш, Хәмидулланы урамга алып чыктылар. Мулла йорты тирәсенә шактый кеше җыелган иде.

Кара машина янына килгәч, ул янә баласы белән хатынына борылды. «Мин сезне яратам», – дип, тавышсыз гына ироннәре белән әйтте дә хәрбиләр белән бергә арткы урынга утырды. Машина кузгалгач та,

борылып карады. Тузан өермәсе артыннан елый-елый, кызы Зөбәйдә йөгерә иде...

Машина туры Казанга юл алды. Биредә Хәмидулланы баштанаяк тикшерделәр, фоторәсемгә төшерделәр һәм төрмәнең халык белән шыгрым тулы камерасына кертеп тыктылар. Биредәге кешеләрне күздән кичергәч, ул һәммәсеннән дә аңкып торучы курку һәм өметсезлек хисен аермачык тоемлады. Араларында кыйналганнар да җитәрлек. Хәмидулла буш урынга килеп утырды.

– Кайдан син? – дип сорады өске нарадагы тоткын.

Хәмидулла кайдан икәнлеген әйтте.

– Һөнәрең бармы?

– Мулла мин.

– Ә, мулла... – Тоткын уйланып торды. – Сиңа кадәр генә ике попны алып чыгып киттеләр, шуннан бирле күренгәннәре юк.

Камерада янә тынлык урнашты. Хәмидулла ятып, бераз ял итәргә карар кылды. Арыганлык үзенекен итте – йоклап киткәнен сизми дә калган. Ул үзенең фамилиясен кычкырган тавышка сискәнеп уянды.

– Тимерханов! Тикшерүче янына!

Аны, озын караңгы коридор буйлап алып китеп, кечкенә генә бер бүлмәгә керттеләр. Тикшерүче симез йөзле нурсыз бер бәндә булып чыкты. Ул өстәл артында утыра. Хәмидулла басып торган килеш калды.

– Тәәк, Тимерханов, – тикшерүче өстәлдән бер папканы тартып чыгарды, андагы кәгазьләрне актарырга кереште. – Сез үзегезнең Троцкий яклы оешмада әгъза булып торуыгызны, террорчылык оешмасында катнашуыгызны таныйсызмы?

– Иптәш тикшерүче...

– Мин сиңа иптәш түгел, – дип, тупас бүлдерде тикшерүче.

– Кем дип эндәшим соң сезгә? – Болай да башы каткан Хәмидулла бөтенләй аптырап калды.

– Гражданин тикшерүче.

– Гражданин тикшерүче, мин бернинди оешмада да катнашмадым.

– Ә менә... – тикшерүче, бер бармагын төкереклəп, папкадагы кәгазьләрне актарырга кереште, кирәген тартып чыгарды. – Ә менә иптәш Лысков сезне атады.

– Ниткән Лысков тагын? Мин андый кешене бөтенләй белмим...

– Белмисең, әлбәттә, шуның өчен яшерен оешма бит инде ул. Ул белә, син аны белмисең. Бирегә эләккәч, беркем дә берни дә белми. Беләсезме, гражданин, ихлас күңелдән әйтелгән дөреслек җәзаны киметә, шуңа күрә...

– Минем бернинди гөнаһым да юк!

– Сезгә гражданин Тимерханов Сәгыйдулла танышмы?

Хәмидулла дерт итеп куйды. Сәгыйдулланың бу хәлләргә ни катнашы бар икән? Аның аркасында ул бирегә килеп эләктеме әллә?

– Таныш, әлбәттә, ул минем бертуган энекәшем.

Тикшерүче папкадан икенче бер кәгазьне тартып чыгарды. Хәмидулланың тез буыннары калтырана башлады, ул ньк тирләп чыкты. Тикшерүченең кулында Сәгыйдулланың соңгы хаты иде.

– Кайда ул хәзер?

– Белмим...

– Башка хатларын юк иттегезме?

– Юк.

– Ул чит илдән торып, совет хакимиятенә каршы нинди эшчәнлек алып бара?

– Бернинди эшчәнлек тә алып бармый, бу аның соңгы хаты, унҗиденче елдан бирле бер хәбәре дә юк.

– «Абый, күңелем сизә, бу кабахәт большевиклар минем башыма җитәчәк», – дип, тикшерүче Сәгыйдулланың хатыннан бер юлны кычкырып укып бирде, аннан карашын янә Хәмидуллага күтәрде. – Димәк, без кабахәт большевиклар, шулаймы?!

– Гражданин тикшерүче, мин энекәшемне соңгы тапкыр революциягә кадәр күрдем. Аның хәлләре турында хәбәрдар түгелмен. Ул вакытта Петроградта ниләр булганын, энем нәрсә өчен большевиклар белән сүзгә керүен белмим.

– Аңлашылды... Ничек әйтәләр әле сездә? Белмимнең башы авыртмый, диләрме? Хәлләрегез бик хөрти, гражданин Тимерханов. Иртәгә кадәр уйларга мөмкинлегегез бар. Конвой, алып китегез!

Икенче көнне аны янә чакыртып, троцкистлар яклы оешмада террорчылык эшчәнлеге алып барганлыгын таныган кәгазьгә кул куюын таләп иттеләр. Хәмидулла килешмәде. Карцерда ике көн яткырдылар. Янә теге кәгазьне күрсәттеләр. Хәмидулла кул куймады. Каты гына итеп кыйнадылар. Бөтен тәне күгәреп чыкса да, Хәмидулланы сындыра алмадылар. Ахыр чиктә гаепләү аның имзасыннан башка да расланды. Мулла әлеге «документ» белән танышып чыккач та, тикшерүчегә барысы да ялган икәнлеген әйтте.

– Ялганмы-юкмы, анысын син дә, мин дә хәл итмим. Мәскәүдә барысын да аңлатырлар үзеңә, – диде тегесе, тагын бер эшне ябуына шат булуын яшермичә.

Хәмидулланы этап белән Мәскәүнең Лефортово төрмәсенә алып килделәр. Казандагы изолятордан соң бу урын җәннәт сыман тоелды. Биредә судка кадәр үз чиратыңны аерым камерада көтәсе, анда хәтта урындыклар да бар.

Озак утырырга насыйп булмады – Тимерхановны ике конвоир алып китте. Суд бүлмәсенә барганда, Хәмидулла барлык белгән догаларын укыды, яшүсмер кызы, әле дөньяга туарга гына торган баласы, хатыны хакына үзен азат итүне, хакыйкатьнең мәкер-ялганнан өстен чыгуын сорады.

Бүләмәгә керделәр. Конвой ике ягына басты. Озын өстәл артында өч хәрби утыра. Янәшәдә генә секретарь. Югары судның хәрби коллегиясе шуннан гыйбарәт.

– Гаепләү белән килешәсезме? – дип сорады судья. – Юкмыни? Ләкин биредәге шаһитлар киресе хакында сөйләгән.

– Мин аларның берсен дә белмим.

– Кәгазьгә басылган сүзләргә каршы барып булмый. Алар, ихлас күңелдән гаепләрен танып, сезгә күрсәткәннәр. Үз тирәгездә кулакларны, муллаларны туплагансыз, өегездә яшерен җыелышлар үткәргәнсез. Оешманың башында кемнәр торганлыгы да язылган.

– Мин бернинди оешмада да катнашмадым.

– Аңлашылды. – Хөкемдар нәзек кенә папкадагы кәгазьләрне караштыргалады. – Әһә, чит илдәге энекәшегез белән тыгыз элемтәдә торасыз. Ул нинди эшчәнлеккә өнди?

– Бернинди эшчәнлек тә алып бармыйбыз, минем аның белән унҗиденче елдан бирле күрешкән дә, язышкан да юк.

– Суд киңәшмә залына китә, – диде уртадагы хәрби урыныннан торып, аңа калган икесе дә иярде.

Озак киңәшләшмәделәр, биш минут та үтмәгәндер, кире чыктылар. Хәмидулланың соңгы өмете өзелде. Бер басма биткә сыйган суд карары нигезендә аны Җинаять кодексының 58 маддәсенең 8 нче пункты буенча террорда гаепләп, ун елга ирегеннән мәхрүм итәләр.

Йа Хода! Әгәр исән калса, төрмәдән чыга алса, ул инде картаеп беткән бер авыру кеше булачак! Ул кыяфәттә туганнары янына кайтып, ничек күзләренә күренер?! Ун ел! Ул кызының ничек итеп үсеп җитүен, улының дөньяга тәүге тапкыр аваз салуын беркайчан да күрмәячәк! Нинди гөнаһлары өчен аңа мондый сынаулар җибәрелә?!

Хөкем карарын Хәмидулла хәзрәт бик авыр кичерде. Укыган догалары да тынычландыра алмый, күз алдыннан боегып, кечерәеп калган Нәсимәсе, машина артыннан елый-елый йөгерүче кызы китми. Бу хатирәләр җанын әрнетә, башка нәрсә турында уйланырга мөмкинлек калдырмый. Камерага кертелүче үзе кебек мескеннәрне дә күрми. Әмма вакыт узу белән тынычланып, Хәмидулла хәзрәт үзен кулга алды. Күңел төшенкелеген җиңәргә кирәк иде аңа. Бирешергә ярамый. Ул исән-имин кайтачак, гаиләсе янәшәсендә булачак, һәм моңа берни дә комачаулый алмаячак! Гарип калсын, гомере генә өзелмәсен. Өендә аны барыбер көтеп торачакларына бер генә дә шиге юк. Кайткан төшенә Нәсимә генә түгел, кечкенә улы Хәбибулла да үскән булыр. Бер Хәмидулла гына түгел, илдәге күпме халык аның төсле авыр язмышка дучар ителде бит. Ул алардан артык та, ким дә түгел. Бирешмәскә, сабыр, акыллы булырга кирәк!

Этап белән Ак диңгез буена данлыклы канал төзелешенә китеп барганда, Хәмидулла ачы язмышына тулысы белән буйсынган иде инде...

***

Хәмидулланы озату кайгысы бераз булса да таралырга өлгермәде – әниле-кызлы Тимерхановларны яңа гарасат көтә иде.

Алардан сорап тормый-нитми, йортларына берничә колхозчы килеп керде.

– Нәсимә, җыеныгыз, сезне авыл читенә күчерәбез, – диде ир-егетләрне иярткән Фазылҗан. – Колхоз идарәсе карары. Амбарыгыздан өй әмәлләп бирербез, мич чыгарырга ярдәм итәчәкбез. Калганы колхозга тапшырылачак.

– Һай Аллам, – дип, Нәсимә егылып китә язды. Зөбәйдәсе булмаса, җиргә дә барып төшкән булыр иде. Ул янә үзендә ниндидер көч чыганагы тапты, кызын ияртеп кереп, чүпрәк-чапрак, савыт-сабаны җыештырырга кереште.

Амбарны бик тиз күчерделәр. Авыл халкына рәхмәт, тәрәзә дә уеп бирделәр, мичен дә чыгардылар. Нәсимә белән Зөбәйдәгә бары тик кирәк әйберләрне генә алырга кушылды, аларын Таһир әмере буенча Фазылҗан исәпләп торды.

Күченеп урнаштылар да кебек. Бер тәрәзәле бу кечкенә йортта тузан катыш көрпә исе килеп тора иде. Шулай да, ана белән кыз аңа бераз булса да нур иңдерә алды. Тәрәзәне чигүле эленге белән капладылар, сәкедәге мендәрләр дә чәчәкле япмалар белән матурлап бизәлде. Барысы да урынында кебек. Хәмидулла гына юк...

Күченгәннән соң бер атна үткәндер, Нәсимә кинәт кендек тирәсендә авырту сизде. Хәле китеп барып утыргач, оят җиренең юешләнүен тойды. Аннан кан саркый иде. Нәсимә барысын да аңлады.

– Кызым, – дип ыңгырашты ул. – Бар, йөгереп кенә Бибисара аптыеңны чакырып мен әле.

Ул кичтә Нәсимәнең карынындагы баласы төште. Залимнәргә ләгънәт укый-укый Нәсимә елап чыкты. Аннан тынычланды. Күрәсең, Ходай насыйп итмәгәндер. Барысы да язмыш кулында. Тормыш китабыңа язылганнан узып булмый. Бәлки, баланың бу әшәке дөньяга килми калуы аның өчен яхшырактыр да. Ходай аны зур афәтләрдән, гарасатлардан саклар өчен шулай карар кылгандыр...

Нәсимә белән Зөбәйдә колхозга керде. Тормышларын бер җайга салдылар. Нәсимә вакыты тигән саен район үзәгенә барып, төрле ишекләрне шакыды, иренең язмышын белергә теләде. Райкомда аны инде танып бетергәннәр иде. Шактый вакыт узганнан соң гына, иренең ун елга хөкем ителеп, лагерьга озатылуын хәбәр иттеләр. Нәсимә бу хәбәргә шатланды. Димәк, исән. Монысы иң мөһиме. Кайда җибәрелүен, нәрсә эшләвен әйтмәделәр. Сәер һәм аңлаешсыз адрес буенча сирәк кенә хатлар язарга, посылкалар җибәрергә мөмкин иде. Беренче хатында ук Нәсимә иренә кыска гына итеп, сүз арасына кыстырып: «Хәбибулла килә алмады» дип язды. Ире аңлаячагын белә иде ул...

***

Сәкинә заводтагы төнге сменадан тәмам йончып кайтып, коммуналь фатирларындагы кысан бүлмәгә кереп, өсләрен салды. Улы Хәмит әле йоклый, мәктәпкә киткәнче аңа иртәнге аш әзерләргә кирәк булачак. Күмәк кухняга чыгып, Сәкинә чәйнекне куеп җибәрде, тиз генә өч йомыркадан тәбә кыздырды. Аннан, чәйнек белән табаны алып, бүлмәгә кереп, улын уятты.

– Тор, улым, мәктәпкә соңга каласың.

Хәмитнең җылы урыннан тиз генә торасы килмәде. Тик теләгең бармы-юкмы, мәктәпкә барырга кирәк шул. Юынып кергәч тә, алар икәүләп, табынга утырдылар.

– Әни, мин мәктәпне тәмамлагач, хәрби училищега керергә булдым, – диде кинәт Хәмит.

Сәкинә телсез калды. Ничек инде хәрби училищега?! Бер бөртек баласын армиягә бирергәме?! Ләкин үзсүзле улы белән алай сөйләшеп булмый шул. Бераз фикерләрен туплап, ул гаҗәпләнмәгән кеше сыман гадәти тавыш белән генә җавап кайтарды:

– Хәрби хезмәтнең ни икәнен беләсеңме соң син, улым?

– Беләм һәм минем шул хезмәткә барасым килә.

– Ай-һай, улым, анда табын әзерләп көтеп торучы әниең булмас шул...

– Беләм, әни.

– Анда баручыларны ныклап тикшерәләр дип ишеттем...

Кинәт ашаудан туктап, Хәмит әнисенә текәлде:

– Әни, ә минем әти, чыннан да, үлгәнме?

Сәкинә чак кына елап җибәрмәде. Тик сер бирмәскә тырышты.

– Күптән мәрхүм улым, күптән, унҗиденче елда урам бәрелешләрендә һәлак булды әтиең.

– Ә без нигә беркайчан да аның каберенә бармыйбыз?

Еллар буе ялганларга өйрәнеп беткән Сәкинәнең моңа да җавабы әзер иде. Күңеленнән кан саркыса да, ул төннәр буе ятланган әкиятен кабатларга керешә:

– Урам бәрелешләреннән соң безне мәетләр янына җибәрмәделәр. Аларны барысын бергә төяп китеп, бердәм каберлеккә җирләгәннәр, кайдалыгын безгә әйтмәделәр. Йә, ярый, мәктәбеңә соңга каласың.

Тик Хәмит төпченүдән туктарга уйламады да:

– Әни, ә нигә син безнең әти турындагы мәгълүматны архивлардан эзләмисең?

– Чөнки, улым, шулай кирәк, – диде, кинәт кырысланып Сәкинә. – Артык күп сораулар бирә башладың әле. Әйдә, чәеңне эчеп бетер дә мәктәпкә йөгер!

Хәмит башка сораулар белән аптыратмады. Улы инде буй җиткән, егет булган, һәм үсә төшкән саен аны алдалап тору кыенлаша бара. Җитмәсә, елдан-ел Хәмит үзенең әтисе Сәгыйдуллага күбрәк охшый бара иде.

Әйе, Сәкинә ничәмә еллар буе улын хакыйкатьтән аралап яши. Әтисе Барый абзыйның вафатына инде шактый еллар үтте. Бакыйлыкка күчәр алдыннан, ул кызына ихлас күңелдән рәхмәтен әйтте. Кырыс, беркайчан да артыгын сөйләшмәс бу кешедән андый сүзләрне ишетү бик сәер дә, рәхәт тә иде.

– Кызым, – диде Барый абзый. – Мин синнән берни дә сораштырмадым, син миңа берни дә әйтмәдең. Сәгыйдулланың илдән качканын болай да аңладым. Син минем хакыма калдың бит. Үземне синең каршыңда гаепле тоям.

– Син гаепле түгел, әти. Сине калдырып китсәм, мин мәңге күңелемә тынычлык таба алмас идем. Бу минем үземнең карар бит. Һәм аны ялгыш дип санамыйм...

Сәгыйдуллага үпкәсе бар иде Сәкинәнең. Яшь булса да, егет кызның хәлен аңларга тиеш иде. Ничек инде ул урамга да чыга алмаган әтисенә бер уч акча тоттырып, билгесез якка китеп югалсын?! Алар, ни кызганыч, икесе ике дөнья кешесе. Берсенең уенда малы белән җанын коткару, икенчесендә яраткан кешесе өчен гомерен фида кылырга әзер тору. Бизмәнгә салып үлчәп торырга да кирәкмәде – Сәкинә әтисен беркайчан да ташламаска сүз биргән иде, шул сүзендә торды.

Бүген ул заводта хезмәткәр, коммуналь фатирда яши, улы үсеп килә, дөньясы түгәрәк кебек. Ә Сәгыйдулла... Сәгыйдулла барыбер яңа тәртипләрдә яши алмас иде. Шуңа аның качып китүе барчасы өчен дә яхшыга гына булгандыр...

Улын мәктәпкә озаткач, Сәкинә йокыга талды. Чираттагы хезмәт сменасы алдыннан хәл алырга кирәк.

***

Хәмидулла салкыннан өшеп уянды. Чатнама суык көннәр торган чак. Быел озаккарак та сузылды бугай, каһәр. Җитмәсә, баракта дежур торган латыш Эрнест янә йоклап киткән. Аңа ышаныч юк шул, начарлыгы белән түгел, яшьлеге белән, бичара, иң кирәкле мәлне йокыга чума. Хәмидулла башта, урыныннан кузгалмый гына, пышылдамый-нитми, иртәнге намазын укыды. Тәһарәт алу, намазлык, кыйбла төшенчәләре күптән онытылды инде. Ул менә шулай көнгә биш мәртәбә, йә яткан җирдән, йә аяк өсли эшләгән килеш, йә ял итәргә утырган вакытта күзләрен йома да авыл мәчетен хәтеренә төшерә. Менә ул чалма-чапаны белән мөнбәр янына килә, Бохарадан алып кайткан намазлыгын җәя һәм намаз укырга керешә. Намаз вакытлары туры да килмидер, аны кояшка карап чамаларга маташа маташуын. Тик бу якларда кояш үзгә шул, туган яктагы төсле түгел. Аннан соң, иртән йә кичен яктымы-юкмы икәнлеген белеп тә булмый. Баракта тәрәзәләр юк, җылы чыкмасын өчен кышка тоткыннар аларны үзләре үк томалап бетерә. Ашаган ризыгы да гел хәләл түгел. Анысын да белә Хәмидулла. Ләкин яшәргә кирәк аңа. Көнгә биш вакыт намазны шулай күзне йомып, хәтердә генә булса да укырга. Чөнки аның әле туган якка кайтасы бар. Аны авылда хатыны, кызы көтә. Шөкер, аларны Хәмидулла белән бергә сөрмәделәр. Ә хатынының сабый бала белән бу шартларда исән калуы, ай-һай... Күңелен нык тырнаганы – бу дөньяга аваз сала алмый калган улы Хәбибулла. Аңа исән-сау туып, үсеп, муллалыкта хезмәт итәргә насыйп булмады...

Һәр җомга көнне Хәмидулла күзләрен озаккарак йомып тора. Авыл халкына вәгазь сөйли ул... Атнага бер һәрбер ир-атны күз алдына китерә, һәрберсенә кирәкле сүзен әйтә сыман. Хәтта аны юк итәргә йөргән кешеләрне дә үзенең күңелендәге җомга намазыннан калдырмый Хәмидулла. Чөнки ул бер нәрсәне бик яхшы белә – болар барысы да вакытлыча. Барысы да үтәчәк. Гаделлек киләчәк. Һәм акыллы, сабыр булса, Хәмидулла ул якты көнне дә күрәчәк.

Авылдан хатлар ике айга бер килә. Аннан ешрак ярамый. Хатыны Нәсимә беркайчан да зарланмый, дөньялар әйбәт, тормышлар яхшы, ди. Лагерьдагы бөтен кешенең дә хатыннары, туганнары шулай дип язалар, әйтерсең, барысын бергә мәдрәсәгә җыеп утыртып әйтеп торып яздыралар. Дөрес, кара буяу белән буялган урыннар да булгалый. Анысын буяп куюлары өчен совет хөкүмәтенә рәхмәт. Якыннары өчен болай да үзәкләр өзелә, аларның да моң-зарын укыса, түзәр әмәл калмас иде...

Иртәнге намазын тәмамлап, Хәмидулла урыныннан торды һәм барак уртасында торган тимер мич янына килде. Буржуйка өстендә чыралар, такта кисәкләре ята. Аны тоткыннар үзләре җыеп алып кайталар, эшләгән урыннан. Тимер мич өстенә куеп киптергәч кенә утка ташлыйлар. Юкса, юеш агачтан баракка төтен тулачак. Хәмидулла, чүгәләп утырып, инде сүнә башлаган учакны тергезеп җибәрде. Эрнест үз урынында йоклап киткән. Яше егермегә җиткәнме икән бу баланың? Аларның отрядында Эрнест – иң яше. Күптән түгел генә китерделәр. Сталин турында мәзәкләр сөйләгән, имеш. Хәмидулла янә латыш егетенә күз салды. Кызлар да кочарга өлгермәгән бу егетнең башында нинди Сталин булсын икән ул?!

Мәзәген дә шул кызык булган өчен генә сөйләгәндер. Телдән-телгә йөреп, Эрнестка кадәр килеп җиткән икән, димәк, аны шактый кеше белә. Мәзәк белән хакимлекне бетереп була, димени?!

Хәмидулла тимер буржуйка тирәли тезелгән өем арасыннан үзенең итекләрен аралап алды. Хәзер отрядны аякка бастырырга тиешләр. Бусы инде ничә ел дәвамында канга сеңгән, лагерь уртасына эленгән рельс кисәген кага башлауларын күңел шомланып көтә, көнгә берничә мәртәбә колаклар ишетсә дә, һаман беренче тапкыр төсле сискәнеп куялар. Аның сүзләрен куәтләгән төсле урам яктан тимер чыңы яңгырады. Тоткыннар, ахылдый-ухылдый, урыннарыннан тора башладылар. Куркынып, Эрнест та уянды, ләкин буржуйкада ут януын күргәч тынычланды. Хәмидулла эчтән генә елмаеп куйды. Итекләрен киеп, җылы киемнәргә үрелде, ике кат бияләен, бүрекне эләктерде. Бригадир Николай, нык, таза гәүдәле кеше, ишек төбенә килеп басып, тоткыннарга борылды.

– Нәрсә, егетләр, җылындыгызмы? – диде ул, көрәк сакалын сыпырып.

– Җылынырсың монда, әле генә йокларга яткан төсле, – дип мыгырданды Сашка исемле тоткын. Ул теләсә нәрсә уңаеннан зарланырга ярата иде.

– Эрнест шәп яккан, сөякләргә кадәр үтте, – дип шаркылдады икенче берсе.

– Нәрсә, суык үттеме? – диде Николай, бер Эрнестка, бер Хәмидуллага ниндидер сер белгән кыяфәт белән карап. Эрнестның буыннары чак кына сыгылып төшмәде. Хәмидулла исә Николайга күз кысты. Бригадир шәп кеше, күргән булса да, Эрнестның йоклап киткәнен беркемгә дә әйтмәячәк. Ә Эрнест инде гаебе ачылуын бер караштан аңлады. – Суык булса, егетләр, утынны күбрәк алып кайтырга кирәк. Кай җирегезгә кыстырып алып керүегез миңа мөһим түгел, утын булмаса катып үләбез.

– Бетәме инде бу кыш, – дип, янә мыгырданды Сашка.

Урамга чыгар алдыннан берәр мәгънәсез сүз чәйнәү – Николайның көндәлек гадәте. Хәмидулла аның асылына төшенде инде – уянмаганнарны уятыр, аңсызларны аңга китерер өчен шулай итә ул. Ләкин һәрбер мәгънәсез сөйләшүне әнә шундый нәсыйхәт, утын алып кайтыгыз сыман күрсәтмә белән җөпли белә. Шәп вәгазьче чыгар иде моннан, мөселман мулласы булса!

Дөбердәп, ишекләр ачылды, караңгы коридорда конвой күренде.

– 3 нче отряд, коридорга чыгыгыз!

Бу – шул ук намаз шикелле көн дә кабатлана торган шөгыль иде. Менә аларны тезеп бастырдылар, санадылар, аннан-моннан тентегән иттеләр.

– Авырулар бармы?

Отряд дәшмәде.

– Ишеккә атлагыз.

Хәмидуллалар отряды юлга кузгалды. Алар артыннан күрше баракның ишекләре ачылды, коридорга дүртенче отрядны чыгардылар.

Баракның төп ишегеннән чыгуга Хәмидулланың битенә чатнама суык китереп сукты. Иртәнге йокының эзе дә калмады. Урамда әле караңгы иде. Биек наратлар белән әйләндереп алынгангамы, бирегә яктылык та үтеп керми төсле, ап-ак кар да кап-кара шикелле. Сирәк-мирәк төшкән утларда кар көртләре ялтырый. Димәк, тагын суык булачак, көндез кояш та чыкса, тәмам өшетәчәк инде.

Хәмидулла тирә-юньгә күз салды. Агачлар белән уратып алынган урман аланы. Ул бүрәнәләрдән өелгән блоклы бараклар белән тулган. Күбесе – тәрәзәсез-нисез. Болары – тоткыннар торагы. Биегрәк, субайда утырганнары исә конвой биналары, хуҗалык корылмалары. Көрәк-сәнәк, балта ише нәрсәләр дә биредә субайлы биналарда саклана. Ә сөрелгәннәрне исә җир идәнле баракларда черетәләр. Бараклардан бер-бер артлы отрядлар чыга тора. Йа Хода! Барлык бу кешенең күңелендәге рәнҗеш-газабын җыйсаң, тәмуг утына ничә елга ягулык җитәр икән! Аларның күз яшендә күпме залим батып үлә алыр иде! Күпме ботарланган язмыш, сөяккә ябышкан тире астындагы җанын күкрәгенә кысып, таушалган кием-салым киеп, чүпрәк-чапракка уралып, бөкре җилкәсендә нахак йөген тарта!

Хәмидулла, гадәттә, уйламаска тырыша бу хакта. Уйлагач, күңелгә авыр, вакыт та алай озаграк узган төсле. Уйламасаң рәхәт. Ләкин уйламыйча булмый.

Иртәнге аш дигәннәре су тулы тәлинкәдән гыйбарәт иде. Хәмидулла, суны чөмереп бетергәч, тәлинкә төбендә ниндидер вак балык сөякләре, ике өшегән бәрәңге кисәкчеге һәм кашык очына сыярлык ярма да тапты. Башкаларның да ашы аныкыннан шәбрәк түгел иде. Алардан соң килгәннәргә куерак булырга мөмкин, ләкин анысы да сирәк була торган хәл.

Ашны ашап бетергәч, Хәмидулла үз кулы белән уеп ясаган кечкенә агач кашыгын яхшылап кул арты белән сөртте дә итек балтырына тыгып куйды. Әбәтне эш урынына алып киләчәкләр. Тәлинкәләр барысына да җитмәс, билгеле, ә менә кашыклар бөтенләй дә юк, үзеңнеке булмаса – беттең. Ипигә Хәмидулла бөтенләй кагылмады, кесәсеннән кулъяулык чыгарып, валчыгы да коелмаслык итеп, кадерләп төрде һәм бишмәтенең күкрәк астына, йөрәк янында махсус тегелгән кесәгә тыгып куйды. Янәшәсендә Эрнест ипиен ашап бетереп, өстәлдән валчыкларын чүпләп утыра иде. Гадәттәгечә, әбәттә аның белән дә ипине бүлешәчәк Хәмидулла. Төзелеш алып барылган төшкә икмәкне аз алып киләләр, ул тәлинкәләрдән дә кимрәк, ярты отрядка да җитмәячәк.

Иртәнге аштан соң отрядлар, бер-бер артлы тезелешеп, конвой күзәтүендә юлга кузгалды. Менә алар лагерьның тимерчыбык белән уратып алынган киң капкасыннан чыгып, урман юлына юнәлделәр. Алдарак барган кешеләр төн караңгысында гүя урман авызына кереп югалалар, аларны кара урман ашап бетереп бара кебек. Аяк астында кар шыгырдый. Суыкта усал этләр дә өрмиләр, башларын түбән иеп, телләрен салындырмаска тырышып, тын гына конвой янында баралар. Әгәр шушы тере чылбырга тезелгән тоткыннар, дәррәү кубып, конвойга ябырылса, солдатларны бер мизгелдә тапап ташлыйлар да бит. Ләкин аннан кая барасы? Хәмидулланы өйдә көтәләр...

Урманнан чыгу өчен ярты сәгать чамасы вакыт кирәк. Аннан инде бөтенләй башка дөньяга эләккән төсле буласың. Ап-ак кар белән капланган киң даланы күз алдына китерегез. Әйтерсең, җир өшемәсен өчен аның өстенә кемдер йошмак юрган каплаган. Һәм менә шул юрганны ертып, тар гына ызан үтә. Хәер, ерактан гына тар булып күренә ул. Әлеге ызан янына килеп җиткән кешеләр аның янәшәсендә кечерәеп калалар. Ызан, әйтерсең, калын кар юрганын ертып, буйдан-буйга, офыктан-офыкка үткән,

аның очы да, кырые да күренми. Якында гына аның тирән һәм шактый киң чокыр икәнлеген абайлыйсың. Әлеге чокыр төбендә, аның ярларында, кырмыскалар төсле кешеләр йөргәне күренә. Аларның кулларында лом, кәйлә, көрәкләр. Тимер гасыр башында уйлап чыгарылган шул кораллар белән кырмыска-кешеләр туң җирне каезлап, Ак диңгездән Онега күленә кадәр су юлы салалар. Әлеге төзелеш – Беломорканал төзелеше, һәм йөзләрчә мең тоткын-төзүче арасына Хәмидулла да килеп эләкте.

Төзелеш эшләре кар-буранга, яңгыр-давылга карамый, бертуктаусыз алып барыла. Тоткыннар таң атканчы эшкә керешеп, караңгы төндә генә баракларга кайтып егыла. Хәер, бу яктан Хәмидуллалар бәхетле – алар, салкын булса да, бүрәнәдән салынган бараклардa йоклыйлар.

Хәмидулла, отрядына ияреп, чокыр төбенә юнәлде. Кичә кичтән калдырган урыннан һәрберсе үз эш коралларын эзләп тапты. Кемгәдер кәйлә, кемгәдер көрәк... Әлеге хан заманындагы әсбаплар белән туң җирне каезларга кирәк. Биредә туфрагы да туфрак төсле түгел, бераз казыдыңмы, дәү-дәү ташлар килеп чыга. Аларны күтәреп бер тәгәрмәчле агач тачкаларга саласы. Чокыр төбеннән өскә таба юнмаган такталардан тар гына сукмак көйләнгән. Көрәк-кәйлә белән эшләмәүчеләр әнә шул юлдан тачкаларны өскә таба күтәрә. Тачкаларда һәм таш каезлауда алмаш-тилмәш эшлиләр, чөнки авыр турфак яисә ташлар төялгән тачкаларны төптән өскә таба тәгәрәтү бик күп көч ала. Атнага бер-ике тапкыр кем дә булса, инде менеп кенә җиттем дигәндә, хәле китеп, чокыр төбенә мәтәлә. Хәмидуллаларның бригадасында андый һәлакәттән үлүчеләр булмаса да, шактый кеше имгәнде. Имгәнүдән бигрәк, тачкалар кызганыч – алар чокыр төбенә төшеп җиткәнче яньчелеп-ватылып бетә. Тәгәрмәче кителсә, бөтенләй дә эш харап, чөнки төзелеш җитәкчеләре алмашка яңасын бирми, зекларга аларны үзләренә төзәтәсе, үзләренә ясыйсы.

Чокыр төбендә, әйтерсең, бөтен ил халкы эшли – ул кешеләр кыймылдавыннан гөжләп тора. Каты суыклар булуга да карамастан, берәүләр туң җирне каезлый, икенчеләре исә, бетон бутап, ярларны ныгытуга керешә. Зур авырлык белән өскә күтәрелгән ташлар яр ныгытмаларына китеп бара.

Төзелештә сөйләшеп торырга вакыт юк. Биредә эшләргә дә эшләргә кирәк. Ара-тирә генә бригадир Николай, кул алмаштырырга вакыт икәнлеген белдереп, әле бер, әле икенче исемне кычкыра. Хәмидуллага бүген биш тапкыр тачка белән чокыр төбеннән күтәрелергә туры килде. Гадәттә, һәрбер тоткынга смена дәвамында шул биш-алты тапкыр тачка өлеше чыга иде, димәк, бүген дә аларның отряды норма буенча бара. Николай лагерь җитәкчеләре белән сөйләшә алса, арттырып та язарга мөмкиннәр, ә бу аларның отряды өчен өстәмә пайка, өстәмә икмәк дигән сүз.

Бирегә килгәннән бирле Хәмидуллага һаман бер уй тынгылык бирми иде – пычагыма кирәкме икән бу чокыр? Әйе, лагерь башлыклары аларга сәвит дәүләте өчен төзелешнең әһәмиятен даими аңлатып тора. Тик бу кадәр интегү, кеше гомерләре хисабына мондый эш майтарырга ярамыйдыр бит?!

Әмма совет власте икенче төрле уйлый. Төзелеш эшләре Мәскәүнең катгый игътибарында, һаман ашыктыралар, нормаларны арттыралар. Бер тапкыр хәтта алар янына Нафталий Френкель үзе дә килде.

Нафталий Френкель турында тоткыннар арасында төрле сүзләр йөри иде. Аның хакында бигрәк тә Николай кызык итеп сөйләргә ярата. Имештер, Нафталий Френкель әле егерменче елларда ук контрреволюцион эшчәнлек өчен кулга алынып, үлем җәзасына тартылырга тиеш була. Ләкин, Николай сүзләренә ышансаң, контрреволюциядә гаепләү аны тоткарлау өчен сәбәп кенә булган. Чынлыкта исә, Френкель үзенең иптәшләре белән шактый күп алтын урлаган, имеш. Үлемнән котылырга ниятләп, Френкель чекистларга әлеге байлыклар турында барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Нәтиҗәдә, үлем җәзасын Соловки утрау-лагеренда тоткынлык белән алмаштыралар. Николай сөйләгәнгә ышансаң, Нафталий алтыннарны бер генә урында яшермәгән, чекистларга ул барлык байлыкларны да күрсәтеп бетерми. Шуңа күрә Соловки лагере җитәкчелеге өчен дә өлеше калган була. Нәтиҗәдә, ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, дигәндәй, Френкелебез исән-имин килеш Соловкидан азат ителә. Алай гына да түгел, заманында үзен кулга алган ОГПУга эшкә алалар моны. Һәм хәзер Нафталий Френкель – Беломорканал төзелеше башлыгы.

Әкияткә охшаш әлеге бәянны тыңлагач, Хәмидулла елмаюын яшерә алмады:

– Николай, бу кадәр кешене сатып алыр өчен ничә вагон алтын урлаган икән ул Френкель? – дип төрттереп куйды.

– Вак җаннар вак акчага сатыла ул, Хәмидулла, – диде Николай, төртмәле сүзгә бер дә үпкәләмичә. – Әллә сезнең эш нормасы һәр көнне үтәлә дип уйлыйсызмы? Кәгазьдә үтәлә. Чынлыкта – юк. Ә нәрсә хисабына үтәлә соң ул? Сергейга әнисе җибәргән дуңгыз салосы, сиңа килгән йон оекбашлар, Павелның посылкасыннан алынган сабын – барысы да адресатларга түгел, ә шул чекистларга китеп бара. Шуның хисабына безнең тамак ягы яхшырак, эшебез җайлырак, йокыбыз тынычрак. Бер оекбашка сатылган кешеләргә вагон-вагон алтын кирәкми ул, Хәмидулла. Безнең хакимнәр артык вак, артык вакчыл...

Нафталий Френкель Хәмидуллалар эшләгән участокка күзен килде. Ул вакытта көчле яңгырлар явып туктаган гына иде. Беломорканал төзелеше пычракка, баткаклыкка чумды. Иртәгә Френкель киләсе дигән көнне лагерь пункты җитәкчеләре тоткыннарны эшкә чыгармадылар, һәрхәлдә, Хәмидуллалар яшәгән бараклардан беркем дә канал ягына китмәде. Иртәдән барысын да дәррәү кубарып бастырып, бер-бер артлы отряд-отряд мунчага алып киттеләр. Мунча дигәннәре лагерь пунктының ерак читендә урнашкан кечерәк барак иде. Отрядны аның чоланына тыгызлап куып кертеп, барысына да чишенергә кушылды. Көзнең салкын көннәре, чоланда урамдагыдай суык, ләкин әмер бирелгәч чишенергә туры килде. Киемнәрне бер урынга ташлаттылар, аннан соң отрядны мунчага куып керттеләр.

Биредә аларга кадәр ничә отряд булгандыр, билгесез, ләкин идәннәр, урамнан ияреп кергән балчыктан кап-кара төскә буялып, тайгак лайлага әверелгән. Бөтен мунчага өч кенә тагарак булганга, тоткыннарга чиратлашып коенырга туры килде. Мунчада чоланга караганда, бераз гына җылырак, ләкин косасыны китерә торган сасы ис аңкый. Ерак почмактагы краннан чак кына җылы су агып тора. Шуннан тагарагыңны тиз генә

тутырып аласың да читкәрәк китеп, кечкенә сабын кисәге белән шыр сөяккә калган тәнеңне ныклап ышкыйсың. Озак маташырга ярамый. Әледән-әле мунча ишеген ачып караучы сакчылар ашыктыра. Икенче яктан, үзләренә чират җитмәүдән куркып, иптәшләрең төрткәли. Бер тагарак су юынырга да, коенырга да. Юынгач та, икенче почмакка барып басып, бөтен отряд эшен бетергәнне көтәсе.

Мунчада кызу булмаса да, кеше күплеге, кайнар су бәрабәренә ул шактый җылынырга өлгерә. Инде юыну тәмамлангач, чоланга чыгу үзе бер җәза. Ачы салкын, әйтерсең, сине ялмап ала. Сөртенергә берни дә юк, юеш тән уттай яна.

Ул көнне тоткыннарга өр-яңа киемнәр бирделәр. Кичке аш гадәттәгедән куерак, тәмлерәк булып чыкты. Икенче көнне иртән барысын да бергә тезеп бастырып, бригадаларга бүлмичә, ишегалдына җыйдылар. Алар каршына лагерь пункты җитәкчесе чыкты.

– Каналармиячеләр! – дип кычкырды ул, һәм аның калын көр тавышы, биек наратларга бәрелеп, кайтаваз булып әйләнеп кайтты. – Бүген төзелеш эшләре үткәрмибез! Бүген сезнең өчен бәйрәм көн! Безнең участоктагы төзелеш эшләре белән танышырга дип, хөрмәтле җитәкчеләребез килә! Мин сезне алдан ук кисәтеп куям – тәртип бозучыларга, провокаторларга, сәвит хакимиятен тапларга маташучыларга карата җәза кырыс булачак, шуңа үзегезнең ни эшләвегезне, ни сөйләвегезне чамалагыз, яхшылап уйлагыз. Бөтенләй сөйләшмәсәгез, тагын да яхшырак. Хәзер без сезнең белән тантаналы митингка барачакбыз. Колонналарда бару тәртибе гадәти көннәрдән берни белән дә аерылмый, тик бүген бишәрләп басарсыз. Уңга-сулга адым ясаучыларны кисәтүсез атачакбыз. Конвой, киттек.

Лагерь пунктындагы тоткыннар, әмергә буйсынып, таныш юлга кузгалды. Конвойга барлык сакчылар да диярлек чыгарылган, хәтта дүрт каланчада утыручыларны да җиргә төшергәннәр. Ике сакчының берсе эт белән. Мылтыклары аркага асылган.

Кораллы солдатлар белән әйләндереп алынуларына да карамастан, тоткыннар арасында бәйрәм рухы хөкем сөрә иде. Беренчедән, уйламаган-көтмәгән җирдән ике көн ял бирделәр. Икенчедән, таушалып-ертылып беткән киемнәр урынына яңаларын, чисталарын тараттылар. Аларны киеп куйгач, тоткыннарга түгел, фабрика хезмәткәрләренә охшап калган төсле булдылар. Сөяккә калган куллары, төпкә баткан күзләрен исәпкә алмасаң, лагерь тоткыннары, димәссең дә. Һәм, әлбәттә, һәрвакыт ач йөргән каналармиячеләр өчен тәүлек пайкасын бераз гына булса да арттыру чын мәгънәсендә зур вакыйга иде. Кайберәүләр ашларында хәтта ит кисәкләре йөзеп йөрүен мактану һәм шатлык хисе белән сөйләде.

Канал төзелеше янәшәсендә сәхнә кебек корылма ясап куйганнар. Ачык далада, каезланган җир янында ул бик тә сәер күренә. Сәхнәне транспарантлар, кызыл әләмнәр белән бизәгәннәр. Нәкъ 1 Май демонстрациясе мәйданы, диярсең. Бер генә нәрсә бу матур күренешне боза – сәхнә артында урнаштырылган ике каланча. Каланчаның һәрберсендә икешәр сакчы булуы да абайлана.

Хәмидуллаларны сәхнә янына тезеп бастырдылар. Аларга таба төрле яклардан башка отрядлар да кушыла торды. Ниһаять, даланы меңәрләгән

тоткын басып алды. Бу халык диңгезе акрын гына шаулый, сөйләшүләрдән гөжли, салмак кына тирбәлә... Халык дәрьясының өч ягыннан этләр өргән, әледән-әле әче сүгенеп, сакчылар кычкырган тавышлар ишетелә.

Җитәкчелек килгәнне алар өч сәгать буе аягүрә басып көтеп тордылар. Ниһаять, тегеләре дә күренде. Сакчылар белән уратылган түрәләр сәхнәгә күтәрелде. Хәмидулла алар арасыннан легендар Френкельне эзләп табарга маташты. Әнә, тегеседер, мөгаен. Ябык гәүдәле, озын күн тужурка кигән, очлы борыны астына тар гына иттереп, мыек үстергән бәндә. Ул тоткыннар алдында чыгыш ясамады, бары тик өстән, сәхнәдән үзенең каршында басып торган халыкны күзләде. Карашы инә төсле очлы, әйтерсең, тәнне тишеп керүчән. Тоткыннарны ялкынлы чыгышлары белән лагерь җитәкчеләре генә «шатландырды». Алар, кунаклар белән салып алу сәбәпле кызарган йөзләрен тагын да катырак бүрттереп, каналармиячеләргә хезмәтнең әһәмиятен, совет власте өчен файдасын тәфсилләп аңлаттылар һәм югарыдан килгән түрәләргә барлык бурычларны да вакытында үтәп чыгачаклары турында ант эчтеләр. Ярты сәгатькә сузылган митингның азагында лагерь тоткыннарыннан оештырылган ансамбль совет хакимиятенең бөеклеге турында моңсыз-нурсыз җырлар башкарды. Шуннан соң тоткыннарга баракларына кайтырга кушылды. Иртәгә шушы мескеннәр сәхнәдән яңгыраган вәгъдәләрне кан һәм тир түгеп тормышка ашырырга тиеш иде.

Кайтырбыз да, кичке ашны ашап йокларга ятарбыз дип уйласа да, Хәмидулла ялгышкан булып чыкты. Аларны янәдән мунчага алып киттеләр.

– Кара әле, түрәләр килгәч, көн саен юындыра башладылар, бетләрбез дип куркалар, ахры, – дип, авызын ерды аларның отрядындагы Петро.

– Яхшы булыр иде ул, көн саен юынуны әйтүем. – Чисталыкны яратучы Хәмидулланың күңелендә дә кешечә тормыш башланыр дигән өмет чаткысы уянды.

Аларны Николайның сүзләре генә айнытып җибәрде:

– Яхшы булды, ди, тот капчыгыңны. Безне мунчага юынырга түгел, киемнәрне алмаштырырга алып баралар. Әнә, карагыз, икенче отряд чыгып килә.

Мунча чоланы бусагасында тоткыннар күренде. Аларның өстендә кичә бирелгән киемнәр юк, янә элеккеге чүпрәк-чапракка уранганнар.

Кичә чишенгән киемнәр, ничек бар – шундый килеш үзләренең хуҗаларын мунча чоланында көтеп торганнар. Тик кайда кемнең нәрсәсе – караңгы чоланда абайлавы мөмкин түгел. Шуңа күпләр кулларына ни эләксә, шуны тотып чапты. Тарткалашкан вакытта күлмәк-ыштаннары ертылып чыкты. Кемдер бөтенләй дә үзенең киемен таба алмады. Ләкин эзләргә, нәрсәнең кайда ятуын ачыкларга вакыт юк – сакчылар ашыктыра. Тоткыннарның кайберләре яланаяк, күлмәксез килеш баракларына атлады. Кичке ашка сасы суүсемнәреннән пешерелгән баланда бирделәр. Икенче көнне барысы да үз рәтенә кайтты – шул ук эш, шул ук юл, шул ук сасы ризык. Нафталий Френкельнең килүе уңаеннан оештырылган бәйрәм хатирәсе булып, канал яры буендагы ике сак каланчасы гына әле бик озак, кышка кадәр караеп тордылар...

...Үз чираты белән өченче тачка ташларны өскә менгезеп аударгач, Хәмидулла әбәт вакыты җиткәнлеген аңлады. Аларның лагере ягыннан җигүле ат килә иде.

– Николай, әбәт килә! – дип кычкырды ул бригадирга.

– Әбәт! – дип кычкырды Николай, үзенең бригадасын күздән кичереп. Чокыр төбе дөбер-шатыр килгән тавышларга күмелде – тоткыннар көрәк-кәйләләрен җиргә ташлап, өскә, ризык янына кузгалдылар.

Бүген, гадәттәгечә, әбәткә билгесез, ләкин бик әче исле нәрсәдән пешерелгән баланда иде. Хәмидулла, үзенең пайкасын алып, зур таш төбенә килеп утырды. Итек балтырыннан кашыгын алды. Аннан, йөрәк ягында тегелгән кесәсеннән саклык белән иртәннән калган ипине чыгарды. Кулъяулыгын ачып, ипине ике тигез кисәккә бүлде. Озак та көттерми, аның янына Эрнест та килеп утырды. Хәмидулла сүзсез генә аңа ипи кисәген сузды, һәм алар, суынып өлгергәнче дип, ашыга-ашыга баланда чөмерергә керештеләр.

Төшке аштан соң бригадир аларга бераз ял бирә. Бу вакытта кем нәрсә эшли – үзе хәл итә. Карга ятып, черем итеп алучылар да җитәрлек, кайберәүләр төрле йомышларын үти, күпләр, әлбәттә, тәмәке тарталар. Ә Хәмидулла тартмый. Ул, күзләрен йомып, эчтән генә өйлә намазын укый...

Хәмидулланың күзләрен йомып утырганын күрсә дә, Эрнест барыбер аңа сүз катарга булды:

– Хәмидулла абый, син ни турында уйлыйсың?

– Ә?...

– Ни турында уйлыйсың, дим.

– Уйламыйм мин, Эрнест. Мин дога укыйм.

– Синең догаң урыс телендәме?

– Юк, Эрнест, мин мөселман бит, безнең догалар гарәп телендә.

– Һәм син гарәпчәне аңлыйсыңмы?

– Аңлыйм, әлбәттә. Мин бит муллалыкка укыдым.

– Ә кем ул – мулла?

– Вәт сиңа, ә? – Хәмидулла тыела алмый шаркылдап көлеп җибәрде. – Мулла – ислам динен гыйбадәт итүче.

– Поп шикеллеме?

– Әгәр теләсәң, поп шикелле дияргә дә була.

– Ә син әле дә Аллага ышанасыңмы? – Эрнест биргән әлеге сораудан Хәмидулла әллә нишләп китте.

– Ышанам, әлбәттә. Әллә соң син ышанмыйсыңмы?

– Белмим. – Эрнестның күзләренә кинәт яшь тулды. – Мин элек ышана идем. Ә хәзер белмим. Әгәр Алла бар икән, нигә соң ул безне – бер гаепсезләрне исән килеш шушы җәһәннәмгә китереп тыкты?!

Эрнестның җан ачысы белән әйтелгән бу сүзләренә Хәмидулла ни дип җавап кайтарырга да белмәде. Хәер, фикерен тупларга өлгермәде дә – кайдандыр еректан, эш башларга вакыт дип, Николайның көр тавышы яңгырады...

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Ркаил
Зәйдулла

# ГЕЛ ЯХШЫГА ЮРАСЫН ТИК КОШЛАР...

## Төштән соң

Төш вакыты узган инде. Тәрәзәдән
башны сузып, күз ташладым үзәннәргә.
Өянкеләр яфрак коя берән-сәрән,
кыргый гөләп ярга ятып өзгәләнә.

Елга тып-тын. Кичке кояш чумып чыккан.
Сулар алсу. Бурлат төсле кайбер төше.
Җил дә исми. Хисләремне үзенә йоткан
дөньяларның төштән соңгы әверелеше.

Әллә ниләр эшләнмичә калган сыман.
Яфрак ята сукмакларга – үкенечләр.
Мин киткәндә әрәмәләр арасыннан,
иярепләр китәр төсле сары төсләр.

Мин юрамыйм алга таба инде берни...
Шундый көлке, шундый төлке – күрәзәче!
Мин тик күрәм – офыкларда шәфәкъ дөрли,
һәм төшемдә соңгы ярым үрә чәчен...

***

Нигә эндәшмисең?
Сизәсеңме
Бер сүз яралганын тып-тын гына?
Тик ул ничек ярала соң?
Әнә
Нидер шартлый галәм бушлыгында...

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; Татарстанның халык шагыйре. «Мәгарә», «Ташка ордым башны», «Саташкан сандугач» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шәраб эчеп сәрхуш булган шагыйрь
Тәүбә итеп, башын игән түбән, –
Сөю хакында сүз әйтер өчен
Вакыт җиткән!
Шушы сүзләр туган:
«Күз яшьләре тамган көйгә
Әрнеп
Яза Тәңре кеше тәкъдирләрен...»

Буш далада бер калкулык калыр,
Күмеп китәр аны ачы әрем.

***

Аһ, син көз!
Күңел үзгә...
Тезләнәсе килә сары яфракларда...
Үз кешеләр ерагая бара,
Күңел төшә, бәлки, ятракларга?

Аһ, син көз!
Төсләр үзгә...
Кып-кызыл ла Миләш тәлгәшләре.
Мин Өрәңге булып басып торам,
Һәм озатам көзге кәләшләрне.

Аһ, син көз!
Син тик сүз лә...
Син бары тик фасыл!
...ул үтәчәк.
Кызыл керфекләре тибрәнә дә,
Күзен кыса миңа бер гөлчәчәк.

***

Кара болыт йөзә иртәдән үк...
Үтәр әле, ачылыр күк йөзе.
Җил исәр дә, үзе белгән якка
Алып китәр бездән юеш көзне.

Әле менә яңгыр сибәләде...
Ачылмады инде, ачылмады! –
Баш өстендә һаман кара болыт,
Керфегемдә – якты тамчылары.

***

Яз килгәндә әллә нишли иде, –
Күңел диимме соң, йөрәкме?
Безне дөнья дәшми кайгырырга,
Шыпырт шатланырга өйрәтте.

Тик яз быел башкачарак килде,
Һавасы да гүя кургашын, –
Гел яхшыга юрасын тик кошлар,
Канатлары нурга уралсын.

Йөрәк минем әллә нишли әле,
Аксап ала кайчак,

Хәтергә
Миннән йөз чөергән бер яр килә,
Их, хәтерне бер җилләтергә!

Ләкин җилләр шундый шыксыз быел,
Яз кояшы шундый караңгы, –
Һич чыгасы килми дөньяларга.

Чыгарга да, диләр, ярамый...

***

Ындыр артындагы инеш
Көмеш сызык кебек кенә.
Кичәгедәй... нәкъ шул килеш.
Су да шул ук – киребеткән.

Чак күренгән бер көймәгә,
Яшел коймадан үрелеп,
Кул изәдем иртә белән...
Үтте томанга төренеп.

Гөләп үкседе тын гына,
Яшел коймага беректе.
Кояш чагылды чыгында –
Елмаю сыман ирекле!

Кич белән китәрмен моннан.
Көймә туктар, утырырмын.
Инеш томаны ябынган
Төш кебек онытылырмын.

## Ачыгавыз

Әбиләрдән сабыйларга кадәр
Бар да җырлый. Сәхнә – шыгрым!
Җырның ертыгы юк. Ләкин шунысы –
Җырлыйбыз соң бүген кем җырын?

И биибез аннан. Искитмәле
Көйләр ишетелә якында.
Кеше кубызына бии-бии
Төшеп кала бугай акыл да.

Ул чибәрлек ярышлары тагын!
Нәни кызыйлар да мисс-мисс-мисс.
Әниләре гайрәт биреп тора –
Королева булсын! Һәм бик тиз.

«Воскрес!» – дип котлап күршеләрне,
Күкәй буяп, шәмнәр кабызып...
Ифтарларда авыз ачабыз без,
Юкса күптән ачык авызлы.

Күңел күзе генә йомык бары,
Денең ни дә аңа, җирең ни...
Бар дөньяга мәшһүр ачык авыз –
Тик тел генә анда күренми.

## Карак

Бер каракны ябып куйганнар, вәт!
Полковникмы шунда, генералмы
Утыз миллион, имеш, ришвәт алган...
Безнең халык бик канәгать калды.

Өен күрсәттеләр – идрит-кудрит!
Бәдрәфе дә футбол кыры шае.
Унитазы алтын... Күргәннәргә
Йөрәк өянәге булмагае.

И нәфрәтләнде халык унитазга,
И сөенде аннан: шәп эләккән!
Вак иләктән үткәрделәр аны,
Хаклык көтеп якты киләчәктән.

## Сайлаудан соң

Сайлау узып китте тагын.
Кемдер алды алачагын,
Кемдер бирде бирәчәген,
Ачыклады күрәчәген.

Сөенеп, гүя сабыйлар,
Сайлыйлар, күрче, сайлыйлар!
Без дә, дип, дөнья тоткасы,
Безне дә санга саныйлар.

Сайлау булды, җайлау булды,
Майлау булды сөртеп канат.
Сайлау участокларына
И китте халык юргалап.

Ә заман кемнең заманы?
Күрербез Ходай язганны, –
Әнә тагын чакырганнар
Безгә дип... Олег Газманны.

## Куар-код

Кая барып бәрелергә
Белмәгән чаклар була.
Юллар бикле, тел йозаклы,
Күзгә ком җиле тула.

Яфрак астына керсәң дә,
Анда – тышта бер тавыш
Ят телдә майтлап сүгенә...
(Кечкенәдән үк таныш.)

Тышауланган аяк белән
Тик таптанып торасың.
Кычкырасы килә дә бит...
Тик ничек кычкырасың?

Бүтәннәрнең тыны да, дип
Чыкмый әнә, шым бул син!
Сулама, тышка да чыкма, –
Бар тишегең йомылсын.

Качасы килә дә ансы...
Булмый яңадан туып.
Тик тор! – дим, кая качсаң да,
Куар-код тотар куып.

***

Ни көтәм? Авызда ачы тәм.
Аяк тавышларын ишетәм.
Кара кайгы, янә мылтык тотып,
Килеп керер кебек ишектән.

***

Укмашканнар безгә каршы барча...
Кочак җәйгән идек туганнарча
Без бергә дип... Алар чукмар тоткан
Таркатырга безне парча-парча.

***

Җәйрәп ята аста үзәнлек,
Чыдап булмаслык хөр гүзәллек!
Искә төште илдә тиң чаклар,
Хәлләр шундый безнең... түзәрлек...

***

Бу болыт кая бара соң?
Туктарга юктыр чарасы...

И койды әллә кайларда,
Чыланды күзең карасы.

***

Сулар кибәр җирдә, уалыр таш,
Тик җылы сүз калыр безгә юлдаш.
Чатнар күктә кояш, югалыр баш,
Канат җилпер ул сүз – ишетүче булмас.

***

Татлы истәлекләр биләмәсендә
Ышыкландым сагыш күләгәсенә.
Кып-кызыл гөл булып шытты шигырем
Чүп-чар сүзләремнең чүмәләсендә.

***

Танымадым авылым урамын –
Хәзер ул нәкъ Рәми язганча тын.
Өч-дүрт бала үтте. Телләре ят.
Оятымнан өнсез-телсез калдым.

***

Әвәләндекме балчыкның үзлесеннән, –
Йөзебезгә нинди сагыш эзе сеңгән?
Киек кошлар әллә кая таралышты,
Ә буш басу оеп ята көз исеннән.

***

Ком күченә, гомер тиз кичелә,
Сагынырсың моңсу бер кичеңдә
Син мине дә... Кабатланмас бу мәл,
Көзге чеклә булыр, көзге чеклә.

***

Йөрәк бүтән татлы әрнемәс дип
Кул селтәгән идем. Вакыт – табиб.
Кара чәчләрендә адаштым бит!
Коткарыр тик әҗәл, вакыт табып.

***

Юлдан яздым тагын, түзмәдем –
Күз нурыңны эчте күзләрем.
Гомер көзләрендә юлыктым да
Сулкылдадым ялгыз, гүзәлем.



Айдар
Хәлим

# МОҢ КАЙТТЫ

ПОВЕСТЬ

**1**

Туган якларына кайткач, Сабирҗан үзендә зур үзгәреш тойды. Сагыну дигәне тиз үтеп, күңеле ифрат та нечкәрде. Югыйсә ул Үзбәкстанның күзләре ешынып үскән сары арыкларына кадәр туеп-җилсенеп, юлга чыккан иде бит; сабый чагыннан ел саен җәйге айларда ата-анасы, туганнары белән төялешеп, авылга кайткан Сабирҗан табигатен, туган-тумача, күрше-күлән, таныш-белешләрен аңлата да алмас дәрәҗәдә сагынып кайта торган иде!.. Бер караганда, авыл аның өчен ят саналырга тиеш. Ул ата-бабасы чыккан авылдан читтә үскән өченче буын. Биредә аның әби-бабалары туган, гомер кичергән, утызынчы еллардагы сыйнфый кыйралышта, ачлык-ялангачлыкта барлык мал-мөлкәтен ташлап, аның әлегә яшь ярымлык кына атасын «уф-алла» дигән вак-төяк арбасына салып, Урта Азия тарафларына чыгып качарга мәҗбүр булган. Ә ул, Сабирҗан, Ватан сугышыннан соң, ачыклап әйтсәк, үткән гасырның илленче еллары уртасында Кәттә-Корганда дөньяга килгән. Әмма, ни гаҗәп, бу кайтуында – әллә инде үзен дә дә картлык баса дигән нәрсә шушы буламы? – ифрат та җирсеп кайтты. Кан тарттымы? Әллә моннан утыз ел элек туган төягенә кире кайтып төпләнгән һәм нәкъ егерме ел элек сиксән өстендә гүр иясе булган ата-анасының рухларымы? Әллә ниндидер көч аны туган нигезе алдында хөкем җавабына тарттырдымы? Икеләтә гаҗәбе менә кайда иде: кайтканда, сагынуы никадәр көчле булган булса, ул туган җирнең үзендә шулкадәр тиз, җилгә очкан томан кебек юкка чыкты да куйды!..

Горбачев демократиясе кузгалып, дөньялар буталгач, какшамас ЭСЭСЭСЭРның какшамас республикалары тәмам какшап, җимереклектә мөстәкыйльлек алып, тыштан шалтыравык, эчтән калтыравык

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

җөмһүриятләргә әверелеп, һәркайсы үз милицияләрен булдырып, прәшке ялтыраткач, юллар-еллар бикләнеп, ата-анасын җирләп киткәннән соң, менә егерме ел кайта алмаган нигезеннән урамга чыгасы да килми инде. Бу ниткән хәл? Чыкса, исәнләшер зат очратмый. Очратса да, карт-коры, аксак-туксак, дигәндәй. Йә лыка исерек булыр. Кибет ягына берәм-сәрәм үткәләгәннәр «Кеше яшәми» дип йортка борылып та карамый. Яши, Сабирҗан әкәгез яши!.. Авыл улының улы, ягъни аның оныгы сыйфатында кайткан һәм вакытлыча булса да нәкъ менә шушында яшәп ята!.. Кичә генә бар нәрсәсеннән гарык, шул ук вакытта ифрат та үз күргән Үзбәкстанының шул сары арыкларына кадәр сагына, хәтта тизрәк кире китәсе килә башлады. Шушы авыл буламы аның Ватаны? Ватан булгач, нигә аннан китәсе килә? Нәрсәдер җитми. Җырлыйсы килгән кебек була, авызын ача, тавышы чыкмый. Гүя үзенә күрә булган моң да каядыр китеп югалган. Нидән шулай? Кешесе ярым-йорты калган, бүген сүнәм, иртәгә сүнәм дип, тын алган авылының аяныч хәле күңелен суыттымы? Әллә ата-анасы вафатыннан соң, тәмам тешсез әбине хәтерләтеп калган урамнар буйлап, туган-тумачаларының, күрше-күләннәренең дә тегендә китеп баруларымы, суларын кереп, буынын ныгыткан елгаларының, суларын эчеп үскән чишмәләренең кибеп-корып бетүләре шулай тәэсир иттеме, аның, ялдагы миһманның, башка эше калмагандай, менә хәзер, шушы минутта, шушы секундта бер генә михнәт кичерәсе – күзен йомасы һәм җыр, бары тик туган моңнарны тыңлап, шул тере моңнарның исән күзләренә карыйсы, андагы теге бердәнбер серле ноктаны – мәңге үлемсез исәпләнгән тормыш ноктасын күрәсе килде. Гүя аның өчен ата-анасыннан васыять рәвешендә тапшырылган авылында, менә бу өянкеләр, менә бу сәрби куакларында менә шул моң ноктасыннан башка бернәрсә дә калмаган иде. Бар идеме соң ул моңлы нокта? Аны табарга кирәк иде!.. Тора-бара аңа бу моңның күзе, күзенең карасы бардыр кебек тоелды. Әмма ул түгәрәк кара кечкенә бер төртке булып кечерәйгәннән-кечерәя бара иде кебек. Сукыраймаганмы, ак салмаганмы бу күзләргә?!

Сабирҗан беркая чыкмыйча, әле үзенең тән җылысыннан почмаклары да җылынып өлгермәгән ташландык йортта, сәгатьләр буе шул моңнарны тыңлап, шул күз карасын эзләде. Ярый әле, кайлардан кайтып, моңнар эзләрлек куәте бар. Ярый әле, мондый михнәтне кичерер өчен хуҗасыз калган йорт-җире бар. Ярый әле, монда кеше бар булып исәпләнә генә, ә менә йорттан электрны һәм газны, һаман да шул бер сәбәп – кеше яшәми дип кисеп ыргытмаганнар. Шушы килеш булса да, йортны сатып җибәрмәгән һәм җимертмичә саклаган өчен абзасы Хикмәтуллага рәхмәт. Атасы моннан күп еллар элек, әле егет чагында, картатасының кушуы буенча бөтенләйгә төпләнмәкче булып, авылга кайткан һәм өйләнгән. Әмма авылын яратса да, колхоз изүенә түзәлмичә һәм тагын да ни сәбәпледер беренче хатыныннан аерылып китәргә мәҗбүр булган. Хикмәтулла әнә шул никахтан калган тере истәлек. Шушы йортта туып-үссә дә, башлы-күзле булгач, үзенә яңа оя корып, башка чыккан...

Әле менә аның Урта Азиядән кунакка кайтып төшкән һәм төп нигездә яшәп яткан «экскурсант» (Хикмәтулла абзасы аны шулай атый) Сабирҗан энесе Зөһрә Сәхәбиева белән Хәйдәр Бигичевнең җырлары тәэсиренә кереп чумды. Бер карасаң, ул авылны ныклап белми, аның кичке «вичырларында»

биеп тә үсмәгән, Сабантуйларында бәйге дә чапмаган, татарча да укымаган, ә менә – тарта туган авыл, нәрсәседер белән тарта!.. Шунда үскән, диярсең! Туган моңнарны тыңлаган саен җаны сыкрый, сыкрый, тагын да сыкрый, әмма, ни гаҗәп, шул сыкрауларда ул ләззәт тә таба. Ничә тапкыр кире кайтып тыңлады икән ул Зөһрәнең «Җидегән чишмә»сен? Хәйдәрнең «Тын сукмакта тал тирбәлә» романсын? Алар икесе дә җыр, әмма беренчесе моңлы мөнәҗәткә охшаса, икенчесе романсны хәтерләтә. Шунысы кызык, XX гасырның соңгы чирегендә туган шушы бөек җырларның икесен дә татарның мәшһүр халык композиторы Сара Садыйкова иҗат иткән. Сабирҗан чит-ятякларда иләнеп-чиләнеп, бәлки, милли музыка белән танышып барудан артта калгандыр?

Ничек кенә булмасын, татар җыр сәнгатенең ул белгән соңгы чорында шулардан да бөек җырларны ишеткәне юк. Һәрхәлдә, хәтерләми. Аларның кешегә булган психологик тәэсире, аның фикеренчә, Огиньскийның «Полонез»ы, Заһидулла Яруллинның «Тукай маршы», Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия» маршларына тиңдер. Никадәр моң! Нинди рух биеклеге!.. Тетрәткеч!.. Сүзләрен кем язган, диегез. Милләтнең бер бөек язучысы Гомәр Бәширов белән икенче бер бөек шагыйре Хәсән Туфан!..

**2**

Зөһрә белән Хәйдәрнең магнит язмага язылган шушы җырларын ул беренче тапкыр, ялгышмаса, теге гасырның сиксәненче еллар уртасында ишетте. Бераз соңрак Ташкент татарларының «Яшьлек» ансамбленең бер яшь җырчысы башкаруында тыңлады. Җырчының моңы да, башкару осталыгы да ул кадәре уш китәрлек булмаса да, Сабирҗанга ошады алар: яхшы тукыма каян гына кыеп алсаң да, яхшы сыйфатын югалтмый бит. Әмма ике атаклы җырчының ир белән хатын икәнлекләрен соңрак кына белде.

Йа Раббы, ун-егерме миллион татардан бер-берсен тап китереп танышкан, табышкан, өйләнешкән һәм гомерләре буена аерылмыйча, бергә, бер сәхнәдә, бер жанрда, бер милләткә, бер Ватанга хезмәт иткән бүтән ике шәхес – бер гаилә җир йөзендә кайда да булса бар микән, дип баш ватты егет ул чакта. Бар микән мондый асылдан асыл парлар башка милләтләрдә? Моның өчен аларның һәркайсының җырдагы кебек үз шөгыльләрендә, үз бакчаларының «өй артларындагы шомыртым»нары булырга тиеш!.. Алар, шушы ике шәхес, бер-берсен очратсын, табышсын, гаилә корсын өчен ун-унбиш миллионлы татар-мөселман өммәте бу чишелешкә Эйнштейнның нинди чагыштырмалылык, теорияләре, нинди геометрик прогрессияләр аша чыгарга тиеш иде икән?

Сәләт-талантның бу кадәр дә сирәк тәңгәл килешлелеге, ягъни симметриясе, бу кадәр гаиләи парлылыкка, бу кадәр гармоник тәңгәл килүенә ул таң калды.

Менә әле бүген дә тыңлый кайчандыр туган авылын газаплаган ачлыктан качып китәргә мәҗбүр булган мөһаҗир оныгы бу ике җырны. Хәтта төшке ашын да онытты. Әйтерсең, ул моңнан болай да тук, кашыгы чөйдән төшмичә, коп-коры килеш эленеп тора. Күкрәгендә кайнаган ярсудан ул мич арасына керде дә тирән чүмеч белән шомбырдатып су эчте, керде дә су эчте. Эчкән саен сусаткан бу моңнардан аның гүя үңәче йолдызланып кибә иде. «Җидегән чишмә»не тыңлап, яшен корыта да, чит-читләрен пәрәвез челтәре каплап

алган тәрәзә янына бара. Моңнардан бушанган арада аларны тазарткаларга, сөрткәләштерергә, юыштырырга кирәк булыр. Тәрәзәдәге тапларга ул әле генә игътибар итте. Беренче тапкыр. Кайтканына да бер атна булса да. Пыяла заманның тын алышын сурәтләгән, диярсең, анда ниндидер эзләр, сызыклы шаукымнар, юллар... Йа Хода!.. Тәрәзәнең ультрашәмәхә нурлардан саргайган пыяласы аша чәчәккә бөреләнгән бәрәңге бакчасы күренә. Туган нигез бакчасына бәрәңгене теге урам очында яшәп яткан Хикмәтулла абзыйсының кызы чәчә. Рәхмәт төшкере, шуның белән булса да, нигезне корытмый. Төп нигездә беркем яшәмәгәнгә, көнгә бер мәртәбә булса да сугылып чыккалый.

Менә шулай уйларыннан арына алмаган Сабирҗан япа-ялгызы Хәйдәрнең «Тын сукмагы» талларына барып, яшен түгә дә тәрәзәсеннән уң яктагы уңайда чалшаеп беткән абзарга күз ташлый. Кайчандыр ат, сыер, кәҗә-сарык малы белән мөгрәп-бәэлдәп торган утарда хәзер мал-туарның, хәтта кош-кортның исе-косы да юк. Ул мал-туардан бушап калган үксез ихата өчен борчылып, авыр тын ала. Аннан җиңелчә уфырып, Зөһрәнең «Җидегән чишмә»сенә килә, тыңлый, янә сагышын сыга да Хәйдәрнең «Тын сукмагы»на кайтып, яшьләрен сугара. Ул яшьлегендәге хәрби хезмәттә океан корабында океаннар гизеп, бу кадәр моң дәрьясын кичкәне юк иде. Тыңлаган саен яңа кодрәт, яңа моң, яңа борылыш, төбенә төшеп җитә алмаслык тирән чоңгыллар...

Менә ул ата-баба туган йортында кемнәр генә утырып шомартмаган урындыкка утырып, аркасына аллы-гөлле мендәрчек сала да, диварга терәлеп, күзләрен йома...

Җидегән чишмәләрдә җиде улак, җиде улак,
Челтер-челтер ага көмешсу.
Көмешсулар ага, кошлар сайрый,
Шул чакларда бигрәк, шул чакларда бигрәк ямансу...

Бу – Зөһрә. Һәм аның бар татар дөньясына таныткан «Җидегән чишмә»се. Каян килә бу кадәр якты, бәгырьне суырган сагыш? Аһ, татар авылы! Умачлы вә токмачлы, таллыклы вә халыклы, бердәм вә җирдән булган авылдан килә мәллә бу кадәр тетрәткеч моң?!.. Синдә генә яратыла ала мәллә мондый чишмәләр? Ләкин шунысы аяныч вә сәер, авыл чишмәләреннән саркылып чыккан моң нишләптер тәү башлап шәһәр сәхнәләреннән яңгырый. Нигә бу җырны халыкка ишеттерү өчен татар баласына – бу очракта Зөһрәгә мотлак авылдан шәһәргә китәргә кирәк булды икән? Белеп торыгыз, Сабирҗан – бу ике җырчы турында газета-журналлардан укып, шактый мәгълүмат туплаган кеше. Менә 1977 елга кайттык, ди ягъни мәсәлән. Пермь. Җыр беренче тапкыр Татарстанда түгел, Пермьдә – Уралда яңгырый. Җыручыга нибары егерме алты яшь. Рояльдә Сара апа үзе. Кар сулары кебек челтерәп, чишмә сулары кебек көмеш коеп аккан бу тавыш, аһ, бу үтә яңгыравык тавыш!.. Сандугачларны да туктатып тыңлата алыр бу тавыш, аһ, бу тавыш!.. Нигә бу кадәр моңлы бу татар? Бу, бәлки: «Син, татар, нигә бу кадәр бәхетсез?» – дип сорауга тиңдер? Бу бәлки: «Син, татар, нигә бу кадәр талантка байсың һәм нигә бу кадәр байлык-барлыкта ирек-хокукка ярлысың?» дигән сорауга җаваптыр?

Бу моңнарны тыңлаганда, аның уч төпләре җылына. Гүя ул, Урал

тарафларыннан Урта Азиягә нан эзләп килгән, кулларыннан башка бернинди эш тапмаган татар баласы, башка зимагур татарлар белән Чимган, Чирчик рудникларында башын-күзен дә томаламыйча, ярымшәрә халәттә атом тузаны йота-йота, уран ташлары төйи һәм бушата. Куллар – утта, күзләрдә яшь. Гүя шушы тумышыннан көмешсу ак, икенче караганда, кояшта күкшел-коңгыртка әверелә торган ташлар ыңгырашып-ыңгырашып, платформага төшкән чакта татар, бары тик татар өчен генә билгеле булган аһәңнәр-моңнар чыгаралар. «Күпме түлисез?» дип кызыксынырга әмәл дә юк, теләк тә, кыюлык та җитми, бары тик карын тук булсын да тавыш-тынсыз гына алга нан килә торсын. Кинәт кенә Сабирҗан башына беренче тапкыр килгән яңа фикердән тетрәнеп китә. Бәлки, татар үзе дә ул бушаткан, изотоп-нурларын даими яктыртып торган уран ташыдыр? Ташы – безгә, ашы, эчке куәте – сезгә. Кызган уран ташларыннан кызган күкрәкләрдә ачу кабара һәм ул үзе моңга әверелеп, йөрәктән өзелеп төшә...

Нәрсә, Сабирҗан үзе дә шушы уран ташы түгелме? Ул тыңлаган моңнарда ураннан килгән мәңгелек энергиясе юкмы? Яланбаш-яланөс килеш, кара тирдә йөзеп, ул төягән ташлар, ул тапкан көч-энергия башкаларны изү өчен дә кулланылмадымы? Нәрсә, Сабирҗан үзе дә аз изелдеме? Әгәр моңнар изелүдән яратыла икән, нигә ул чакта шушы җырчылар кебек ул да моңлы түгел? Теге уран тузанында коенып туган ач моңнар кая китеп югалдылар икән? Моңны тирәннән аңлый, аңлый гынамы, аның тетрәткеч борылышларыннан үтә алмыйча, бугазына нидер килеп тыгыла, елый, үкси, әмма җырлый гына алмый. Шулай да күз күрмәгән, колагы ишетмәгән уран ташлары төяп, юл башына чыккан егеткә әнә шул моңнар аңа яшәргә һәм көрәшергә көч-куәт бирде. Ташкент транспорт инженерлары институтында берьюлы ике факультетны бик яхшыга тәмамлап, ике кызыл диплом алды ул. Яшь белгечне Таҗикстанның удар төзелешенә – ул чакларда башланып кына килгән Нурек гидроэлектростанциясенә эшкә җибәрделәр. Ул анда утызынчы еллар азагында шул ук Пермь якларыннан Урта Азиягә качып китәргә мәҗбүр булган мулланың төпчек кызы Мәрфуга-гөлкәен эзләп тапты. Әмма кайнар мәхәббәт тә аңа теге ул эзләгән моңнарны түгел, рәхмәт төшкере, балаларны бүләк итте. Бу азмы? Куанычыннан кычкырып җырлыйсы килде, җырлый алмады. Нурекның беренче агрегатын сынаганда, ташкын астында калып, кыялар арасыннан бүрәнә кебек доңгырдап, гөбердәп акты, умырткасыз калды. Ничәмә-ничә операция үткәрде икән ул? Күңеле ничекләр генә нечкәрмәде, әмма моңы һаман да килмәде. Булмаганга килмәде. Кайтмады. Булмаганга кайтмады. Күңеленә утырмады. Булмаганга утырмады. Ә менә моңны тирән аңлавы калды. Беркая да китмәде һәм бетмәде. Көчәя генә барды. Каян килгән соң ул мондый аңлау? Үзбәк җиреннән түгелдер бит? Сары арыклардан түгелдер?

Җырчыларыбыз астан өскә, өстән аска кадәр йөрәкләрне актарып, фәнни тел белән әйткәндә, «альттан сопранога якын аһәңнәргә кадәр сикерә алсын» өчен шулкадәр изелергә тиеш булган мәллә соң безнең милләт? Аны бу кадәр дә изәр өчен кем кемгә нинди хокук биргән?! Җырчы «Шул чакларда бигрәк ямансу» дип өзелгәндә, йөрәгегезнең парә-парәсе кисәктән кисәккә өзелеп төшмәйме? «Төшмиме» генә түгел, чынын-дөресен әйткәндә, нәкъ әнә шул «төшмәйме»?

Тын сукмакта тал тирбәлә:
Кулың талга тиядер.
Йөрәк әйтә: сагынгандыр.
Су буена киләдер...

Бу – Хәйдәр. Кулың талга тиядер... Талга гынамы? Йөрәккә түгелме? Моны татар аңлаганча тагын да кем аңлый ала? Сабирҗанга билгеле: моң – җанның-йөрәкнең мәңге изелеп, кинәт кичерүдән саркыла торган чыгы. Моң – милли холыкның чагылышы гына түгел. Чит-ят якларда күпне күргән-кичергән кеше буларак, шунысына инанган: моң – шәхси күрсәткеч булудан бигрәк, ул иҗтимагый, социаль күрсәткеч. Моң тарихы – башта теләмичә, карыша-карыша изелү, аннан каешланып, изелергә өйрәнүдән изелү тарихы. Кемнәрдер тарафыннан изелгән бер генә милләттә дә татардагы сыман мондый моң юк һәм була да алмый. Гүя ул изелүгә каршы баш күтәрмичә түзгән өчен җәза. Чөнки ул ураннан, аның изотоп микъдарыннан өзелеп төшкән могҗиза. Уты-яктысы – безгә, кодрәти энергиясе – сезгә. Нәрсә ул моңсызлык? Моңсызлык еш кына эчпошыргыч дәрәҗәдәге тотрыклы бертөрлелектә – консерва калае эчендә бикләнеп-шикләнеп, канәгать яшәү нәтиҗәсе. Моңсызлык – башкалар язмышына битарафлык, теләктәшсезлек билгесе. Җир йөзендә иң моңлы милләтләр – инглизләр тарафыннан изелгән һиндиләр, галлар тарафыннан изелгән итальяннар, чжу-чженьнәр, монголлар тарафыннан изелгән кытайлар, кытайлар тарафыннан изелгән ниппуннар, уйгырлар, урыслар тарафыннан изелгән болгар-татарлар... Барлык гайрәтле пентатоника тупас көч, тәре яулары астында изелүдән челтерәп килеп чыккан чишмә!.. Әгәр урыс өстеннән татар-монгол изүе чынлап та булган булса, урыс бу кадәр моңсыз булмаган, басып алу чире белән чирләмәгән, Мәскәү сазлыкларыннан Тын океанга кадәр кеше хакына яшәмәгән һәм аларның җыр ишарәтләрен сөеклебез Илһам Шакиров «калай» дип атамаган булыр иде...

Бу җыруларны тыңлаганда, Сабирҗанга Җир һәм тереклек яңадан тетрәнгәндәй һәм яңадан яратылгандай була. Ул тагын да күзләрен йома.

...Караңгы тынлык. Шомырт кара заттагы эфир. Әйе, әлегә анда бернәрсә дә юк. Вакыт та, Ара да, Җир дә, Күк тә, Атабыз Адәм галәйһиссәлам дә, Анабыз Һава галәйһиссәламия дә юк. Кинәт, колак пәрдәләрен шаңкытып, нидер гөрселди һәм кап-караңгы дарьяда моңланып, ниндидер ак нокта барлыкка килә. Бу – Ай, Ай, Ай!..

Артта – Аллаһ, алда – Моң. Бар дөнья тын. Шылт та итми.

Ноктаның сулыйсы килә – суларга һавасы юк, ноктаның эчәсе килә – эчәргә суы юк, ноктаның ашыйсы килә – ашарга ашы юк. Ләкин ул тук. Аллаһтан тук. Бер селтәнеш – миллион, бер сулыш – миллион ел. Миллионы – мизгел, мизгеле – миллион. Кинәт шушы ак ноктадан тагын да гөрселдәп-шартлап, ниндидер ябып тотылган, кысылган көчләр иреккә чыга һәм галәмдә гүләп вә үкереп, илаһи Көч – Потенция актарыла, Плюс белән Минус, Изгелек белән Явызлык, Савап белән Гөнаһ, Ак белән Кара яратыла...

Һәм – бар дөнья тын. Шылт та итми. Тавышланмагыз, уран моңыннан татар моңы хасил була!

Айдан азат булган көчләрдән ике төс – Ак вә Кара, ике сыйфат – Изгелек белән Явызлык аерымланганчы тагын бер мизгел – миллион ел үтә.

Ай исә кызлар кашы кебек сөрмәле нәзек сызмага, кавын телеме кебек Ярымайга охшап калган. Яралып килгән дөнья шушы Ярымайга карап тулыша һәм шушы Ярымайга карап кими.

Кинәт караңгы затлы эфирны туфан-океаннар баса, айкылычлар булып айкалган яшеннәрдә тирбәлеп, дулкын белән дулкын, плюс белән минус, изгелек белән явызлык, ак белән кара никахка керә һәм изгелектә явызлык, явызлыкта изгелек, акта кара, карада ак яралу – Шайтан куркынычын кисәтеп, эфирда тормыш һавасы, дәрьяларда яшәүнең яшел төге – хлорофилл барлыкка килә. Ул да шушы Менделей бабай системасына кереп утырган үзебезнең татар уранынннан икән. Хлорофилл белән һава тагын да никахка кереп, туфрак, утраулар, коры җирләр хасил итә. Ярымай исән!.. Ул яңадан тулыша гына!.. Кап-кара дәрьядагы Айның ак ноктасы зурайганнан-зурая барып, бөтен Аралыкны тулаем басып ала һәм – кинәт хасил булган илаһи шартлаудан шомырт агачы сыман чәчкә атып, бер таҗыннан чиксез зур – Күк гөмбәзе, Күк гөмбәзендә Кояш, шомыртның миллион ак чәчкәләренең таҗларыннан миллион йолдызлар, миллион атылачак янарташлар, океаннардагы яшел төк – хлорофиллдан Җир йөзе, Җир йөзендә – уңдырышлы, шомырт кара тупрак, тупракта миллион төр үсемлекләр, миллион төр бөҗәкләр, миллион төр җанварлар, миллион төр җиләк-җимеш бар итеlә...

Бар дөнья тын. Шылт та итми. Һәм аларга ярдәмгә Падишаһ буларак – Акыл Иясе Адәм галәиһиссәлам күренә!.. Һәркайсын үзенә хас зиһен белән һидаятьләп, Җирдә вә Күктә нәсел орлыгын саклаучы Бөек Мәхәббәт хиссияте барлыкка килә!.. Барысы да моңнан, барысы да ураннан!.. Урамыңны ташламаган кебек, моң иясе булган ураныңны ташлама!..

Бисмиллаһ ир-рахман ир-рахим!.. Артта – Аллаһ, алда – моң!..

Тагын да миллион, тагын да миллион ел үтә...

Көннәрдән бер көн яңа эраның һиҗри буенча 1327, милади буенча 1949 елның 16 июнендә Евразия киңлекләрендә сибелгән татар өммәтенең Олы Иделнең Хәзәр диңгезенә аккан уң канатында – ун мең татар авылының гүзәл Чүмбәли дигәнендә хак мөселман этисе Әббяс (Гәббас) белән хак мөслимә Рәшидә Бигечләр гаиләсендә беренче булып, ир бала дөньяга килә. Аңа Хәйдәр, гарәпчәдән Арыслан дигән исем кушалар. Ул чынлап та татар моңының арысланы булып үсәр дип кем уйлаган? Татар моңының Чүмбәлидән берничә чакрымда гына яткан Актүк авылында туып-үскән икенче бер бөек башламчысы Рәшит Ваһаповның, Сарман тарафларындагы Яңа Бүләктә туып-үскән икенче бөек дәвамчысы Илһам Шакировның яңа, моңарчы күрелмәгән дәвамчысы булыр дип кем уйлаган?

Безнең күкрәкләрдә бездән артып алынган уран гүелди!

Күзләрен ачмыйча гына, Сабирҗан бераз гомер тын ята. Аннан аңына килеп, елмая. Ул шат. Аллаһ бер татарга бу җирдә ураннан яратылган бу кадәр җыр даһиларын бүләк итсен дә, елмайма, ди, тагын!.. Менә гаеш!..

Илһам дәвамчысы булу өчен әлегә юл ерак. Хәтта Илһам дәвамчысы булуга ирешкәч тә хурлаучы, татарга хас көнчел яманавызлар табылыр. Кем кем, ә менә кара көнчеләргә татарда дефицит юк. Алар кирәгеннән артып

киткән. Әгәр мөмкинлек булса, аларны чит илләргә экспортка да чыгарып булыр иде. Алар Хәйдәр, бигрәк тә аның атасы турында юньсез фикерләр таратырлар. Имеш, Әббяс холыксыз булган, имеш, эчкече булган, имеш, Хәйдәр балта белән пычак арасында гына үскән...

Тамбов якларының икенче бер сүз даһие Һади Такташ күз алдына килә. Заманча мәктәбе дә булмаган «мишәр» Сыркыдысында шушы «көнҗәлә башлы» егеткәй барлык ун-егерме миллионлык татар халкына үрнәк татар тел мәктәбен-шигъриятен тудырсын әле! Менә кайда ул безнең йөзләрчә изотоплы уран! Менә кайда ул Тянь-Шань сыртларыннан сикереп төшеп, Чимган тауларында нурланып яткан куәт!

Әмма онытмыйк: әлегә бер милләтнең ике канатында бераз алдарак әйтә биреп куелган теге ике ай яратыла гына!..

Әйе, күпмедер гомер үткәч, яңа дәвернең һиҗри буенча 1329, милади буенча 1951 елның 25 апрелендә шул ук Евразия киңлекләре буйлап аккан Олы Иделнең сул канатында яткан Салих-Тукай авылында хак мөселман Габделкотдус, хак мөслимә Миңлегөл Сәхабиләр гаиләсендә бишенче бала булып, бер кызчык дөньяга килә. Аңа Зөһрә – гарәпчәдән, якты, ачык йөзле кыз дигән исем бирәләр.

Зөһрәнең әнисе ягыннан бабасы Зиннәтулла-кардәш бер төркем авылдашлары белән колхозлашудан качып, Казан артындагы Урта Пошалым авылыннан Сарман якларындагы Салих авылына килеп, анда урман төпләп, йорт сала. Нибары ундүрт йортлы Салих авылының икенче, җәннәтне хәтерләткән очында барлыкка килгән яңа утарларга бөек шагыйрь якташлары Тукай исеме бирәләр һәм авыл шушы ике бөек исемгә сөйкәлеп, Салих-Тукай дип йөртелә башлый. Гадәттә, кечкенә елгаларның шавы зур булган кебек, авыл кечкенә булган саен әдәплелек тәрбиясе зуррак була.

Бигечләр белән Сәхабиләр гаиләсенең икесендә дә, бер-берсен белмәсә-күрмәсәләр дә, алдан сөйләшеп куйган кебек охшашлык күп була: ике яктан да нәселләр – атаклы балта осталары. Ике нәселдә дә мөселман мөнәсәбәтләре – Коръән-кәрим кануннары хакимлек итә. Коръән яктысы Зөһрәгә бабалары Зиннәтулла, Гыйззәтулладан, атасы Габделкотдустан килгән булса, Хәйдәргә ул бабалары Хәсән һәм Әзиз (Газиз) кардәшләрдән килә. Сабый чактан ук камил мисыр мәкаме белән догалар укыган оныгына карап, бабасы Хәсән: «Кунакка барганда, минем Хәйдәр оныгымнан авызын сорап торыгыз», – дип әйтә торган була. Гаиләләрдә шундый тәртип яшәгән: ир – баш, хатын – муен. Ләкин муен сынмаган, сыгылган, бөгелгән генә. Канлы бәрелешләрдә икесе дә кат-кат яраланып, икесе дә намазларын Ватан сугышы яланнарында да ташламаган Габделкотдус белән Габбәс, балаларына да, хатынына да хөрмәт, сөю-сәгадәт аша килеп, аларны һәртөрле куркынычтан яклый, матди яктан тәэмин итә, Миңлегөл белән Рәшидә исә балаларын һәм ирләрен сирәк тугрылык белән карый, тәрбияли. Алар дүртесе дә – ике ипле һәм камил пар – барысы да тал тамыры кебек инеш ярларыннан күтәрелгән авыл балалары. Алар икесе дә саф Тукай телендә гармоник белем бирә алган татар авылының иң бөек мирасы булып тәрбияләнәләр. Бу авылларда тупрак та моңнан әвәләнә. Алар икесе дә шушы моң эчендә үзләнеп үсә...

Сабирҗан маңгаена бәреп чыккан гарьлек тирләрен сөртеп ала. Ул тир

уран бушаткандагы тир сыман кайнар салкын. Әгәр ул авылда яшәп, татарча укыган булса, бәлки, моңы да кире кайткан, үзе дә җырлый башлаган да булыр иде? Җырның башы туган тел бит!.. Их, нигә таралган аларның ата-бабалары авылларыннан болай читләргә чыгып?! Аларны сасы баракларга күкрәкләрендә күкрәгән яманташ-янарташлар чакырганмы? Ник алар үз урамнарында үз урыннарын һәм үз ураннарын тапмаган?!

Гадел Котдус – гаделлек сөйгәне өчен аны халыкта шулай дип атыйлар – сыздырып, тальянда уйный, моңлылардан моңлы әнисе Рәшидә күкрәк төбе белән моңлана. Тик беркайчан да кычкырып җырламый. Мөнәҗәт кенә әйтә. Ул да милләт җанындагы ураннан килә. Моңны Аллаһ шул рәвешле биргән. Зөһрәнең үз әнисендәге кебек моңлы тавышны башка беркемдә дә очратканы булмас. Ул тавыкларын да мөнәҗәт әйтеп чакырыр. Тавыклары да мөнәҗәт ишетми торып, җимнәрен чүпләмәс. Коръән укыган әнисенең мәкаменә бар халык таң кала. Әтисеннән күреп, гармунчы булырга теләгән Зөһрәгә әтисе кырт кисә: «Гармун – кыз бала эше түгел. Җырлар булсаң – җырла. Моң вә моңлану – пәйгамбәрләрдән калган ихтыяҗ».

Сабирҗан бу җанга якын ике җырчының тәрҗемәи хәлләрен өйрәнүгә бик күп игътибарын бирде. Тора-бара алардагы моң ташкынының куәтен билгеләү аның үз тормышының да мәгънәсенә әверелде. Ул алар турында кайда нәрсә белгән, нәрсә ишеткән, барысын да хәтере шүрлегенә салаҗыя барды. Әле генә газетадан укып белде, Хәйдәрнең нәселе исә шушы Чүмбәли күршесе Актүктән чыккан легендар җырчы Рәшит Ваһаповка барып тоташа икән. Әйтәсең бармы: нәселләр ике яктан да моң ияләре – әнисенең әтисе Азиз (Газиз) кардәш, әнисе һәм бигрәк тә сирәк тенор аһәңле әтисе юлга чыкканда, авылдан чыгу белән җырларга яраткан...

Икесенең дә «өй артындагы шомырт»лары үсә, алардан һәр яз саен миллион йолдызлар чәчкә атып, күккә вә җиргә атылалар. Икесенең дә телләрендә туган тел, җаннарында талант исә беркемгә сиздермичә бөреләнеп кенә килә, кальбләрендә – иман. Икесенең дә өй почмакларындагы шүрлекләрдә иске Коръән. Чын Адәм булу өчен тагын ни кирәк? Зур сәнгать юлына чыгып, намазга баскан Хәйдәр, әнә, көндәлегенә теркәп куйган бит: «Горурлык – башка кешегә буйсынмау теләге, мин-минлек – Аллаһка буйсынмау теләге ул. Бу дөньяда бар нәрсә дә Аллаһы Тәгаләдән һәм аларны мәхәббәт белән яратып, кабул итә белергә кирәк... Күңелең белән һәрвакыт Аллаһка омтылырга кирәк...» Әлегә кайдадыр еракта Салих-Тукайның табигый җәннәтләрендә кәҗә бәтиләрен күтәреп, көтүдән алып кайтып килгән Зөһрә сеңелкәш соңыннан бу язмаларга өстәп куяр: «Аллаһы Тәгаләгә инану Хәйдәр белән безнең икебезне рәттән куяр. Безнең кальбебез бер иде. Бәхетле җан үлгәндә дә әрәм булмый. Адәм баласы үлгәнче үзен Аллаһы белән очрашуга әзерли. Яшәешнең максаты – мәңгелектә, бакыйда шушы очрашуга әзерләнү. Дөрес яшәгән кеше вөҗдан газабы кичерми. Иманлы җанның «әрәм булуы» мөмкинме?»

Әлегә алар – урамнары уранлы, ураннары урамлы булган сабыйлар авылның катыклы-сөтле, читәнле-киртәле, умачлы-токмачлы хәятенә сыгынып үсәләр. Тыштан караганда, алардан да гамьсез, вакытлары бихисап кеше юк. Уйна да көл! Эчтән караганда, алардан да мәшәкатьле кеше юк. Хәйдәр – сабый чагыннан бодай бөртеге кебек тулы, гәүдәсе

төз, беләк-балтырлары тимер кебек нык. Ул чынлап та – хәйдәр, арыслан, димәк. Көрәшә башласа, үзе кебек малайларны унлабын бер өемгә өеп куя. Ул үзенең яшәвенең мәгънәсен барысыннан да авыррак күтәрүдә күрә. Сикерсә – барысыннан ераккарак сикерә, йөгерсә – барысыннан тизрәк йөгерә, күтәрсә – барысыннан авыррак күтәрә. Ике потлы гер. Бүген егерме, иртәгә утыз, аның иртәгәсенә кырык тапкыр. Штанга. Ул Җирнең ике Ярымшары кебек авыр. Бүген ике якта иллешәр, иртәгә алтмышар, аннан җитмешәр килограмм. Ул –Хәйдәр. Ул – Арыслан. Сигез яшьтә – ул инде атасы белән урман кисә, билен буып, ташкойма сала, озын наструк белән бүрәнә ышкылый; ун яшьтә – сигезле чалгы белән пакустан чак күренеп, печән чаба, буе мөгезенә җитәр-җитмәстән сыер асрый... Уңга селтәнә – Мин бәхетле итәм сине, халкым! Сулга селтәнә – мин бәхетле итәм сине, Ватаным! Ләкин ул әле үзенең кем буласын да белми, бары тик томанлы рәвештә сиземли генә ала. Яхшы кеше булачагын белә – монысы хак. Бу киләчәктә яхшы булачак кеше Ватанының аның белән больнис коридорында нишләячәген күз алдына да китерә алмый... Ундүрт яшендә комбайн штурвалына күтәрелә, иген ура... Чүмбәли кырларында җир сөрә, тырмый, иген чәчә, урак ура. Штурвалдан төшкәч, ул салкын чишмә суларын чиләге белән күтәреп эчеп, тамагын чарлый һәм калган суын чиләге-ние белән бөдрә чөчләренә, кояшта янган тәненә томыра...

И тормыш, нигә бу кадәр мавыкыргыч матур син?! Авыл читендәге ул балык кебек йөзгән тирән күлләр, ул кошлар белән кайнашып сайраган юан тирәкләр, ул татлы нектар – сәлсәбил җитештергән чәчкәле акланнар, салкын төннәрдә, кышларда аны җылыткан урманнар!.. Исәнмесез, мәңгелеккә исәнмесез!..

Егет әсәрләнүеннән исенә килә: аһ, комбайннан иген ташырга кеше җитми? Үзе үк урган игеннәр тутырылган житмеш килолы кытай капчыкларын колачында уйната-уйната, атлы арбага төяп, авылның ындыр табагына үзе үк ташый башлый... Аңарда уран көче, урман көче бар! Файдаланыгыз, кулланыгыз, тик исраф итмәгез, урламагыз гына! Юлда аны сызгыра-сызгыра, әрләннәр каршылап-озатып кала. Сызгыру да моң. Исәнмесез, моңлы әрлән туганнар!.. Кышкылыкка нан-азык хәстәрләп калыгыз!..

Аның бер минут та буш вакыты юк икән бит. Әйе, ихатасында ике потлы герләре көтеп кенә ята. «Өй артында шомыртым бар!..» Шул биек шомырт астында гына – турник. Бүген егерме күтәрелсәң, иртәгә – утыз тапкыр күтәрелергә, бүген син анда ун тапкыр «кояш» булып әйләнсәң, иртәгә – егерме тапкыр әйләнергә бурычлысың. «Их, үзем каен булсам!..» Көн саен. Күзгә чалынган саен. Көннән-көн күбрәк, ешрак, авыррак. «Сандугачым икәнсең, җитәр көзләр – китәрсең!..» Менә ул штанга һәм гер күтәрү буенча Түбән Новгород өлкәсе чемпионы исемен дә яулады. Чаңгыда беренче, йөзүдә беренче. Әнә ул – таза буйлы, төз гәүдәле, төскә-биткә сирәк, гали батыр кебек киң яурынлы, гладиатор кебек такта күкрәкле, алга чыгып торган иякле-борынлы мондый егет асылы татарда гына түгел, башка мәмләкәтләрдә дә бар микән?! «Җаның теләмәгәннәргә булсаң, нихәл итәрсең?» Тукта, кем җырлый моны?

Әле үзенең никадәр зур тарихи шәхес буласын, татар сәнгатендә нинди урын тотачагын уйлап та карамаган үсмер, «көчле булу»ның фәннилектән

ерак торган максатына тугры калып, күз-колак, контрольдән читтә, үзен авырдан да авыр сынаулар белән изә, җәфалый, газаплый, күтәрә-төшерә, чәбәкли һәм таптый, шулай итеп, киләчәк язмышында фаҗигале роль уйнаячак һәм соңгы чиктә үзен бик иртә алып китәчәк артериаль басым – «гипертоник криз» дигән хастасын хәзерләгәнен белми дә...

Сабирҗан күз алдына китерә, егет күкрәгендә типкән уран дәһшәтен куярга урын эзли. Бер караганда, бу дәһшәт һәркемдә булырга тиеш кебек.

Ә Зөһрә ничек? Үтә дә җиңел сөякле, бик тә тәвәккәл, Җир шарын йөгереп үтәргә әзер булган Зөһрә шулай ук бишмәтен киеп, калын чәч толымнарын аркан кебек итеп тышка чыгарып салып, билен буган да әтисе белән печән, утын әзерләп, урманнан кайтып керми. Биш кыз баладан соң өлкән кызлары егерме бергә чыкканда, бәлки, монысы малай булыр дип көттерә-көттерә табылган балалары да кыз булып чыкты бит. Ләкин малайларга биргесез ул Зөһрә. Таудан чаңгы шуганда, аны тотып тыеп булмый, физик эшкә дигәндә, кулында очкын уйната!.. Шуңа күрә Котдус-кардәш кызын үзеннән калдырмыйча урманга йөртә. Нәкъ Такташның «Урман кызы» булды инде ул. Теге башыннан шытырдатып тотып, аркылы пычкыны да җәһәт кенә тарта. Әтисенең яраткан агачы имән булды. Зөһрәсен дә имәнгә охшатып, нык итеп тәрбияләде. Әле менә күптән түгел икәүләп сарай салдылар менәтерәк. Иңнәренә көянтәсен салып, авыл читендәге челтер чишмәләр – су юлыннан кайтып керми. «Ай югары, ай югары, айга менәсем килә...» Бар, менеп кара. Тиз генә мендең, ди. Көянтәле Зөһрә-кыз кебек, үзе дә айга очып китәр кебек тоела.

Куркыныч та, мавыктыргыч та. Анда баргач, кире кайтып буладыр бит инде ул?! «Айга менеп, түбән карап, сезне күрәсем килә...» Тукта, кемне? Кемне күрергә? Кемне бик күрәсең килә? Улакларга шабырдатып су коеп, малларны эчергәндә дә, җиләк-җимеш, яшелчәләрне сугарганда да, хәтта самавырга су салганда да айга карый ул. Ай үзенеке – аны Ай барыбер үзенә алачак!.. Һәм ул аннан кемнедер күрәчәк. Бу «кемдер» аны бирегә китереп тә куячак!..

Их, ул кышкы кичләрдә кич утырулар! Күрше апалар керә, кайсы йонката, йон эрли, кайсы бәйләм, кайсы челтәр бәйли. Чигү чигә. Зөһрә дә челтәр бәйләргә ифрат та ярата. Ап-ак җепләрдән мендәр кабына дип бәйли ул аларны. Тышта Кыш-бабай да тәрәзә пыялаларына челтәр бәйләп, сурәт төшерә. Әтисе гармунда «Хафизалам иркәм»не уйный. Зөһрәне җырлаталар. Апалар да, әнисе дә аңа күрсәтмичә генә елыйлар. «Зөһрә, үскәч, кем буласың?» – «Шәфкать туташы». «Нигә?» «Әти-әниемне, апаларымны чирләрдән саклыйм!» «Җырчы булмыйсыңмыни?» – «Юк!» «Нишләп, сине бит бар тирә-як хәзердән үк җырчы дип белә!» «Белсә ни!»

Өченче сыйныфка кадәр генә укыды ул Салих-Тукайда. Аннан сигезенче сыйныфка кадәр сигез чакрымдагы Иске Дөрешкә йөреп укыды. Көн саен. Чаңгыда, биләсәпиттә. Кара бураннарда үзенә тап булган кара бүреләрнең күзләренең туң боз кебек зәңгәр икәнлеген үзе күреп инанды ул. Тугызынчы-унынчы сыйныфларны исә кайчандыр бөек җырчы Илһам абыйсы Шакиров укыган Теләнче Тамак мәктәбендә тәмамлады.

...Чүмбәлигә бер тапкыр Казаннан артистлар килде. Атаклы җырчылар Зөһрә Хисмәтуллина, Идеал Ишбүләков, музыкант Марс Макаров...

Җанында кайнаган кичерешләрдән чиксез дулкынланган Хәйдәр иң алдагы рәтнең уң канатында утыра. Былтыргы концертта да шушында утырган иде күзләреннән моңсулык агылган бу егет. Нәрсә тели ул? Менә бу юлы, концерт бетүгә, үзендә батырлык табып, сәхнә артына үтте һәм җырчыларга үз башкаруында «Карурман»ны тыңлауларын үтенде. Марс Макаров янына килеп, баянында тональлекнең башлам басмагын да күрсәтеп бирде:

– Менә шушыннан, абый...

Җыр башлану белән аңлашылды: аларның алдында сирәк сәләткә, инде хәзердән үк сәхнә культурасына ия булган әзердән-әзер лирик-драматик тенор басып тора. Әмма ул татарның Павароттие булачак дип, беркем уйламый. Итальянча күкрәк диафрагмасы ифрат та киң, тын басымы ифрат та көчле, опера җыры буенча белем алган сыман осталык белән җырлап җибәргән егетнең аһәңе иске клубның түшәмен җимерердәй булып, диварларын калтыратты.

– Син, энем, укымыйча да җырчы булгансың инде. Әмма консерваториягә кереп, музыкаль белем дә алсаң, тагын да әйбәтрәк булыр иде... – диде консерватория профессоры Зөләйха Хисмәтуллина.

– Мондый халыкчан тавыш белән консерваториядә әллә нәрсә майтара алмассың, – диде Идеал Ишбулатов. – Сезгә турыдан филармониягә барырга кирәк, анда белем сорамыйлар. Аннан, син бераз борынга җибәреп тә җырлыйсың икән, энекәш...

Әйтсә әйтә инде ул кайвакыт безнең юл башында очраган Идеалларыбыз!..

Германиядә танкист булып хезмәт иткән егетне, көчле күкрәк тавышын танкодромда ишетеп-танып, хәрби җыр һәм бию ансамбленә солист итеп алалар. Һәм ул – солдат армиядән кайткач, медицина училищесе тәмамлап, шәфкать туташы булып эшли башлаган Зөһрәсе белән Казанның кап үзәгендәге консерваториядә атаклы татар композиторы Нәҗип Җиһанов канаты астында очрашып таныша. Дөрес, профессорлар Зөһрәне тыңлагач та «Консерваториягә керергә киңәш итмибез. Сездә халыкчан тавыш», – дип, кире борып җибәрергә дә күп сорамыйлар. Булачак «йолдызларның» икесен дә – әле алар бер-берсен белмиләр дә югыйсә! – консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов үзенә чакыртып ала. Дөрес, Хәйдәр аңа уку елы башланганнан соң өч айга диярлек соңга калып элгә. «Сездә лирик-драматик тенор, – ди ул Хәйдәргә. – Сез – татар операсы җырчысы. Сез шундый ук җегәрлек белән татар халык җырларын да башкара алачаксыз. Әмма укырга кирәк...» Зөһрәгә исә «Бездә әлегә милли җырчылар бүлеге оештырылмаган. Сезне опера вокалы бүлегенә эксперименталь үрнәк рәвешендә кабул итәбез...»

Их, ул чактагы куанулар!.. Алар – студентлар!.. Бер-берсен белмәгән-күрмәгән ике талантны Аллаһы Тәгалә үзе кавыштыра дип әйтергә мөмкин. Тик бу очракта «эксперименталь» рәвештә түгел. Чынбарлыкта. Хәйдәрнең куен иркәсенә охшап тәбәнәк күренгән Зөһрәсенә әйткән беренче сүзе: «Кара, син нинди бәләкәй икәнсең!» Зөһрәсенең Хәйдәренә беренче әйткән сүзе: «Кара, син нинди биек Отелло икәнсең!» Әйе, Хәйдәр алыптай таза гәүдәле. Кеше алдында бөгелеп-сыгылып, комплиментлар сибеп бармый. Үзенең тарихи миссиясен яшьтән үк белә. Кирәк чакта бу хакта шаярып кабатларга ярата: «Минем үзегезгә кайчан килгәнемне язып куегыз. Кирәк

булуы ихтимал...» Менә шундый горур мишәр. Үзе бик тә ярдәмчел, әмма кешедән ярдәм сорау – аның өчен түбәнлек.

Ике арадагы дуслык тора-бара тирән мәхәббәткә әйләнә. Хәйдәрнең күзләрендә мөлдерәп торган ниндидер сихри сагыш үзенә тарта аны. Каян бу кадәр сагыш? Каян килә ул. Аннан – ягымлылык. Сихри елмаю. Сирәк, халыкчан милли акыл. Нәрсә, «суперталантлар» шундый буламы әллә? Аңардагы сиземләү, пәйгамбәри тоем. Аерым яшәсәләр дә, консерватория гомумторагының газ плитәсендә аш пешә. Уртак аш. Уртак чәй кайный. Озак та үтми, алар Иске Дөреш авыл советында язылышалар... Йөрәкләр куанычтан бер булып тибә, тау кырлачларында алтын кылганнар тирбәлә, тулган ай исә Зөһрәнең чиләгенә утырып коедан чыга... Сәхнә. Аh, сихри сәхнә. Сәхнә алдында нәрсә: сине чәбәкәйләп каршылаган тамашачымы, әллә көнчеләр упкынымы? Бар, бел. Чамала. Милләт үзе биргән сәхнә. Сәхнәгә чыгу – әйе, упкын каршына чыгып басу. Сәхнә ул гел упкын алдында әйләнеп тора. Бер алдын, бер артын күрсәтә. Шунысы куркыныч. Ләззәт тә, газап та...

Зөһрәнең сөю белән илhамланып, милләткә бүләк иткән беренче энҗеләре – «Туган тел», «Әллүки», «Сәгать чылбыры», «Курыкмагыз, кошлар»ы, Хәйдәрнең – «Кыр казы», «Төннәр буе йоклый алмый ятам...», «Гүзәлем», «Яңа кара урман», «Озата барма»лары...

Милләттә булмаган хәл: аңа берьюлы бер гаилә булып, ике бөек җырчы килде. Гарәпчәдән күчергәндә, баhадир-арыслан ир-егет Хәйдәр hәм ачык йөзле кыз бала Зөһрә.

Аh!.. Шул ук тулган ай Зөһрәнең чиләгенә утырып, коега чума...

Берәүгә дә әйтмәгән борчуларын чишә аңа сөйгән яры. Үзенә тиеш булмаган үлчәүдә чиксез авыр йөкләр күтәргән баhадир егетнең яшьлегендә кан тамырларына көч килгән, шуның нәтиҗәсендә кинәт кенә кан басымы күтәрелә дә куя икән. Сабирҗан аңлый: Хәйдәрнең дә үз Чирчиклары, үз Чимган рудниклары булып, ул да башкалар өчен уран бушаткан. Шул ураннан бу моң. Мондый өзлектергеч хезмәт, медицина теле белән әйткәндә, артерияләрдәге кискен тромбоз халәтен якынайткан. Егерме биш яшьлек Хәйдәренең күкрәк кенәгәсенә язып куйган юллары Сабирҗанны тетрәтеп сискәндерде: «Җанның чистарынуы газап, михнәт, ахыр чиктә, үлем аша килә... Мин озак яшәмәм, ахры...»

Көпә-көндез күк күкри: Ләйлә-Мәҗнүн, Таhир-Зөhрә, Ромео-Джульетта, Хәлил-Галиябанулар мәхәббәтенә тиң мәхәббәт hәм күпкә, бик күпкә алдан үкенечле, йөрәк төенен өзә торган сискәнү!.. Йа, Хода!.. Алар бит әле сөешеп тә туймадылар! Кайсы молекула, ниткән янарташ, нинди атомнан атылып чыккан, гомумән алганда, каян килгән бу сизенү?! Әле аларга, кеше өстеннән кайтып кермәгән, үзләренең бердәнбер уллары Айратны тәрбияләрлек үз почмаклары да булмаган яшь гаиләгә – ике талантка дөньяга чыгарга, үсәргә, милләтне hәм үзләрен чын-чыннан үлемсез итәргә кирәк! Ә бала... елый!.. Ул яратып елый. Үзләренә күк сорап, җир сорап, ил сорап, җыр сорап, нан сорап елый!.. Җир йөзендә hәркемнең үз урамы, үз ураны, молекуласындагы үз атомы бар. Моның горурлыгыннан башка бернинди дә гарьлеге юк. Бәхет белән кайгы-хәсрәт аралаш!.. Мондый моң – чиге булмаган халыкчанлыкның энергия чыганагы. Аның

матди молекуласында нейтронны протоннан, изотопны изотоптан аерып, дөньяны яктыртырга һәм яндырырга, көл итәргә мөмкин. Ул яктырта һәм сүндерә ала. Шулай итеп, урам моңыннан уран моңы яратыла. Бу энергия Пәйгамбәребездән шулай килгән, шулай булачак, Хәйдәрем!.. Синең исәнлегеңне генә бирсен!.. Дәрес вакытында да, репетиция вакытында да, сәхнәдә җырлаган вакытында да дарулы шприц тоткан кулы белән Хәйдәренә ярдәмгә килергә әзер Зөһрәсе нindидер яңа, мәңгелек чаралар эзләп, авылына, үзен сыендырган урманнарына кайта, көннәр буе Хәйдәрен яшәтәчәк тере тамыр – гомер тамыры, яшәү тамыры – валериан тамыры эзли. Зөһрәнең тормыш тамыры эзләгән бармакларында әлегә йөзек-балдаклар юк. Алар йөзекләрне бармакларына халыкка зур җырчы булып танылганнан соң гына кигерешәчәк. Тагын да кайсы кавем балаларында бар мондый сабыр итагатьлелек!..

Җидегән чишмәләргә йөзек салдым, йөзек салдым.
Җидегән йолдыз күреп калсын, дип.
Җанкай-җанаш алсын да куансын,
Вәгъдәләрем булып, вәгъдәләрем булып калсын, дип...

Бу – Зөһрә. Күңел тирәгебездәге сандугач. Өй артындагы шомыртыбызның былбылы.

Аһ, бу моң!.. Керепләр батасың!.. Сабирҗанга менә шушы җырны тыңлау өчен генә дә Ватанына иртәрәк кайтасы булган!.. Үзе бушаткан уранның мәртәбәсен үзенә даулыйсы, табасы булган. Нәрсә, санаулы инсаннар, санаулы өммәтләр генә, кем әйтмешли, «син, мин һәм Мөхәммәтәмин»нәр генә хуҗа булырга тиешме мондый буранлы уранга? Югыйсә җиргә бит һәркем үз урамы һәм үзураны белән туа! Сабирҗан аптырый: егерме ел ничек итеп бу җирне күрми, бу җырларны тыңламый яшәгән ул?! Ә нигә ул чакта аның туган авылы урамына чыгасы, аяктагы кешеләренә күренәсе килми? Дөньяны, тормышны чиксез ярату һәм шул ук вакытта шул ук чынбарлыкка күренергә теләмәү. Боларның сәбәбе нәрсәдә, болар икесе ничек тоташа? Тукта, бу нинди көч җирнең нинди кан тамырларыннан чишмә булып саркып чыга да, йөрәкләрнең кайсы кан тамырларыннан мондый моң булып ургыла? Менә шушы үрләрдә, басынкы битләүләрдә, битләү-кул кушырымнарында татар мандолинасы кебек тын гына чиртеп яткан татар чишмәсе – Җидегән чишмә, татарның кимендә мең еллык тарихы, ягъни уран үзәге түгелме? Әнә, Җидегән чишмә өстеннән кызларның кыйгач кашы кебек нечкә сызык Ай күтәрелә... Бу кадәр моңны бар итү өчен ничәмә-ничә буын Сабирҗаннар рудникларда агулы уран бушаткан, комлыклардан сары арыклар сузган, ыжгыр салкыннарда лашман тарткан, бозлы яңгырларда сабан сөргән икән? Теләсә нинди, юк-бар, чүп кавем тудыра аламы, семәрли аламы бу моңны? Юк!.. Мең тапкыр юк!.. Бабаларыңны зурлыйсың киләме? Җидегән чишмәгә бар! Балаларыңны зурлыйсың киләме? Җидегән чишмәгә бар! Татар ул үзе Җидегән чишмә. Татарның яңа тарихы Казан алынган көннәрдә туган һәм үлемсез Рәшит Ваһап, Мәгафүр Хисмәтулла, Илһам Шакир тарафыннан башкарылган «Озын көй», «Җанкай-җанаш», «Рамай», «Хафизәләм-иркәм», «Кара урман» җыруларыннан соң бар булган «Җидегән чишмә»дән башлана иде. Сабирҗан, кем әйтмешли, «үзбәк татары», «нугай», сизенә: Гомәр

абзый Бәширгә бу җырның сүзләрен, Сара апа Садыйковага көен, җырчы Зөһрә-сылу Сәхабиевага аның күкрәк моңын Аллаһы Тәгалә үзе индергән. Бу Күкләр бүләге. Мондый халыкның уранлы урамнан кинәт кенә югалуы мөмкинме?

Дулкынлануыннан нишләргә белмичә, Сабирҗан яңадан кешесез тереклек таплары белән сурәтләнгән тәрәзә каршына килде. Пыяла бу юлы тазарак, чистарак күренде. Бәрәч, әнә тегендәрәк, нәрсә ул? Тәрәзә аша аңа сәрби куакларыннан бәрәңге бакчасына сузылган аралыкта серәеп, тере кое сиртмәсе карап утыра иде. Аларның коелары бар иде микәнни? Авылына кайтып-китеп кенә йөргән «эмигрант» моны хәтерләми дә. Аякларының авыртынуын сизмәгәндәй, ул болдырга сикерде, болдырдан яшел бәбкә үләне аша коймасы аугалаган бакча каршындагы кое сиртмәсенә таба атылды. Әйе, коеның сиртмәле баганасы бар һәм алар исән икән; сиртмәнең чиләксез бавы, дөресрәге, бау урынына кулланылган дилбегә, ул да исән, әмма өзелгән җиреннән җимсез иләк кебек җилдә чайкалып, баганага уралгандай итә дә яңадан ычкына, уралгандай итә дә яңадан ычкына... «Яңа чиләк эләргә кирәк булыр». Бу фикердән Сабирҗан дерт итте. Ул коеның кыргый үлән белән буыла башлаган бугазына карады. Аста, тирәндә, якты сулар, суларда аның йөзе чайкала. Сулар исән икән. Үзе дә исән икән. Әнә күзләре чекерәеп яна, тик җырламыйлар гына. Кинәт кое авызыннан кечкенә таш төшеп суда чупылдады. Ул тынычсызланып боҗраланган су көзгесендә үзен танымады. Йөзендәге күзләр, борын, яңаклар берсе өстенә икенчесе менеп җимерелә иде. «Исән икәнмен». Кызык, нәсел, милләт ничә буыннан соң корый икән? Бездә булган уран аларда юк микәнни? Туган тел чишмәсе ничә буыннан кибә-коргаксый икән? Ул яшьләнгән карашын өскә күтәрде. Карашы иске йортның чалшайган нигезендә туктап калды. Нигезнең уртадагы өлешеннән һәркайсы куна тактасы кебек ап-ак, зур, яссы ташлар ишелеп төшкән. Гүя ябынып яткан юрган астыннан янбашына салкын һава өрде. «Бу ташларны коймалап төзәтәсе булыр». Шулчак Үзбәкстанның сары арыклары арасында төенчек кочаклап калган Мәрфугасы күз алдына килде. Нәрсәдер исенә төшкәндәй, ашыгып, кире өенә керде. Магнит тасма җырлаудан туктаган иде. «Магнит туктаса да, безнең Зөһрә туктамый ул», диде Сабирҗан эченнән. Һәм җырны яңадан әйләндереп җибәрде.

**3**

Биредә яңгыраган һәр аһәң мәхәббәт, котылгысыз язмыш тарафыннан бездән тартып алынган мәхәббәтне кире кайтару турында иде. Сөю. Нәрсә ул? Ул намус, гаделлек хакына авырлыкларны җиңүме, әллә җиңеллек хакына авырлыклардан җиңелүме? Мәхәббәтнең, сөюнең кавышу йөзеге бирәү генәме? Бирәү генә булганда, нигә ел фасылы дүрт тә, нигә язлар кабатлана? Адәм баласы мәхәббәтнең бу йөзеген ничә мәртәбә киюе мөмкин? Ул бит аны бары кия генә ала, сала алмый, шулай бит? Зөһрә-сылуның «Җидегән чишмә»сендәге йөзек аның уйларын әллә кайларга алып кереп китте. Моннан берничә көн элек кенә авылының бер ялгыз хатыны Салиха белән икесе арасында яралган серле төен зиһененнән бер генә минутка да чыкмыйча аны газаплы вә ләззәтле уйларда бимазалый иде. Әллә ничек кенә килеп чыкты инде шунда. Йорт-җирен юыштырып-

җыештырып чыгарга дип чакырткан иде ул аны. Бушка түгел, әҗерен түләп. Әллә ир-ат назына сусаган хатын арбап алды, әллә үзен шунда шайтан котыртты... Юк, мондый адымга барырга хакы бар идеме, дигән сорау борчымый иде инде аны хәзер. Буласы булган. Гомер иткән сөекле Мәрфугасы алдында тотачак җаваплылыгы да куркытмый. Никахсызнисез бу эшкә хакы бар идеме? Шул гына. Болар барысы да аны борчыса да, алар, соңгы чиратта, үз язмышына үзе хуҗа булуы, теләгән хәлдә, аерылу-кушылу мәсьәләләрендә исламият, шәригать кануннары ярдәмендә мәсьәләне үзе генә дә хәл итә алуының гамәли бер чагылышы гына иде. Ул гомер буе бер мәхәббәткә табынып, бер генә гаиләдә, бер генә хәләл җефет, бер генә хатын белән яшәп, өч кыз бала үстергән, начармы-яхшымы, аларны башлы-күзле иткән, шул нияткә хезмәт итүдән башка юлларны, борылышларны күз алдына да китермәгән «бер генә мәхәббәткә тугры» Сабирҗан илле җиде яше өстендә, аның уенча, унҗиде яшеннән белергә тиешле булган иң «гади» сөаль белән башын изә иде: нәрсә ул мәхәббәт? Мәхәббәтле булдымы ул, әллә мәхәббәтсезме? Мәхәббәт дигәне берәү генә буламы, әллә кабатланамы? Кабатланса, Мәрфугасыннан башка икенче бер хатыннан, бу очракта Салихадан, берәр ир бала тудыра алыр идеме? Ала, тик балаң ятим генә үсмәсен!.. Әллә мәхәббәт дигән нәрсәнең мондый чиктән үткәрми торган чиге, ары кертелми торган коймасы бармы? Мәхәббәт – иманмы, әллә мизгеллек хис кенәме? Мәхәббәт – язмышмы, әллә язмыш – мәхәббәтме? Әллә болар икесе дә бергәме? Әллә мәхәббәт берәү булып, язмышлар күп буламы? Язмышлар күп булганда, алар шул ук бер мәхәббәттән яраламы, әллә башка бер тойгы-гамәлдәнме?

Мәхәббәт – бер вә бердәм, әмма ул – тирән тойгы гына, димәк, бер, мәңге бер булган мәхәббәтнең язмыш чишелешләре бихисап булуы мөмкин, дигән фикергә килде Сабирҗан әле җыештырыла гына башлаган иске өендә. Мәхәббәт бер вә бердәм, әмма аның тамырлары, бөҗралары гына төрле, дип куәтләп куйды тагын да. Һәркемнең үз матдәсе, үз ураны, үз атомы, атомның җимергеч һәм яшәрткеч көче бар. Изгелеге һәм явызлыгы. Кайсын куллану – синең эшең. Изгелеген куллансаң, тормыш изгелеккә, явызлыгын куллансаң, явызлыкка тартыр. Аларның барысының үзәген яктыртып, чалкан туган ай – иман үзе ятадыр. Намус ятадыр. Мәхәббәт һәм ятимлек – дошман көчләр. Мәхәббәт үтерелгән җирдә ятимлек ярала. Шуңа да кайда сугыш, шунда ятимлек. Шушы мәлдә аны тагын уранның җир язмышындагы урыны, сугыш һәм тынычлык мәсьәләсе борчый башлый. Уран галәмнең иң карт, иң борынгы, иң беренчел казылма байлыкларыннан санала. Атом төшенең бүленеше аңа энергия бүләк итә. Бу бүләк кешенең йөрәк ташыннан моң дигән гыйбрәтле вә гыйззәтле төшенчәне китереп чыгара. Уран – шул ук моң, моң – шул ук уран ул. Уңга тартсаң – моң, сулга тартсаң – атом бүленеше. Уңга тартсаң – тормыш, сулга тартсаң – үлем. Үзбәкстанның ялкынланып янган кояшы астында тирләп-пешеп, бу нечкәлекләрне төшенергә дә өлгерә алмыйча уран бушатканда, Сабирҗан төсләрен үзгәртеп тора торган шул аксыл яшенташ белән берлектә моң энергиясен, атом изотобын, хәтта ки атом бомбасы энергиясен бушатканлыгы турында уйлый да алмаган бит! Кемдер моңлы кешене бәхетсезгә юрый. Юк, дөрес түгел. Моң иясе – бәхет иясе. Атом иясе – бәхет иясе. Тик кешелеккә адәм затлы тигезлеккә генә ирешергә

кирәк. Дөньяның йөзләгән кавемнәреннән бары тик биш-алты кавемгә генә атом хуҗасы хокукын бирү уранны урлау, моңны урлауга тиң булган җинаять. Моны Халыкара хөкемнәр хәл итәргә бурычлы. Табигатьтән тигез, ирекле булган атом төше белән ирексезләрне, түбәнсетелгәннәрне куркытып яшәү тигезлек арбасының күчәрен сындыра. Менә Сабирҗан шул моңны эзләп, ата-бабасы Ватанына кайтты. Бәлки Ватан аңа туган моңнарын да кайтарыр?!

Сабирҗан Җир шарының алты кыйтгасын күз алдына китерергә тырышты. Җир йөзендә нәрсә бар, адәм баласының күзе нәрсәгә илтифат итә – мәһабәт калалар вә салалар, таң калырлык биналар вә каралтылар, юллар вә аэропортлар, мәгърур һәйкәлләр вә стадионнар, борынгы китаплар вә китапханәләр, утыртылган, үстерелгән агачлар вә чәчкәләр һәм болар арасында иң мөһим, иң бөек казаныш – атабыз Адәм галәйһиссәлам вә анабыз Һаваның балалары булган миллиард-миллиард кешеләр – болар барысы да Аллаһыдан килгән мәхәббәт җимешедер. Бу байлыклар барысы да мәхәббәт вә Бала хакына иҗат ителгән. «Мин сине яратам!» – дигән бер җенеснең вәкиле булган Адәмзат икенче җенес вәкиләсе Адәмиягә. «Кабул итеп ал, мин дә сине яратам, бу минем сиңа һидаям!» – дип җавап биргән Адәмия.

Илле җиде яшендә ата-баба нигезенә кайткан Сабирҗан хәзер Сократтан ким булмаган философ иде. Җир йөзендә хәтта иң көчле үтерү кораллары – безнең авыл урамы уранынннан алынган атом бомбалары да мәхәббәт хакына көчәнә-көчәнә уйлап табылган, чөнки хакимнәр аларны ярышып: «Минем мәхәббәтем синең мәхәббәтеңә караганда көчлерәк, чистарак, камилрәк, әгәр син шуны инкарь итсәң, мин синең үзеңне шартлатам һәм җиреңне басып алам!» – дип раслау хакына ясаган һәм басып та алган... Ләкин иң көчле дәүләтләр дә җимерелгән, әмма Мәхәббәт исән калган. Яшәсен Мәхәббәт!.. Мәхәббәт яңадан яратылган, Мәхәббәт кабатланган, Мәхәббәт хакына иң даһи иҗатчылар җир йөзендә кешелек күрмәгән биналар, әсәрләр, могҗизаи корылмалар төзегән. Шулай итеп, Мәхәббәт-Иман берәү булып калса да, балаларда вә оныкларда бөҗраланып, аның кабатланыш-язмышлары төрле вә сагынычлы булган...

Тукта, нәрсә ишетә? Кем җырлый? Аһ, Хәйдәр!..

Таллар тагын талпындылар!..
Иеләләр, күрәсең;
Чәчләреңне сыйпап синең
Сөенәләр, күрәсең...

Талгын гына агып яткан Җидегән чишмәнең чулпы чыңнарын гүя шул чишмәне утырган таллар эләктереп алалар һәм күкләргә талпыналар... Иелеп талпыналар! Тукта, атом, шартламый тор! Хәер, бабайлар иелгән башны кылыч кисми дисәләр дә, кайчакта иелә барган саен башлар киселә бара... Иң бөек, горур шагыйрьләр дә иелгән башлары белән зинданнарда утыралар бит әле. Җыр сүзләренең авторы шагыйрь Хәсән Туфанны гына ал. Совет властеннан төрмә алса да, шул ук властьтан орденнар да алды ул. Әмма халыкның үз шагыйрьләре дә шул ук халыкның «дошманнары» булып табылган. Менә кайда ул уран рудасын бушатканнар! Зинданда утырган шагыйрь сөйгәненең чәчләрен сыйпый алганнары өчен хәтта

таллардан, җилләрдән көнләшә биреп куя. «Сөенәләр, күрәсең...» Никадәр өзелми калган нечкәлек! Мондый нечкәлекне Сабирҗанның бүтән төр төрки шигърият-музыкада очратканы булмады. Юк, ул моны башка милли моңнарны кимсетергә теләүдән әйтми. Белгәнен генә тәкрарлый. Әнә, тын сукмактагы таллар өстеннән кызларның теге кыйгач кашы кебек сызык Ай күтәрелә... Мондый җырны тудыру өчен тарих тәгәрмәче астында изелеп, руда астында ишелеп тә, исән калу кирәк. Сез ишетәсезме?

Таллар тагын талпындылар?!

Без яшәргә тиеш!

Әнә Хәйдәрнең бәрхет моңлы тавышы киң күкрәкләрдән ургылып, күкләргә аша һәм, бөтерелә-бөтерелә, иң югары ноктасына менеп җитеп, тургайга әйләнә? Аннан, бу үз хокуклары хакына көрәшкән өчен Себергә «катырга» куылган, моңнары хакына чит мәнфәгатьләр өчен канлы сугышларда кырылган, шахталардагы күмер катламнары, коммунизм төзелешләренең руда тачкалары астында изелгән миллионнарның аһы булып, җиргә гөрселди!.. Соңгы чорлардагы йомшарган татар җырына хас булган вак көнкүреш таллыкларының, мескенлекләренең бередә әсәрәсе дә юк. Шуңа да, бу җыр гына түгел – җыру. Мондый җырулар «башлары иелгән» килеш тә көрәшкә чакыра. Бу горурлык, пентатоник ягымлылык, лирик өзлегү белән сугарылган драма кара көчләр алдында бирешмәгән кеше ихтыярына дан җырлай, залимнарның битенә лачкылдатып төкерә!..

Яктырт, атом, моңландыр, атом, тик җимермә, үтермә генә!

Зөһрәнең дүрт минут җиде секунд барган «Җидегән чишмә»се, Хәйдәрнең алты минут унбиш секунд барган «Тын сукмакта тал тирбәлә»се, җәмгысе ун минут егерме ике секунд барган ике җыруда Сабирҗан өчен татар моңының гына түгел, татар дигән милли шәхеслекнең мең еллык яшәеше чагылыш тапкан иде. Сабирҗанга шушы ике җыр Зөһрә һәм Хәйдәрне бер Җирнең, бер минең ике ярымшары, бер йөрәкнең ике яртысы итеп күрсәтте. Гүя алар шушы бер тәрәзәнең ике өлгесе, бер гәүдәнең ике кулы, ике аягы, ике күзе булып яратылган. Зөһрәгә исә, Аллаһы Тәгалә алиһәи хатын-кыз буларак, алтынчы, әгәр кирәк икән, җиденче-сигезенче тойгыларны да биреп, ирнең сөйгән яры, тугрылыклы, сүзсез буйсына торган колы, аның һәр теләк-ихтыяҗын үти торган хатыны, түземле бала анасы сыйфатларын да һидаять иткән иде...

Сабирҗан газны кабызып, чәй кайнатты. Ясаган чәе суынды. Кинәт ул өшеп киткәндәй булды. Җылынырга теләп, тагын кайнатты.Тагын ясады. Тагын суынды. Тәрәзә аша кое сиртмәсе, сиртмәсендә бидрәсе. Бидрәсендә һаман да шул уран тирбәлә иде...

Хәйдәр!.. Сарманнан алтын толымлы Салих-Тукай авылы кызы сине үлеп ярата һәм сиңа гомерен багышларга әзер!..

Зөһрә!.. Нижгар якларыннан татарның чын бер талантлы егете сине үлеп ярата!.. Ул сиңа гомерен багышларга әзер!..

Нинди бәхет!.. Бар микән җир йөзендә алар кебек туры килгән пар?!

Алар тере һәм тере булмаган табигатьтә плюска – минус, минуска плюс буларак яратылган иде.

Инде гаилә корып өлгергән ике яшь җырчының татар сәхнәсенә, киң мәгънәдә әйткәндә, чиксез дөньяның җыр сәхнәсенә басуы йөрәктәге

б а с ы м н а н башлана иде. Бу кадәр басымга түзәргә кирәк! Басымга түзү өчен әле әүвәлдә сәхнә дигән серле нәрсәнең үзенә чыгып басарга кирәк бит. Мондый моң басымы тантаналы танылу аша гына түгел, ә бәлки, моңача күрелмәгән изелү, түзем һәм сабырлык аша киләдер. Җаннан тышка чыгарга дип талпынган моң басымы! Җирдә, һавада, утта һәм суда!.. Көндә, төндә, кичтә һәм таңда шәфагында да басым!.. Басым һәркайда!.. Туганнар һәм урманнар, авыллар һәм давыллар арасында да басым!.. Авыл сәхнәләрендә һәм КамАЗ төзелеш мәйданнарында. Уфада һәм Ленинградта. Мәскәүдә һәм Омскида. Һельсинкида һәм Владивостокта. Консерватория аудиторияләрендә һәм әле студент чакта ук җырлый башлаган Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә... Ил буйлап гастрольләргә чыкканда, туксанышар-йөзәр концерт биргәндә. Ачлы-туклы, ялсыз-нисез сикәлтәле юлларда, кайда ат арбасында, кайда тузанлы машина әрҗәсендә, кайда җәяү чаптырганда. Кем, нинди басымнар, нинди уран балкышлары түзәр бу кадәр сынауга? Комбайн бункерына аккан иген, җидегән чишмәләрдән ак чиләкләргә аккан көмеш сулар басымы көне-төне тынгы белми башкарылган моң басымы белән алышынды. Тукай... Җәлил... Пушкин сүзләренә язылган җырлар-романслар кирәк!.. Чайковский, Рахманинов, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Ренат Еникеев, Фасил Әхмәтов әсәрләреннән яңа программалар, яңа яшь җырчылар, композиторлар кирәк!..

Алар сәхнәләргә чыгу белән залларда чебен очкан тавыш та ишетелгәндер. Бу заллар концертлардан соң яртышар сәгать кул чабулардан айный алмагандыр. Шуңа күрә дә утыз-утыз биш яшьләрдә алар Татарстанның атказанган, бераздан – халык артистлары, Хәйдәр исә Россиянең атказанган артисты булып та җитешкәндер. Җир йөзенең төрле почмакларыннан килгән хатлар. Әмрикә, Төркия, Финляндия, Венгриядән чакырулар... Сабирҗанга Хәйдәрне икенче бөек җыручы Радик Гәрәевнең Уфаның опера театрына эшкә чакыруы билгеле. Финляндия милли операсында тыңлану һәм башка һәм башка күңелле ядкарьләр көткән бит аны!..

**4**

Басым – җанда. Басым – тәндә. Басым – канда. Хәйдәр күп кенә спектакльләрне югары кан басымы хәлендә башкарырга мәҗбүр иде. Сабирҗан бу хакта Татарстан һәм Башкортстан матбугатындагы язмалардан укып барды. Кирәген кисеп алып, теркәп тә куйды. Хәйдәрнең кан басымының күтәрелү сәбәбен табиблар озак вакыт билгели алмыйлар. Ниһаять, бу ачыкланган да сыман була. «Бөер яны бизләрендә яман шеш», имеш. 1978 елда Мәскәүдә Хәйдәргә операция ясыйлар. Зөһрә төннәрен-көннәрен Хәйдәре янында. Әмма пычак астында гипертония төене чишелми, ни кызганыч, чуала гына... Әмма шушы шартларда да үзеннән авыр йөкне күтәреп өйрәнгән авыл арысланы Хәйдәр сәхнәдә дә арыслан булып калуын дәвам итә. Егерме ел эчендә опера театрында татар һәм рус телләрендә барлык драматик тенор партияләрен берүзе башкара. Менә кайда ул атом көче! Оркестр тавышын басып китеп җырлаган мондый тенорның театрда алмашы булмаган шул. Чүмбәлидән татар егете, татар опера-музыкаль драмаларыннан тыш, саф урыс телендә күпчелек

урыс операларындагы арияләрне дә җырлый. Хөснул Вәлиуллинның «Самат» операсында Самат, Җиһановның «Җәлил»ендә Җәлил, Вердиның «Отелло»сында Отелло, Бизенең «Кармен»ында Хозе, Чайковскийның «Карга бикәсе»ндә Герман һәм башка дистәләгән партияләрне башкарып, күпмилләтле Рәсәй опера сәнгатенең алтын хәзинәсенә зур өлеш кертә. Шуның белән беррәттән, киң диапазонлы милли җырчыбыз Хәйдәр Бигеч татар халык җырларыннан үлемсез яңа гөлбакча барлыкка китерә. Татар композиторлары яңа җырларын бары тик аңардан гына җырлату турында хыяллана. Ул егерменче гасырның соңгы чирегендә татарның югары милли җыр сәнгатен тудыруда тоташ бер буын җырчылар башкара алмаган бурычны башкара...

Мәскәү профессорлары Татар опера һәм балет театры җитәкчелегеннән аны Италиягә җибәрүләрен үтенә. Әмма хуҗалар ничек кенә булса да җибәрмәү ягын карый. Ягъни уранның атомы табылмый. Акчалары булмаган икән. Менә бит ничек. Хәйдәрләргә дигән акча исәбенә Мәскәү һәм Петербург җырчыларын миллионлы контрактларга яллап, ун ел буе аларны Голландияләргә гастрольләргә йөртеп, акча сугу өчен акча ныграк кирәк булган икән. Көнбатыш «маэстролары» чамасыннан чыкканда, Хәйдәр Бигеч кебек гомере буе бушка, «кәпик» хакына кан тамырларын шартлатып җырлаган бөек җыручы үзе дә сизмәс бәгырь үче белән тавышын өзлектерде. Кайсы Карузо, Павароттилар мондый басымга түзеп, бушка җырлаган булыр иде икән? Әгәр Италиягә тәҗрибә алып кайтырга җибәргән булсалар, тавышы белән үзе идарә итеп, болай өзлекмәгән дә булыр иде, бәлки...

Сәхнәдәге басымга өстәп – һаман да шул кәефкә карап күтәрелә торган шәхси кан басымы. Рәсәй бары тик кәеф боза торган ил булгач, монда басым гел күтәренке, кәеф гел төшенке булучан икән. Сәхнәдә дә, өйдә дә, урамда да ул Зөһрәсе кулындагы шприц сагы астында. Җитмәсә, авылдан авылга гастрольгә йөргәндә, Зөһрәсе белән ике тапкыр автокатастрофага юлыгып, шифаханәдә дә ятып чыгалар. Уллары Айратка иптәшкә тагын бер йөрәк парәләре – Айсылу исемле кызчыкны алып кайталар, әмма ул озын гомерле булып чыкмый, сигез айлык чагында үлеп китә. Бала кыр казы! Кыйгак-кыйгак!.. Шулай итеп, Салих-Тукай авылы зиратында Бигеч нәселенең беренче кабер ташы атом ташы булып, башын күтәрә. Беренче һәм соңгысы булсын иде!..

Хасил булган бушлыкны тутырырга теләп, Зөһрә тагын бер ир бала алып кайта. Анысы җир йөзендә сигез генә сәгать яшәп кала. Аны, Исмәгыйль исеме кушып, шул ук Салих-Тукай зиратына җирлиләр. Икенче бала, кыр казы! Кыйгак-кыйгак!.. Ике-өч ел эчендә иңнәренә ике фәрештә куна һәм икесе дә оҗмах кошы булып, мәңгелеккә очып китә!..

Сабирҗанның үз гаиләсе, үз балалары күз алдына килде. Алар хатыны белән Таҗикстанның Нурек һәм Кулябларында, Үзбәкстанның Иске һәм Янги-Юлларында алты сабыйларын җирләделәр. «Духтари, әй, духторҗан, духтори Точикистон!» Андагы өч кабердә өч кушуч җылылары калды. «Яшасин, яшасин, irikли Узбекистон!» Инде килеп, өч кушуч җылылары Үзбәкстан тупрагында калды. Ярый әле, җәсәдне тапшырырга төрки җир, төрки тупрак бар. Киң күңелле таҗик, үзбәк халкы шул тупракка кабул итмәсә, нихәл итәр идең?! Утызынчы-кырыгынчы елларда сыйнфый

суештан һәм ачлыктан Урта Азиягә качып котылган миллион татарларга ашарга нан, кунарга түбә бирмәсәләр, нихәл итәр идең? Ярый әле, эшсез-икмәксез татарга бушатырга аларның атомсыз булса да рудасы булган! Рәхмәт ул халыкларга, билдән бөгелеп рәхмәт!.. Өч кызының берсе таҗикта, икенчесе үзбәктә, өченчесе урыста кияүдәләр иде. Урыстагысы аерылды. Ул кайчандыр тамырсыз калган нәселнең, милләтнең дүртенче буыннан юкка чыгуы турында япон теориясен укыган иде. Тукта, юкка чыгарга, молекула атомы үләмени? Тукта, ул үзе нәселенең авылдан аерылган ничәнче буыны? Алай дисәң, яһүдиләр нигә милләттәшләрен уникенче буынга кадәр бар дип саныйлар һәм аларны бәни Исраэльгә кайтару өчен тырышып яталар? Алар атомны мәңгегә буйсындырганмыни? Безнең белән алда тагын нәрсә булыр? Әй, бу басымнар, басымнар, басымнар!..

Җидегән чишмәләрнең талы бөгелә, талы бөгелә,
Әкрен искән җәйге җилләргә.
Сез каласыз инде, без китәбез,
Без китәбез ерак, без китәбез ерак илләргә...

Җир йөрәгеннән яшәргә дип бәреп чыккан чишмәне нинди генә ташлар-таулар белән күмдерсәң дә, барыбер үзенә юл табачак. Бу талларга кунып сайраган сандугач – Зөһрә-сылуның моң-сагышын басарлык көч тә тумаган әле дөньяда. Бу моң тамчы булып тама да океан дәрьясы өстеннән сәгать чылбыры кебек түгәрәкләр ясап, офыкларга тарала. Аңа бу җырны шахталарда таш баскан татар егетләре, урманнарда агач баскан татар кызлары, Псков урманнарында әле булса күмелми яткан татар сугышчылары, сыер җигеп, үзләре тәртә арасына кереп, сабан артында өзелгән ятим татар хатыннары да тыңлыйдыр кебек. Әнә алар җир сөреп килә, ә татарның Паваротгилардан ким булмаган Хәйдәре җир башына баскан да аны гүя итальян опера сәхнәсе ясап җырлый да җырлый... Әле генә аларның иңнәреннән җәннәткә очкан сабыйлары Айсылу белән Исмәгыйль дә бу моңнарны тыңлыйдыр кебек. Әнә, ул Җидегән чишмә каршындагы талга сөялгән дә җырлый, ә Хәйдәре бераз гына түбәндә чишмәнең киңәеп буылган тамырыннан акбүзатын сугарып тора, имеш. Шулай күз алдына килә Сабирҗанның. Хәйдәрнең тын сукмагында таллар күккә талпынганда, Зөһрәнең чишмәсе авызындагы таллар бөгеләләр. Бөгеләләр генә... Нишләп имән дә, нарат та түгел бу татарның табынган «шәҗәрә агачы» – мәрхәмәтле тал? Нишләп тал ул? Нишләп гел бөгелә татарның бу таллары? Ураны-атомы табигатьтән үзенеке булып та, үзенеке булу хокукыннан мәхрүм ителгәнлектәнме? Борынгыдан бөгелә. Һаман да шул басымнанмы? Бөгелүдән туктарга вакыт түгелме? Йомшаклыктан, ихтыярсызлыктан, көчсезлектәнме, – дип уйланды Сабирҗан. – Юк, – диде ул үз-үзенә. – Бу көчсезлектән дә, куркаклыктан гына да түгел. Татарның талы... нечкәлектән, көчле хистән, басымнан туган моңнан талпыныр өчен бөгелә. Бу тал – үлемсез. Кискән саен, тамырын корыткан саен үсә тора, үрчи тора. Әнә бит ул нәрсә ди? Сез к а л а с ы з инде, ди. Без к и т ә б е з, ди. Илдән китәләр дә – илдә калалар да. Тик нигә китәләр? Бәлки, китүдән туктап торырга кирәк иде. Бу китү т е г е н д ә китү – үлемнең үземе? Үлем «генәме»? Илне ташлап китүләр, сагынганда

гына, авылга кайтулар турындагы очсыз җырлар чире бетермәдеме безне? Нигә кире кайтмыйбыз? Авыл беткәнгәме?Аны без үзебез бетермәдекме һәм бетермибезме?

Бәлки, «китеп кайтулар» татарның яшәү рәвешедер? Борынгы заманда бабайларыбыз барасы җирләренә ат өстендә «барып кына кайтканнар» бит. Шуңа күрә аны «барымта» дип атаганнар. Бал кортлары да шулай «барып кайтып байый» түгелме? Сабирҗанның хәтерендә, ул Янги-Юлда беренче тапкыр умарталык ачып җибәргән елында, кортларга бал җыю өчен җиңелгә төшсен дип, якында – кортларның борын төбендә карабодай, клевер чәчте. Әмма, ни гаҗәп, галиҗәнап кортлар ул чәчкән үләннәрдә тукталып та тормыйча, ары – биш, хәтта унар чакрымга очтылар. Баксаң, якыннан алынган нектар корт борынында кайтып җиткәнче, баллы сагызга – балавызга әверелеп өлгерми, моның өчен Вакыт вә Аралык кирәк икән. Ул бары тик ширбәт булып кына кәрәзгә тама. Кортларның ерактан алынган сәлсәбиле очып кайтканда, җилдә җилләнеп вә какланып, баллы сагызга әверелеп өлгерә... Татар да бал корты кебек эшчән бит, ул да ширбәтен читтән ташырга, бу ширбәтне алтын кәрәзгә әверелдереп алып кайтырга тиеш иде югыйсә!.. Бал төче дә, әче дә, тозлы да булырга тиеш түгел, бал бары тик баллы гына булырга тиеш икән!..

Без китәбез ерак илләргә... Нигә китәбез? Менә безне алып китәсе ат башын күтәрә. Атмы? Тимер чәлтерле бәләкәй «уфалла» арбасы түгелме? Ат икән. Авызлык тимере солы салынган тас калаенда ярсып зеңгелди. Күк күкри. Яңадан дөнья ярала. Ураннан атом-төш чәчрәп тама.Талчыбык кебек бөгелеп, күктә Айның нәп-нәзек телеме утырып туа, офыклар сөрмәләнә... Ә тормыш – дәвам итә!.. Озакламый, Италияләргә җибәрмәсәләр дә, Павароттилар белән таныша алмаса да, Вердиның «Аида» сыннан Радамес партиясен итальян телендә җырлаячак. Аның тарафыннан башкарылып та язылмыйча калган дистәләрчә опера партияләрен, дистәләрчә онытылган, «Кыр казы» кебек онытылып барган халык җырларын радиода һәм телевидениедә яздырып калдырачак!.. Бар, табып кара син үзләре үк бер операга торган җырларны итальяннарда!..

Таллар шулай тирбәлүне...

Хәйдәрнең җиде кат җир астыннан килгән көчле тавышы күкрәк читлеген җимереп чыгып, тышкы дөнья аша һәм көчәйгәннән-көчәя барып, күкнең җиде катлы гөмбәзенә күтәрелеп каплана. Гөмбәз пыяла кебек зеңләп тетрәнә һәм чатнаган гөмбәздән чәчрәп, йолдызлар коела. «Таллар шулай тирбәлүне» дигән гыйбарәнең «т» һәм «л» авазлары кабатлана-кабатлана талларны сыйпаганда, җырчының мәгърур вә йөрәкне ерткан моңлы ташкынга әверелә, инде син «Тагын да нәрсә булыр? Нәрсә булыр?» дип тынсыз торганда, «Киләсеңдер син дисәм...» дигән гыйбарәнең «син»ендә җанның җиде катламыннан сыгылып чыккан сагыш, юксыну, якты моң тагын да көчәеп, өзелеп, өзлегеп күтәрелә-күтәрелә дә, «дисәм» дә гүя үксеп шартлап, яңадан күкрәк читлегенә кереп бикләнә, тынычлана, аннан тагын үзәнлекләр арасыннан килеп чыккан бормалы юл кебек яңадан килеп чыга...

Син түгел лә... син түгел шул...
Син түгел ул...

– дип үкси, үкси, үкси дә йөгереп, тыны капланган адәм кебек сулкылдый, сулкылдый, сулкылдый, талларга килеп сөрлегә, йомшак җил хасил була, җилләр талларны сыйпый, таллар тагын тирбәлә, аннан бу үлемсез авазлар, чишмәдән чайпалтып алган бер кушуч көмешсу кебек бармак араларыннан тамчылап саркып, комга тама – тамчылар чак сизелерлек түгәрәк эз калдырып, комга сеңә, сеңә, сеңә... Һәм – соңгы үкенечле аһәңнәр:

Җи-и-и-ил и-и-и-кә-ә-н...

**5**

...Сабирҗан бөек җырчының һиҗри буенча 1376, милади буенча 1998 елның 13 ноябрендә, тууына бер елдан нәкъ илле ел тулар алдыннан гомере өзелгәнен, 16 ноябрьдә миһраҗ кичендә ләхеткә куелганын белсә дә, үзен ничек кенә көчләмәсен, аны булган100 вакыйга итеп күз алдына да китерә алмый иде. Вафат хәбәрен әүвәлдә интернет, аннан Татарстаннан килгән газета-журналлар китерде...

...Җомга көн, кичке сәгать алтылар булгандыр, Зөһрәләрдә – телефон. Казанның Республика диагнозлар үзәгеннән дәррәү тавыш: «Килеп җитегез, вашему Бигичеву плохо». Зөһрә бар дөньясын онытып, үзләреннән ерак булмаган диагностика үзәгенә чапты.

Башында әллә нинди уйлар кайнады. Ни булды икән? Алар бит иртән театрда репетициядә, аннан, төштән соң радиода булганнар иде. Соңгы елларда Хәйдәрнең башына бик күп сынаулар төште шул. Ике баласының үлеме. Кара көчләрнең Җәлилләр, Җиһановлар төзегән татар опера һәм балет театрының репертуардагы татарлыгын җимереп ташлаулары ничек кенә җанын рәнҗетте аның. Татар артистлары, шул исәптән Хәйдәр, эшсез – туган театрсыз, тамашачысыз, телсез-хәтерсез калды. Уран атомсыз иде. Мөмкинме бу?! Чит илләргә түгел, Рәсәй, Татарстан буйлап та гастрольләргә чыгармадылар. Таланты белән дә, туры сүзлелеге белән дә тугры Тукай һәм тугры Сәйдәшнең дәвамы иде шул ул. Сыкранып булса да, турысын әйтте. Бу кемгәдер ошап җитмәде. Болай да бушка эшләп, такы-токы яшәгән ике халык җырчысының гаиләсе ипи белән суга торып калды. Аның каравы, алар исәбенә Петербург һәм Мәскәүдән ялланган Гольдберглар кавеме Голландияләрдән кайтып кермәделәр. Казан алтынына коендылар. Боларны кемдер медальләр биреп, «Халыклар дуслыгы тантанасы» итеп күрсәтергә тырышты. Җан әрнемәслекме? Кадерен белсәләр, бу яшендә өзелер идеме ул? Ачлы-туклы, почмактан почмак эзләп, кыйналып, кимсетелеп яшәмәсә, шушы яшендә шушындый ир-азамат дөнья белән хушлашыр идеме? Мондый талант Әмрикәдә булган булса, аның виллалары Гавай, Әдрән диңгез ярларында яктырып утырган булыр иде!..

Баласын җуйган ана болан кебек атылып барып керсә – Зөһрә ни күзләре белән күрсен, аның сөекле ире – халык артисты Хәйдәр Бигичев, бар милләтнең бердәнбер Хәйдәре, кабул итү бүлмәсе коридорында үлеп үк ята. Йөзләре агарынган-күгәренгән. Аңлылыкка аңында иде ул. Сөйләшкәләп

тә куйгалый. Зөһрәне күрү белән ул яңа бәладән котылуына ышанып, елмаерга тырышты:

– Үлә яздым бит, Зөһрәм... – ди. – Башта уң аягым йөрмәс булды, аннан зәхмәт сулына күчте... Шартлый, аяк тамырларым шартлый, түзәр әмәл юк!.. Җитмәсә, полисымны да алырга онытканмын икән!.. Полис сорап, һаман кабул итми яткыралар!..

Нинди полис?! Татар җирендәге Татарстанда Татарстанның халык артистыннан – полис?! Мондый чакта кешедән полис даулар чакмы?!

Нишләргә дә белмәгән, әмма бу очракта беренче итеп басымны төшерә торган укол бирергә кирәклекне яхшы белгән Зөһрә шүрәлеләргә охшап хәрәкәтсез калган табибларны утлы карашы белән көйдереп алды:

– Нишләп карамыйсыз?!

– Килгәндә, басымы югары иде, хәзер нормальләште, – диде табиблар берни булмагандай, тынычландырырга тырышып. – Менә хәзер авыртуны баса торган укол бирәбез...

Зөһрә авырудан полисын таләп итеп яткырган арада инде аякларында пульслары да туктап барган Хәйдәрнең салкын балтырларын, аяк очларын уа башлады, Хәйдәрен тынычландырырга ашыкты:

– Хәйдәрем, түзә күр, йөрәгең яхшы, инфаркт-фәлән юк, ярдәм итәрләр – без бит табиблар кулында!.. Монда алар һәйбәтләр, бу элеккеге Обкомпартия хастаханәсе!..

Хәйдәрне уратып катып калган табиблар, шәфкать туташлары бихисап, тик алардан тиешле шәфкать кенә юк иде. Ә табиблар алмаш-тилмәш телефонга асылынып, алтынчы хастаханә табиблары белән маңгайга-маңгай бәхәс алып баралар:

– Бу безнең авыру түгел, бездә сосудистый хирурглар юк! – кычкыралар бу яктан трубкага. – Монда острый тромбоз артерий обеих бедер!

«Сосудистый хирурглар» юк икән. Хәйран икән. Хәйдәр һаман:

– Зөһрә, полисны... полисны алып килдеңме?..

Саташа бугай. Аһ, бу полис дигәннәре! Зөһрә килгәнче, полис соратып, укол да салмыйча яткырып тинтерәткән авыруны нинди хәлгә төшергәннәр!.. Моның өчен больнисы-ние белән хөкемгә тарттырырга кирәк!

Ә вакыт үтә, секундлар сәгать, минутлар тәүлекләр кебек озын!..

– Тизрәк алып китегез бездән бу авыруны! – дип кычкыра телефонның бирге очындагы табиб телефонның аргы очындагы табибка, инде тәмам чыгырыннан чыгып. – Бу безнең авыру түгел, сезнеке!.. Кабул итмәсәгез, сез җаваплы!..

Хәйдәр бар көченә ышандырырга тырыша:

– Алла хакына... Президентка... Сәкинә апага шалтыр...ат! Алар безнең җыр... ярата!..

Түземе бетеп үкси башлаган Зөһрә атылып барып, табибларны талкый башлады:

– Нишләп катып калдыгыз, нишләп ярдәм итмисез?! Халык артисты Хәйдәр Бигичев алдыбызда үлә бит!..

Ниһаять, үзара бәхәсләшә торгач, тиешле ярдәмен күрсәтә алмаган диагностика үзәге табиблары, әрләшә-талаша, авыру Хәйдәрны алтынчы

хастаханәгә илтеп тапшыруга иреште. Секундлар чынлап та – сәгатьләр, сәгатьләр – тәүлекләр кебек озын иде!.. Ә Хәйдәрнең хәле авырайганнан-авырая барды. Ул инде баягы кебек эндәшми дә, сөйләшергә тырышмый да, дөньяга игътибары тәмам беткән кебек, Ходаем!.. Авыруны ятактан тәгәрмәчле арбага күчереп салып, кабул итү бүлмәсенә алып кергәч, аны ике яшь табиб карады:

– Чынлап та безнең авыру икән...

Чынлап та... Зөһрәнең кәефе күтәрелгәндәй итә. Хәйдәр моны ишетми.

– Каны бот буе артерияләрендә генә тибә... – ди «сосудистый» табиблар. – Что делать?

Кәеф яңадан төшә. Фаҗига якын, фаҗига якыная, фаҗига килеп җитеп килә!..

– Сез ашыгыч операциягә ризамы?

– Риза, риза!.. Әмма тизрәк, Алла хакы өчен!..

– Бәлки, дәвалап карарбыз? Операция кирәк тә булмас...

Кәеф тагын күтәрелеп куйгандай итә дә, эчне тоташ шом биләп ала – хәл шулкадәр дә кискен микәнни?

– Әгәр сезнең дәвалауны дәвам иттерәсегез килә икән, ханым, – ди табиб салкын кан белән. – Дежур аптекадан кирәкле даруларны алып килегез!.. Без көтәбез!..

– Нинди дарулар? – ди үз колакларына үзе ышанмаган Зөһрә. – Нинди дарулар тагын? Республика больнисында дарулар да юкмыни?!

– Юк. Менә сезгә дарулар исемлеге... – ди күзләрен яшергән табиб. – Гепарин. Фибролизин. Анальгин. Аспирин. Сульфадимизин. Бездә аларның берсе дә юк. Шприц белән система, менә бу сыекчаларны алырга да онытмагыз!..

– Дежур аптека? Кайда ул?

– Чехов урамында!..

Йа, Ходай! Сәгать төнге тугыз икән инде. Хәйдәренә ярдәм күрсәтә алмыйча, алар өч сәгать мыштырдыйлар ласа!..

Аһ, ул даруларга акча да кирәктер бит әле! Хәйдәр чак кына ишетелерлек итеп пышылдады:

– Минем кесәдә... юкмы бераз?

Хәйдәре кесәсеннән йөз тәңкә, шундагы очраклы бер изге җан иясеннән бурычка акча алып торып, ул елый-елый, сүнеп барган ирен хастаханә коридорында калдырырга мәҗбүр булган хатын, кара төнне яктыртып, түшәлеп яуган карларны ерып, барлык Казан буйлап анальгин белән аспирин эзләп чапты!.. Миллионын да, йөрәген дә биргән булыр иде, янында газиз татар халкы кочагын ачып торган булса. Кызганычка, безнең урам үзенә тиеш булган хәләл урынсыз, хәләл урансыз һәм хәләл молекула-атомсыз иде. Хатын берни булмагандай, өнсез-көнсез килеш Тукай, Такташ, Сәйдәш, Туфаннан кала бишенче бөек үлемен каршыларга әзерләнә. Һәрхәлдә, өстән караганда, барысы да тәртиптә кебек. Сәхнә исән, күктә йолдызлар бихисап. Дөнья атом тузанына күмелеп, галәмнәрдә гизә. Әмма беркем дә, бер генә татар да өстәл сугып: «Җитте безгә! Әйдәгез, моң һәм бездән тартып алынган уран буранын кире үзебезгә кайтарыйк!» – дими...

Ниһаять, Зөһрә дежур аптеканы эзләп тапты. Бикле. Ишегендә бернинди язу юк. Ул Җир шары кебек зур йорт тирәсеннән әйләнә-тулгана йөгерде. Баксаң, төнгә йортның теге башындагы кеше күрмәс кечкенә җилтәрәздән җибәрәләр икән даруларны.

Урап килүенә Хәйдәрне дүрт кешелек палатага күчергәннәр. Тәрәзә янындагы койкага. Янында беркем юк. Ничек итеп мондый авыруны ялгызын калдырырга мөмкин? Хәле мөшкил. Күтәреп кертеп, каты койкага ыргытканнар, аны бит бу хәлендә кузгатырга да ярамый иде!.. Шушылар да табиб дип атала микән?

Әле ире һушында иде. Зөһрәсе аны тынычландырырга кереште:

– Хәзер, Хәйдәрем, хәзер... Даруларны алып килдем... Врачларны биредә яхшы, диләр... Ярдәм итәрләр. Түз, җаным, түз...

Зөһрә иркәсенең кулларын уа башлап, йөзенә караса, йөрәге жу итте: Хәйдәр башын кырын салды, аз гына елмайгандай итте дә хәрәкәтсез калды.

– Хәйдәрем, ач күзеңне! – дип кычкырып җибәрде бөтен палатага Зөһрә. – Һәм авызына тын өрә башлады. – Ач күзеңне, Хәйдәрем!.. Син нишлисең?!

Хәйдәр вафат иде инде. Казан, Татарстан, барлык татар халкы ятим калган иде. Татарстанның халык артисты Хәйдәр Бигичев «яшь капитализм» котырып чәчкә аткан үрнәк Татарстанның дәүләт хастаханәләрендә биш сәгать буе ярдәм көтеп, сөйгәненең – көрәштәше, язмышташы, берүк гаиләдән Татарстанның икенче халык артисткасы Зөһрәсенең, кара төннәрне ерып, дару алып кайтканын көтеп кенә яткан кебек иде гүя. Ул тупсадан күренү, башын кулына алу белән елмайган да хушлашкан. Сабирҗанга билгеле булуынча, аның төйнәлгән йодрыгын көч-хәл белән ачтырганнар. Ул йодрыкта нинди кодрәт, нинди рухи ачыш һәм казанышлар төенләнгән булды икән? Сабирҗанның иманы камил, анда иң бөек байлык – туган татар халкына бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт булган. Ә мәхәббәт дигән могҗиза ул серле матдә. Материя. Атом. Аның белән дөньяны яшәртергә дә, шартлатырга да мөмкин. Хәйдәрнең уч төбендәге атом ул Үлемсез Моң иде. Караңгылыкка урын калдырмаган уран яктылыгы иде. Җимергеч көчкә юл бирмәгән Изгелек иде...

Шулай итеп, Казанның алтынчы хастаханәсенең данлыклы тарихына караусыз үлгән халык артисты Хәйдәр Бигичевнең үлеме өстәлде. Моң да юк, изгелек белән явызлыктан торган уран да юк. Тәүбә дә, хөкем дә булмаячак.

Нәкъ җырдагыча. Җил икән. Син түгелсең, җил икән. Башка бернәрсә дә түгел.

Зөһрә шашкан күзләре белән катып калды.

Тукта, нәрсә булды соң әле? Дөнья – караңгы баз. Янында беркем юк. Бу бүлмәдә ятып, тере мәеткә әйләнгән өч гәүдә Хәйдәрнең үлем хәбәреннән торып утырганнар. Дүртенчеләре хәрәкәтсез. Чынлап та җырчы Хәйдәрме ул? Түгелдер лә!.. Шул булса, нигә? Кем үлде? Нигә үлде? Ә ул нигә үләргә тиеш?

Юк, Зөһрә үзе саташа бугай.

Юк, саташмый.

«Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун».

## 6

Табиблар кереп, шыгырдавыклы тәгәрмәчләрдә тәгәрәтә-тәгәрәтә Хәйдәрнең үле гәүдәсен реанимация бүлегенә алып чыгып киттеләр. Нигә? Яңадан терелтү өченме? Мөмкинме? Аклану өченме? Аллаһ болай да күреп торды бит. Гөнаһын кая куярлар? Нигә аны гына? Нигә бу реанимация дигәннәренә Зөһрәнең үзен дә алып китмиләр?! Барлык халыкны, милләтне? Безнең урамдагы уран бураннарында ахырзаман килмиме?

Ниндидер көч Зөһрәнең колагына пышылдады. Киңәш итте. Ул айнып киткәндәй булды. Ул бит бик мөһим бер нәрсә эшләргә тиеш. Алланың тәкъдире шулайдыр. Шулайдыр. Ул өстендәге сары кофтасын салды, кыйбласын чамалап, идәнгә җәйде һәм ире үлгән төштә ястү намазын укый башлады...

Юк, бу театр түгел иде.

Бу әле ләхет иясе булмаган мәетнең рухына чыгылган беренче дога иде.

Һәм ул аның хәләл җефетенең җеназасына багышланган иде.

Гомере буе үзеннән авырракны күтәргән, физик яктан ифрат та нык, көчле, чыдам арыслан, кул көрәштергәндә, аның кулын ега алырлык кеше табалмаган кеше, үз аңында булып, биш сәгатькә якын табиблардан ярдәм ялварып, коточкыч авыртынулар кичереп, түзеп яткан, йөрәге эшләп торган, кардиограммасы яхшы булган Бөек Җырчы Илендә ил табалмыйча, шулай елаудан шешенеп беткән иркәсе кулында җан бирде. Тукта, бәлки, ул терedер? Юк. Бәлки, аңа тын өреп карарга кирәктер? Юк, ул тынны да кабул итми.

Бу инсан, мондый инсан, мондый зат башка илдә, башка мәмләкәттә булсамы?..

...Әнә, аның Чүмбәли авылының мәгъруур улының, Салих-Тукай авылы киявенең, якты шәм кебек сомгыл гәүдәсен татарның сирәк акылга ия имамы Харис хәзрәт Салихҗан юып, ак кәфенгә төрә. Ә ул, гүя үлмәгәндәй, елмаеп ята. Соңыннан Салихҗан хәзрәт «Минем үз гомеремдә җеназасында бу кадәр дә матур итеп елмаеп яткан инсанны күргәнем юк иде», – дип белдерер.

Әйе, табигатьнең сирәк күренеше иде шул ул. Хәйдәр белән Зөһрә, гомумән, инсаниятта сирәк күренеш иде. Җир йөзендә йолдыз-талантлар бихисап. Йолдыз-талантлар кавышалар һәм аерылышалар. Мондыйларга кавышу да, аерылышу да – сенсация. Хәйдәр белән Зөһрә – йөзек кашына тиң талант, тик йолдызлар сенсациясе түгел. Алар бер-берсеннән аерым яши алмаган мәңгелек планеталар иде. Шулай, дөнья сәнгате тарихында, алар кебек, бары тик кавышкан гына, тик аерылмаган, бер-берсенә, талантларына, милли сәнгатьләренә тугры калган ике күгәрчен, ике аккош, ике сандугач – бер моң академиясе булып, парлы, гаиләи бердәмлектә яшәгән талантлар сирәк. Андыйлар, бәлки, Азиядә биш, Европада биш, Африкада биш, Америкада биш, Австралиядә биш пар булгандыр? Бәлки, алай да юктыр. Ул үзе инглиз җыр сәнгатеннән Дженни һәм Роджер Скорцоуз, алман балет сәнгатеннән Гертруда һәм Герхард Раушенбах, Әмрикә спорт сәнгатеннән Сарра һәм Маккей Смитлар барлыгын гына белә. Башка, сенсациядән сенсациягә кадәр аерылып яшәгән «йолдыз Киркоров-Пугачёваларны», кем исәпләгән? Ә менә Рәсәйдә чын йолдыз-гаилә әлегә берничә генәдер: Зөһрә Сәхәбиева һәм Хәйдәр Бигичев.

Балет биючеләре Екатерина Максимова һәм Владимир Васильев. Галина Уланова һәм композитор Родион Щедрин. Татардан, бәлки, бу исемлеккә тел осталары Мәрьям һәм Айрат Арысланнар, телче-галимнәр Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитовалар, җырчы һәм композитор Асия һәм Вәсим Әхмәтшиннар да керә алалардыр? Татарның Асылъярлары. Гүя йөз елга якын элек бөек драматургыбыз Мирхәйдәр Фәйзи «Асылъяр»ын алар өчен генә язган булган, диярсең. Шәрәф белән Ләлә. Кем уйлаган, шушы бергәлекне раслагандай, Зөһрә белән Хәйдәр Бигичевлар Шәрәф белән Ләләнең атаклы «Асылъяр» җыруын бергә җырлыйлар бит:

Асылъяр,
Хуш инде,
Аерылабыз бит инде...

Бәлки, татардан аларга кадәр яшәгән тагын бер шундый иҗади парны өстәргә мөмкиндер: җырчы (булачак композитор!) Сара Садыйкова белән атаклы режиссёр Газиз Айдарскийны? Дөрес, алар да берничә ел гына яшәп кала – үлем тиз аера. Дөресрәге, аералар. Мондый тәҗрибә – яшь талантларга мәңгелек үрнәктер һәм сабактыр.

...Кинәт, колак пәрдәләрен шаңкытып, нидер гөрселди һәм кап-караңгы дарьяда моңланып, ниндидер ак нокта барлыкка килә. Бу – Ай, Ай, Ай!.. Дулкын килә – дулкын китә. Өй артындагы кара шомырт агачларыннан чәчрәп, көлтә-көлтә ак чәчкәле йолдызлар атыла...

Яңа, мәңгелек дөнья яратыла.

Артта – Аллаһ, алда – Моң.

Бар дөнья тын. Шылт та итми.

Ил түгел бу. Җил икән.

Биредә пульсыңны түгел, полисыңны сорыйлар. Чөнки алар Шүрәлеләр. Үзләренең бармакларын бүрәнәгә тыккан Былтырдан полис сорыйлар.

Сабирҗанның хәтеренә шигырь килеп төште:

Гаепне ачар булсаң, хәзер бездә
Тиештер Ватаныңнан ерак качмак;
Юк исә башың бетте, үзеңне тиз
Ясарлар төбе төшкән агач башмак!..

Кем шигыре бу? Нәҗип Думави!..

Хәйдәрне, милләтнең асыл баласын, Җидегән чишмәнең тын сукмагында тирбәлгән талларга булган басым алып китте. Күтәрсә – үзеннән авырны күтәрде. Эшләсә – күпкә арттырып эшләде. Җырласа – микрофонын читкә алып куеп, үз тавышы – чын мәкаме белән җырлады. Бу талларга тиң басым җир йөзендә башка беркайда да, беркемгә дә, бернәрсәгә дә булмады. Бу басымга түзү никадәр авыр булса, аның мәгънәсе, мәртәбәсе шулкадәр зурдыр, олугътыр...

Хәйдәрдән соң дөнья, үз хаталарын аңлап, яңадан яратылырга тиеш иде кебек.

Менә ни өчен Хәйдәр Бигечне югалту Тукай, Такташ, Сәйдәш, Туфан үлеменнән соң, милләткә килгән бишенче бөек югалту иде.

Бу Казанның атаклы алтынчы хастаханәсендә «муниципаль полис» дип аталган катыргы хакына ирне, илне югалту иде.

Кем җавап бирер?

**7**

Син түгел ул, җил икән...

Җырчының җан басымыннан тетрәп чыккан авазлар хәзер авыз куышлыгында кысыла, гүя киләптәге җеп кебек бер учка төйнәлә, күкрәк читлеге кыллы гөсләгә – аһәңнәр җилгә әверелә, алар альттан дискантка кадәр күтәрелеп, талантның үлемсезлеген, хәтта мәңгелек югалту булып исәпләнгән югалтуларның да мәңгелек булмыйча, илаһи табигатьтә, кешелекнең җан вә юлларында биниһая эз калдыруын раслап, тына, югала...

Җил икән. Җил икән! Җил икән!

Сабирҗан күзендәге яшь ташкынын кул аркасы белән сөрткәндәй итте. Яшь кайнары тәненең тиресен пешереп алды. Бу мәңгелек уран ялкыны иде. Урандагы мондый моңны вә шигырьләрне тәмугны җир йөзендә кичкән милләт кенә тудыра аладыр. Мондый моңны вә шигырьләрне тәмугны җир йөзендә кичергән милләтнең инде шул ук тәмугны үз язмышларында икенче кабат кичергән балалары гына тудыра аладыр.

Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов һәм Сара Садыйкова.

«Тын сукмакта тал тирбәлә» романсы һәм «Җидегән чишмә» җыруы – татар милләтенең дөнья халыкларына Йөрәк Чакыруы ул.

Син түгел ул, җил икән...

Сабирҗан җырлап җибәрде. Моң кайтты!.. Сабирҗан үзе дә җырлый икән ләбаса!.. Җырлый башлар өчен туган нигезе генә җитмәгән бит!.. Ул уйламастан өстәлгә йодрыгы белән сукканын сизми дә калды:

– Җитте безгә читтә себерелергә!.. Авылыма кайтам!.. Урынымны урамымнан табам! Хатынымны да, балаларымны да... барысын да урамыма алып кайтачакмын!..

Аның күзләре кызарып шашкан иде. Ул үксегән авазлар чыгарып, башы белән өстәлгә капланды. Бераздан өстәлгә суккан уң кулының ләззәт белән сызлануын тойды. Аңа кайткан моң булып йодрыгыннан кан чәчрәгән иде...

***

**P.S.** Мавыгып китеп, «Җидегән чишмә»ләргә багышланып, үзе дә җиде бүлек булып туган бу әсәремдә мин геройларымның төс-башларын сурәтләргә дә онытканмын. Бик күрәсе килгән кеше кое суының көзгесенә карасын. Аның чагылышында ул Зөһрәнең, Хәйдәрнең һәм Сабирҗанның кыяфәтләрен күрер. Җитешмәгән сыйфатларын үзеннән дә өстәр.

.



Нәҗибә
Сафина

# МӘҢГЕЛЕК БЕЛӘН ЭЛЕМТӘ

## Яшьлеккә дәшү

*Шундый сүз эзлим, табылса – мәңгегә калдырырлык!*
*Мин яшьлектән яшен эзлим – коллыкны яндырырлык!*

Исәнмесез, саулармы? Җанда янар таулармы?
Безнең йөрәк ярсуларын сезнең йөрәк аңлармы?
Әйтеп карагыз, дисезме – йөрәкнең ни дигәнен?
Аңлатырга тырышыйммы нидән аның көйгәнен?
Һәрчак югалтканын эзли, тапмыйча тынмый кеше.
Инде ул бишенче гасыр милли дәүләтсез өши.
Югалтулар шулкадәр зур – төшмәс өчен төпләргә,
Канат куярга мәҗбүр без мәңге очмас күпләргә...
Данны түгел, җан сакларга түгелә, аһ, көчебез...
Яшәми бакыйга күчә шулай күпме кешебез...
Тарихның сират күперен кичү чоры татарның.
Кирәк икән, шул күпергә басма булып ятармын!
Нык булса минем үзәгем, милләт басып атласын.
Тик туар таңнары гына үздәүләтсез атмасын!
Үз илендә, үз җирендә сөйләшсен үз телендә.
Рухи афәт болай яшәү ата-баба көлендә...
Минем җанда бабайлардан кабынган ялкын үрли.
Аһ, тик мин дә китеп барам үз дәүләтемне күрми...
Алыгыз, сез, шул ялкынны! – Алыгыз җаным белән!
Шагыйрь җиргә шул ялкынны тик күчерергә килгән.

## Шигырьме, гомерме?

Сайлау алдына куйсалар, шигырьме, гомерме дип,
Минем шул мизгелдә калыр бар саным күмер көеп...
Минем кан тамырларымда кан урынына – шигырь.
Кисеп карасагыз, барыбер кан түгел, шигырь чыгар.

---

Нәҗибә САФИНА (1949) *– шагыйрә, публицист. «Әгәр дә уйлаганда...», «Без – шигырь, тормыш – проза», «Кан хәтере» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Шигырь төсендә булыр ул, булыр хыял төсендә,
Моң төсендә, гамь төсендә! – Димәк, яшәү көчендә.
Шигырь яшәү төсендә ул, сөю, нәфрәт төсендә.
Шагыйрь яна бу дөньяда төтәгәннәр өчен дә...
Шигырь туган тел төсендә, туган туфрак төсендә!
Шигырь мәхәббәт төсендә бөтен дөнья өчен дә!
Шигырь шагыйрь төсендә ул! Шигырь – киләчәк төсе!
Ритмлы хәрәкәттә – йөрәкнең бөтен көче!

## Китеп барам

*(Татар язучыларына)*

Бер дә кайтмас җиргә китеп барам...
Сагынсагыз, сез дә киләчәксез.
Әмма китү язык язучыга,
Милләт калса әгәр киләчәксез...
Милләт калса телсез, киләчәксез,
Караңгы гүр якты була алмый.
Гөнаһлар да керә гүребезгә,
Санибыздан бер адым да калмый.
Керер гәүдә эзләп очар җаннар,
Инәлерләр: «Кая татар, татар!»
Мәрхүмнәргә шундый авыр булыр, –
Гамьсезлеге үз туфрагын таптар.
«Җирдә чакта, җаның санда чакта
Уйлау кирәк иде шушы хакта!
Сиңа милләт җанын ярып бирде,
Алып барсын диеп киләчәккә!
Бар кылганың саның өчен булды,
Җан таләбен артка куя бардың.
Җан таләбен үтәмәскә һәрчак
Сәбәп таба тордың, мин, дип, арыдым.
Җир әйләнеп, һаман урый барды
Гөнаһларың үзенең кучәренә,
Ышанганга җәсәдеңнең беркөн,
Барыбер дә үзенә күчәренә.
Китеп барам мәңге кайтмас җиргә! –
Бу бит тамырыннан ялгыш, хата!
Китеп барабыз без киләчәккә! –
Уйлау кирәк бераз шушы хакта!
Китәрбез дә котылырбыз диеп
Юатмагыз, зинһар, үзегезне!
Тәмуг утларында янмас өчен
Әйтеп китү кирәк сүзебезне –
Яраклашмый, ялагайланмыйча
Бүген хаким булган затларга,
Милләт рухын сүнмәс маяк итеп,
Киләчәккә горур атларга!
Ничә гасыр иңәр санын эзли
Милләт өчен баш салганнар җаны...
Җан авазын ишеттермәс өчен
Көчәйтәләр һаман чиркәү чаңын.
Бер дә кайтмас җиргә китеп барам,
Диеп кенә, чыңлап китәр идем...
Сагышларым яфракларга төреп,
Ләхетемне тәхет итәр идем...
Алай итә алмыйм, җаным кушмый, –
«Киләчәккә маяк – милләтең! – ди, –
Акла милләт киләчәге өчен
Корбан киткәннәрнең өметен!» – ди.
Яфрак төшкән саен шул өн килә,
Өзелгәннәр санын кем санаган...
Үзебез булып, киләчәккә барыйк! –
Җиргә кабат туу юк анадан!
Бер дә кайтмас җиргә түгел, беләм,
Китеп барам гомер көзләремә...
Миңа түгел, колак салсагызчы
Яфракларның әйткән сүзләренә...

## Кайчан шигырь языла?

*Вөҗдан – шагыйрь җаны,*
*Шигырь – аның чаңы.*

Җаның бар дөньяга ачык булса,
Җаныңа җыр ташкын булып тулса,
Җылыталсаң җирне кояш булып,
Моңнарыңда йөзсәң айдай тулып,
Нәфрәтләнсәң җанны кысканнарга,
Хакыйкатьтән читкә посканнарга,

Бәхет түгел, тәхет даулаганга,
Мәхәббәтне таный алмаганга.
Җан җылыңнан китсә күкләр түгелеп,
Башкаларга җаның бирсәң бүлеп,
Шигырь язу шул ул – гашыйк булсаң үлеп...

## Әйт, кем тиде?

*Апас районы музеенда җирле рәссам Илгиз Маликовның 1891 елгы Ышна вакыйгасына багышлап язылган картинасын күргәч.*

**1**

«Музейларга кермәм», – дигән идем,
Ничек кермисең, ди, керәсең...
«Инде башка күрмәм», – дигән идем,
Керәсең дә тагы күрәсең...
Чыбыкларның сыгылып торган чагы, –
Март, ахыры, таллар – чәчәктә.
Тагы бер музейга барып кердем,
Каршы алды тальян, чәкчәк тә...
Күз яшьләрем чәчрәп кенә чыкты
«Күрмәм» дигән күренеш алдында:
Гыйсъяннарны пешкән чыбык белән
Суктыралар... Ышна ягында...
Хәким дигән иблис, җаһил, ялчы
Җансыз сандыр, бары сан гына...
Санап бара, ничә чыбыктан соң
Гыйсъян җаннан калыр кан гына.
Каны агып торган ак күлмәкле
Ил ирләре ята, сугылган…
Мәйдан халкы җаны әрнүеннән,
Кара кайгысыннан егылган.
Йөз утыз ел элек... Бүген дә шул
Хакыйкатьның сырты ялангач.
Суктыралар башка корал белән,
Таллар гына ала алмагач...
Җәза тактасында – тагы берәү,
Богаулылар тора чиратта...
Әллә уйлыйсызмы бу көннәрне
Калган диеп күптән еракта?
Юк, юк! Азат җаннар китми җирдән!
Җир – ул азат җаннар тәхете!
Тик көрәшеп кенә алып була
Халкың өчен җирдә бәхетне!
Җәллад ничә гасыр тал пешерә,
Кылыч кайрый, туплар ясата.
Ә азатлык – богау тотмый, аны
Алып булмый дию – сафсата!

**2**

Музейларга кермәм дигән идем,
Ничек кермисең, ди, тарихыңа! –
Җаны булган чыдамаслык хәлләр...
Анда – тарихның да җаны гына!
Ыңгырашып, үксеп елый-елый
Чыгып барам Апас музееннан.
«Әби, ник елыйсың, кем тиде?» – дип,
Итәгемнән тарта, аһ, бер олан.
Туктап калам, ничек елмаерга?! –
Бу илаһи сабый күзләрендә
Өмет нурын саклап калдырырга!
Алай гына түгел, кирәк! Кирәк! –
Өмет нуры сүнгән җаннарда да
Өмет нурын кабат кабызырга!
«Әйт, кем тиде?» – ди бит сабый бала. –
Туган телдә туры карап күзгә!
Җавап бирәм: «Бел син, нарасыем,
Бәхет өчен нәрсә җитми безгә? –
Синең белән минем аңлашуым
Туган телдә һәм дә бәйсез илдә!
Кем тидеме? Ансын һәркем белә! –
Дәшми яшәүләре газап гел дә.
Музей – тарих, ә син – киләчәгем! –
Хәлләремә кердең туган телдә!
Мин еламыйм, язгы тамчылар ул
Түбәләрдән тамып тора әнә...»

## Бурыч һәм бер уч

Мин бу җирдән күпме язлар алдым
Күпме назлар алдым мәхәббәттән.
Җәйләреннән күпме җылы алдым,
Сагышларым Иделләргә салдым.

Күпме серләремне сыйдырды ай,
Давылларда күпме ярсуларым!
Күкрәүләрем күкрәгемә сыймый,
Ташкын иттем күпме кар суларын...
Яфрак-йөрәкләрнең өсләренә
Басып йөрдем сары көзләрдә лә.
Күпме нурлар, җылы елмаюлар
Өзеп алдым ачык йөзләрдән дә.
Җылыттылар мине, өшеттеләр,
Яраттылар мине, тараттылар...
Йолдызлы күк дигән мәңгелекнең
Күзләренә хәтта караттылар.
Мин бу җирдән шулкадәр күп алдым, –
Бурычлы мин җиргә, зур бурычлы.
Ә калдырып китәм куенымдагы
Туган туфрагымнан тик бер учны...
Җирнең ярасына сипсәгез лә...
Бурычымны гафу итсәгез лә...

***

Ышанасы килми... Ләкин мин дә
Җир өстендә тиздән булмам инде.
Һәм берәүнең кайнар кочагына
Сөю кузы булып тулмам инде.

Моңсу итәрмен күк кемнәрнедер
Бәлки, бик тә, бик тә бәхетле?!
Ләкин тартып ала алмас алар
Ләхеттән дә үзенә тәхетне.

Сагынучылары да, бәлки, булыр...
Яфракларны көзләр саргайтыр.
Сарысын да, соры, карасын да
Салкын карлар тагы агартыр...

Яз дөньяны кабат чишендерер, –
Умырзая башын түбән ияр.
Бу язларның тәүге шыткан гөле –
Әүвәлгесе барыбер ул – мин! – дияр.

Ышанасы килми. Ләкин мин дә
Бу дөньяның иң нык көтелгәне!
Чама белми фани җил иркендә
Ахыргача гына сүтелгәне!

Бакый дөнья җыеп алды менә, –
Талларымның тоям тамырларын.
Мин бәхетле, мин бит тоеп ятам
Фани таллар мине тануларын?

«Ышанасы килми», дигән идем,
Шулкадәрләр ышанасы килә. –
Каберем өстендәге талларыма
Яшел бәбкәләре менеп килә...

Аһ, күрәсе генә килә, килә!..



Рүзәл
Мөхәмmәтшин

# ЛАЛӘЛӘР

хикәя*

Бүлмә кысан иде.

Күкрәк тутырып сулыш алсаң, бушлык калдырмыйча, дүрт як диварга терәлерсең кебек. Җилкәләр түшәмне ышкып тора. Сыңар тәрәзә өстеөстенә бизәлеп, чуарланып,челтәрләнеп беткән. Аның аркылы сүрән генә яктылык сирпелә.

Шәкерт акшарланган дивардагы уемтыктан уймак кадәр пыяла савыт чыгарды. Көнгә таба борылып, каш турысына күтәрде. Төбәлеп бакты.

Риваяти Фәрһаднең йөрәк суты сыман кырмызы буяу!

Аны, май кушып, шушы куелыкка, шушы җетелеккә, шушы бербөтен камиллеккә җиткергәнче, никадәр бөҗәкне сытып он итәргә кирәк икән? Игътибар илә карасаң, арада үлеп өлгермәгәннәре дә бихисап, диярсең: буяу кымшана, буяу тере иде...

Шәкерт, аякларын шәрекъчә бөкләп, идәнгә утырды. Тезләренә ләүхен[1] салды. Катыргыдагы тонык сызыклар буенча караташын батырып уздырды. Аннары каурый каләмгә үрелде...

Әмма палас өстенә сузылган бармаклар һавада эленеп калды.

Үзе дә искәрмәстән:

– Каң-каң! – дип куйды ул.

Ашыкмыйча гына урыныннан торды. Чуарланган челтәр янына барып басты. Тәрәзә ачты. Йөзенә кайнар коры җил агымы бәрелде.

Җилдән тозлы тәм килә иде...

Шәкертнең карашы нәрсәдер эзләгән шикелле офыкларны капшады.

---

[1] Ләүх – такта.

---

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсының «Хикәя» номинациясендә 1 урын алган әсәр.

---

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. «Каралама», «Бүре мин», «Мин дә китәрмен әле» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

Яңадан бер хәтереннән кичерде ул: анда, ил-суларның аръягында, кош очып җитмәс ераклыкта, бөтенләй башка дөнья бар...

Анда бөтенләй башка тормыш кайный.

Үз ыгы-зыгысында.

Ансыз гына.

***

Юл кешесенең юлда булуы хәерле, диләр.

Кирәксез нечкә хисләрне җаннан кагып, егетләрчә саубуллаштык. Билгеле, барысы да имин сәфәр теләде.

Иң ахырдан Аида белән күзгә-күз орыныштык.

Аида – үзгә шул. Идарәдәге башка хезмәттәшләр кебек түгел.

Беркемгә охшатмыйча, йөрәгеннән өзеп озаткандай, муеныма сарылды:

– Миңа Бохарадан кояш, тәмлүшкә һәм... алсу чәчкә алып кайт, яме?

Аның кайнар тыны баш миен эретерлек иде. Һушым, тамырын җуйган люстрага бәрабәр, идәнгә чәчрәде. Кочактан чыгуга өшеп киттем.

– Килештекме?

– Моңа җавап та бирәсемени әле? – дидем, исәнгерәгән халәттә.

– Ым кагуың да җитә.

– Хуш.

Аиданың татарчасы шактый нык иде:

– Бу – хушлашу гына түгел бит?

– Юк.

– Әйе алайса?

– Әйе.

Шулай аерылыштык.

Минем, аэропортка юнәлгәнче, өйгә чабып, чүпрәк-чапрак җыясы, паспортны табасы, чырайны шомартасы бар иде. Тамак төбе дә ничектер кымырҗап, кипшереп торамы соң?..

Тәүге мәртәбә очкычка утыруым лабаса!

Юл аягына, дип кенә инде.

***

Димәк ки...

Республика Шиһабетдин Мәрҗанинең олуг юбилеена әзерләнә иде.

Ел дәвамында башкарыласы эшләр аерым планга тупланды.

Бусы яхшы иде, әлбәттә.

Әмма, гадәттәгечә, күләм артыннан куып, чараларның эресе-вагы, кирәксезе-кирәге – һәммәсе дә шыплап тутырылды аңа.

Мин, дәүләт хезмәткәре буларак, бусын да начар дип әйтә алмыйм.

План шунда ук тормышка ашырыла башлады.

Мәшһүр мәгърифәтченең биографиясе, цитаталары, сурәтләре тупланган панно эшләнде. Гыйнварда ук. Календарьлы, затлы, саллы итеп. Башта, һиммәтле һәдия кебек, сырлана-сайлана, җитди адреслар буенча гына таратылды ул. Аннары ел ахыры җитәрәк экономиянең кирәгеннән артык экономияле булуы ачыклангач, бюджет оешмаларына да өлеш тиде.

Ул көннәрдә республика яңа юбилейга әзерләнә иде инде...

Хәер, вакыйгаларны ашыктырып җибәрдем бугай.

Сүз башына чигенеп әйтәсе килгәнем шул: әлеге планда Бохараның «Әмир Гарәп» мәдрәсәсенә истәлек тактасы кую да каралган иде. Мәрҗани хәзрәтләре анда бик озак еллар буе белем эстәгән.

Бусы – яхшы.

Әмма нәрсә ул Бохара? Ничек ул Бохара? Кайда ул?

Аны арыш ипиенең өстенә ягып ашыйлармы, астынамы, дигәндәй...

Киңәшмә вакытында берничә маңгайга төртеп:

– Сез!.. Ачыклап кайтыгыз, – диделәр.

Безнең эштә командировкалар еш тәтеп тормый. Бигрәк тә чит илгә. Бигрәк тә хөкүмәт хисабына. Шуңа күрә бу йөкләмәне, ничектер, сукранмыйча, хәтта үзенә бер энтузиазм белән кабул иттек:

– Баш өсте!

***

Аэропорт эчпошыргыч зур иде.

Без өчәү – бик кечкенә.

Берәү – министрлыктан, берәү – Диния нәзарәтеннән, берәү – мин.

Әйе, өчәү.

Табышып бетәрбезме, дип борчылдым.

Бәхетемә, озак та үтмәде, ишек төрендә Рафаэль күренде.

Исәнләштек.

Бераздан чалма-чапанга төренгән хәзрәт җитеште.

Исәнләштек.

Делегация җыелып бетте.

Җөмләдән, Рафаэль – аның җитәкчесе иде.

Кая барганымны белми бара торгач, мин урманга кереп адашкан сарык хәлендә калдым. Кайсы як – уң, кайсы як – сул? Мәгърип кайда, мәшрикъ кайда? Ас? Өс? Юл ничек? Очраклы рәвештә «яшел коридор»га тарыгач та, эчкәре узарга базмадым. Тупланып җитүебезне көттем. Белер-белмәс юл күрсәтү Ленин бабайга гына килешкән.

Өчәүләп паспорт тикшертергә бастык.

Шунда хәзрәт, аңкавына нидер атып, авызын каплады.

– Элек тел астына үлән салып йөри идем, – диде, кабаланып. – Бусы куәтлерәк нәрсә. Юкса, баш мие түнеп бетми...

Аның сүзләре шактый дөнья күреп өлгергән мине дә сискәндерде.

Төсем үзгәрүеннән сәерсенепме:

– «Драмина», – дип өстәргә кирәк тапты ул. Кулында чуар дару кабы үсеп чыкты. – Биеклектә чайпалуны авыр кичерәм...

Тутырып:

– Дурак! – диде эчке тавыш.

Хәзрәтне чик аша авырсынып кына уздырдылар. Тегеләй күз текteләр, болай. Елмаерга куштылар, каш җыерырга. Профилен карадылар, анфасын...

Ахырдан аңа тиешле «Хәерле юл!» да, иясенә ияреп өлгермичә, минем чырайга бәрелде.

Хәер, үзем дә бераз таптаныбрак тордым.

– Сәфәрегезнең максаты?
– Командировка, – дидем.
– Ялгызмы?
– Юк. Делегация белән. Хәзрәт яңа үтте әнә...
Шушы төштә чал дөнья чак кына тәшвишләнеп алды.
Тикшерүче ханым, шаять:
– Сез дә... хәзрәтмени? – дип анықларга теләгәндер.
Мин аны:
– Сез дә... делегациядәмени? – дип аңладым.
Ул исә, гомумән, көтелмәгәнчә, кыскартып:
– Сез дә... мени? – дип сорады.
Бу вакытка минем тамак төбе кипшереп тормый иде инде...
Һич каушамыйча:
– Әйе, – дидем, иркен сулап.
Ханым сары май шикелле эреп китте. Авызы ерылды. Нишләптер. Алсу мөһер сугылган паспорт учыма шуып керде.
– Рәхим итегез! Хәерле юл!
Ышанычлы кеше булуым йөземә чыккан, күрәсең.

***

Карап торышка очкыч – канатлы электричка икән!..
Шундый ук кәнәфи. Шундый ук багаж киштәсе.
Әмма электричкадан аермалы буларак, монда юл буе билет тикшереп йөрмиләр. Һәм, ихтимал, «куян» ишеләрне ишектән куып та төшермиләрдер.
Җирдән кубу халәте искиткеч иде.
Бәдәнемне ташлап, биеклеккә җанымны гына алдым гүя.
Гарешкә ашкандай. Тфү – өч тапкыр!..
Җиңелчә баш әйләнде. Авырлык җуелды.
Авышып менү сәер иде. Кәкре каенга терәтелгән сыман.
Колак эчендә нидер сынды. Әүвәл – берсендә, соңыннан – икенчесендә.
Озакламый ап-ак томанга чумдык.
Аяк астында иксез-чиксез юрган кабарынып чыкты.
Аның ертыклары аша яктылык, йортлар, биналар шәйләнде.
Мин, ниһаять, Җирнең тарту көченнән арынып, аклык, тоташ аклык эчендә калуымны аңладым.
Калак сөякләре авыртып куйды.
Канат урыны.

***

Очкыч Ташкент аэропортына төшкәндә, кояш баеган иде инде.
Бүген монда кунсак, иртәгәсен Бохарага кузгаласы.
Аңарчы минем төнге шәһәрне күрәсем килде.
Бәлки, берәр кумырыкта яшь Такташка тарылыр?
Яшь, дип... Картлык аңа орынмаган да.
Әллә орынганмы?
Бәлки, кабер авызына тәмам чаларган, тузган, янган хәлдә барып аугандыр ул? Андыйлар гомерлеккә җитәсе коры-сарыны берәмтекләп тота

белми. Олавы белән утка томырып көл итә. Шул вакытта дөнья беразга гына булса да яктырып ала.

Юк, миңа Такташ очрамаячак.

Чынбарлыкның күзенә карап яшәргә кирәк.

Такташ Казанда. Такташ үле.

Рафаэль, эш күплегенә сылтап, номерына посты. Калган икебез (ике эшлексез, димәк) җилләнеп кайтырга уйладык. Ишекнең ябылуын ишетүгә:

– Әссәлам! – диде хәзрәт.

– Вәссәлам! – дигән җавап иреште.

Урам, төн пәрдәсен этеп, яңа танышларын шәһәр түренә озатты.

Ташкент җылы иде.

Мондагы гыйнварны авыз тутырып гыйнвар, дисәң, шул мизгелдә үк безнең Шүрәле үзен Кар кызы дип игълан итәчәк, көт тә тор!

Агачлар шау бөредә.

Өрфиядәй һавага салкынча язгы сафлык сеңгән.

Һәр тараф – пөхтәлек.

Машиналар күп түгел. Алары да юл йөрү кагыйдәләрен санга сугып бетерми икән. Хәзрәтне берәү зебрасы-ние белән бергә бәреп китә язды. Сүз уңаеннан, шунда мин аның сүгенүгә хирыслыгын ачыкладым.

Гарәпчә – тозлап-борычлап!

Мин ул телне әлләни белмим үзе. Бөтенләй белмим хәтта. Әмма башны түмәр салырга әзермен: андый интонация белән салават укымыйлар.

Без Эчке эшләр вәзирлеген арттан урап уздык. Космонавтлар монументына кагылдык. Хыялга тиң Зәңгәр гөмбәзләр бульварын кичтек. Аңардан соң уңга каерып, күпмедер баргач та, Туран әмире Аксак Тимер хозурына килеп чыктык. Гайрәтле иде ул, бөек иде. Мәгърур иде!

Тимурилар музееннан сулга салуладык.

Отыры күз алдында Олы Мәҗлес, Хөкүмәт биналары калыкты. Мөстәкыйльлек мәйданына аяк басып карадык. Аның иркендә без татарга да рәхәт иде...

Һич уйламаганда, Шәрәф Рәшидовның бил буе сынына юлыктык.

Мин тулар-тулмас хәтер сандыгын капшадым. Совет Үзбәкстаны җитәкчесе. Брежневның якын дусты.

– Мамыктан үзенә аркан үргән кеше, – дип өстәде хәзрәт. – Монда әлегәчә шәхес культы чәчәк ата, диләр.

– Белмим.

Хәлбуки, шушы һәйкәл янында Аксак Тимернең аты да горуранәрәк күренә иде...

Без кайтырга борылдык. Икенче мәртәбә гөмбәзләр бульварыннан үттек. Бу юлы – алдын-артын бутап. Композитор Юныс Рәҗәби барельефына җиттек. Шунда озын, иркен һәм яп-якты проспектны капыл караңгылык өзде. Ары таба куе төнне ерып атладык.

Озакламый «Шәрекъ» сүзенә тезелгән хәрефләр балкышы күзне кырды.

Безнең отель иде бу.

***

Иртәгәсен әче таңнан торып, юлга кузгалдык. Уртак вагонга туры килсәк тә, билетларны аерым-аерым юнәткәнгә, өчебез өч урынга арка терәдек.

Алар икесе алгарак урнашты.

Мин юл буе йокы исереклегеннән арына алмый изаландым.

Һушым җыелган саен борын төбендә хәзрәтнең чалмасы уйнады.

Аны тануга, кыйбламның җуелмавына куанып, кабаттан сүнә бардым.

Рафаэль дә ориентир булырдай югыйсә. Мәгълүматлы. Тыныч. Төпле. «Җиде кат үлчә...» мәкале танышмы икән аңа? Юктыр, мөгаен. Ул һәрвакыт сигез тапкыр үлчи. Һәм беркайчан да кисми. Чөнки бер киселгәннең кире ябышмавын яхшы белә. Аның белән эш кыру җиңел. Чабуыннан ычкынмасаң, аждаһаның авызына тереләй кереп, арт шәрифеннән исән-имин чыгасың.

Ләкин ул хәзрәттән кыскарак. Мин аны биек терәүле утыргычлар арасыннан таба алмадым.

Сыңар күзем чалмада булса, икенче сыңары – тәрәзәдә иде.

Анда – сап-сары, кайбер урыннары хәтта агарып калган коры басулар...

Буй-буй канаулар ерылган...

Анда – җиләк-җимештән сыгылып төшәчәк шәрә үсенте-куаклар...

Анда – арматурадан корылган койма-капкалар...

Озакламый йөзем сабаклары сарылып, аларны җәннәт капусы итәчәк.

Анда – чалыш чагылышым.

Гүзәл пейзажны бозып тора.

***

Безне вокзалда ук каршы алдылар.

Күрештек, таныштык.

Туризм департаменты егетләре икән. Яшьтиләр үзе.

Куш авыздан:

– Xush kelibsiz! – диделәр.

Имгәтелгән татар теле колакны сыдырып узды. Ят хәрефләр шулай тәэсир иттеме? Үзбәкстан утызынчы елын ышанычлы адымнар белән яңалифкә күчү юлында иде.

– Саумысыз! – дидек, урыс имласында.

Ары таба алар үзләренчә әйткәнне без үзебезчә ишетергә күнектек.

– Хаким урынбасары Шәһрияров сезне өйләдән соң көтә, – диделәр.

Аңарчы вакыт бар иде әле.

Иң беренче эш итеп, индәге йөктән арынасы, өстәге сәфәр тузаныннан кагынасы, чайканып аласы килде. Букча төбендә аунаган кәчтүм-чалбарны хуш тәнгә үтүкләп кигәч тә, фырт кияү төсле ясанып-сибенеп, теләсә кая барырга ярый иде.

Борынгы шәһәрнең күз алмасына тиң «Күгелдаш» отеленә урнаштык.

Атаклы мәдрәсәнең адашына.

Алар бер-берсеннән кул сузымы ераклыкта гына иде.

Ләб-и-Хаус мәйданында.

Без моны соңрак белдек, билгеле.

Гыйнвар – бу яклар өчен буш, иписез вакыт булып чыкты. Туристлар

өере майга таба гына ябырылачак әле. Хәзер суык, диләр: термометр ун градус җылы күрсәтә.

Миһман[2] йортлары, чәйханәләр, базарлар – барысының да! – кышкы аю ише, уйкулы-уяулы хәлдә, бармак суырган чагына тарыдык.

Бохара кеше-карага тансыклаган иде.

Безне отельдә гуманитар ярдәм сыман кабул иттеләр...

Күңел тулды. Букча бушады. Иң ахырдан муенга галстук тагылды.

Хәзерләнеп беттек.

Без чыкканчы, егетләрнең берсе эзен суыткан иде инде. Икенчесе, үзен Җиһангир дип таныштырганы, ресепшендагы күн көрсиеннән купты:

– Чәйлибезме?

Йөрәк астында нәрсәдер хуплап, тавыш бирде.

Тар урамнар аша үтеп, Хуҗа Насретдин һәйкәленә якынлаштык.

Каршыда – исеңне җуярлык манзара ачылды.

Ләб-и-Хаус!

Ясалма сулык тирәли укмашкан пулатлар ансамбле.

Борынгы китаплардан кагып төшерелгән тере әкият, тере могҗиза!

Бохара – тулаем шундый иде.

Надир Диванбәге ханәкәсе[3] кырындагы ресторанга кереп сыендык. Өстәлгә сый-нигъмәт бөялде: өресе мәмрәп торган шурпа, кыздырылган ит, ирен тиюгә эрегән кәбаб, пылау – буларын сулауга миңгерәрсең, валлаһи! Табагы белән җиләк-җимеш. Тәм-том. Чәйнектән елга урынына агылган чәй.

Бераз алга күчеп, икърар итим: без биредә кадер-хөрмәттән өзелмәдек. Сәгате җиттеме – һәрвакыт, һәркайда ачык чырай, мул табын булды. Мин берничә тапкыр түш кесәмә үрелеп карадым. Әмма хәзрәт, кулыма суккандай караш атып, ихлас ниятемнән кайтарды:

– Куй, шәрекътә шулай гадәтләнгән! Рәнҗетерсең...

Аннары, койрык маеның ахыргы кисәген шәштән суырып:

– Кунак – хуҗаның ишәге, – дип өстәде.

Хәзер өстеңә атланып йөрсәләр дә, сүз әйтә алмыйсың инде.

Боларда «чәйләү» мондый булгач, «ашау» нинди икән соң?

Тууыннан бирле диета саклаучы Аида күз алдыма килеп басты.

Мин аның куркыныч төшенә үтеп кердем гүя.

***

Хушланганнан соң хакимияткә киттек.

Батырҗан әкә Шәһрияров безне ишек төбендә үк каршылады, түрдән уздырды. Сохбәтләштек. Бик җылы, җанлы әңгәмә оешты.

– Шиһабетдин Мәрҗани – бөек шәхес, – диде ул.– Эшнең безгә караган өлешен кызу тотарбыз. Документлар тиз арада хаким өстәленә ятар.

Татарстан, татар халкы, аерым алганда, «Ак барс» командасы турында матур-матур фикерләр ишеттек. Авызыннан болай кош очырган кешенең сөйләме, һичшиксез, нәрсәдер сорап тәмамланырга тиеш иде.

[2] Миһман – кунак.
[3] Ханәкә – суфыйлар торагы.

Һәм – үтәли бактым!

Йомгаклар алдыннан ул, кабыгына яшеренмичә:

– Бездән өстәмә ярдәм кирәкме? – дип, җанын ачты.

Рәнҗетмәс өчен генә дә баш кагарсың.

Юкса, нинди ярдәм тагы? Иң югары катта хуплау тапкан килеш!

Татарстан, әлбәттә, барлык чыгымнарны үзе күтәрәчәк. Сынчысын да табачак, язуын да төшерәчәк, тактасын китереп урнаштырачак та. Әйткәндәй, текстны өч телдә язарга карар кылынды: үзбәкчә, урысча, татарча (латин имласында). Ләкин «Әмир Гарәп» зур. Җитмәсә, ЮНЕСКО мирасы.

– Тышкы яктан мәдрәсә диварына кадак кагарга ярамый, – диделәр.

Казанда бу мәсьәлә җиңел хәл ителер иде...

Без формализм яклы түгел.

Монда исә күнәргә туры килде.

Батырҗан әкә:

– Җиһангир – күзем-колагым, – дип саубуллашты. – Аны тулысынча сезнең ихтыярга тапшырам.

Үзе шунда ук хезмәткәренә борылды:

– Кунаклар чәйләгән идеме?

Бертавыштан:

– Әйе! – дидек.

– Хушыгыз алайса.

– Рәхмәт!

Күктә эри барган кояшның кайнар нуры йөрәк тамырына тамды. Күңелнең иң караңгы почмагы да яктырып китте. Бөтен буыннарга җылылык таралды. Истирахәт хисләрдә чайкалган көйгә күкрәк киерәсе килде.

Хәзрәт:

– Сөбханәкә Тәгаләнең биргәненә шөкер! – дип җөпләп куйды.

Без данлыклы «Әмир Гарәп»кә юнәлдек. Мәдрәсә мөдире хәбәрдар – ул делегацияне көтеп тора иде инде. Татар тотып карамыйча ышанмый. Истәлек тактасы куелачак урынны билгеләп ачыкларга, тәгаенләргә килештек. Мәрҗани турында сүз бара лабаса! Монда ордым-бәрдем эш йөртергә ярамый. Без беренче очраган нүешкә разый түгел.

Бусы хәл ителгәннән соң, тактаның якынча үлчәмнәрен исәпләп, сызымнарын сызып, кайтыр юлга кузгалырга да мөмкин иде. Аңарчы беркадәр күчтәнәч-һәдия җыеп өлгерсәк, яхшы.

Без Бохара өстеннән кояш белән бергә югалырбыз.

Саба җилләре уянганда, эзебез дә калмас.

Яңа көн безне юксыныр.

***

Бохара-и-Шәриф!

Бу могҗизаның чынбарлык булуына мәңге төшенеп җитмәслек!

Мондый корылмаларны кеше кулы торгыза аламыни?

Хәзрәт кичерсен: илаһның шатлыклы күз яшеннән яралган шәһәрдер бу! Югыйсә сулуга кабарлык матурлыкларны тагын ничек аклап, ничек аңлап булсын?

Мин аның чеметемен дә тел белән сурәтләүдән гаҗиз.

Бохара – таштан язылган шигырь.

Аның иң кечкенә хәрәкәсе дә миннән зуррак, миннән бөегрәк.

Исәпсез-сансыз биналардагы бизәкләр – чигү итеп чигелгән, диярсең!

Илаһи хозурлык!

Па-и-Кәлән мәйданына аяк басуга берничә гасыр артка чигерелеп куясың гүя. Аннары әкренләп кенә, бүгенеңә кайта башлыйсың.

Һәр адым – бер чор.

Саманилар, Шәйбанилар, Аштарханилар, Мангытлар дәвере...

Әнә риваяти Сиявуш, үгез тиресен телеп, Арк кальгасының чикләрен билгели...

Әнә Бохараны аударган Чыңгыз хан әгъла[4] Кәлән манарасы каршында тораташ басып тора. Манара – биек! Карашың – очына җитмәслек! Өскә төбәлгәндә, җиһангирның очлымы төшеп китә. Җиз башлыгын күтәреп алырга дип, җиргә иелә ул һәм... үзе дә искәрмәстән аһ итә:

– Син мине тезләндердең түгелме соң, Бохара?..

Әнә Йәмән әмире Габдуллага мәдрәсә корыр өчен Гобәйдулла хан өч мең фарсы әсирен коллыкка сата...

Әнә Шиһабишәкерт «Күгелдаш» көтепханәсендә «Вафийәтел-әсляф» рисаләсенең[5] тәүге җөмләләрен кәгазьгә төшерә...

Бу туфрак изге суфыйларның, әүлияләрнең сөяге белән ашланган.

Монда һәр калкулыктан яктылык, гыйрфан тарала!

Илаһи мөкатдәслек!

Фани дөньяга килеп, Бохараны күрми китү – сукыр килеш туып, кояшны күрми яшәүгә бәрабәр.

Мин Җир йөзендә моннан да гүзәлрәк урын барлыгына ышанмыйм.

Бохара – гыйффәтле шәрекъ шаһинәсе!

Мин башымны җуеп гашыйк булдым аңа.

***

Шәкерт зөбәрҗәт һәм сәфид буяуларны кулына алды.

Соңгысына аеруча мөкиббән ул. Чөнки аңа барысы да сыйган: туу да, яшәү дә, үлем дә... Юк та кебек үзе, әмма, һичшиксез, бар да. Һичкайчан кычкырып, күзгә төртеп тормый.

Сабый чагында аның һәммә тавыкларны акка әйләндерү хыялына бирелгәне булды. Өй халкына белдермичә, чуар кош-кортларга әтәч койрыгы тагып, биниһаясен әткәсе тарафыннан суйдырып бетерде.

Аннары үкенде, билгеле. Җүләр эш кылынган, диде.

Табигатьнең бөтен купшылыгы – төрлелектә.

Шәкерт үткен каурыен пыяла савытка батырды. Сәфид буяу йөгертеп, чит-читен каймалар өчен кырмызы таҗлар өстенә иелде. Каләм очы орынуга гөлт итеп, чәчкәнең чәһрәсе үзгәрде.

Бушлык эчендә яралган рәсем һаман саен күперенде, куерды.

Азактан зөбәрҗәт буй сузылды.

[4] Әгъла – бик яхшы, матур.
[5] Рисалә – әсәр, китап.

«Әлфе ләйлә вә ләйлә»дән[6] хәтерлиме соң әле? Сүз кузгалгач, шушы гүзәл чәчәк йөзем суы илә учакка әйткән, ди: «Мин ирენгә тимичә дә исертәм вә ялкыным сүрелмичә янам».

Икенде вакыты үтеп, көн ахшамга авышты.

Шәкерт әсбапларын ләүхенә җыйды.

Аннары, чигүле чапанына төренеп, алдан килешенгәнчә, остазы Бабарәфикъ дамелла хозурына ашыкты.

Артык мәшәкать санаганга, артыннан ишеген бикләп тормады.

***

Бүлмә кысан иде.

Күкрәк тутырып сулыш алсаң, бушлык калдырмыйча, дүрт як диварга тәрәлерсең кебек. Җилкәләр түшәмне ышкып тора. Сыңар тәрәзә өсте-өстенә бизәлеп, чуарланып,челтәрләнеп беткән. Аның аркылы сүрән генә яктылык сирпелә.

– Җәмгысе 114 хөҗрә[7]. Коръән сүрәләре санынча, – диде Хәйдәрхан әкә.

Үзе түрдән узып, тәрәзәне тартып карады. Ачык икәнлегенә инангач, этеп, эшермәсен төшерде.

– Бусы, чыннан да, Мәрҗанинекеме? – дип кызыксындым мин.

Рафаэль астыртын елмайды:

– Шәрикләреннән сорашып кайтмыйсыңмы?

Алай да өнгә килүемне күрмәгәч:

– Символически инде, – дип өстәргә кирәк тапты.

– Ярар, – дидем күнеп.

Халык мәкале хәерчегә сәлам биргәнче кат-кат уйларга куша.

Безнең җанны да нәфес корты кимерде. Оятны онытып, берәр хөҗрә ишегенә ямаулык кадәр генә булса да, истәлек билгесе беркетергә сорадык. Монда, имеш, Мәрҗани үзе яшәгән! Шәп бит?

Алар янә ризалашты.

Җитмәсә, аскы каттагы дәресханәгә «Монда Мәрҗани укыган!» дип, тагын берне урнаштырырга кыстадылар әле.

Бу юлы без ризалаштык инде.

Шуннан соң, мәдрәсә мөдиренә ияреп, караңгы коридорга уздык. Бормалы тар баскычларны таптый-таптый, ишегалдына төштек.

«Әмир Гарәп», Бохарадагы биниһая биналар сыман, гаять үзенчәлекле итеп салынган иде. Түбәсе ябылмаган дүрт почмаклы йортка охшатып, димме? Үзәге – куыш. Калын дивар урынына – алагаем зур пиштакның[8] ике иңеннән икешәр катлы хөҗрәләр тезелгән. Алар өстендә – күккә ашкан пар гөмбәз. Фирүзәләрендә – алмаз-җәүһәр балкышы!

– Таш капчык эчендә калгандай, – диде Рафаэль, тирә-юньгә багып.

Һәркемнең үз хакыйкате.

– Аның каравы, җәйге чилләдә рәхәт, – диде мәдрәсә мөдире. – Кояш кайсы яктан караса да, биредә һәрвакыт җиләс, күләгә.

– Әнә теге әйванда[9] ничек булыр?

---

[6] «Мең дә бер кичә» китабы.
[7] Хөҗрә – мәдрәсә торагындагы бүлмә.
[8] Пиштак – портал.
[9] Әйван – бинаның гөмбәзле, өч яктан дивар каплап, бер ягы ачык калган уемтык өлеше.

Алар өченче, ягъни төп истәлек тактасын куярга урын барлый иде.

Хәйдәрхан әкә Рафаэль ишарәләгән якка борылды.

– Карап килик.

Мин баскан җиремдә чалкан китеп аумас өчен аркама терәү табарга тырыштым. Артымда ни бар соң?

Казан кирмәне? Сөембикә манарасы? Бөтен авырлыгымны салып сөялсәм, чыдармы ул?

Шайтан каласымы?

Кара пулатның яңа гасыр цементы тоташтырган шома ташларымы?

Нигә мин аларның җылысын тоймыйм?

Ә монда – йөзем пешә...

Шәһри Болгарның яңаруы «Болгар» номерлары җимерелгән чорга туры килгәнгәме әллә? Бүгенге каланчам миңа андый эшләрнең ничек эшләнүен тулаем ача.

– Ни өчен «Күгелдаш» яисә Сәмәркандтагы «Ширдар» түгел?

– Ничек?

Хәзрәт җәһәннәмнән калыкты гүя.

– Мәрҗани аларында да укыган бит. Ни өчен истәлек тактасы нәкъ менә монда куела?

– Белмим, – дидем.

– Аны сез хәл итмәдегезмени?

– Юк. Без кечкенә кешеләр.

– Кем алайса? – Ул, чыннан да, аптыраган төсле иде.

– Башкалар. Без – кушканны үтәүче генә.

– Күңелеңә хуш йөкләмәләр генә кушыламы соң?

Мин, җавап кайтармыйча, хәзрәткә төбәлеп бактым. Аның карашында нәрсәдер сүнеп, үзгә нәрсәдер кабынды:

– Дөнья бу, йа! Кем эшләми – шул ашамый.

Ул, шомлы халәттә япа-ялгызымны калдырып, ары атлады.

Шык-шык. Түшәлгән таш буйлап.

Каның тартмаган өлеше дә төшә, билгеле...

Җаның ятмаганны да эшлисең.

Бу – вазифам гына, мин аны функционер буларак башкарам, әмма Адәм баласы сыйфатында – катгый каршымын, дисең.

Шәхесеңне икегә таркатып, юаныч эзлисең.

Болай яшәүнең дөреслегенә вөҗданыңны күндерергә һәм, сафсата сатуыңны анык аңлаган хәлдә, муенына кирпеч тагылган сукыр әнчек сыман, шуңа күнәргә тырышасың. Аркылы карасаң да, торкылы карасаң да, син – барыбер син бит инде ләбаса!..

– Юк! – дип юанасың.

Урам җыеннарын таптап узган гвардия бурзайлары да үзен шулай юатадыр. Вакытында айнзацгруппалар үзен шулай юаткан кебек. Кулларын юып, ипигә үрелгәнче.

Иманым камил: хәзрәт бик тирәнгә кереп уйланды.

Әмма уендагысын теленә күчермәде.

Мәрхәмәтле иде ул.

Ишегалдын иңгә-буйга таптап узганнан соң, яңадан яныма килеп басты:

– Шиһабетдин хәзрәтләренә карата үзең нинди фикердә?

– Уңай, – дидем мин. – Указ чыкты бит.

– Үзең, дим?

– Уңай.

– Габдулла Тукай язган шигырьне дә беләсеңме?

– Беләм.

– Мәрҗанинең каберташы очында – куш уч кадәр шар сыны урнашкан. «Тулган ай күк балкып чыккан Шиһап хәзрәт...» Төшендеңме?

Көтелмәгән тәэсир ташкыны үпкәне өшетеп үтте, чигә турысына сукты.

– Шәп! – дидем мин, хисләремне тыймыйча. – Беренче тапкыр ишетәм.

– Димәк, гүрен яд кылганың юк...

Хәзрәт Бохара һавасы кебек салкын һәм коры иде.

Дөрес, Бохара һавасы тозлы да әле.

Ниһаять, мин үземне март уртасында урамга чыгарып эленгән палас урынына күрә башладым.

Бертуктаусыз кагып-сугып торалар, ичмасам!

Тузан гына оча.

Безне Хәйдәрхан әкә чакырып алды.

– Васыяте буенча, Габдулла Йәмәни «Әмир Гарәп»тә мәңгелек ышыгын таба. Бу вакытка ул – Нәкшбандия тарәкатенең шәехе, Мәварәәннәһер халкын Кызылбашлар мәмләкәтенә каршы күтәрелергә өндәүче, Гобәйдулла ханның остазы. Җөмләдән, Гобәйдулла хан үзен дә янәшә җирләргә сорый... Әйдәгез, төрбә эченә узыйк. Җәмәгать килеш дога кылырбыз.

Хәзрәт минем колагыма иелде:

– Вафатыннан соң Мәварәәннәһер хакимнәренең байтагы суфыйлар янына сыенырга тырышкан. Алай Аллаһка якынрак булырбыз, дип ышанган алар. Кешенең асылы шундый: берьюлы ике дөнья рәхәтенә ирешәсе килә...

Хәйдәрхан әкә сөйләгән вакыйгалар артыннан җитешә алмадым мин.

Һәр җөмләсе саен абынып егылдым.

Хәзрәтнең ни әйтергә теләвен бөтенләй аңламадым.

Рафаэль, ирен чите белән елмаеп, телефон маңгаена шалт-шолт чиертте.

«Тарәкать» сүзенең мәгънәсен эзли иде, ахрысы.

***

Отельгә кайттык, җыендык.

Бераздан ачкычлар ресепшендагы өстәл өстенә шуды.

Алар кырына Олугбәк мирза сурәте төшерелгән кәгазь кисәкләре өелде.

Безне бер авыздан:

– Янә килегез! – дип озаттылар.

– Хушыгыз! – дидек.

Аэропортка илтәсе кәҗә сукмагы ике-өч базарны ерып узды.

Ары-бире чабулаганда, кулга нават, чикләвек, кипкән кавын толымы, хәлвә ише тәм-том, чүпрәк-чапрак иярде.

Букчалар сәдәфләнмәс хәлгә җитәрәк иске-москы өеменә юлыктык. Ямалган китаплар, кителгән савыт-саба, чуар рәсемнәр... Әмма сатучы да, вакыт та, һәм, дөресен әйткәндә, артык кызыксыну да булмаганга күрә, анда озак тоткарланмадык.

Эзен өзәр алдыннан хәзрәт янә бер мәртәбә Бохарага карашын ташлады. Сәердән-сәер итеп:

– Тарих, үткәннәрдән битәр, киләчәк ул, – диде. – Шуның хакына яшәргә кирәк! Һәр көн тәмамлана. Ә киләчәк – бетми.

Бу турыда әллә кайчан оешкан фикеремне һични какшатырлык түгел иде. Хәтта хәзрәт тә кире дүндермәячәк: мин – бүген яшәү тарафдары.

Чик аша чыкканда, җелегемә үтеп, җәзалап бетерделәр.

Чыраем ышаныч уятмадымы?

Хәзрәт валлаһилап:

– Без аның белән бергә, мосафирлар, – дип ялвара торгач кына, тикшерүче ханымның йөзеннән каракучкыл болытлар таралды.

Теркәлдек. Паспортка яшел мөһер сугылды.

Залга кереп урнаштык.

Алда – озын төн иде. Төндә – озын юл иде...

Моңарчы сабыр-тыныч күренгән хәзрәт бераздан борсалана башлады.

Вакыйгалар төенләнеше тәшвишле төсмер алды.

Беренчедән, яңа гына билетларны әзерләргә кушкан диспетчер кинәт тынды.

Икенчедән, диварга кадакланган телевизор ялт итеп кабынды. Мәскәү журналистларына ышансаң, Россияне, барон Мюнхгаузен сөйләгендәге сыман, тоташ кар каплап киткән иде...

Өченчедән, ниһаять:

– Рейс алтмыш минутка кичектерелә, – диделәр.

Шушы игъланны ишетүгә хәзрәт тоташ гарәпчәгә күчте.

Инәсен дә орды, җебен дә.

Андый сәләт читтән уратып йөргәнгә, Рафаэль белән икәү урыс теленә мөрәҗәгать итеп чикләндек. Авыртмаган башка тимер тарак: үзеннән-үзе Мәскәү – Казан очкычына да соңардык, дигән сүз иде бу.

Әмма хәзрәтнең хәле безнекеннән мең кәррә мөшкелрәк булып чыкты.

Татарчага чигенгән арада:

– Мин «Драмина»ны эчеп өлгергән идем бит инде! – дип ираулады ул.

Моның нәрсә аңлатканы озак көттермичә безгә дә барып иреште.

Хәзрәт күзгә күренеп үзгәрде. Яңагы өшегән кеше шикелле, әйтәсе килгәнен ярты сәгать буе авызында күшәргә тотынды. Аннары, гомумән, чәйнәп тормыйча йотты гына. Болын кадәр аэропорт аның өчен тараеп калды гүя. Әле диварга бәрелде, әле тәрәзәгә сыланды. Үләме инде, дигәндә, йомшарды тагы. Керфекләре авырайды. Гәүдәсе, умырткадан салдырылгандай, тотрыклыгын югалтты. Утыргычка илтеп аудардык. Шуып төште. Өстенә букчалар бастырып куйгач кына тынычланды.

Алтмыш минут – туксанга, ике сәгать – өчкә әйләнде.

Ахырдан бөтенләй:

– Иртәгә килерсез, – диделәр.

Төн уртасында авикомпания арендалаган «Азия» отеленә кайтып аудык.

Ресепшенда гөлләр күрүгә йөрәгемне яшен өтте. Кан тамырлары буйлап ялкын йөгерде. Икеле-микеле халәттә, гаять каушап кына:

– Җегетләр, – дип өн салдым. – Эш шунда ки... Бик кадерле кешемә алсу чәчкә юнәтергә сүз биргән идем мин. Һәдия урынына. Һәм...

– Аңламадым, – диде Рафаэль. – Әкияттәге кебекме?

– Ну соң.

– Нарасый баламыни?

– Юк, – дидем. Әйтергәме, әйтмәскәме? – Аида.

Рафаэль салават күпере төсләренә кереп алды. Аннары, бейджлы кемсәгә борылып, яшелле-күкле тавышы белән:

– Миңа аерым бүлмә бирегез! – диде.

Исерек, чыннан да, айнымасын икән. Зиһененә мүкәли-мүкәли кайта барган хәзрәт, колак артына китереп суккандай:

– Вәгъдә – иман! – дип куйды. – Бергә кунарбыз!

***

Икенче көнне ул Бохара әтәчләре белән бергә мине дә уятты.

Пәрдәләрне каерып ачты. Йөземне тәмуг уты ялап узды гүя.

– Кояштан оят!

Нишләтәсең, башка чарам калмады – борылып яттым.

Кош-корт, дигәннән.

Монда элгәрерәк, хәтта әле Шәрәф Рәшидов чорында да, ләкләкләр күп булган. Борынгы фотоларга карасаң, Чәр-Минар, Хуҗа-Гаукушан кебек манараларның кара чалма ябынып утыруын күрәсең. Йөзәр еллык оялар! Аннары шәһәрдән су киткән. Кошлар да.

Чынлыкта бу нечкә торыклар бәби ташымый. Үзәнлектә куян баласы аулый алар. Томшык очына эләккән бичаралар, җан бирер алдыннан, сабый елавына тиң тавышлар чыгара. Матур риваятьнең төбе – менәтерәк!

Хәзер хәзрәт колак итемне якынча шулай кимерә иде.

– Тор, әйдә, тор! Базар ачылгандыр. Вәгъдә – иман!

Башка чарам калмады – киттек.

Юл уңаеннан Рафаэльнең дә ишеге кагылды. Әмма әшнә кеше, түшәгендә бастырылгандай талпынып, безне мөмкин кадәр ераккарак озатты:

– Йоклыйм!

Төптән ялгышты ул – Такый Түлпәк Фурашан базары отельгә якын иде.

Сәүдә рәтләренә кереп баттык.

Хәзрәт ары йөренде, бире йөренде. Өстәлдә яткан һәрнәрсәне кармалап карады. Папаханы киде, чүәкне салды. Сатучыларның хәл-әхвәлен сорашты, нәсел-нәсәбен тикшерде. Сәйфулла әкәнең алтынчы буын тимерче булуы ачыкланып, кечкенә чакта хатынының кызамык чиреннән газап чигүенә күчелгәндә мин, ниһаять, түзмәдем:

– Хәзрәт, бәлки, чәчкә эзләрбез? – дидем.

– Бәрәч, син як-ягыңа карап йөрмисеңмени? – дип шаккатты ул.

Һәм – тамчы да үзгәрмәде.

Бохара пычагы күңелемдәй нечкә кәгазьне урталай телеп төшерде.

Ары таба игътибарымны бермә-бер арттырдым. Әмма үтәли тишәрдәй итеп төбәлсәм дә, күз кызыгырлык һични тапмадым.

Өметкә иң якыны – фарфордан эшләнгән анар җимеше иде. Бик нык тырышсаң, аның алсу чәчкә икәнлеген Аидага раслау мөмкин дә булыр иде, бәлки. Бик нык тырышсаң. Бәлки. Яхшысынмадым шул.

Базар, гөмбәз астына сыешмыйча, бүселеп чыккан иде.

Зыр әйләнә торгач, иске-москы өеменә юлыктык. Ямалган китаплар, кителгән савыт-саба... Дежавю кичереп алдым гүя. Карашым чуар рәсемнәрнең берсендә тукталды. Гаҗәеп кабарынкы тюльпан ясалган иде анда. Төсләре уңа төшсә дә, чамаламаслык түгел: очы-очына ак буяу тамган җете кызыл... хәер, кызылмы соң?.. таҗлары; кызлар биледәй нәфис, ямь-яшел сабагы; өтер сыман бөтерелгән яфраклары... Бу әсәрдән һәвәскәрлек белән бергә әллә нинди, бөтенләй аңлаешсыз олпатлык, тирәнлек бөркелә иде.

Ул арада, каршыдагы лампадан өрелгәндәй, хуҗа оешты.

– Ал шуны, – диде хәзрәт.

– Белмим инде, – дип, астан уртны чәйнәдем.

– Ал, валлаһи, үкенмәссең!

Дин әһеленең Аллаһны шаһит итүенә ышанырга ярыйдыр, шәт?

Шуңа күрә:

– Күпме? – дип сатучыга бактым.

Язгы ләкләкләр сафыдай тезелеп киткән саннар мине аяктан екты.

Алай гынамы! Хәтта хәзрәт гарәпчә әйтер сүзен онытты.

– Без төрле валютада сөйләшәбезме әллә?

– Юк, – диде хуҗа. – Бу – гаять кадерле нөсхә. XIX гасыр. Могътәбәребез дамелла Бабарәфикъ әл-Хөҗәнди мирасханәсеннән. Торыннары тапшырды.

– Күпме чигерәсез?

– Мин сезгә чигерелгән бәяне атадым.

Беркавым муен тамырын кашып торырга туры килде. Яшермим: җаныма ятты ул рәсем. Кабат шуның ише берәр нәрсә очрармы әле? Икеле.

Янчык төбенә чумдым.

Хәзрәт исә, кочаклаплар алып, сатучыны юмаларга кереште.

Ахыр чиктә аның:

– Эш башын котлап... – дигән сүзләре йогынты ясады бугай.

Чирек бәһа чигерелде.

Ни кызганыч, миндә аның кадәр дә акча калмаган иде.

– Тагын бер тырышып кара инде, – дидем хәзрәткә.

Оҗмахта хосусый кишәрлек һәм чаларган чәче саен хурия вәгъдә иткәндерме – белмим, әмма сатучы яңадан рәсемнең ярты хакын ташлады.

Тилчә телләнсәм дә, килешмичә ярамый: хәзрәткә биредә, чыннан да, мөнәсәбәт үзгә иде. Аны әллә кайдан күреп таныйлар. Кулларын йөрәк турысына куеп сәламлиләр. Һәммә җирдә урыны – түрдә.

Көнләштемме мин? Юктыр, мөгаен. Кызыктыммы?.. Юктыр.

Һәркемнең үз тәкъдире. Һәркемнең үз юлы.

***

Отель бусагасында безне Җиһангир каршы алды.

Кыстый-кыстый, уптым илаһи чәйханәгә җыеп китте.

Төшке аштан мин буталчык хисләргә бирелеп чыктым. Кәеф күтәрелсә дә, сөмсер коелды. Шөкер кылуны онытып, зар түктем:

– Янә корсак үсә инде.

Әмма хәзрәт бу юлы да игә китерде:

– Сукранма, кайткач, бичәң белән бергә пресс ныгытырсыз.

Теш арасында казына-казына:

– Алсу чәчкә табылдымы соң? – дип кызыксынды Рафаэль.

– Әйе, – дидем.

– Алайса, ни өчен без һаман монда?

Мин, телемне йоткандай, иң җыердым.

– Бохара һавасын озаграк сулап ләззәтләнер, изге туфрак җылысын озаграк тоеп кинәнер өчен, мөгаен, – дип, ярдәмгә ашыкты Җиһангир.

Аңа ияреп, шәһрестандагы яһүдиләр мәхәлләсен кичтек.

Хәзрәткә «Синагога мәчете» дигән язу ошады.

Саманилар төрбәсен яд кылдык.

Гап-гади кирпечләрне иңгә-буйга тезеп, почмаклап-юнып төзелгән бу мәһабәт бина эчендә таш каплаган ялгыз каберлектән кала һични юк иде.

– Монда берничә буын әмир җирләнгән, – дип аңлатты Җиһангир. – Исмәгыйль Самани үзе. Әтисе Әхмәд бине Әсәд. Улы Әхмәд бине Исмәгыйль. Учыңны салып, чын күңелдән теләсәң, һичшиксез, нәсел-ыруың ишәер, диләр.

Салкын бизәкләр өстендә кулым дерт итте.

Сафсата!

Реалист булырга кирәк.

Минем шушы агымга бирелеп, Чәр-Бәкер – Әрвахлар шәһәре хакында сөйлисем килә. Әмма сөйли алмыйм. Без анда барырга җитешмәдек.

Отельгә чакырып кайтардылар.

Букчаларны барлап бетерүгә номердагы аппарат тавыш бирде:

– Җиһангир коры авызга китмәгез, ди. – Рафаэль иде бу. – Тамак төбен чылатып җибәрергә кыстый. Ресепшенга төшәсеңме?

Нигәдер:

– Берүземме? – дидем мин.

– Кемне ияртер идең тагы?

Хактан да: мондый эшкә хәзрәтне кодалау килешми бит инде.

Беренче катка төштем.

Җиһангир чәйгә охшаган «Бохара» эчемлеге койды.

Җилпедек.

Француз коньягын эчкәндә, хатын-кыз турында уйлыйсың, диләр.

Әрмән коньягын эчкәндә – француз коньягы турында.

Ә монда – үзбәкнеке.

Нәрсә уйларга да белмәссең.

Янә җилпедек.

Ни кызганыч, озаклап җилпенергә вакыт юк иде.

Җиһангир безне аэропортка кадәр озата барды.

Шулай саубуллаштык.

Бу юлы очкыч, ниһаять, Бохарадан купты.

Һәм монда кичерелгәннәрнең барысы, барысы да күз ачып йомганчы ерак тарихка әверелде.

***

Без, Җир читенә җитеп, аякларны салындырып утырдык.

Кош менмәс биеклектән бакканда, дөнья мәшәкатьләре шулкадәр вак, мескен, бичара иде. Мин күкрәк турысында якты нурлар кызышканын тойдым. Тиле ләззәткә бирелеп, шүрлеккә үрелдем. Папкадагы рәсемне ачтым.

– Карале, хәзрәт, бу тюльпан Аидага ошармы икән?

– Тюльпан түгел, лалә, – диде күршем. Ул бүген даруын эчеп тормады. Алай да күкләр куенында ойый бара иде инде. Үз кешеләре – нишләтәсең!

– Барыбер ләбаса.

Хәзрәт ризалашмыйча кашын чытты:

– Юк. Лалә – Аллаһ гөле ул. Алар икесе дә бер үк хәрефләрдән җыела: әлиф, ләм...

– Мим.

– Анысы юк.

– Аидага ошармы икән соң?

– Ник ошамасын?

– Ну, чәчкәсе бигүк алсу түгел бит.

Бу хәл, чыннан да, бераз эчемне пошыра иде.

– Нинди?

– Ну, көрән.

– Күңел күзе белән карарсыз.

Ул гырлап җибәрде. Мин яңадан иңенә төрттем:

– Хәзрәт, – дидем. – Мәрткә китми тор.

– Йә?

– Монда язу да бар түгелме соң?

– Бар.

– «Лалә» дигәнме? Кармакка охшаган тамга күрәм төсле...

– Шәһадәт язылган анда.

Гадәттә, өч сүзнең икесе аңлаешлы булса, җөмлә мәгънәсенә төшенелә. Әмма бу шундый сүз иде ки... бер дә төшенелмәде.

– Анысы ни әле?

– Әшһәдү әннә иләһә илләллаһ вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән расүлүллаһ.

Яңадан оешып сорау бирергә базу миннән бик зур батырлык таләп итте:

– Тәрҗемәсе ничек әле?

– Аллаһтан кала илаһ юк, Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәссәлам – аның илчесе.

Мин шунда гына күкрәгемнең ни сәбәпле кызышканын аңладым.

Җан газабы кичергәндәй:

– Хәзрә-әт! – дип иңрәдем. Фаҗигам бөтен буена сузылып каршыма басты. – Аида... керәшен бит!

Ул Бохара папахасын җилкә чокырына ук этеп төшерде дә:

– Шуннан? – диде, исе китмичә.

Аннары яңа куәт белән гырлауга күчте.

Бер үк вакытта Рафаэль тагы да югарырак ноталарга кизәнә иде.

Ике моң арасында япа-ялгызым калдым.

***

Без, Аллага шөкер, исән-сау кайтып җиттек.

Кояшлы гыйнвар иртәсеннән яңа тормыш башланды.

Өстәлнең сул почмагына бөялгән кәгазьләр өеме, элеккечә, эш көне ахырына уң почмакка күченә бирде. Ул арада, элеккечә, резолюцияләр яуды, карарлар кабул ителде... башлар әйләнде.

Бүләгемне Аида бүлмә уртасына элеп куйды. Дивардагы панно янына.

Хәзер ул рәсем һәрвакыт өстемдә тора сыман.

Бохарада истәлек такталары ачылды. Берьюлы өчәү: дәресханәдә, хөҗрәдә һәм ишегалдындагы әйванда. Соңгысы бигрәк матур. Бил тиңентен баганага утыртылган. Борынгы ярлык рәвешендә.

Берничә айдан Рафаэль белән икебезнең балаларыбыз туды. Юк, уртак түгел. Аерым-аерым. Аның – малай, минем – кыз. Белмим, ничек шулай туры килгәндер...

Аңарчы мин Шиһабетдин хәзрәткә кагылышлы китаплар сорап алдым. Тәрҗемәи хәлен, төп хезмәтләрен, замандашларының истәлек-хатирәләрен, мәрсия-мәдхияләрен барлап чыктым.

Язын, дөнья кардан арчылуга, Яңа бистәгә юл тоттым. Татар зиратына. Эзләгән каберемне табып, чәчәкләр салдым. Алсу лаләләр. Аллаһ гөлләре.

Ташны тетеп-тетеп бетергән язуларга күз тектем.

Һәм яңадан тома сукыр булуымнан гарьләндем.

Һәм бөтенләй һушсыз калдым: һәйкәл очында – һилал[10] иде...

Кабинетыма кайткач та, күн көрсигә урнашып, Рафаэльгә шалтыраттым. Турыдан гына. Сәркатибен урап. Өтек-төтек әңгәмә оешты.

– Теркәп куймаганмын. Синдә хәзрәтнең номеры бармы?

– Нинди хәзрәтнең? – диде ул.

– Чалма-чапанлы.

– Ха!

– Бергә Бохарада йөргәне инде.

– Син сәламәтме? – Төрепкәдәге тавыш җитдиләнде.

– Абсолютно.

– Без Бохарада икәү генә идек.

[10] Һилал – яңа туган кыйгач ай.



Гөлнара
Җәлилова

# ТАБЫЛСЫН ЯКУТЫ ВАКЫТНЫҢ...

***

Кыл урта.
Кара төн, әйтерсең,
урынын җәяргә иренеп,
ак мендәр күпертеп куйган да,
чәйнеген тергезә үрелеп.
Дегеттәй каһвәле чынаяк...
Тез чәнчеп, тәрәзә төбендә...
Мин йоклыйм дияргә өлгермим,
төн дәшә йолдызлы күгенә!
Йолдызлар тынлыгы. Кара төн.
Җем дә җем күз кыса һәр тараф...
Йолдызлар санаучы җүләрләр
Ят аңа. Таш кала битараф.
Каһвә бар. Тәрәзә төбе һәм...
(ярый ла тәмәке пыскытмыйм!)
Сагыну...
Йолдызлы, маэмайлы
җандагы авылны кузгатмый
ничекләр түзәсе?..
Кыл урта –
Бу йокы кая соң, йә Газыйм.
Сүнегез, таш кала утлары!
Авылның ак шәмен кабызыйм.
Кыл урта.
Тәрәзә төбе һәм чынаяк.
Каһвәсе суынган.
Ап-ак шәм «чәпе-чөп» кафельгә.
Такта чәй чокчынам шкафымнан...

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА (1983) – *шагыйрә, журналист. «Синме бу, бәхет?», «Кояшлы сукмак» китаплары авторы. Грозныйда яши.*

***

Төннәр озын, име, көне – кыска,
декабре – кара, кары – ак.
Җәннәт җимешләре алдый алмый –
күз алмасы тулы туган як.

Ак кар яткан ак урамнан туңып,
яңгыратып көлеп җиһанны,
кар кызыдай кайтып килсәң иде
сизмичә дә тәпи туңганны!

Суган-сарымсаклы пилмән исе –
чолан сайгагына бас кына...
Мин клубтан кайтам. Бит кызышкан,
итек-бияләйләр боз менә.

«Әй, наныем, озак булдың, – диеп,
әбекәем чыккан ут элеп:
– Кайтканмы? – ди.
– Әйтмим! – дигән булам,
Күзләр яна прожектор булып!

Никтер искә төште...
Еллар – йомгак,
язмыш үзе – Бальзак романы.
Бар галәмем Яңа Әлем булган,
чепалгышын[1] ашыйм Грозныйның.

Ә җан иске, ничек туган – шундый:
бик самими үзем, усал да.
Эт каешы түгел, тик тисәләр,
Этләшкәннән калмас мыскал да.

Йөрәк яралары күп түгел, тик
күңел киштәләре йозакта.
Дөнья өйрәтмәде диеп булмый –
Авызлар да пеште кайчакта...

Ничек хәлең?
Син исән бул, яме!
«Чана юлы төште», дигән бул...
Юллар ерак, бары җанда гына
туган якка дәшә көртле юл...

## Балачак нигезе

**1**

Чык суыгы төшкән – күшектерә,
тешең тешкә тимәс, һай, бик салкын.
Капка баганасы терәтергә
– Мин әле бу, мин бу, мин! – дим, – кайттым.

Үги кебек басып торам, үксеп...
Көтсәң дә син – көтмәгәндәй инде!
Такталарын сүтеп алганнар да,
яңа «күлмәк-калфак» көтә өйне.

Безнең өйне! Балачагым өен!..
Бүрәнәләр мине танып дәшә!
«Кер, наныем!» – дияр иде дә соң, –
монда идән – безнеке дә, түшәм...

Тунаганнар әнә бура өйне...
Такта батмый, профнастиллар көтә.
Алмагачлар, ирга төптән кисек.
...Ә мин нишлим – минем тыным бетә.

**2**

Яңа хуҗа. Чылбырда эт. Яңа гараж.
Чолан ягын, әнә, тышлаганнар таштан.
Безнекеләр: тәрәз, гөл чүлмәге, лапас,
тавык кетәклеге. Тавыклары качкан...

[1] Чепалгыш – чечен халкының милли ризыгы.

Балачагым нигезендә үги булып,
җиде яттай басып торам өнсез-тынсыз.
Кочып юатырга әбекәем дә юк.
Бакчабыз да – гараж! Ирга, алмагачсыз...

Капка баганасы исән! Кул тоткасы
миңа егылмаска калган терәкмени.
Мин ят түгел монда! Түгел! Кендек каным
Тамган нигез өчен, шиксез, кирәкмен мин!

**3**

Ятлар ут кабызган тәрәзләрдә
минем өчен күпме яшәү яна.
Балачагым чырык-чырык килеп,
чәй чөмерә анда, кәнфит каба...

Кулдан-кулга йөртеп «пәп» итәләр,
Иң татлысы әүвәл миңа башта,
Сыртка кояш төшкәнче үк йоклау –
Мин бит оные! Миңа бар да бата!..

Мин «Гөлем» дә, мин «наныем» анда...
"Тор, товарищ, чәй суына ату..."
Капка баганасы тота күрсен, –
коймак белән чәй эчәргә кайттым...

Чәй суынган икән. Мине көткән
пар күзләрем, юкса, янда кебек.
Болытлардан таган төшкән әнә:
Тормыш – бәхет, тормыш – бары күбек...

***

Ярлары юылган дөньяның
юарга тырышып карасын,
дулкыннар котыра-котыра
и, ялый кан типкән ярасын...
Әй, диңгез!
Иртәнге биштә дә
акылың шагыйрьләр тирәсе...
Тынычлан димим лә, мин дә – шул.
Тукран күк чукыйк соң чигәсен
дөньяның.
Ә аңа барыбер...
Ярлары ашалган, юылган...

Кыйммәтләр шәүләсен иш иткән
тез башы кутырлап кубылган...
Ишекләр күптәннән ачылмый,
Кешелек кешене иш итми...
Нинди яр?!
Җәйләрдән көзләргә
бирерлек бер кушуч наз җитми...
Ярлар юк.
Күбекләр гел өстә...
Дулкыннар, әй, бәрә мамыкны,
дулкыннар яр ашый һәм җанны...
Уяныйк!
Табылсын якуты вакытның!..

***

Фальшь сәхнәсе бу. Софитларның
Утларыннан күзләр камаша.
Куяннары, әнә, урын эзли,
Филләр көтә цирк-тамаша.

Заманы бит шундый – мишурасы,
төчелеге тешкә сылана.
Ялтыравык таккан монафикълар
Мәрьям-ана булып кылана.

Ярый әле битлекләре кәттә –
Дегетне дә кәрәз итәрлек.
Көннәр кигән кара күлмәкләрдән
ак төннәрнең исе китәрлек...

Фальшь сәхнәсе бу... Тыңла гына –
балга манып нотык сөйлиләр!
Ярый әле, күпләр былбыл кошның
карга икәнлеген белмиләр...

***

Һавада ак күмәч исеме?
Кояшмы тәбикмәк өлгертә? –
Сулап та, яшәп тә туймаслык
яшеллек бәхете исертә.

Елмаю ягылган һавага
болытлар кый[2] баллы мамыктыр:
март-апрель «пырхылдый-пырхылдый»
чемодан тутыра. Шымытыр[3]...

Яшәү соң һай тәмле! Тел төбем –
чыркылдык кошларның бәлзәме.
Ак мичтә ак майда чажлаган
ак күмәч, ак шомырт исле бу – май яме.

Яшәргә соңлама.
Май кебек өр-яңа күлмәк ки – яшелне.
(басуның тузаны бетмәс ул!)
Син менә нәкъ бүген яшисең.
Сора бер:
– Мин чынлап яшимме?..

***

Басу өсләп тузан күтәрелә –
бураznалар башын калкыткан.
Яңгыр көтә җиһан. Аҗаганлап.
Сеңердәге эссе ялкыткан.

Сутлы үлән башын иеп, сусап,
әй, тилмерә, бәгырь, яңгырга.
Гөрселдәтеп күкне, камчы-камчы,
орып-орып, шаулап яу гына!..

Туфрак дымга мохтаҗ – сеңер шартлый.
Тамчы-тамчы дога, там гына.
Игеннәргә яшәү көчен өрче!
Һәм болытлар аксын, тын гына...

Туган туфрак тыны: еш-еш сулый,
җанны меңгә бүлә бу челлә.
Яргаланган җирем уч төбендә –
әрнүем дә шушы, көчем дә...

[2] Кый – гадәттән тыш, артык, чиксез мәгънәсендә (диал.)
[3] Шымытыр – буш, берни дә юк мәгънәсендә (диал.)

# ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ

## Саннар күктән төшми

Юбилей – ирешелгән уңышларны барлау өчен җайлы форсат. 2006 елда, «Казан утлары»ның 1000 саны чыгу уңаеннан, «Сүнмәс утлар балкышы»* дигән китап дөнья күрде. 700 битле, 88 табаклы, 2 килограмм авырлыктагы ошбу монументаль басмада 400гә якын авторга урын бирелгән иде! Бактың исә, аларның һәркайсы журнал битләрендә зур-зур романнар, поэмалар, шигырьләр, хикәяләр һәм публицистик язмалар белән катнашкан. Узган гасырның икенче яртысында басылган кайбер әсәрләрне генә санап үтсәң дә, шагыйранә әйткәндә, бер горурлык хисе туа... Г.Әпсәләмов – «Ак чәчәкләр», Ә.Фәйзи – «Тукай», Ф.Хөсни – «Җәяүле кеше сукмагы», М.Әмир – «Саф күңел», И.Гази – «Онытылмас еллар», С.Баттал – «Сигезенчесе кем?», Н.Фәттах – «Бала күңеле далада», А.Гыйләҗев – «Өч аршын җир», Ш.Маннур – «Муса», Ә.Еники – «Әйтелмәгән васыять», М.Мәһдиев – «Фронтовиклар»... Кыскасы, бер язмада гына санап бетерү мөмкин түгел. Алар барысы да «Казан утлары»н «Почет билгесе» орденлы иткән һәм аның 100 еллыгын алтын гасырга әвереләдергән язучылар!

Һәр язучы әдәбият мәйданына үз укучысы белән килә. Безнең буын аларның тугры укучылары.

## Дуслар җыелган җирдә

Кулына диплом алу белән туп-туры «Казан утлары»на килеп эшкә урнашучыларны белмим мин. Киләм дигән кеше иң әүвәл төрле тармакларда: радио һәм телевидениедә, сәхнәләрдә, завод-фабрика газеталарында, мәгърифәт өлкәсендә, фәннәр академиясендә иҗади тәҗрибә туплап, аннан соң гына олпат журналның ишеген шакыгандыр. Һәркемнең максатка үз сукмагы бар.

Шәхсән үзем, шушы журналда эшләү турында хыялланмаган идем, дисәм – монафикълык булыр. Хыялландым, әлбәттә. «Хөрмәтле иптәш, менә болайрак кирәк иде, тегене укы, моннан өйрән, язып чиләнмә, коелар казуыңны бел...» дип, миңа күп хатлар язган абыйларны бик күрәсем, алар белән иңгә-иң эшләп карыйсым бик килгән иде...

Культура институтының режиссура бүлегенә кергәндә, миңа 27 тулган иде инде. (Күпләр бу яшьтә диссертация яклый инде). 17-18 яшьлекләргә ияреп, көпә-көндез укырга туры килде. Үкенмим. Сюжет, фабула, мизансцена, образлы тел, интрига кебек төшенчәләр драматургия өчен генә түгел, ә чәчмә әсәрләр өчен дә ифрат зарури икән.


Диплом алганда, миңа 30 яшь, ә «Казан утлары»на 60 иде инде...

СССР чорында яшь белгечне кая да булса эшкә урнаштыруны комиссия хәл итә иде. Һәм ул карарга буйсыну катгый рәвештә мәҗбүри. Зәй районының мәдәният йортына сәнгать җитәкчесе булып барасың, диделәр... Коелып төштем, «Казан утлары»ннан түгел, Казанның үзеннән 250 чакрымда бит әле ул!

Батулла үпкәләмәсен, безнең Шәле халкында да зәйлеләр холкы... Юк, беркая да бармыйм!

Һәм тагын «Казан утлары»ның ярдәме тиде, дөресрәге, журналның хатлар бүлеге мөдире Роберт Миңнуллинны очраттым. Без аның белән, әлеге дә баягы, шул «Идел» яшьләр лагерендагы семинарда танышкан идек. Бактың исә, алга таба дуслашырлык сәбәбе дә табылды: икебезнең дә хатыннар Клара исемле; икесенең дә туган көне – 5 гыйнвар. Минем малай белән аның кызы да бер үк елда туды, 2 нче гимназиядә

* Китапның төзүчесе Рәфикъ Юныс, шеф-мөхәррире Равил Фәйзуллин.



*Татарстан язучыларының X съезды. 1984 ел.*

бергә укыдылар: «Оптимист» ширкәтендә йорт күтәреп, бер-беребезгә кунакка йөрештек.

Роберт «Казан утлары»на чаклы «Яшь ленинчы» газетасында эшләде. Минем балалар өчен язылган хикәяләремне әдәби ел йомгакларында зурлап бәяләгәне бар... Баш редактор Роза Туфитуллова дигән матур апа кабинетына килеп кердек. Роберт, яучыларыңны да уздырып, мине мактый. Роза ханым башын аска иеп кенә: «Беләм инде, беләм мин аның каләмен, буш урын бар. Су бораулаучы булып та эшләгәч – ерак юлда йөргүдән дә курыкмас», – диде дә мине «Мәктәпләр һәм пионерия» бүлегенә тапшырды, рәхмәт төшкере...

Әдәбият бүлегендә – шагыйрь, коммунист Госман Садә, таланты белән графоманнарның ачуын китерерлек шагыйрь Зөлфәт. Спорт бүлегендә тынгысыз Нияз Акмал. Ә каршымда – үзенә зыян китерердәй тыйнаклыгы һәм байлар көнләшерлек юмартлыгы белән прозаик Вакыйф Нуриев... Тагын 35 елдан соң без әле аның белән «Казан утлары»нда эшләячәкбез икән...

## Таш баскыч та шыгырдый

«Яшь ленинчы» газетасы сигезенче катта иде. Тугызынчы катта «Чаян» журналы, Ә «Казан утлары» – унынчыда.

«Чаян»да унҗиде ел да дүрт ай буе җаваплы секретарь булып эшләгән Мәгъсүм абый Хуҗин үз теләге белән гариза язган. «Ник?» – дип сораучыларга «Бер журналга ике тәкә башы сыймый», – дип җаваплый иде...

Соңыннан гына белдем, үз урынына ул минем исемне әйтеп киткән икән.

Шулай итеп, мин «Казан утлары»на таба тагын бер катка күтәрелдем.

«Чаян»да эшләгән дәвердә мин «сатирик язучы» дигән мактаулы кушаматка ия булдым. «Көндез – редакциядә, кичләрен – сәхнәдә... Эстрада авторның хәреф хаталарын сиздерми. «Чаян»да исә, хикәя-шигырьләр генә түгел, ә һәр фельетон, мәзәк, рәсем аслары – барысы да әдәбиләшкән. Һәм кечкенә генә кытыршылык та бөтен Советлар Союзына миллион тираж белән тарала...

Мәгъсүм абый батырлыгын кабатламадым, «Чаян»да унике ел гына эшләп өлгердем. Ниһаять, унынчы катка күтәрелер сәгать җитә бугай, дим. УНИКСның мең кешелек тамаша залында 50 яшьлек бәйрәмемне гөрләтеп үткәрдем дә...

Хәер, барысын да кул сәгате түгел, ә «Ком сәгате» хәл итеп куйды...

360 битлек романым җыелган килеш өстәл тартмасында ята. Кемгә дә булса тапшырудан тыелып торам, чөнки ачы тәҗрибәм бар...

Иртәнге сигезләрдә эшкә киләм. Юкса, өлгереп булмый, «Чаян» рус һәм татар телләрендә, аерым-аерым булып, айга дүрт тапкыр чыга.

Еш кына талантлы егетләр ишегемне шакый, гозерләрен беләм: «Юк, дип кенә әйтә күрмә, зинһар!..» Төннәр буе иҗат газабы кичергән даһиларга хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырышам.

Гадәттәгечә, тагын ишекне шакыйлар, тик керергә ашыкмыйлар. Үзем чакырып алдым.

Рәшит Әхмәтҗанов, минемчә, талантлы шагыйрьләр арасында иң тыйнак кеше иде. Ул ничек тиз керсә, шулай тиз чыгып китә белә. Туктатып: «Роман язып караган

идем, сездә проза бүлеген кем алып бара?» – дип сорап өлгердем. Җавап та бик кыска иде: «Любоебыз! Ну, иң әүвәл Флүс укып чыга. Бир, үз кулларым белән тапшырам...»

«Ком сәгате» йөрүдән туктады. Бер көн ике көн булып тоела башлады...

Баскычны таштан койсаң да, барыбер шыгырдый... Унынчы кат белән тугызынчы кат арасындагы мәрмәр басмаларда аяк тавышы ишеткән саен миңа таба киләләрдер кебек. Телефон шалтыраган саен: «Укыдым!» дигән хәбәр көтәм.

«Ком сәгате» тиз йөри икән... Өч көн эчендә Флүс абый «Чаян»га килеп керде, кулында кулъязмам юк. «Керә-керешкә үк: «Камил, мин бит сине артист дип йөри идем, син коеп куйган язучы икәнсең, инәңнең башы!» – дип, аркамнан сөеп өлгерде. Өч санга рәттән планлаштырып та куйганнар.

Үзебез олыгайсак та, хыял картаймый! Равил Фәйзуллинның: «Казан утлары»на килергә исәбең юкмы соң?» – дигән соравына халык шагыйренең үзенчәрәк: «А почему бы нет?!» – дип җаваплfavored.

## Кичә һәм бүген

«Казан утлары»на эшкә килгән мәлне мин үземне «Фәтхулла хәзрәт» кебегрәк хис иткән идем: 30 ел буе җиң сызганып эшләгән Рәдиф Гаташ һәм Мансур Вәлиев; көнозын баш күтәрмичә кулъязма эшкәртүче Наис Гамбәр; үзе шагыйрь, үзе прозаик Рашат Низами, терекөмеш кебек баскан урынында йөгереп тора; заманында китап нәшриятының баш казые булган Марс Шабай еламсырап йөри; «Абый» дигән повестемны язып бетерәсем бар дип, Марат Закир югалып-югалып ала; менә дигән балалар язучысы Алмаз Гыймадиев, «Акчарлак» нәшрияты ягына карап, тәрәзә аша кемнәр беләндер турыдан-туры элемтәдә...

Минем күзнең хәтере бик юк, әмма колакның хәтере шәп. «Фатих Әмирханнардан соң сатириклар тумаган» дигән имеш-мимешләр җан авазы булып саклана... Академик журнал дип исәпләнгән «Казан утлары»нда «Уены-чыны бергә» рубрикасы ачтык. «Печән базары» дигән конкурс игълан итеп, кырыклап язучының күңел түрендә сатира һәм юмор шаукымы барлыгын белдек. Ул әсәрләрне «Яңа базар» дигән аерым җыентыкка туплап чыгардык.

Соңгы 20 ел эчендә Хисам Камалов, Айдар Хәлим, Фоат Садриев, Марсель Галиев, Зөлфәт Хәким, Ркаил Зәйдулла, Фәүзия Бәйрәмова, Факил Сафин, Нәбирә Гыйматдинова, Марат Әмирхан һ.б. бик күп авторларның кулъязмалары белән танышканда, мин дипломатиягә өйрәндем, тәкъдимнәрем булса, киңәшләремне ягымлы тел белән җиткерергә тырыштым.

Кире борылган әсәрләр гомерне кыскарта. Әгәр кулъязмаларның әдәби эшләнеше җитенкерәмәсә, без аны, редколлегия аша кулдан-кулга йөртеп, таушалтмадык, үзара киңәшеп, уртак тел таптык. Журналда басылган әсәрләр өчен укучы алдында да җавап бирәсе бар бит әле. Шуңа күрә мин үзем эшкәрткән һәр әсәрнең кыскача аннотациясен аерым дәфтәргә теркәп бардым. Еллар үткәч тә онытылырлык түгел.

Язучылар берлегенең уртак сөенече булган «Казан утлары»ның киләчәген фаразларга алынмыйм. Әйе, 100 еллыгын үткәргәч, ул 101нче елына керер; әйе, юбилейдан соң (октябрь аенда) аның 1200 саны дөнья күрер; бәлки әле, соңгы елларда икеләтә арттыра алган тиражын да саклап калыр, бирсен Ходай! Журнал мине Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты итте. Шуңа күрә дә мин аннан саубуллашмыйча гына киттем. 70тән узгач, ыгы-зыгылы конвейерда эшләп булмый инде ул. Без хәзер балаларыбыз һәм оныкларыбызның «киңәшчесе» генә. Әдәбият мәйданына төркем-төркем кызлар килә башлагач кына, өеңә кайтып китүне җиңел дип уйлыйсызмы әллә?! Юк!

Шунысын онытмагыз: өлкәннәр, арабыздан киткәннәр, урта буын, яшьләр, җыйнап кына әйткәндә, язучылар һәм укучылар – барыбыз да «Казан утлары» шәҗәрәсенең мактаулы балалары...

**Камил КӘРИМОВ,**
*ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

# ИҖАТ КАЗАНЫ

Журналыбыз бер гасыр буе каләм әһелләренең иҗат җимешләрен җиз иләктән уздырып, редакцияләп, халкыбызга тәкъдим итә. Бу ифрат җаваплы эш. Чөнки һәр әсәрнең артында автор тора. Ул кайнар уй-кичерешләре белән сугарган хезмәтенең халыкка шул кайнарлыгы белән барып җитүен тетрәнеп көтә. Айлар, еллар буе күңелендә кайнаган уй-хисләрен салган әсәренә әз генә саксыз кагылу да язучының йөрәгенә кадала. Редакция әсәрләргә нинди генә югары идея-эстетик таләпләр белән якын килсә дә, минемчә, журнал авторлар белән чын иҗади мөнәсәбәтне саклап кала алды.

Бусы язмамның түбәтәе булыр. Яланбаш та бик әйбәт, дисәгез, түбәтәен салдырырсыз. Әмма ташлый күрмәгез. Җир йөзендә гигант таулардай матди һәм рухи байлыкларны исраф итүгә, җимерүгә эчем янганлыктан, мин бала чагымнан ук ипи валчыгыннан алып, сыңар сәдәфкә кадәр сак карыйм. Карун икәнсең, димәгез. Безне – сугыш елы балаларын тормыш шуңа өйрәтте һәм исән калдырды. Кешеләрнең кайнар тире белән тудырылган әйбергә хөрмәт белән карау, һәр нәрсәне чамалап кына, әрәм-шәрәм итмичә тоту, ертылса – ямау, өзелсә – бәйләү, сынса – ялгау, купса – беркетү кебек күренешләр безнең өчен язылмаган закон иде. Хәзер генә ул кием-салымны берничә киюгә болгап ату, ризыкны ашап бетермичә түгү, тузарга да уйламаган тормыш кирәк-яракларын чүплеккә озату бүгенге тормышның беркемне дә гаҗәпләндерми торган атрибутларына әверелде. Ә түбәтәйне салдырып куйсагыз, мин аны киләчәктә җай чыкса, бер язмама «кигерермен».

Инде төп сүзгә күчик. Туган авылым Олы Чакмак җидееллык мәктәбендә укыган чак. Бер көнне дәресләр беткәч, бишенче, алтынчы, җиденче сыйныф балаларын иң зур бүлмәгә җыйдылар. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Газизә апа Гайнетдинова (җырчы Ләйсән Гыймаеваның әбисе) калын гына журнал тотып керде, безгә аның турында сөйләде. Бу «Совет әдәбияты» журналын минем күргәнем бар, сугыш афәтләрен кичеп исән-сау кайткан Сабир абзый гел шул журнални укып утыра иде. Анда М.Бубенновның «Ак каен» романы басыла башлаган икән. Без шул романны кычкырып укырга тотындык. Беребез аруга, икенчебез укуны дәвам итә. Ул мавыктыргыч шөгыль безне дөрес һәм тиз укырга да, әдәби әсәрдәге вакыйгаларны бөтен тирәнлеге белән кабул итәргә дә өйрәтте. Мондый укулар ничә мәртәбә булганын хәтерләмим. Тик шунысы бәхәссез, без сугышның ни дәрәҗәдә дәһшәтле икәнлеген аңладык, әтиләребез кебек, колхозын калдырып, кулына корал алган Андрейның фашистларга каршы аяусыз көрәшен күз алдыбызга китердек. Шуннан бирле «Совет әдәбияты» минем ай саен көтеп ала торган кунагыма әверелде. Чөнки бу вакытта мин мәктәп китапханәсендәге әдәби китапларның шактыен укыган, сүз сәнгатенең тәмен тоя башлаган идем инде. Урта мәктәпне тәмамлаган елда (1958) минем тәүге хикәямә район газетасы оештырган конкурста беренче урынны бирделәр. Бу вакыйга минем «язучы булырга» дигән яшерен хыялыма канат куйды, иҗатка ныклап тартылдым. Ә сөекле журналым кунак кына түгел, киңәшчемә, аерылгысыз юл күрсәтүчемә әйләнде. Язучыларыбызның иң яхшы иҗат үрнәкләрен, әдәби хәрәкәтнең барышына, аерым әсәрләргә багышланган тәнкыйть мәкаләләрен көне-сәгате белән китереп җиткерүче басманы башкача бәяләп тә булмый. Әсәре журналда дөнья күреп, аңа «табадан төшү»гә үк тәнкыйть тә игътибар итсә, язучы икеләтә шатлык кичерә. Минем дә андый дулкынландыргыч вакытым булды. 1992 елда «Казан утлары»ның 10, 11 нче саннарында «Таң җиле» романым дөнья күрде. Ике ай узуга, ягъни 1993 елның

гыйнвар санынннан журнал «Безнең тормыш. Безнең әдәбият» исеме астында дискуссия башлап җибәрде. Ул Фоат Галимуллинның «Гыйбрәтләр алсак иде...» дигән зур мәкаләсе белән ачылды. Күренекле тәнкыйтьченең романны үзенә хас тирәнлек белән анализлавы, әсәрнең төп идея-проблемасын баш герой Нуриасманың тормыш рәвеше, эш-гамәлләре аша гаҗәеп әтрафлылык белән ачып бирүе мине чиксез сокландырды. Тәнкыйтьтәге әлеге образны нәкъ мин уйлаганча, гомерем буе гади татар хатынын күңелемдә кадерләп йөрткәнчә аңлаткан иде. Дөньяны туфан суыдай баскан ялганнан безне бары тик Нуриасма кебек мәңге чигенмәс, хакыйкать өчен гомерләрен бирергә дә әзер торучы вөҗданлы татар гына коткара алачак. Ләкин, минем уйлавымча, алар артык күп түгел.

Ф.Галимуллин әлеге мәкаләсендә соңгы елларда журналда басылган шактый әсәрләрне тикшереп, аларны югары идея-эстетик категорияләр бизмәненә сала һәм язмасын түбәндәге юллар белән тәгәлли:

«Күрәбез, соңгы елларда татар прозасында җәмгыятебезнең хәл-әхвәле төрле яклап һәм шактый үтемле яктыртыла. Иң мөһиме – шул мохитнең кешегә тәэсире сәнгать чаралары ярдәмендә өйрәнелә...

Хәзергә әле без каләмдәшләребезнең тәнкыйть белән мавыгып китүләрен дә күреп торабыз. Шулай да әдәбиятта тәнкыйть рухы үзмаксат булып әверелмәсен иде. Безгә бүгенгебезне, киләчәгебезне яхшырак, кешелеклерәк итәргә булышса гына, аның мәгънәсе булыр. Язучының каләме барыннан да элек шуңа хезмәт итәргә тиеш.

Ә сез ничек уйлыйсыз?»

Дискуссиядә чыгыш ясаган авторлардан Г.Тавлин «Иман яңартканда» (№ 2), Ә.Низаметдинов «Кузгалды уйларым...» (№ 3), С.Шәрипов «Хакыйкатьнең ачысы» (№ 3), К.Тимбикова «Энҗеле калфак» (№ 4), Р.Фәизов «Алда яктылык күренә» (№ 6), Р.Сибат «Борчулар һәм өмет янәшә» (№ 7), Ф.Бәшир «Исә җилләр» (№8) үзләренең мәкаләләрендә минем романга киң тукталып, аңа уңай бәя бирделәр, кайбер концепцияләрем белән бәхәскә дә керделәр. Мин кинәт үсеп киттем. Бу һич тә әллә кем булдым дигән сүз түгел. Язганнарыма тагын да җитдирәк карарга кирәклекне бөтен барлыгым белән, һәр күзәнәгем белән аңлау дигән сүз иде бу. Киләчәктә мин ирешелгән биеклегемнән югарырак күтәрелергә тиешлегемне аңладым һәм шушы бурычка тугры калырга тырыштым. Роман турында журналның зур сөйләшү оештыруы аның китап булып кабат-кабат басылуына уңай йогынты ясамыйча калмагандыр. Татарстан китап нәшрияты аны 1993 елда – 3000, 1994 тә – 20000, шул елны Башкортстанның «Китап» нәшрияты 3000 тираж белән чыгарды. Халык соравы буенча мин аны 2011 елда үз хисабыма 2000 тираж белән бастырып, тагын укучыларыма юлладым. Бәхетле китап булды ул! Әмма шушы сүзләрне язгач, ул чакта журналның проза бүлеге мөдире булган Тәүфикъ Әйдигә зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Тәүфикъ бик таләпчән, үз фикерен дәлилли белә иде. Аның белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, мин әсәрне идея-композицион яктан шактый камилләштерүгә ирештем дип уйлыйм. «Бәхетсезләр бәхете» трилогиямне (2001, 2005, 2007), шактый повесть, хикәяләремне журналга әзерләгәндә, Камил Кәримов белән иҗади аңлашып эшләвебез дә минем өчен осталык мәктәбе булды. Журналны «иҗат казаны» дип атавым юкка гына түгел. Ул казанда кайнау университеттә, әдәби курсларда алган белемнәрне конкрет әсәргә әвереледерү тәҗрибәсе булып, өлкән әдипләр иҗатында кала, аларның әсәрләре аша яшьләргә күчә. Журналның бер гасырлык эшчәнлеге турында уйланганда, аның татар телен, культурасын, милләтен үстерү һәм камилләштерүдәге ролен һәр язучы үзенчә тоя, аңлый. Моның өчен илебез тарихын, төзәтә алмаслык ялгышлар, дәһшәтле еллар, үсеш-яңарыш дәверләре аша үтәргә, тормыш белән әдәбиятның мөнәсәбәтен җентекләп күзәтергә, өйрәнергә кирәк.

**Фоат САДРИЕВ,**
*Татарстанның халык язучысы*

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Рафис
Корбан

# СОҢГЫ САБАНТУЙ

ХИКӘЯ

**1**

Ни дисәң дә, Сабан туеның иң кызыклы бәйгесе көрәш инде ул! Сабан туе ел саен малайлар көрәше белән башланып китә безнең авылда. Минем бер елны да көрәшмичә калган юк үзе. Өченче ел гына көрәшеп булмады. Сабан туен үткәрмәделәр ул елны. Шул коронавирус аркасында инде. Ә болай, көрәш минем өчен – Сабан туенда иң мөһим бәйге. Башка елларда үз яшемдәге малайлар арасында гел батыр кала идем. Былтыргысында батырга чыгып булмады. Миңа каршы алтынчы класста укый торган Ирекне чыгардылар. Мин ул чакта дүртенчене генә бетергән идем әле. Шулай да, Ирек белән бер буйда булгач, яшемә карап тормадылар. Ирек бәләкәйрәк буйлы, ләкин тәҗрибәсе зур, аның да малайлар көрәшендә катнашмыйча калганы юк. Былтыргысында, соңгы бер елда буйга үсеп китүем миңа зыянга булды, үземнән зурраклар белән көрәштерделәр.

Уку елы тәмамланып килгәндә, без – малайлар арасында быелгы Сабан туенда кемнең батыр калачагы хакында бәхәс чыгып алды. Физкультура дәресе иде. Язгы ташулар бетеп, Ашыт ярларына кайткач, Камил абый дәресләрне мәктәп артындагы әнә шул ташу вакытында су астында кала торган тугайда үткәрә башлый. Быел да физкультурага безне шул мәйданга алып чыкты. Гадәттә, без анда туп тибәбез – ике командага бүленеп, футбол уйныйбыз. Бу көнне Камил абый җиденчеләрне дә алып чыккан. Безгә футбол уйнарга кушып, команда бирде дә, үзе җиденчеләр белән озынлыкка сикерү буенча дәрес үткәрә башлады. Мин үзем физкультура дәресләрен күтәп алам. Футболында да, волейболында да, озынлыкка, биеклеккә сикерүләрдә дә «бишле» билгеләре генә минем көндәлектә. Иң яратканым – Камил абыйның дәресләрдән соң калып алып бара торган көрәш түгәрәге. Ул түгәрәккә җиденчедә укый торган әнә шул Ирек тә йөри. Бу юлы Камил абый футболны ахырынача уйнатып бетермәде. Җиденчеләрдән сикерү буенча зачётларын алды да безне дә уеннан туктатып:

– Нәрсә, егетләр, Сабан туе җитә бит, көрәш буенча күнегүләрне башлыйбызмы? – диде.

Уенны ташлап, барыбыз да Камил абый янына җыйналдык.

– Быел Сабан туе буламы соң? Коронавирус бетмәде бит, – диештеләр кызлар.

– Буламы, булмыймы – анысы башка мәсьәлә. Була калса, егетләр көрәшкә әзер булып торырга тиеш. Шуңа күрә тренировкаларны башларга кирәк. Көрәшче Шамил абыегыз мәйданга әзерләнә башлаганга биш былтыр инде, – диде Камил абый.

Камил абый ул мәктәп спорт залында авыл егетләре белән көрәш буенча тренировкалар алып бару өстенә, Сабан туенда баш судья да әле. Баш судья булып ул тора башлаганнан бирле көрәшне егетләрнең авырлыгына карап үткәрә башладылар. Минем былтыр Иреккә җиңелүем дә шуның аркасында гына булды. Югыйсә Ирек миннән өч яшькә олырак, ләкин авырлыкларыбыз бер чама. Миннән шактый алда көрәшләрдә катнашып килгәч, анда тәҗрибә дә зуррак – әмәлен белә. Быел да шулай булыр инде. Тагын да ул калыр инде кырык килолы көрәшчеләр арасында батыр булып...

Камил абый тренировканы арабыздагы иң кыска буйлы Мансур белән Мәхмүтне көрәштерүдән башлады. Икесе дә җитез, чәер кебек чытырдап ябыша торган чөгәш малайлар. Бер ябышсалар, ычкындырам димә инде син аларны бер-берсеннән. Бер дә махы бирә торганнардан түгел. Әүмәкләшеп тик йөриләр түгәрәк тирәли. Тәмам хәлдән тайдыралар бер-берсен. Никадәрле чөгәш булсалар да, беркайчан да батыр калганнары юк үзләренең. Икенче хутка чыкканда, яраурак малай туры килә дә әйләндереп сала үзләрен. Әллә ничә тапкыр минем белән дә туры килгәннәре бар. Һәркайсында сыртларына салдым, шуңа күрә миннән шүрлиләр, мин өстә калсам, миңа каршы көрәшергә чыкканнары юк. Ирек тә гел шул малайлар шикелле үзенең көндәшен тәмам талкый, әйләндереп йөртә-йөртә арытып бетерә. Арыганын сизә дә бер уңайлы чакны туры китереп күтәреп тә ала, китереп тә сала көндәшен сыртына. «Ых» та итмичә каласың.

Камил абый тәмам хәлдән тайган Мансур белән Мәхмүтне көрәштән туктатты да:

– Хәл җыеп алыгыз, малайлар. Менә Булат белән Таһирның көрәшкәнен карап торыгыз бераз, – дип, җиденче класс малайларын чакырды.

Булат та, Таһир да Сабан туйларында малайлар көрәшен башлап җибәргән көндәшләр. Бер елны Булаты белән миңа да район мәктәпләре арасында зона ярышында көрәшергә туры килгәне бар. Мин ул чакта икенчедә генә укый идем әле. Шулай да кече яшьтәгеләр арасында батырга чыгып, район буенча бәйгегә җибәрделәр үземне. Советлар Союзы Герое Муса Җәлил призына барган сайлап алу уеннары иде ул. Мин җиңә алмадым үзе. Шулай да үзенә күрә бер мәктәп булды. Әти әйтә: «Егылып, борын канатмыйча гына батыр калып булмый ул», – ди. Борын канатканым юк болай, ә егылырга туры килгәли.

Таһир белән Булатның әүмәкләшүе озакка бармады. Булат тегене бөтереп алды да үзе артка таба егылып китте һәм башаркан әйләндереп тә салды. Сизмичә дә калды Таһир үзенең сыртка төшкәнен.

– Менә шулай көрәшергә кирәк! Нәрсә, Мансур, күрдегезме, ничек оста гына тәгәрәтте Булат көндәшен?!

Малайлар дәшмәде. Әйтерлек сүзе юк иде шул, чиста бәрде Булат.

– Йә, кайсыгыз чыга Булатка каршы? – дип дәвам итте Камил абый сүзен. Үзе малайларның җавап биргәнен дә көтмәде: – Нәрсә, Рөстәм, сынап карыйсыңмы көчеңне? – дип, миңа таба борылды.

Бер дә көрәшәсем килеп тормый иде Булат белән. Иректән бер дә ким түгел ул чөгәшлектә.

– Ул миннән зуррак бит. Үз ишләре белән көрәшсен, – дидем мин, көрәшәсе килмәвемне белдереп.

– Сабан туенда батыр каласың килсә, үзеңнән көчлерәкләр белән көрәшеп ныгытырга кирәк буыннарыңны. Әтиең өйрәтмимени соң бер дә? – диде Камил абый. – Әйдә, егет бул, чык Булатка каршы.

«Ярар, екса егар, Камил абый дөрес әйтә. Әти дә шулай ди», дип уйладым да, теләр-теләмәс кенә түгәрәк уртасына атладым.

– Менә маладис, – диде Камил абый. – Күрсәт әле Таһирга ничек көрәшергә кирәклеген.

– Таптыгыз көрәшче. Булат түгел, мин дә егам аны, – диде, егылуыннан гарьләнеп, классташларыннан читкәрәк барып баскан Таһир. – Минем белән көрәшеп карасын әле башта, Камил абый? – диде ул шунда, түгәрәк уртасына, безнең янга таба атлап.

– Нәрсә дисең, Рөстәм, кайсы белән көрәшәсең? Син ризамы?

Камил абыйның шул соравы минем гайрәтне күтәреп җибәрде.

Барыбер егыласы. Кайсы екса да, барыбер түгелмени?

– Көрәшеп карыйм, – дидем дә Таһирның биленнән кысып та алдым.

– Хәрәмләшмә, мин тотмаган бит әле, – дип, Таһир ычкынырга теләп тартыша башлады.

– Дөрес әйтә. Бергә башлагыз, – диде Камил абый һәм безнең янга килеп, минем кулны Таһирның биленнән аерды да: – Менә шулай, башладык! – диде.

Кыш буе Камил абыйның түгәрәгенә йөреп, өйдә әти белән дә буш вакыты булган саен аннан төрле алымнар өйрәнеп, бер елда минем осталык шактый арткан иде. Әле генә егылып, һаман да исенә килеп бетә алмаган Таһир, мин биленнән кысып алгач, ничектер каушап киткән кебек тоелды. Башны башка терәп, бил алыша башлагач, колакка аның мышкылдавы тагын да көчлерәк килеп бәрелде. Ул, билен бирмәскә тырышып, тәмам чүгәләп бетте. Авырлыгы да бар, ни дисәң дә, җиденче класс малае бит. Гәүдәгә аның хәтле булсам да, соңгы елда гына буйга тартылганлыктан, минем буыннар әле бик нык түгел иде бугай. Ул, мине билдән үзенә таба тартып китерергә тырышып, тагын да ныграк мышный башлады. Шунда әтинең өйрәткән хәйләсе искә килеп төште. Мин Таһирны кисәк кенә үземә таба тарттым да, бая Булат күрсәткән әмәл белән артка егылып киттем һәм башаркан әйләндереп атмакчы булдым. Ләкин әле генә шундый ысулдан егылган малай бу юлы каршылык күрсәтергә өлгерде, җиргә аяклары белән тезләнеп, миңа үзен күтәреп алып атарга мөмкинлек бирмәде. Беренче һөҗүм минеке булды. Инде Таһирның һөҗүме сорала иде. Ул озак көттермәде, мине түгәрәк буйлап әйләндереп йөртә башлады. Бу безне дикъкать белән карап торган Камил абыйга бик ошап бетмәде, ул:

– Күтәреп алып көрәшегез, күтәреп алып! – дип, кисәтү ясады.

Татар көрәше башка көрәшләрдән шуның белән аерыла да: көндәшләр берсе берсен, аяклары җирдән аерылырлык итеп күтәреп алып, сыртына салырга тиеш. Дөньяда көрәшләрнең бик күп төрләре бар. Һәрберсендә дә үзенә генә хас алым кулланыла. Без, малайлар, билләребезне беләк көче белән кысып кына көрәшкән булып маташабыз. Ә чын көрәштә билләрне сөлге урап кысарга кирәк. Алай да җиңмәсә, сөлгеләрне билләренә бәйләп көрәштерәләр.

Мин буйга Таһирдан бер уч киңлеге озынрак. Озын кешенең билен кысарга җиңелрәк, әмма күтәреп алуы киресенчә – авыррак. Шуңа күрә Таһир, никадәр маташса да, минем билне кысуын кысса да, аякларны җирдән аерып алып күтәрергә хәле җитмәде. Бу тырышулары бераздан аны ардырды. Шунда мин аны кисәк кенә күтәреп алдым да җиргә тәгәрәттем. Ләкин сыртына төшереп, өстендә ятып кала алмадым. Ул җан-фәрманга тартышып, минем өскә әйләнеп менде. Камил абый аны җиңүче дип билгеләде. Арабызга килеп басты да, куллардан тотып, аның кулын өскә күтәрде. Карап торган малайлар, кызлар:

– Дөрес түгел!

– Рөстәм екты, Таһир әйләнеп кенә өстенә ятты!

– Яңадан көрәшсеннәр! – дип кычкырыштылар.

Ләкин Камил абый Таһирның җиңүен дөрес дип тапты.

– Бүгенгә җитәр. Тренировканы икенче физкультура дәресендә дәвам итәрбез. Быелгы Сабан туеның булачак батырын күрдек, – дип, дәресне тәмамлап куйды.

– Сабан туе күрсәтер чын батырның кем икәнен! – диделәр безнең класс кызлары, мине яклап.

**2**

Малайлар көрәше малайлар көрәше генә инде ул. Сабан туен башлап җибәрү өчен бер бәйге генә. Чын көрәш бәйрәм кызгач, авыл хезмәтчәннәренә бүләкләр биреп, Казаннан махсус чакырып кайтарылган артистлар алар өчен җырлар башкарганнан соң, төрле вак-төяк уеннар уйналганнан соң башланып китә. Монысында инде мәйданга егетләр чыга. Араларында быел батыр булырга тиешле пәһлеваннар да була. Алары да әле көрәшне кыздырып җибәрер өчен уйнап кына, бил алышкан булып кыланалар. Батырга алыш, барлык көрәшчеләр дә бер кат әйләнеп чыккач, мәйданда капчык киеп чабулар, бүрәнә сыртында капчык белән сугышулар, аркан тартышулар беткәч, ике командага бүленгән кыз-киленнәр чиләк-көянтә белән мәйданның бер башындагы мичкәләрнең суын икенче башындагыларына ташып тутырганнан соң, өлгер малайлар колга башына менеп, кояшта пешеп утырган әтәчне алып төшкәннән соң башлана.

Элеккерәк елларда безнең әти дә көрәшмичә калмый торган иде. Бер елны батырга калу өчен соңгы көрәш вакытында ялгыш егылып, уң кулы артка каерылып, ике җирдән сынганнан соң мәйданга чыкмый башлады. Йөрәге бик җилкенсә дә, кулының сынган җиреннән дөрес ялганмавы комачаулый. Дөресен генә әйткәндә, гарип булып калды әтинең уң кулы ул вакытта. Табиблар яңадан сындырып, ниндидер тимерләр белән турайтып, бер елдан артыкка сузылды кулының төзәлүе. Алай да төзәлеп бетмәде. Яңгырлар, кышкы бураннар вакытында сызлап интектерә, ди.

Әти генә түгел, аның ике абыйсы да көрәшчеләр иде. Әти кулын сындырып, көрәшми башлагач, абыйларының хатыннары, минем җиңгиләр була инде, Ислам абыйны да, Васил абыйны да көрәшкә чыгармый башладылар. «Энекәшегез кебек гарип булып калуыгызны теләмибез», – диделәр.

Санаулы көн тиз үтә, диләр бит. Сабан туе көне дә бик тиз килеп җитте. Камил абый безне көн саен мәйданга алып чыгып, берничә классның физкультура дәресләрен Сабан туена әзерлек формасында, бергә үткәрә

торгач, без, малайлар, ай ярым эчендә кыш буе парта артында утырып оеган тәннәребез язылып, чын көрәшче атлетлар булып җитештек.

Авылга кунаклар күп кайтты. Безгә дә әтинең Казандагы абыйсы Ислам белән Чаллыдагы дәү абыйсы Васил, бөтен гаиләләре, миннән ике-өч яшькә генә олырак малайлар, кызлары белән икешәр машинада иртәгә Сабан туе була дигән көнне үк кайтып төштеләр. Кайтып төштеләр дә бакчадагы беседкада гына чәйләр эчеп алганнан соң, барысы да машиналарына утырып, урман буендагы яланга менеп киттеләр. Әти әйтеп караган иде, «Йөрмәгез әле шул машина белән, җәяүләп, табигатьнең матурлыгына хозурланып йөреп кайтыйк», – дисә дә, тыңламадылар. Алар артыннан әни дә әтине, машина белән генә барыйк, дип үгетли торгач, без дә гараждан әтинең «Тойота»сын чыгарып, барыбыз бергә шуңа кереп тулдык та абыйлар артыннан элдердек.

Әти багажнигына бидон белән чишмә суы, җиз самавыр да салган иде. Әлерәк кенә беседкада чәй эчүләренә карамастан, Васил абый шундук каяндыр коры-сары, чыршы күркәләре җыеп килеп, самавыр торбасына ут элдереп җибәрде. Җиңгиләр җиргә җәймәләр җәеп, алып менгән ризыкларны сумкадан бушатып, мул гына табын да корып куйдылар.

Яланда сүз гел Сабан туе, көрәш турында гына барды.

– Нәрсә, Рөстәм, көрәшәсеңме иртәгә? – диде Ислам абый, минем баштан сыйпап.

– Белмим әле, – дидем мин, әни ягына карап. Әнинең мине бер дә көрәштерәсе килми, әтиең кебек егылып харап булып куярсың дип куркыта. Камил абыйның физкультура дәресен көрәш тренировкасына әверелдерүенә дә ачуланып йөри.

– Көрәшмәгәч тә, нинди егет була соң инде ул? – диде Васил абый, әнине юри үртәп.

– Әйе менә, көрәштер әнә үзеңнең Вәсимеңне, бик көрәштерәсең килсә! – диде әни. – Әтисенең дә кулы гарип калды шул көрәш ди-ди!

– Вәсим дә көрәшәчәк, үзем дә шул көрәш дип кайттым. Көрәшәбез, Алла боерса! – диде Васил абый, сүзен сүз итеп. – Көрәшчеләр нәселе без, беләсең килсә! Безнең әткәй дә көрәшә иде. Аның этисе – Бәшир бабай да көрәшкән.

Әни аның саен үзенекен такылдый, гел каршы килә:

– Шулайдыр, борынгы заманда үлеп беткән кешеләрнең көрәшче булуын кем белгән?!

– Белгәннәр шул. Белүчеләр бар, – диде Васил абый. Аннары утырган җиреннән торып басты да, нәрсәдер исенә төшкәндәй, шап итеп учы белән маңгаена сугып куйды: – Туганнар, Ислам, Мәхмүт, әйдәгез әле, самавыр кайнап чыкканчы зиратка барып килик. Әтиләрнең каберләрен карап, рухларына дога кылып, – диде.

– Башта ук кирәк иде, кайтканда истә иде, онытылган бит, каһәр! – диде Ислам абый, абыйсына кушылып. Шулай диде дә торып басты һәм без – малайларга карап: – Әйдәгез, малайлар, сез дә, әби-бабайларыгызның каберләре кайда икәнен күреп килегез. Бездән соң сезгә каласы дөнья. Ата-бабалар рухына дога кылучылар булырсыз, – диде.

Зират безнең авыл артында гына, урманга терәлеп тора диярлек. Әтиләр җәяүләп кенә, шунда таба кузгалдылар. Без дә, өч малай, аларга иярдек.

– Озак йөрмәгез! – дип кычкырып калды әни.

Без әти белән җәй буена әллә ничә мәртәбә барып киләбез зиратка. Язын карлар эрегәч, каберләрне сынып төшкән агач ботакларыннан чистартабыз. Аннары җәй башында яңа тишелеп чыккан үләннәрдән арындырабыз. Чардуганнарны да әледән-әле буяп торабыз.

Әтиләр зиратта әби белән бабайның каберләре янына баргач, сөйләшмичә, тын гына басып тордылар. Эчтән генә дога укыдылар.

– Ничек көрәшмисең, ди, эткәйнең, Бәшир бабайның рухлары кичермәс үзебезне?! – диде шунда Васил абый, дәү әтинең каберенә күрсәтеп.

– Хатыннар ни әйтмәс, аларның сүзен тыңлап торсаң монда, – дип куйды әти, дәү абыйсының сүзен җөпләп. – Үзем дә көрәшер идем әле, менә бу гына ирек бирми, – дип, гарип кулына күрсәтеп алды.

– Зыян юк, Рөстәм үсеп килә менә. Ул чыгар көрәшергә синең урынга, – дип, Васил абый минем баштан сыйпап алды. Аннары миңа карап: – Нәрсә, Рөстәм, тап төшермәссеңме карт дәү әтиебезнең «көрәшче Бәшир» дигән данына? – дип сорады.

Мин ни дип җавап бирергә дә белмәдем. Бәшир бабай – ул безнең Мөхәммәди дәү әтинең әтисе. Аны да көрәшче булган, диләр. Сугышта һәлак булган ул. Аның көрәшче даны турында мин берни дә белмим. Әти дә сөйләргә яратмый. Карт дәү әтине сугышта хәбәрсез югалган, ди ул. Сугыш вакытында фронттан «Хәбәрсез югалды» дигән хаты килгән кешеләрне, имеш, сатлыкҗан, «халык дошманы» булган икән, дип сөйләгәннәр. Авылда нарасый бала белән тол калган хатынына да көн күрсәтмәгәннәр, «халык дошманы хатыны» дип. Дәү әти исән чакта сорап караганым булды, ул да берни дә сөйләми иде карт дәү әти турында. Бары тик: «Сатлыкҗан булмаган ул. Бары тик пленга гына төшкән. Беркемне дә сатмаган. Андый кеше сатлыкҗан була алмый!» – дип кенә әйтә иде.

– Йә, нәрсә, көрәшәсеңме иртәгә, Бәшир дәү әти рухын хаклап?! – дип, янә сорады Васил абый.

– Көрәшәм, әлбәттә! Тик син миңа Бәшир дәү әти турында чын дөресен сөйләрсең, җәмә, – дидем мин, аның хакында күбрәк белергә теләп.

– Сөйлим, нишләп сөйләмәскә. Кешедән яшерерлек бернинди кыйтылык та кылмаган безнең Бәшир дәү әти. Киресенчә, горурланырлык кеше булган. Мактауга лаек кеше. Тик бер шартым бар: син көрәшеп, малалайлар арасында батыр каласың! Ә мин Сабантуй батыры булып калыр өчен көрәшәчәкмен. Тәкәне чалып, шашлык пешергән чакта рәхәтләнеп, бөтенегезгә дә иркенләп сөйләрмен.

**3**

Безнең әтиләр өч туган: әти үзе, ике абыйсы Ислам һәм Васил. Әйттемме икән әле – безнең әтинең исеме Мәхмүт. Безнең авылда Мәхмүтләр өчәү. Бутамас өчен өчесенә да кушамат такканнар. Кулын сындырганнан соң, әтигә «чулак Мәхмүт» дигән кушамат ябышып калды. Аңа хәтле аны «атлет Мәхмүт» дип йөртәләр иде. Яшь чагыннан ул гел спорт белән шөгыльләнгән. Карап торсаң, гел инде менә безнең бишенче класс тарих китабындагы Греция атлетларына охшап тора аның гәүдәсе. Әтинең солдаттан ясап кайткан фотоальбомында атлетик күнегүләр вакытында

төшерелгән әллә ничә сурәте бар. Берсендә хәтта турникта кояш ясап әйләнә. Чемпионатларда катнашучы атлетлардан бер җире дә ким түгел!

Ислам абый белән Васил абый да эти шикелле үк нык бәдәнле, мускуллары уйнап торган таза кешеләр. Әллә читтә яшәгәнгәме, кушамат такмаганнар аларга. Мәмәт Исламы, Мәмәт Василы дип кенә йөртәләр. Мәмәте нәрсә икән инде аның дип аптырый идем кечерәк вакытта. Мәмәт – дәү этинең исемен кыскартып әйтүдән генә килеп чыккан сүз икән ул. Мөхәммәди Исламы диясене Мәмәт Исламы дип кенә калдырган халык.

Әтиләр – өч туган, өчесе дә көрәшчеләр.

Сабан туен быел да малайлар көрәше башлап җибәрде. Тик миңа батыр калу насыйп булмады. Югары очтан Мидхәт абыйларга Казаннан бер малай кайткан. Махсус мәктәпкә йөргән, ахры, чыккан бер малайны егып барды. Мине дә озак йөртмәде мәйдан әйләндереп, көтмәгәндә генә күтәреп алды да, сыртка да салды.

Капчык киеп йөгерүләр, капчык сугышлары, аркан тартышлар тәмамлангач, Камил абый мәйдан уртасына көрәшчеләрне чакырды. Быел да авылда халык арасында агроном Шамил абый батыр калырга тиеш, дигән сүзләр таралган иде. Әти көрәшми башлаганнан бирле, ел саен ул батыр калып килде. Быел да аны яз башыннан бирле өч сарык чалып ашаган икән инде дип сөйләделәр. Ашагандырмы, юкмы, шулай да Шамил абыйның да гәүдәсе теге грек атлетларыннан бер дә ким түгел.

Камил абый көрәшчеләрне чакыруга, мәйдан уртасына төрле яклардан эреле-ваклы егетләр чыгып баса башлады. Менә берзаманны Сабан туен бер тирәдән карыйбыз дип утырган җирләреннән безнең Ислам белән Васил абыйлар да торып бастылар. Аларны күреп, халык «ах» итте. «Кала икән быел Шамил төшеп», «Мәмәт малайларына икән быел тәкә!», «Василы калыр инде, анысы төптәнрәк чыккан», дигән чыш-пыш сөйләшүләр китте.

Камил абый көрәшне хөкем итүдә ярдәм итәр өчен үз янына этине дә чакырды. Ләкин эти, абыйлары да көрәшәсе булгач, риза булмады. Гадел хөкем итми, абыйларын яклый дип әйтерләр дип, карап кына утырырга булды. Дөрес эшләде дә. Көрәшчеләр арасында әллә нинди хәйләләргә баручылар да килеп чыкты. Камил абый гадел судья, андыйларны бик тиз урыннарына утыртып барды. Әти хөкем итә башласа, яклаша дип әйтәчәкләре көн кебек ачык иде. Чынлап та, ахырдан батырга Ислам абый белән Васил абыйга көрәшергә калды.

– Көрәшеп тә торасы юк, килешегез дә, тәмамлагыз бәйрәмне!

– Көрәшсеннәр! Сабантуйның ямен бозмасыннар килешеп!

– Василы җиңә инде! Нәрсә маташырга! – дигән тавышлар ишетелде.

Көрәшчеләр җыелып торган җиргә килеп, Ислам абый белән Васил абыйның хатыннары – җиңгәчәйләр, ирләрен көрәштермәскә маташып алдылар.

– Көрәшмичә генә килешегез, халык дөрес әйтә. Кайсыгыз җиңсә дә, тәкә бер учакта пешәчәк бит инде. Бер-берегезне имгәтеп куйсагыз тагын, булыр аннан! – диде Ислам абыйның хатыны.

– Көрәшсеннәр, көрәшсеннәр! – дип шаулашты аларны ишетеп торган хатыннар.

Батырга көрәшне башлар алдыннан көрәшчеләрне бераз ят иттереп, тын алдырып алыр өчен музыкаль тәнәфес игълан иттеләр. Казанның кайсыдыр

клубыннан килгән ирле-хатынлы артистлар фонограммага гына берничә җыр башкарып алдылар. Халыкның шуңа да күңеле булды. Коронавирус булгач, болай да зур залларга барып, концерт караудан мәхрүм халык, үз яннарына кайтып җырлап биргән артистларны бик шатланып, күңеле булып карады.

Ниһаять, хәлиткеч көрәш вакыты җитте. Абыйлар мәйданга җәелгән келәмнең кыл уртасына чыгып басты. Камил абый аларның билләренә сөлгеләрне бәйләде.

– Гадел көрәшегез, бер-берегезгә юл куймагыз, – диде Камил абый, абыйларның үзләренә генә ишетелерлек итеп пышылдап.

– Мин егылсам, халык юл куйды дип әйтәчәк. Ачуланма инде, энекәш, – диде Васил абый.

– Егып кара, – дип көлде Ислам абый.

– Була икән әле монда хәлләр, – дип куйды абыйларның сөйләшүен колак чите белән генә ишетеп калган эти.

Чынлап та, Васил абый үзе турында югары фикердә булып чыкты. Көрәш башланып, абыйлар бер-берсенең көчләрен сынашып, берничә мәртәбә генә билләрен тартышып алдылар да, Ислам абый аңламастан гына Васил абыйны селтәп тә атты. Халык «ах» итте!

– Менә бит ничек җиңел генә күтәреп салды!

– Сөйләшкәннәр!

– Юри җиңелде!

– Яңадан көрәшсеннәр! – дип кычкырышты халык.

Яңадан көрәшеп тору булмады. Ислам абыйга тәкәгә өстәп, суыткыч бирделәр.

Кич белән әниләр бакчадагы беседкага табын кордылар. Тәкәне дә чалып, хатын-кызлар тиз генә эчен-башын эшкәртеп, ирләр казан асып, шунда ук аш пешерергә куйдылар. Бәйрәм табынына этиләрнең дус-ишләре, күрше-күлән җыйналды. Бакча гөр килде. Ә миңа Васил абыйның Бәшир бабай турында сөйлим дип биргән вәгъдәсе тынгылык бирмәде.

– Васил абый, сөйлә инде Бәшир дәү эти турында, – дидем мин аңа, эшен бетереп, табын әзерләп мәш килүче хатыннарны күзәтеп утырган җиренә барып.

– Син дә булдырмадың, мин дә батыр калмадым. Бәшир дәү эти безне ачуланмадымы икән соң анда? – диде Васил абый.

– Нишләп ачулансын?! Барыбер Ислам абый батыр калды бит! Ул да аның оныгы лабаса!

– Шулай инде, шулаен. Ярый, сөйлим алайса, тыңла, – дип, Васил абый мине читкәрәк, алмагач төбенәрәк алып китте. Безнең сөйләшүне ишеткән эти белән Ислам абый, аларның малайлары да безгә иярделәр. Алмагач янына килеп, җайлашып утырышкач, Васил абый сөйли башлады.

– Бәшир дәү эти безнең ише генә көрәшче булмаган ул. Чын пәһлеван булган, диләр иде аны элекке, үзен күреп белгән авыл картлары. Әле егет чагында ук авылда гына түгел, тирә-як Сабан туйларында мәйдан тоткан ул. Бер сезонда бер көтүлек тәкә җыеп кайта торган булган. Менә шул дәү этиебез соңгы Сабан туенда тирә-якта аннан да зуррак дан тоткан бер пәһлеван белән бил алышкан. Ишетеп беләсеңдерме, нәнәм, менә шушы Ашыт елгасының башына таба китсәң, шунда Бәрәзә дигән бер зур гына авыл бар. Алты йөз – җиде йөз йорт кына булган ул заманнарда Бәрәзәдә. Һәр йортта алты-җидедән

генә исәпләсәң дә, ничәмә мең кеше яшәгән дигән сүз! Менә шул авылда Хафиз исемле көрәшче яшәгән, ди. Тирә-як сабан туйларында гына түгел, бөтен Казанда данлы көрәшче булган ул! Даны Мәскәүләргә, татарлар яшәгән бөтен төбәкләргә барып җиткән, ди. Безнең Бәшир дәү әти менә шул Бәрәзә Хафизны еккан бит Бәрәзә сабан туенда. Менә шуннан уйлап кара инде, нинди көчле пәһлеван булган безнең Бәшир дәү әтиебез. Бәрәзә Хафизны еккан да аңа тиешле иң затлы, иң симез тәкәне атының арбасына бәйләгән дә алып кайтып та киткән Битаманга. Бөтен Бәрәзә халкын шаккатырган карт дәү әтиебез. Карт дип, ул чакта әле ул яңа өйләнгән генә булган. Безнең әткәй мәрхүмнең туган елы гына булган әле бу.

Бәрәзә Хафизны җиңеп кайтуын кайткан дәү әти, тик икенче көнне үк Бәрәзәдән җигүле тарантаска төялеп, бер көтү егет килеп төшмәсенме безнең авылга! «Кайда ул батырыгыз?» – дип эзлиләр икән дәү әтине. Ә дәү әти тегеләрнең киләсен алдан белеп, урманга качып котылган. «Китсен ул батырыгыз авылдан! Яшәтмибез без аны!» – дип янаганнар дәү әтидән үч алырга килүчеләр. Шуннан соң Бәшир батыр яшь бичәсе, бишектәге сабый нарасые, әти-әнисе белән хушлашып, берәр елдан дөньялар тынычлангач әйләнеп кайтырмын дип, җәяүләп чыгып киткән авылдан. Шул китүдән киредән әйләнеп кайтулар насыйп булмаган Бәшир дәү әтигә. Бер айдан хаты килгән. Донбасс якларына барып, шахтага урнашкан булган. Күмер чабарга. Тик хат килгәннең икенче көнендә үк илдә афәт чыккан – сугыш башланган. Икенче хаты фронттан килгән дәү әтиебезнең. Шуннан соң инде бүтән хаты килмәгән. Беркадәр вакыттан яшь бичәсе, безнең Разия дәү әниебезгә хат ташучы авылда иң беренче булып «Хәбәрсез югалды» дигән хат китереп тоттырган. Менә шулай, ямь-яшь килеш тол калып, безнең әтиебез буласы нарасыен интегә-интегә үстергән карт дәү әниегез. Никадәр җәбер-золым күргән ул. «Хәбәрсез югалганнар»ны ул елларда дошманга әсирлеккә төшкән, «халык дошманы» дип гаепләгәннәр. «Халык дошманы» хатынына көн күрсәтмәгәннәр НКВД шымчылары. Боларны карт дәү әниебез үзе генә белгәндер. Нинди нык булган ул, бирешмәгән, Мөхәммәди улын атасына тиң итеп, чын пәһлеван итеп тәрбияләп үстергән. Безнең әткәй дә, мәрхүм, бөтен тирә-якта дан тоткан көрәшче иде. Көрәшче Бәшир каны аккан шул аның тамырларында. Безнең барыбызның тамырларында да көрәшче Бәшир бабай каны ага. Соңгы сабан туе булган ул аның Бәрәзә Хафизны еккан Сабан туе. Бүген менә минем дә көрәштә катнашкан соңгы сабан туем булды бу. Ләкин мин үкенмим. Менә бит, яңа пәһлеван үсеп килә! – Васил абый шулай диде дә мине кочаклап алды. – Дөрес, ул да егылды бүген. Ләкин аның җиңүселәре алда әле. Бәшир дәү әти данын озак яшәтәчәк әле ул! Шулай бит, Рөстәм?!

Мин аңа берни дип тә җавап бирмәдем. Минем өчен дә соңгы Сабан туе иде бу. Егылган Сабан туйларымның соңгысы. Киләсе Сабан туйларында мин һичшиксез батыр калачакмын! Алла боерса!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# ХИКӘЯ ҖЕГӘРЕ

## АЙДАР ХӘЛИМГӘ – 80 ЯШЬ

Соңгы дүрт дистә ел эчендә татар әдәбиятының үтә мөһим проблемалар белән сугарылуы, һичшиксез, Айдар Хәлим әсәрләре белән дә бәйле. Ул поэзия, проза, драматургия, публицистика, балалар әдәбияты кебек өлкәләрнең һәркайсында бердәй югары дәрәҗәдә иҗат итүче күпкырлы каләм иясе буларак, соклану хисләре уята. Алай гына да түгел, әдип үзенең иҗади басуында әлеге өлкәләргә кагылышлы жанрларны «ай урагы» белән түгел, ә «үзйөрешле комбайны» белән ура кебек. Гүя аңа үзе аеруча уңышка ирешкән хикәя-новелла жанрыннан повесть («Өч аяклы ат»), роман («Татар вакыты») кебек күләмле әсәрләргә, хәтта өчәр томлык роман-эпопеяга («Хунвэйбин») күчү берни тормый.

Айдар Хәлим, ни-нәрсә турында гына язмасын, әйтәсе фикерен җиткереп үткәрә. Ул дөнья, ил яшәешендәге теге яки бу күренешкә үтә сизгерлек күрсәтә. Әсәрләре, үз халкына төбәлеп, җанындагы иң кайнар, иң нәзек, бөек мәгънәле хис-тойгы – миллилек белән сугарылган. Әдип татар әдәбиятында башкаларны кабатламау, сәнгатьчә камиллек, бөтенлек белән үзенчәлекле урын тота. Аның иҗатына кагылышлы тәнкыйди мәкаләләрдә ассызыкланучы әлеге фикерләр кече күләмле проза жанрлары мисалында да раслана.

«Миңа калса, заманнар узу белән язучылар әдәби әсәр уйлап чыгарудан, гомумән, туктарлар кебек. Язучылар, әгәр инде алар булсалар, уйлап чыгарып язмаслар, бәлки, тормышта үзләре өчен әһәмиятле яисә кызыклы нәрсәләр турында гына сөйләрләр». М.Мәһдиев «Бәхилләшү» әсәренә эпиграф итеп, Лев Толстойның менә шушы сүзләрен сайлаган иде. Р.Зәйдулла билгеләп үткәнчә, М.Мәһдиев кебек сизгер йөрәкле каләм иясе бу фикергә очраклы гына тукталмаган, әлбәттә. Бу фикерләр заман әдәбиятында расланып бара. Айдар Хәлимнең «Китап», «Чыршы бәйрәмендә», «Виктория» хикәяләре дә, иң беренче чиратта, сюжетлары нигезенә нәкъ менә әдипнең үзе кичергәннәр, күңеленә нык уелып калган хатирәләр салынуы белән укучыны җәлеп итә.

Әлеге әсәрләрнең үзәк геройлары – сабыйлар, яшүсмерләр. Конфликт, психологик кичерешләр, хис-тойгылар алар күңелендәге сафлык, чисталык белән сурәтләнә. Балачакта кичерелгән җан әрнеше олы тәҗрибә, өлгергән карашлар белән сугарыла. Автор аларны өстәмә тәэсир-мәгънәләр белән баета һәм зур гомумиләштерүләр ясый.

«Чыршы бәйрәме» хикәясенең үзәк конфликты – матурлык, бөтенлек турындагы хыял, матур итеп яшәргә омтылыш белән кырыс чынбарлыкның бәрелеше. Үзәк герой – сугыш нәтиҗәсендә әтисез калган меңнәрчә ятимнәрнең берсе. Аңа үз гомерендә абыйсына ияреп, беренче тапкыр чыршы бәйрәменә барырга форсат чыккан. Малай аны бик тә ямьле, күңелле итеп күзаллый. Шуңа күрә бу бәйрәмгә матур киемнәр белән барасы килә. Тик алар, аеруча чабаталары, бик тузган. Зирәк малай, ничек итсә итә, яңаларын юнәтә. Балалар чыршы бәйрәменә китәләр.

Чыршы урынына бастырылган сары каен чаукасы, аның ботакларындагы кәгазь кисентеләре, шул каен тирәсендә биеп маташкан чабаталы, ертык бишмәтле балалар, сугыштан берсе аяксыз, икенчесе контузия белән кайткан ике бертуган укытучы абыйлар, кичке авыл тәрәзәләрендә җемелдәгән утлар, балалардан да ятимрәк, ачрак хәлсез атлар – кыскасы, һәр образ-персонаж, образ-деталь, образ-сүз әдипнең балалык чорына туры килгән елларның сәяси-җәмгыяви-икътисади хәлен күз алдына бастыра. Әмма хикәянең төп идея-мәгънәви эчтәлеге боларны гына ассызыклау түгел. Әдип укучының игътибарын

шушы матди җитмәүчелек, фәкыйрьлек күзгә бәрелеп торган шартларда бәйрәмнең балага ясаган тәэсир сурәтенә юнәлтә. Әйтерсең, ул чабата урынына яхшы күн итек, бишмәт урынына килешле тун кигән?!. Кәгазьдән генә кисеп ясалган уенчыклар да атласмыни?! Ул сабыйларга хас самимилек белән шундый зур серле бәйрәмдә катнашуына куана, ихласлык белән күңел ача. Бу аның гомерендә беренче чыршы бәйрәме бит. Бала күңелендә кайнаган хис-тойгылар авторның әрнүле, сагышлы моңы белән өретелә. Тик бу аның кызгану хисе түгел. Киресенчә, әлеге ятимнәр язмышлары үтә катлаулы чорга туры килсә дә, үзләренең дөньяда барлыгын, кабатланмас бердәнбер һәм матурлыкка, шәхси бәхеткә хокуклы булуларын расларга тырышалар. Бу тартышта алар җиңүчеләр булып чыга.

«Китап» хикәясендә дә әдипнең җанында гомере буе дәвам иткән балачак хатирәләре урын алган. Район үзәгенә туган телдә уку китаплары кайткан. Нибары биш данә. Алар 85 тиенлек хак белән бары тик яхшы билгеләренә генә укучыларга сатылачак икән. Өченче сыйныфта укучы герой бу исемлектә бар. Чөнки ул чирекне гел «бишле»гә генә укып бара. Әмма юньле-башлы ашарына да булмаган гаиләдә әлеге сумманың тиене дә юк. Затлы китапка ия булу теләге шул хәтле көчле ки, малай барлык зиһенен эшкә җигә. Кырыс чынбарлык шартларында исән калырга тырышу, тырмашу, тарткалашу нәтиҗәсендә үзләштерелгән компетенцияләр, метапредметлылык ярдәмгә килә. Ул китапны кулга алу бәхетенә ирешә. Автор баланың психологик-эмоциональ халәтен бик нечкә, табигый итеп күрсәтә. Чөнки геройның күңелендә кайнаган шатлык, эзләнү, борчылу, чарасызлык, өмет хисләре – болар барысы да сугыш елларында китапка сусаган Нәҗметдин улы Борисның да хисләре. Әсәр китапка сәҗдә кылу рухы белән сугарылган. Язучы, гомумән, китапка омтылышны бик югары бәяли. Аның фикеренчә, китап укымаган кешедә иман булмый.

Билгеле булганча, Айдар Хәлим – әдәбиятка шигърият аша килгән язучы. Ул бүген дә, холык-фигыле, яшәү рәвеше, иҗат максаты, көрәш кыйбласы белән генә түгел, бәлки, фикерләрен сәнгатьчә яңгырату алымнары ягыннан да шагыйрьләрчә иҗат итүче булып кала. «Виктория» хикәясен нәкъ менә шагыйрь каләме белән язылган дип бәяләргә була. Автор аеруча игътибарга лаек дип саналган фикерләрен кабатлаулар, мәгънә нуры чәчә торган метафора, фокус-детальләр аша җиткерә. Әсәрдә мәгънәсенә зирәк укучы гына төшенердәй образлар да урын алган. Вакыйга вакыты 1955 елның 22 февраль көне дип төгәлләштерелгән. Сугыш беткәннең 10 еллыгы якынлаша. Иртәгәсе көн – Совет армиясе бәйрәме. Әлеге зур бәйрәм хөрмәтенә мәктәптә чаңгы ярышлары оештырыла. Канәгать исемле яшүсмер малай җир йөзендә күрелмәгән «фабричный» чаңгыларда, беренче булып килеп, барысын да таң калдырырга ниятли. Әмма бабасы нимес җиреннән трофей итеп алып кайткан чаңгылар шумый (чөнки алар урман-тау гаскәрләре өчен эшләнгән). Канәгатьне хәтта мәктәпнең иң көчсез саналган укучылары да үзләре генә әмәлләгән чаңгыларда узып китәләр. Малай ярдәмгә сугышта үлеп калган этисенең рухын да, ул казыкка элеп калдырган ак аргамакның баш сөяген дә чакырып карый. Тик берсе дә булышмый. Чамадан тыш авыр нимес чаңгылары аркасында, кичә генә алдынгы булып та, бүген адәм көлкесенә калган малай гарьлектән ачынып елый. Фикерле, зирәк укучы бу вакыйгага олы идея-эстетик мәгънә салынган булуына төшенә ала. Очыну, хыял, коры теләк, Көнбатышка ияреп, «без булдырабыз» ерпачлыгы белән генә максатка ирешеп булмый шул. Үз көчең, үз җегәрең кирәк. Һәр милләт, һәр халык үзенең яшәешендә, үсешендә пассионар нигезләренә, гореф-гадәтләренә таянырга тиеш. Җир йөзендә нибары әлегә 13 елын яшәгән малайның үз чаңгыларына беренчелекне кайтару ачышы әнә шундый зур гомумиләштерүләргә – төрки татарның тарихи урынын җуйдырмаска тырышу ниятенә барып тоташа. Айдар Хәлим һәрдаим татар әдәбиятын яңа образлар белән баетырга тырыша. Алар арасында үтә дә үзенчәлекле, кабатланмас булганнары бар. Бу хикәядә шул рәттәгеләрнең берсе – «макаронник» образы урын алган. (Армия срогыннан соң үз теләге (күбесе тамак ялына) белән хәрби хезмәттә калган, халык аңында сержант-старшина кебек «бик зур дәрәҗәгә ирешкән» кешеләрне халык телендә «макаронник» дип йөртәләр. Әдип фикеренчә, «макаронниклар» – татар

авылларына тәмәке, аракы, сүгенү сүзләрен, сөйкемле марҗаларын алып кайтып, ил, тел, милләт казнасын җимерүгә шактый өлеш кертүчеләр. Канәгатьнең физкультура укытучысы – Гариф шул катлам хәрбиләрнең типик вәкиле. Ул урысча сүзләр сөйли. Шулай иткән саен үзен башкалардан акыллырак саный. Физкультурадан тыш, немец, география фәненнән дә укыткан Гариф, «кеше һәрчак сугышка әзер булырга тиеш» дип, яшь буынның иманын сава. Әлеге чаңгы ярышына да укучыларга «полный боевой вклад» – автомат, консерва тыгылган вещмешок белән килергә кушыла. Автомат урынына утын түмәре, консерва урынына каткан ипи кисәге дә ярап тора. Әмма вещмешок әзер булсын. (Макаронник образы әдипнең «Теге малай», «Штабтан шалтыратмадылармы?» хикәяләрендә дә тәнкыйди яссылыкта сурәтләнә).

Айдар Хәлим иҗаты, жанр төрлелегеннән тыш, хис-тойгы төсмерләренә байлык белән дә сокландыра. Автор сәнгатьчә фикерләрен фаҗигалелек, драматик, сатирик кебек пафосларда бердәй оста яңгырата ала.

«Паравыз кычкыртты» – фаҗигале-драматик хис дулкынында иҗат ителгән хикәя. Сугыш башланган көннәр. Авыл дүрт ир-егетен сугышка озата. Болар – беренчеләрдән булып сугышка китүчеләр, авылның иң асыл ирләре. Берсе – авылның иң яхшы чалгычысы, икенчесе – иң көчле көрәшче, өченчесе – иң уңган тракторчы, дүртенчесе – иң оста гармунчы. Авыл яшәешендәге дүрт терәк багана. Гармунчысы Газинур исемле. Газинур яшь кәләше Тәнзилә белән туйдан соң нибары бер ай яшәп калган. Шуны исәпкә алыптыр инде, авылдан бердәнбер хатын-кызга – Тәнзиләгә генә – Әкчин каласына ирен озату хокукы бирелгән. Алар иртәнге дүрткә каланың вокзалына килеп җитәләр (военкомат әмере). Әлегә хыял белән чынбарлык, әкият белән чынбарлык, гөман белән томан арасында яшәгән Тәнзилә «сугыш» дигән фаҗиганең тирәнлеген күз алдына китерә дә алмый. Үз гомерендә беренче мәртәбә паровоз күргән унсигез яшьлек авыл кызының башкада: «Сугыш чыкмаган булса, кайчан күрер идем әле бу паровозны?» Исемлек барланып, ирләргә вагоннарга утырырга әмер яңгырагач та әле, ул чынбарлыктагы фаҗигане бәяләр дәрәҗәдә түгел. Күңеленнән «Шушы исемлек буенча алып кайтырлар микән?» дигән уй йөгереп уза. Паровоз гыйфрит тавышы белән кычкыртып җибәрә. Нәкъ менә шул мәлдә Тәнзиләнең гөманнары томаннан аерыла. Ул кинәт бу аерылуның мәңгелеккә икәненә төшенә. Паровоз кузгалып китә. Яшь хатын бар көченә ирен алып киткән эшелон артыннан йөгерә башлый. Ул күздән югалганчы йөгерә дә йөгерә... «Унсигез яшендә тол калган Тәнзилә гомере буе шул состав артыннан йөгерәчәк. Килен булып төшкән тупсасында картаячак һәм 92 яшендә дөнья куячак». Менә шундый эпилог белән очланган хикәя «сугыш» дигән афәт фаҗигасен үтә тирән итеп чагылдыра.

Айдар Хәлим – сурәт офыклары, дөньяви карашлары киң, белемгә бай булган язучы. Тормышның әчесен-төчесен күп татыган, күпне күргән язучының үзенә мәгълүм булган һәр вакыйгага, һәр күренешкә үз карашы, һәр шәйгә үз фикере бар.

А.Хәлимнең үткен каләме каһәрле, имансыз халыкара сәясәтнең, кешелексез империяләрнең бик күп җинаятьчел гамәлләрен фаш итте. «Үрнәк эшелон» хикәясендә менә шундый гамәлләрнең берсе урын алган. Үзәктә – 1944 елда хаксызга Ватаннарыннан сөрелгән кырым татарлары фаҗигасенең бер сурәте. Тимер юлдан 007 литерлы эшелон чаба. Анда гомер буе тупланган малыннан, дөньясыннан көчләп кубарылган биш мең кеше сөргенгә китеп бара. Алар арасында җиде яшьлек улы белән Бәкер исемле ир һәм берсеннән-берсе кечкенә дүрт кызчыгы белән Мәмдүдә дигән хатын да бар. Бу бәхетсез кешеләр, шул исәптән нарасый балалар да, «сатлык җан», «сатлык милләт вәкилләре» дип тамгаланган. Бу халыкара хыянәтчел вакыйганың гайре табигый булуы (парадоксы) да шунда ки, әлеге сатлык балаларның әтиләре, сатлык хатыннарның ирләре, туганнары фашистларга каршы көрәштә кан коя. Бәкернең әтисе яраланып, фронттан кайткан, әнисе Севастопольдә оборона эшләрендә җәфа чигә. Мәмдүдәнең ире исә – совет гаскәрләрендә офицер. Тоткыннарны Татарстан һәм Башкортстан НКВД сы солдатлары (күбесе татарлар) саклый. Эшелон бер станциядә туктый. Тоткыннар вагоннардан җиргә сибелә. Һәркем

иркенлектә, тере, җанлы табигать кочагында сулыш алып калырга тырыша. Шулай да иманын җуймаган халык башта намазын укый. Әмма Аллаһы Тәгалә адәм баласына билгеләгән вакыт аларныкы түгел. Ул табигый хаҗәтләрен үтәү өчен генә бирелгән. Чамалы вакыт бик тиз узып китә. Эшелон кузгала. Чыр-чу килгән кешеләр арасында Бәкер үзенең улын күздән югалта. Көтелмәгән бу хәлдән шашынып калган ир эшелоннан кире сикереп төшә дә елга буена йөгерә. Улы шунда булырга, су коенырга киткән булырга тиеш. Шулай булып чыга да. Бала да состав кузгалып киткәнне күрә. Инде күп явызлыкларны татыган малай, әтисе белән дә мәңгегә аерылачагын аңлап, эшелонга таба йөгерә башлый. Әтисен күрү шатлыгына сабыйның нәни йөрәге түзми, коточкыч тетрәнүдән, киеренкелектән шартлый. Шулчак автоматтан очередь бирәләр. Бәкерне дә, инструкцияне бозып, аларга ярдәм итәргә килеп җиткән НКВД солдаты татар Шиһабетдинне дә ерткыч хәрбиләр юк итәләр. Шулай итеп, ике бертуган халыкның балалары Хәрәбәле сазларында козгыннарга азык булып ятып кала. Соңыннан офицерлар киңәшмәсендә бу хәл тикшерелә. Сәясәт ялчысы булган рәсми тарих, кирәк булганда, «Казан татарлары белән Кырым татарлары арасында бернинди уртаклык юк» дип тәкрарласа, бу юлы инде дәүләтнең карагруһ офицеры «Кырым татарлары да, Казан татарлары да – алар барысы да бер нәсел этләре» дип, мәсьәләне явызлык файдасына хәл итә. Тик шулай да Казан татары үлеме бушка төшсә, Кырым татарлары өчен түләргә кирәклеген искәртә.

Һәр олы әдипнең иҗаты бербөтенне тәшкил итә. Теге яки бу язучының һәр әсәре башкаларына табигый рәвештә килеп ялгана. Шулар арасында аның тулаем иҗатының асылы, квинтэссенциясе сыман берничә әсәре була. Алар әдипнең бербөтен иҗатына фикер нурларын чәчә. Һәр әсәр үз чиратында идея-эстетик мәгънәсе белән шушы әсәрләргә килеп тоташа. Безнең карашка, Айдар Хәлимнең «Калеб яратылганда» һәм «Көчле кеше» әсәрләре нәкъ менә шундый үзенчәлеккә ия булып тора.

Алар икесе дә кешенең көч-гайрәт чыганаклары турында уйландыра. «Калеб яратылганда» – нәсер жанрында язылган әсәр. Аның сюжеты бик гади. Төсләр, аһәңнәр, исләр, һәр эреле-ваклы җанлы нәрсәнең хәрәкәтләреннән оешкан бербөтен гармонияле манзара: төнге йокыга талырга хәзерләнгән табигать. Ике хатын – нәни лирик геройның әнисе һәм аның ахирәте – йон төенчекләре белән авылга кайтып баралар. Ике сугыш толы бертавышка «Идел» җырын көйли... Алар артыннан кечкенә малай атлый. Шушы бербөтен галәми бөтенлектә, сихрилектә сабый бала әлегә үзе аңлап бетермәгән яшәеш серен тоемлый. Тәҗрибәле әдип кешенең бу күңел халәтенә «җан сугарылу», «калеб яратылу», «Мин кешеләрне яклый алам» дигән гүзәл гамь белән сугарылу, йөрәккә сөю, көю, гаҗәпләнү хисләре урнашу мизгеле дип бәя бирә. Бу халәт – шәхес калебендә дөньяның, яшәешнең гармониясе, бөтенлеге ачылган мизгел. (Танып-белү теориясендә һәм психологиясендә «озарение души», «инсайт» төшенчәсе белән йөртелә). Әдип кеше күңеленең без белмәгән якларын шул дәрәҗәдә нәкышлап бирә ки, һәрнәрсәне яратасы, яратудан елыйсы килә. Авторның галәми колачлы фикере, хис-тойгыларның тирәнлеге, нечкәлеге таң калдыра.

«Көчле кеше» – фәлсәфи-гамәли хикәя. Ул Вольтер, Руссо, Л.Толстой рухында язылган фәнни трактатны хәтерләтә. Әдип кешедәге «көч» дигән сихри күренешнең беренчел алшартларын билгеләргә омтыла. Алар түбәндәгеләр: 1) гаилә; 2) табигать, аның нигъмәтләре; 3) халык авыз иҗаты, фольклор әсәрләре, аларда чагылыш тапкан кайгыны, авырлыкны сабырлык белән күтәрә белү хикмәте; 4) хезмәт; 5) мәхәббәт. Айдар Хәлим фикеренчә, яшәеш менә шушы алтын баганалардан тора.

Йомгак ясап әйткәндә, Айдар Хәлим – тирән мәгънәле, сәнгатьчә нәфис яңгырашлы хикәя-новеллалар остасы. Әлеге әсәрләр танып-белү, тәрбия, эстетика җәһәтеннән татар әдәбиятының хәзинәсенә байлык өстәделәр. Язучы бүген дә шушы рухта, шушы дулкында иҗатын дәвам итә.

**Лилия ГАЛИТЗУЛЛИНА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ДӨНЬЯНЫ БАРЫ ТИК ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРТҮЧЕ

## РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ – 75 ЯШЬ

Танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, татар милләте, тарихи-мәдәни мирасыбызны саклау һәм киләчәк буыннарга җиткерү, татар мәдәниятен үстерү өчен янып йөрүче Разил Вәлиевнең татар әдәбияты тарихында үз дәрәҗәле урыны бар. Җитмештән артык китап, дүрт пьеса, 200дән артык җырлар авторы, әдәбиятның өч төрендә – поэзия, проза, драматургиядә актив иҗатчы, гамьле публицист буларак, ул XX гасырның соңгы чирегеннән бүгенгәчә әдәби барышны әйдәп баручылардан. Аның төрле жанрларны колачлаган иҗатына фикер хөрлеге, милли-иҗтимагый үткенлек, шигъри теллелек хас.

Хөр фикерле, әдәби-эстетик эзләнүләрне үз күргән 1960 нчы елгы авангард шагыйрьләр буынының дәвамчысы һәм бер вәкиле булып, әдәбият мәйданына килгән Р.Вәлиев иҗатына, күрәсең, заман үзе кыйбла билгеләп, юл күрсәтә. Х.Әюп, әйткәнчә, «яңа аваз булып» кереп, «Роберт Әхмәтҗановлар, Равил Фәйзуллиннар, Рөстәм Мингалимовлар, Гәрәй Рәхимнәр башлап җибәргән шигъри ташкынга куәт өстәп җибәрә. Ул чорда беркадәр бүтәнчәрәк, ятрак кебек тоелса да, Разилнең шигъри фикерләве үзенә игътибарны тиз җәлеп итте, укучының күңеленә үтеп керде. Моңа яңа чагыштырулар гына түгел, ул шигырьләрдәге тирән фикер, эчкәре яшерелгән лирик моң, ул чакта ук инде халык мәнфәгатен кайгырту кебек сыйфатлар сәбәпче булгандыр, мөгаен. (...) Ул – дөньяны үзгәртергә һәм бары тик яхшы якка гына үзгәртергә дип, күңеленә беркеткән, шуңа омтылып яшәгән, кылган гамәлләрен шуңа багышлаган игелекле шәхесләрнең берсе»[1] .

Бу чор – татар поэзиясендә яңарыш юлларын эзләү вакыты. Бер яктан, халык җырына, аһәңенә, образлылыгына якынаю – саф татарча «җырлап торган» милли моңлы һәм яңгырашлы лирик әсәрләрнең татар әдәбиятында алгы урынга чыгуын тәэмин итә. Әниләр, туган җир, иҗат белән халык язмышының уртаклыгы мотивлары калкуланып, милли геройлар идеаллаштырыла. Шәхси кичерешләр өермәсендә тасвирланган, тыныч тормыш матурлыгын җырлаучы лирик герой – озак еллар мәйдан тоткан гражданин лирик геройны алмаштырса да, аңа хас булган җәмгыять гаме белән, ил һәм халык бәхетен алга куеп яшәү сыйфатлары югалмый. Икенче яктан, яшерен эчтәлек, эзоп теле, кинаяле-астарлы шигырьләр – укучыны уйландырырлык, совет идеологиясе иләге-цензурасы аша уза алмаслык көтелмәгән мәгънә-фикерләргә алып чыга. Беренче карашка ачык, үтәкүренмәле тоелган мәхәббәт, пейзаж лирикасында да иҗтимагый-сәяси яңгыраш калкуландырыла, ассоциатив бәйләнешләр, символлар яки образ-ишарәләр ярдәмендә үзгә эчтәлеккә юл күрсәтелә. Бу яңалыклар Р.Вәлиев шигъриятендә дә күзәтелә, аның иҗаты, үзе максат итеп куйганча, безнең әдәбиятны шушы юнәлештә үзгәртүдә буразналар ярып бара:

*Нәселемә мин хыянәт итмәм! –*
*Игенчеләр безнең ыруда.*
*...Буразналар ярып барсаң иде*
*Шигъриятнең олы кырында*[2] .

Р.Вәлиев – романтик шигърият кешесе. Аның шигырьләрендә, татар авангард шигъриятенең үзәгендә торган, зур дулкыннар уятучы һәм азатлык турында җырлаучы «диңгез җилләре» мотивы өстенлекле («Җилләрне син күп күргәнсең, диләр…»),

[1] Харрас Әюп. Кышкы учак җылысы // Мәйдан. – 2006. – № 8. – 23 б.
[2] Вәлиев Р. Игенчеләр нәселе // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 110 б.

лирик герое төп кыйммәтләр итеп, тормышта матурлыкны, гаделлекне, яхшылыкны билгели һәм дөньяны шушы үлчәмнәргә тәңгәлләштереп үзгәртергә омтыла. Бу лирик герой Такташ гыйсъянчысын хәтерләтә. Эпиграф итеп тә, Такташтан «...Әйе, минем көчле рухымнан / җир вә күкләр калтырар» дигән юллар сайланган «...Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә...» шигыре Р.Вәлиев иҗатының «визит карточкасы»на әйләнә:

*Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә*
*Акыл күпме җавап эзләгән...*
*Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,*
*Йә булмаса, үзем үзгәрәм*[3].

Шигырьнең үз эчендә «Үлем белән якалашканда да / Акны кара диеп сөйләмәм» диюче лирик герой тормышны каләм көче белән дә, хаксызлыкка каршы көрәшеп тә үзгәртергә алынган кеше булып күзаллана. «Айны кояш диям, теләсәм» дигән сүзләр аның үз дөреслеген урнаштыруга тирән ышанычы булып ишетелә.

Кинаяле шигырь – тарих фаҗигасенә эләккән күп язмышларны күз алдында тергезә. «Тарих тәгәрмәченә тимер кыршау кидергәндә тапталып үлде» дигән тәэсирле образ кешелек тарихындагы төрле дәверләрдә кичерелгән фаҗигаләрне искә төшерә, аларның шигырь эчтәлеге була алу мөмкинлеген күрсәтә.

Мондый күренеш беренче карашка пейзаж лирикасы булып тоелган текстларда да еш очрый. Әйтик, көз сурәтен ясаган «...Һәр көз саен таллар...» шигырендә соңгы тезмәләр, агач тамыры / нәсел тамыры / милли традицияләр-милләтне сугарган кыйммәтләр кебек ассоциацияләр янәшәсендә милли эчтәлек ала:

*Көзге җилләр телем алсалар да,*
*Тамырымда мәңге калырмын*[4] .

Мондый өмет-ышанычның сәбәбе табигать белән кешенең – берлегендә-бөтенлегендә булып аңлашыла («Җиргә мәдхия»).

Еш кына киная алымы фикерне бәяләмичә генә, игътибарлы һәм әзерлекле укучы күңеленә керерлек итеп җиткерә. Шатлык пафосы өстенлек иткән «Авылда туй» шигырендә беренче һәм соңгы строфаларда күренеп, каймалап алган татар өе-урыс капкасы образы шундыйлардан:

*Киереп ач урыс капкаларны!*
*Керсен кунак безнең өйгә дә!*
*(...) Каерып ач урыс капкаларны! –*
*Керсен бәйрәм татар өенә*[5] .

Бер төркем шигырьләрдә төрки-татарларның үткәне идеаллаштырыла, шагыйрь ерак тарихтан үрнәк, халыкның үзаңын үстерерлек үзәк эзли. Аларда тарихи шәхесләр образлары – милли үзаң билгесенә, халыкка хезмәт итү символына әйләнәләр. Мондый шигырьләрдә шагыйрь индивидуаль авторлык символлары белән эш итә. Символларның үзенчәлекле кулланылышы, вакыт ягыннан бәйләүче символлар белән янәшә, Р.Вәлиев иҗатында җемелдәүче образлар, яктылык, тавышлар, билгеләр белән уйнау күзәтелә. Еш кына символлар яки аллегорияләр шигырьнең берничә эчтәлекне үзенә сыйдыруын тәэмин итә («Алма»). Ирекле формалар, традицион булмаган алымнар, бигрәк тә, модернистик шигырьләрендә үзенчәлекле дөнья сурәте тудыруда

[3] Вәлиев Р. ...Елый-елый, сугыша-сугыша жирдә // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 28 б.

[4] Вәлиев Р. ...Һәр көз саен таллар // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 52 б.

[5] Вәлиев Р. Авылда туй // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – 103 б.

катнашалар. Әйтик, француз модернисты Шарль Бодлерга багышланган «Шагыйрь» шигыре иҗади шәхеснең холкы, рухи хөрлек, кешенең танылу, исем-ат алу кебек проблемаларга кагыла. Тезислап, җемелдәүче образлар рәте ярдәмендә Р.Вәлиев француз шагыйренең тормыш юлын – исем алуга, танылуга омтылыш буларак карый. Әмма шагыйрьнең теләге ул үлгәннән соң гына тормышка ашуны билгели.

Шигырьдә сурәтләнгән дөнья экзистенциаль, хаос халәтендә, үлгәннән соң исем алу бу хаосны үзгәртә алмый, дөньяны гармониягә китерми. Киресенчә, автор тарафыннан гаделсезлек буларак бәяләнә. Шулай Р.Вәлиев романтизмның яраткан проблемасын модернистик яссылыкка күчерә. Алымнар да шуңа тәңгәл сайланган. Җемелдәүче образлар кеше тормышындагы иң әһәмиятле моментларны күрсәтә: әнидән мактау өмет итү (Сабый чакта урындыктан егылды./ Көне буе әнисен көтеп, / Еламыйча / уч төбендә бер тамчы кан саклап йөрде. / Аңламадылар), матурлык белән беренче очрашу (Малай булгач, / беренче тапкыр / йолдыз атылганын күрде. / Кешелеккә яңалык сөйләр өчен, / йокламыйча, / төне буе таңны көтеп ятты. / Тыңламадылар), шагыйрьнең башкалар тарафыннан танылу өмет итүе, тормышның тиз агышына төшенү… Бу мизгелләрне детальләштерү текстны лирик геройның монологына әйләндерә. Әмма тезмәләрне төгәлләүче бәяләүләр: «Аңламадылар», «Тыңламадылар», «Җырламадылар», «Соңладылар» – икеләтелгән йөкләмә алган: лирик герой монологы автор монологы-бәясе белән тоташа. Бер үк вакытта өченче «тавыш» хасил була: шагыйрь лирик геройны, гомумән, кешеләргә каршы куя:

*Менә бүген*
*барысы үтте, барысы бетте.*
*Кешеләр аны әрнеп тыңладылар...*
*Аңладылар... Соңладылар...*
*Каберенә башларын орып,*
*җырын җырладылар*[6].

Өченче тавыш – кешеләр җыры экзистенциаль сагышны, үкенечне көчәйтә һәм бу процессны тормыш законына әйләндерә. Һәр очракта да һәр кеше үз тирәлегендә танылу теләге белән яши, әмма моңа ирешә алмый. Шуңа күрә тормышта гармония юк. Мондый эчтәлек үзенчәлеге текстның модернистик әсәр булуын тәэмин итә.

Шагыйрьнең фәлсәфи иҗатында кеше фәлсәфәсе – шәхесне зурлау фәлсәфәсе үзәктә тора. Башлангыч шигырьләреннән булган «Кеше»дә һәр кеше – материк, кыйтга дип ассызыклана. «Мизгел» шигырендә, әйтик, хыялда тергезелгән абсурд дәрәҗәсендәге сурәт – кешенең җир шарыннан да зуррак фикри көчен, аның һәр җан иясенең ваемын үз күңеле аша уздыра алырлык кичерешләргә сәләтен, яшәештәге һәр нәрсәне үлчи һәм бәһали алырлык сизгерлеген шигырьгә әйләндерә, һәр шәхеснең, асылда, иҗатчы булуын раслый:

*Бизмәнләдем күз яшьләрен, таң чыкларын –*
*барын, барын, барын.*
*Онытып тордым йолдызларның*
*тик төннәрен януларын.*
*Бер мизгелгә*
*уч төбенә куеп тордым.*
*Әйе, әйе,*
*мин бер мизгел*
*шагыйрь булып алдым*[7].

Кеше өчен мөһим кыйммәтләр арасында лирик герой өметне атый («Автобиография»),

---

[6] Вәлиев Р. Сүзләрдән дисбе: шигырьләр, җырлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – 85 б.

[7] Вәлиев Р. Үзгәрергә // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – 349 б.

лирик геройның теләсә кайсы халәтендә өмет катнашу Р.Вәлиев иҗатының бер үзенчәлеген хасил итә.

Р.Вәлиев иҗатында мәхәббәт темасы аерым урын тота. «...Хатларыңны утка яктым синең...», «...Сине эзләп, мин тауларга мендем...», «Саубуллашу», «...Көзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...» һ.б. әсәрләрдә бу хиснең төрле мизгелләре тасвирлана. Хисләр аның шигырьләрендә еш кына күрмә образлар рәте ярдәмендә белдерелә. Нәкъ менә шул әйбер, табигать образларының көчәйтелүе хис көчәйтелүен тәэмин итә. Әйтик, «Гашыйк булгач» шигырендә ул шулай:

*Бер тамчы су – төссез.*
*Бер бүлмә һава – төссез.*
*Океан – зәңгәр.*
*Күк тә зәңгәр.*
*Кайчандыр бу күзләр төссез иде...*
*Хәзер – зәңгәр!*[8]

Зур булмаган, ирекле шигырьдә иң әһәмиятлесе фикри сурәт булып чыга: мәхәббәт – шулкадәр олы көч, ул кешенең күзләрен төскә мана диюче лирик герой, гашыйк кеше, аны яшәү мәгънәсе дәрәҗәсенә куя.

Бу иҗатта, саф сөю шигырьләреннән бигрәк, сөю фәлсәфәсе өстенлек ала. «Мәхәббәт» шигырендәге:

*Монда Кояш*
*океан төбеннән күтәрелә.*
*Монда сукбай һәм буйдак Ай –*
*кул сузымы җитә.*
*Монда давыл*
*дулкын биеклеге белән үлчәнә*[9] *,*

– кебек сурәтләр тирән фәлсәфә белән сугарылган. Бер яктан, океан, күз яше, кояш, ай, көн, төн кебек бинар образлар ярдәмендә мәхәббәт – үзе шигырь дигән фикер әйтелә. Икенче яктан, кояшның – океан төбеннән күтәрелүе, Айның – кул сузымы ераклыгы, давылның исә – дулкын биеклеге белән үлчәнүе кебек гыйбарәләр, гомумән, тормыш-яшәеш кануннары булып та укылалар.

Аһәң, яңгыраш матурлыгы, көйле, моңлы булу Р.Вәлиевнең бик күп текстларына көй язылуга китерә. Хәтта гражданлык лирикасы үрнәкләре дә җыр булып киткән. «Татарстан», «Бәхетем башкаласы», «Саумы, Казан!» кебек гимн-шигырьләр, «Нигә, әни, нигә картаясың?», «Сагынам», «Таң җыры», «Зинһар өчен, кермә төшләремә...», «Чаба поезд, чаба» кебек лирик тезмәләр нәкъ шулай – язганда ук, билгеле бер аһәңгә йөз тотып иҗат ителгәннәр кебек тоела.

Р. Вәлиев сүзләренә күренекле композиторлар Р.Яхин, Ә.Бакиров, И.Шәмсетдинов, М.Яруллин, Ф.Әхмәтов, Р.Кәлимуллин, Л.Батыр-Болгари, Р.Әхиярова, М.Шәмсетдинова, Р.Абдуллин, Ш.Тимербулатов, Л.Хәйретдинова көйләр язалар. И.Шакиров, Ә.Авзалова, Х.Бигичев, З.Сөнгатуллина, В.Ганиева, Р.Ибраһимов, Р.Сәхәбиев, Р.Ибраһимова, А.Фәйзрахманов кебек танылган җырчылар башкаруында алар популярлык казана.

Балалар өчен шигырьләр – Р.Вәлиев иҗатының зур бер тармагы. Иң кечкенәләр өчен дә («Уенчыклар», «Санарга өйрәнгәндә», «Барысын да яратам», «Йокла, энем!», «Елаудан үзе туктады» һ.б.), урта яшьтәгеләргә адресланган шигырьләр дә («Соңгы кыңгырау», «Туган ягым», «Без – кояш балалары», «Май кояшы», «Кояш кебек» һ.б.)

[8] Вәлиев Р. Гашыйк булгач // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 36 б.
[9] Вәлиев Р. Мәхәббәт // Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда. 1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962-2006). – Казан: Татар. кит.нәшр., 2006. – 62 б.

бар аның иҗат хәзинәсендә. «Безнең диңгез»дә беренче тапкыр үзе идән югач, ак күбек белән тулган өй кызга диңгез булып тоела; әнисе дә әтисенә хәлне шулай аңлата! Яки елак кыз, үзе үсеп, елаудан туктый («Елаудан үзе туктады»), киреләнгән сеңел дә – апасы тарафыннан көндез генә начар, йоклаганда бик әйбәт дип бәяләнә («Минем сеңлем»), ә инде сыердан куркып качкан малай үзен аңа юл биргән тәрбияле бала дип күзаллый («Тәрбияле малай»). Бала психологиясен юморга әйләндерү осталыгы («Кыярга кырау төшә», «Безнең диңгез», «Үпкәләгән»), бала фантазиясенә тәңгәл образлылык («Кышкы йокы», «Тегермән») Р.Вәлиев шигырьләренең нәни укучысына якын булуын тәэмин итә.

***

Язучының чәчмәдә беренче тәҗрибәләре татар прозасына үзенчәлекле каләмгә ия, моңа кадәр татар әдәбиятында ачылмаган сурәтләү сукмаклары табарга сәләтле әдип килүен күрсәтеп тора. Психологик анализга тартылып, кешене чиктәш халәттә: үлем алды саташуы («Яшисе килә», 1978-1979), акылдан язу («Эт кояшы», 1968), хакыйкатькә төшенү («Иске сәгать дөрес йөри», 1981) баскычында тасвирлап, беренче повестьларында әдип шәхес-җәмгыять проблемасын үзәккә куя һәм аны фәлсәфи аңлатуга ирешә. Аның әсәрләренә бәя биреп, Т.Миңнуллинның «Сәер кешеләрнең күпләр төшенеп бетмәгән якларын укучыга күрсәтә»[10] диюендә хаклык бар.

Фәлсәфи-психологик характерлы «Эт кояшы» повесте, вакыйгалылыктан бигрәк, вакыйга ярдәмендә тормыштагы бер ситуацияне шартлы модель дәрәҗәсенә күтәрә. Әсәр башында ук аны укырга ике ачкыч китерелә. «Ма фәгалтум би Йосыф?» (Йосыфны нишләттегез?) эпиграфы татар укучысына мәгълүм исем аша әсәрне Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы белән тоташтыра, үзәк геройга бәя булып яңгырый, әсәрнең төп концепциясен билгеләп куя. Повестьның исеме исә эт кояшы – ялган кояш мәгънәсендә аңлашылып, эпиграфтагы сорауның кешене әйләндереп алган тирәлеккә, җәмгыятькә юнәлгән булуын искәртә.

Вакыйгалар катламы шушы ишарәләрнең дөрес аңланылуын дәлилләп килә. Нечкә күңелле, кызганучан, башкаларга яхшылык кына теләүче, үзе дә тормыштагы гаделсезлекләрне төзәтергә әзер төп герой Ирек тормышта әлләни зур каршылыкларга очрамый да кебек. Алданган кызга – Әминәгә өйләнүе, көндәлек тормыш вакыйгалары, малайлары туып, Әминәнең үлүе кебек үсеп барып, вакыйгалар Ирекнең акылдан язуына китерә. Алар, нигездә, ялгызлык фәлсәфәсенә иллюстрация. Кешегә дошмани тирәлектә Ирекне аңлар, хәленә керер кешеләр бик аз. Тулаем усал тормышта һәр кеше үзе өчен көрәшә. Җәмгыятьнең шәхесне рухи юк итүен раслау кебек билгеләнгән экзистенциаль фәлсәфә, беренче чиратта, вакыйгалар бирелешеннән үсеп чыга. Ул ретроспекция ясап тасвирланган гарип бәбкә күренешендә тагын бер кат кабатлана.

Хикәяләү психологик тирәнәйтелеп, чиктәш халәттәге Ирекнең аң агышы, эчке монологлары, җан диалектикасы төсендә тәкъдим ителә. Ул әсәрнең исеме белән ассоциациягә керә һәм төп фәлсәфи фикер, концепция түбәндәгечә: тормышта кыйммәтләр үзгәргән, урыннарын алышкан, кешеләр ялгыш күзаллаулар белән яшиләр. Бу фикер Ирекнең балачагыннан китерелгән түтен күренешендә дә кабатлана. Кечкенә малай, авыл өйләрендә мичкә якканга күрә, кояш чыкмый дип уйлый, моны хакыйкать дип ышана («Янәсе, һәркем, үз җылысы турында кайгыртып, бөтен кешеләргә начарлык эшли, уртак кояшны каплый»[11]). Әлеге мисалда үзгәрешсез хакыйкать булмавы, кешенең тормыш-яшәешкә карашлары ялгыш булу мөмкинлеге тагын бер кат ассызыклана.

«Кеше рәхимсез» дигән нәтиҗә чын матурлыкның, чын мәрхәмәтлелекнең тормышта ясалма – мәсәлән, сәнгатьтәге – матурлык белән алыштырылуына кагылышлы ясала. «Әле көндез генә урмандагы иң зифа каенны эһ тә итмичә җиргә егып салган агай кич театрга

[10] Миңнуллин Т. Талантлы буынның бер вәкиле // Р. Вәлиев. Мәхәббәт һәм нәфрәт:: шигырьләр, повестьлар, истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. –10 б.

[11] Вәлиев Р. Эт кояшы // Р. Вәлиев. Мәхәббәт һәм нәфрәт:: шигырьләр, повестьлар, истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 329 б.

килеп, каен булып бизәнгән, чибәр дигән аты да чыкмаган кызның уйнавына сокланып, нигә суган суы сыгып утыра?». «Алар үзләренең чын йөзләрен яшерәләр һәм шуңа күрә, бер генә минутка булса да, бу түбәнлекләрен онытып тору өчен сәнгать, әдәбият, музыка дигән матур исемнәр астында яңа дөнья, яңа кеше яратмак булалар, шул уйдырма дөньяга, шул уйдырма геройларга табыналар, үзләрен Аллага саныйлар, даһи дип атыйлар»[12].

Икенче нәтиҗә сәламәт һәм авыру кешеләрнең «урыны алмашыну» кебек шәрехләнә. Әлеге ике фәлсәфи фикер Ирек язмышы мисалында тагын бер кат игътибар үзәгенә куела. Ирекнең үз эчендәге каршылык ярату белән кызгану чикләрендә тирбәлә. Тирә-юньдәгеләр Ирекка Әминәне кызганып өйләнгән дип карыйлар. Ирек исә кызны ярата. Бу каршылык Иректә, гомумән, кызгану сәләтенең төп сыйфат итеп бирелеше аша тирәнәйтелә. Зиратта Ирекнең, хатынының үлемендә үзен гаепле санап, «хатны укымадым» дип кычкыруы (әйтерсең, шулай итеп аны тормышка кайтарырына ышана!), аны югалтуны күтәрә алмыйча, авырып китүе бу мәхәббәтнең чын булуын искәртә.

Шуның белән янәшә, каршылыклы төстә, Ирекнең эш-гамәлләре кызгану ноктасыннан да аңлатылыш таба. Чөнки әсәрдә үзәк урынны алып торган эчке монологта проблема башка яссылыкка күчерелә. Ул монологта берничә фикер калкытып куела һәм әсәрне аңлау кырын киңәйтеп җибәрә. Беренчедән, ул Ирекнең Әминәгә игътибары, өйләнүе үзенең аң төпкелендә кызгану нәтиҗәсе кебек бәяләнгәнлекне күрсәтә. Икенчедән, Ирек кебек («пәйгамбәр» амплуасындагы) кешеләрнең барлык эш-гамәлләре кызганудан килеп чыкканлыкны ассызыклый. Өченчедән, кызганып ясалган адымнарның башкаларны бәхетле итмәвенә киная ясый. Дүртенчедән, монологның ахыры Ирекнең соңрак акылдан язу сәбәбен тагын бер кат күрсәтә. Гомумиләштергәндә, кызгану сәбәпле кылынган яхшылыклар, кызганганга эшләнгән эш-гамәлләр җинаять дәрәҗәсендәге ялгышлык, хата кебек шәрехләнә. Шулай итеп, аң төпкелендә Ирек Әминәгә кызганып өйләндем дип саный, аларның үзара аңлашып бетә алмау сәбәбе дә – шунда. Ләкин ул кызны ярата. Акылдан язуның асылы да Ирекнең Әминәне югалткан мизгелдә шушы хакыйкатькә төшенүе белән бәйле.

Язучы әсәрдәге фәлсәфәне ике төрле «уку» мөмкинлеге калдыра. Һәр икесендә дә дошмани тирәлектә яшәүче шәхеснең ялгызлык фәлсәфәсе соңгы нокта булып тора. Аңа каршы мәхәббәтне кую мөмкинлеге сиземләнә, чалымлана. Ә инде повесть үзе татар әдәбияты барышында беренчеләрдән булып, тоташ аң агышы кебек хикәяләүне кулланган модернистик әсәр буларак бәяләнергә хокуклы.

«Иске сәгать дөрес йөри» повесте да шушы юнәлештә язылган. Төп герой Искәндәр – нечкә күңелле, кешеләргә яңа дөньялар ачарлык музыка иҗат итү хыялы белән яши торган ир. Язучы шушы хыялның – көнкүреш мәшәкатьләренә бәрелүен ир тормышындагы гадәти булмаган аралыкта – ирне хатыны Сөмбел һәм кызы Ләйсән ташлап киткәннән соң искә төшерелгән күренешләрдә сурәтли. Тирән психологизм белән сугарылган хикәяләү төп геройның хакыйкатькә төшенүенә килү юлын күзәтә, озатып бара. Яшәүнең максаты – көй иҗат итү, моңа бернәрсә дә комачау итмәскә тиеш дип санаган Искәндәр тормыштагы иң гади һәм үзе өчен мөһим мөнәсәбәтләрне кадерләми башлаган. Бу мөнәсәбәтләр арасында мәхәббәт тә, баланы ярату да, дуслык та, ярдәмчеллек тә бар. Әсәр ахырына Искәндәр шул мөнәсәбәтләрдән башка максатка ирешү – музыка иҗат итү дә мөмкин түгеллеккә төшенә. Чөнки кеше өчен иң кадерлесе – туганлык җепләре, гаилә икән. Повесть исеменә чыгарылган сәгать, вакыт агышын белдерүдән тыш, шуны символлаштыра. Әсәр башында «ютәленнән буылган карт сыман гыжылдаган» иске сәгать, хатыны белән кызы янына юл тоткан Искәндәрнең хакыйкатьне аңлавын хуплап, төп фикерне тагын бер кат ассызыклый: «Әйе, бу анның өендәге сәгать, бабасыннан калган борынгы сәгать иде. Ул, бар дөньяны яңгыратып, төнге уникене суга башлады. Ләкин элеккечә буылып-буылып, гыжылдый-гыжылдый түгел, ә илаһи музыка авазлары таратып, ярсый-ярсый суга иде. Искәндәр бу илаһи

[12] Шунда ук. – 359 б.

музыканың сәгать сугуыннан түгел, үз күңеленнән агылып чыкканын аңлап, һушсыз калды. Күзләрен күккә төбәп, әкрен генә пышылдады: «Бабай сәгате терелгән. Борынгы сәгать терелгән. Иске сәгать дөрес йөри!»[13].

Иске сәгать символының тагын бер мәгънәсе төсендә, язучы кешенең, уңышка ирешү өчен, милли яшәү рәвешен, милли тарих-мәдәният белән бәйләгән тамырлардан аерылмау шартын калкуландыра. Повестьта тудырылган образ гаҗәеп кызыклы. Ул татар әдәбиятындагы музыка белән холык-характер янәшәлеген тудыра алган иң гүзәл әсәрләрнең – Г.Рәхимнең «Идел» (1923), Ә.Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе» (1975), Ш.Хөсәеновның «Мәхәббәт сагышы» (1964) повестьларының дәвамчысы булып кабул ителә.

Повестьның үзәгендәге интеллектуаль-психологик эксперимент яшәүнең мәгънәсен, бигрәк тә, талантлы кешенең тормышта үз урынын эзләвен ачыклауга багышлана. Язучының бу мәсьәләдәге позициясе Искәндәрнең Хәмиткә әйткән сүзләренә салынган: «Җирдә туган җан иясе җирдә яшәргә тиеш. Күккә хыял белән генә менәргә кирәк, күңел белән, җан белән генә. Шекспирлар, Бетховеннар кебек. Галәмгә синең гәүдәң түгел, рухың кирәк. Тимер-бетон йортларга караганда, җан җылысы күбрәк кирәк кешеләргә. (…) Кеше иң элек үз күңеленең ап-ак өен салырга тиеш»[14] .

Әлеге ике повесть арасында язылган «Яшисе килә» хикәяләү ягыннан алар белән бер юнәлештә: ул тормышны үлем алдындагы герой саташуларында тергезә. Әмма повестьның герое башка тип кеше – хәрби хезмәттә шартлаган гранатаны үз гәүдәсе белән каплаган Рифкать Миргазизов, көчле ихтыярлы, гаделлекне бар нәрсәдән өстен куючы, акыллы-тәрбияле, «дөрес» егет. Аның саташулар, истәлекләр агышы 19 еллык гомерендәге иң мөһим нокталарны калкуландыра. Шушы агышта татар тормышы, башкалар мәнфәгатьләрен алга куеп яшәүчеләрнең күзаллаулары, эш-гамәлләре күренә. Әйтерсең лә, язучы башкалар хакына үз гомереңне корбан итәр өчен нинди булырга кирәк дигән сорауга җавап эзли. Текстның чиктәш халәттәге герой саташулары кебек төзелүе исә укучыга гаять көчле эмоциональ тәэсир ясап, аны кызгану (яшь гомернең өзелүе өчен), үкенү (үлемне җиңеп булмау), горурлану (кешенең үз гомерен башкалар өчен корбан итә алуы; шул адымга барырлык яшьләр булу) кебек хисләр кичерергә мәҗбүр итә.

Башка повестьларыннан аермалы, героик пафоска мөрәҗәгать итеп язылган булса да, әсәрдә совет чынбарлыгына караган, уйландырырлык тәнкыйди фикерләр дә чагылып китә. Әйтик, болар Рифкатьнең әтисе улына авылдан китү сәбәпләрен аңлатканда күренә: «Әй, улым, үз ихтыярың белән йөрүмени ул. Нужа куып йөртте бит, нужа. Сугыштан соң, бәхет эзләп, ярты авыл шахта ягына кузгалды. Әниең белән без дә шуларга ияրдек. (…) Ярату гына түгел, чуар тавыкларына, урам этләренә кадәр сагына идем, төнлә төшләремә кереп тилмертә иде. Кан береккән, җан береккән инде безнең ул авылга. Ата-баба туфрагы бит»[15]. Яки Харис бабай болай дип ачына: «Шәһәр кешесе таш җанлыдыр ул. Утырып кала бит игеннәр, утырып кала. Әле бер тишек борыны авыз ерып көлеп торган була: «Кайгырма, бабай, ил зур безнең, хөкүмәт бай, монда иген булмаса, читтән китерерләр, мул җирдән», дип акыл сата»[16].

«Иске сәгать дөрес йөри» повестендагы совет чынбарлыгының җитмәүчелек, әшнәлек, кешегә сайлау мөмкинлеге булмау кебек мәсьәләләре, «Эт кояшы»ндагы руслаштыру сәясәте белән бәйле фикерләр (әсәрдә, хәтта, бу мәсьәләдә тарихи ретроспекция ясала – язучы Әминә исеменнән бабасының шушы сәясәт корбаны булып дөньяга килү тарихын сөйли) бер җепкә тезелә. Шулар ярдәмендә язучы укучы белән совет чорының милли һәм социаль сәясәте, кеше кадере булмауның тоталитар дәүләттә төп сыйфатка әйләнүе турында сөйләшә.

[13] Вәлиев Р. Иске сәгать дөрес йөри // Р. Вәлиев Мәхәббәт һәм нәфрәт:: шигырьләр, повестьлар, истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 260 б.
[14] Шунда ук. – 174 б.
[15] Вәлиев Р. Яшисе килә // Р. Вәлиев. Әсәрләр: 4 томда. 2 т.: Роман, повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 443 б.
[16] Шунда ук. – 467 б.

Интеллектуаль проза ярдәмендә әзерлекле укучы белән тормыш-яшәешнең катлаулы мәсьәләләре турында сөйләшү Р.Вәлиевнең «Мирас» (1983) романында аеруча калку. Роман исеменә чыккан төшенчәне язучы төрле яклап шәрехли һәм аның һәр өлкәдә әһәмияте хакында уйландыра. Роман үзе дә – төрле әдәби юнәлеш һәм агымнардан мирас булып килгән язу рәвешен, алымнарны трансформацияләп, яңача куллануның матур үрнәге кебек килеп чыккан. Полемика, бәхәс төсендә сюжет бирелеше татар әдәбияты өчен яңа булган бу роман интеллектуаль поэтика белән психологик прозага хас эстетиканың синтезына нигезләнә. Хикәяләү исә фикер агышына, тормышны акыл белән танып-белүгә буйсындырыла.

Гадәттә, мондый әсәрләр классик әдәбиятка оппозициядә, әдәби стереотиплар белән уйнап һәм алардан баш тартып языла. Бер яктан, чынбарлык – детальләштереп тасвирлана. Икенче яктан, автор позициясе, үгет-нәсихәт укудан баш тартып, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни-әхлакый мифларны җимерүгә хезмәт итә, әмма сурәтләнгәннәргә бәя бирми. Полемик проза укучыны аңа көчләп тагылган идеологик догмалардан, иллюзияләрдән азат итә.

Тормыш моделенең тудырылу рәвеше, төп герой бирелеше, сюжет-композиция хасияте һ.б. яклары белән роман соцреализмның төп сыйфатларын искә төшерә, бер үк вакытта әсәрнең идея-эстетик асылы бөтенләй башка нәтиҗәгә – тормышның күптөрлелеге һәм күпкырлылыгы, кешеләр хакыйкатенең, каршылыклы һәм төрле булган хәлдә, бердәм тормыш-яшәеш агышын хасил итүе хакындагы фикергә алып килә.

Романның үзәк герое Ихтыяр – гомум мәнфәгатьләре белән яшәүче, булдыклы хезмәт кешесе, бар яклап үрнәк егет. Хәтта исеме дә әсәр эчендә тагын бер тапкыр шушы кысаларда уйнатыла: «төзелешкә ике генә нәрсә кирәк: төзү материалы һәм ихтыяр көче» дигән сүзләр ихтыяр төшенчәсенең, төп герой исеме белән ассоциацияләшеп, аерым шәхес сыйфатлары тупланмасы кебек тә аңланылу мөмкинлеге тудыра.

Ретроспекция ясап искә төшерелгән, студентлар отрядында колхоз председателе белән бәрелешүдән алып, шәһәр төзелешендә эшли башлагач килеп чыккан авырлыклар белән очрашулар – барысы да Ихтыярның тәвәккәл, кыю, акыллы, киң карашлы, киләчәккә йөз тотып яши торган, максатчан, эшлекле шәхес булуын кат-кат ассызыклый. Роман, асылда, шушы егетнең тормышта үз-үзен табу тарихын сөйли дә. Студентларның эшкә таралышу, шәһәрдә калуны яки читкә китүне сайлау кебек вакыйгалардан башланып китүе белән үк, әсәр совет чоры әдәбиятына аваздаш кабул ителә. Ә инде яшь егетнең яңа шәһәр төзелешенә эшкә килүе, урындагы күп кенә җитешсезлекләр белән күзгә-күз очрашуы, артка калган бригаданы алып, аны аякка бастыруы, бетон заводына реконструкция ясауга ирешүе һ.б. вакыйгалар шушы тәэсирне көчәйтәләр. Традицион производство романнарындагы кебек урындагы җитәкчеләрнең кәнәфи сакларга омтылуы, яшь кешегә таяныч булган беренче секретарь Рим Идиятович образы килеп керү, ахыргача максатчан була алмыйча, үз идеалларына хыянәт иткән Нурислам Фарукшин язмышы, әсәр яңа шәһәрдә үз урынын тапкан Ихтыярның рухи җиңүе белән тәмамлану да вакыйгалар катламының очраклы сайланмаганлыгына ишарә ясый.

Төп сюжет сызыклары бирелеше дә традицион совет чоры романнарын хәтерләтә. Иҗтимагый сюжет сызыгы Ихтыяр һәм аның фикердәшләренең яңа шәһәр, яңа тормыш төзүдә фидакарьлеген бер үзәк тирәсенә җыя. Совет әдәбияты өчен традицион романтик оппозиция: эш өчен янып йөрүчеләр һәм үз мәнфәгатьләрен өстен куючылар каршылыгы үзәктә тора. Ярдәмче сюжет сызыгы егетнең мәхәббәт тарихы кебек төгәлләшә. Ул мәхәббәтне дә кешеләр арасындагы фикерләр, омтылышлар уртаклыгына бәйле хис кебек аңлата.

Ләкин ярдәмче сюжет сызыклары традицион модельне тирәнәйтеп-ассызыклап килмичә, яңа әдәби күренеш хасил итеп урнаша. Башлап, Ихтыяр тарихына якын ике тарих – бабасы (Зыятдин бабай) һәм әтисе (Тимерхан) тарихлары, үзара чагыштырылып, тормышны өч төрле аңлату варианты кебек тәкъдим ителә. Әдәбиятта мондый күренеш

хакында сөйләгәндә, дискурс төшенчәсен куллану уңай. Әсәрдәге Зыятдин, Тимерхан, Ихтыяр дискурслары өч төрле аң, өч төрле идеологик нигез, өч төрле фәлсәфә һәм хакыйкать хасил итә. Бу дискурслар советкача, совет һәм постсовет чорын әзерләү пространствосында янәшә яшәп килүче дөньяга караш булып гомумиләшә. Аларны язучы әсәр буенча урнаштыра һәм материал совет идеологиясендәге гомумбилгеле стереотипларны файдаланып, шуларны кире кагу төсен ала. Язучы шулар ярдәмендә совет чоры идеологиясендәге мифларны юкка чыгара.

Мәсәлән, Ихтыяр ике позицияне башта ук ачыклап куя: «Ә бабай… бөтенләй башка. Нигә алай икән? Бер карасаң, аның уйлары да, максаты да зурдан түгел сыман… Җирдәге һәр кеше үз өендә, үз ишегалдында, үз бакчасында тәртип урнаштырырга тиеш, ди ул. Җирдәге һәр кеше бәхетле булса, ил дә бәхетле була. Әтисе, киресенчә, иң элек ил кайгысын кайгырта, бөтен илдә берьюлы тәртип урнаштырмакчы була»[17].

Алга таба карашлар каршылыгын ассызыклап бару дәвам итә. Мәсәлән, карт Тимерханга болай ди: «Чатыр чабып дөнья куарга өйрәнгән кешеләр шул сез. Өстән кушканга гына йөрисез, план тутырыр өчен генә. Кеше күңел кушканны эшләргә тиеш, кеше кушканны түгел. Шунсыз кылган эшеңнең мәгънәсе дә, кадере дә булмый»[18]. Һәм күмәк хуҗалыкка сүзне күчереп, өстәп куя: «Акыллы хайван зур көтү белән йөрми ул». «Өстән кушкан – күңел кушкан» каршылыгы совет чоры әдәбиятында еш очрады. Романда автор аны традицион, кешеләрнең әхлакый үсеш дәрәҗәсе белән бәйләп түгел, бәлки, идеологик төрлелек ноктасыннан шәрехли.

Ихтыяр дискурсы, беренче чиратта, егетнең эш-гамәлләрендә ачыла. Үзәк герой авырлыклар алдында туктап калмыйча, эш өчен тырышуы, үз идеяләрен тормышка ашыру өчен барысын да эшләве белән матур. Ихтыярның иң зур уңышы – яңа шәһәр эчендә авыл атмосферасын, авылның үзен саклап калуы исә Зыятдин белән Тимерхан бәхәсендә үзәк мәсьәләләрнең берсе булган «искене җимереп яңаны салу, яки искене саклау» каршылыгына яңа чишелеш варианты бирә. Искене саклап, яңаны төзү фәлсәфәсе яңа буын фәлсәфәсе, автор идеалы булып аңлашыла.

Бу фәлсәфә Нурислам һәм Ихтыяр сөйләшүләрендә төгәлләшә. Сөйләшүләрдә совет тәртипләренә, идеологик стереотипларга тәнкыйть аермачык. Нурисламның: «Безнең сүз – закон! Безнеңчә уйламаган, безнеңчә яшәмәгән кеше – искелек калдыгы. Менә бу авыллар да искелек калдыгы. Аның хәзер безгә кирәге бетте. Без аны төбе-тамыры белән себереп түгәбез дә тап-такыр мәйданда яңаны корып куябыз…»[19], – диюе ирония булып яңгырый. Шунда ук әлеге идеологик законның ни өчен кирәк булуы, асыл мәгънәсе аңлатыла: «Чөнки такыр җирдә эшләү рәхәт, чөнки анда сиңа комачау итүче юк». Совет идеологиясендәге мираска караш мәсьәләсен Нурислам Ницшеның «властька омтылыш» фәлсәфәсе белән бәйли.

Шундый ук каршылыклы позицияләр әсәрне үтәли кисеп баручы сөйләшү-диалогларда калкытып куела. Иң беренче чиратта, бу бәхәсләр романның формаль яктан совет чоры романнары кебек бәяләнергә тиеш түгеллеген укучыга җиткерә. Форма ягыннан полифония күренеше иң әһәмиятле урынны алып тора һәм карашлар-фикерләр бәхәсе әсәрне җыйнаган лейтмотивка әйләнә. Сөйләшүләр күп кенә иҗтимагый проблемаларны ача һәм авторның тәнкыйди мөнәсәбәтен ачыклый.

Романдагы төп проблема – туган җирне, авылны саклау мәсьәләсе. Ул гаять киң, иҗтимагый, фәлсәфи, мәдәни яссылыкларда куела. Иҗтимагый яктан, авылларны су басу, аларның юкка чыгуы – заман, фән-техника прогрессы, тормышның үзгәреше алып килгән факт итеп бәяләнә. Ташлыяр авылының шәһәр эчендә югалуы, авылны күчереп саклап калу тасвирлану автор позициясен ачыклый төшә. Фәлсәфи яктан, язучы мөнәсәбәте каршылыклы, нигездә сызлану төсен ала. Бигрәк тә шофёр егет Фаил позициясе буларак

[17] Вәлиев Р. Мирас // Р. Вәлиев. Әсәрләр: 4 томда. 2 т.: Роман, повестьлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. – 58 б.
[18] Шунда ук.- 57 б.
[19] Шунда ук. – 115 б.

белдерелгән фикерләр үткен, тәнкыйди, ачынулы. Авылларның югалуы – милли мәдәниятнең югалуы, милли менталитетның югалуы, традицияләрнең, димәк, мирасның югалуы ул. Шуңа да язучы әсәр эчендә шушы хәлдән чыгу юлларын эзли. Ахыр чиктә, аның аерым кешегә бәйле икәнен белдерә. Һәр кешенең күңелендә туган җир каршында җаваплылык тойгысы була икән, туган җир яши дигән сүз. Җаваплылыкны язучы, хәтта, ирек һәм азатлык төшенчәләреннән дә югары күтәрә. Туган җирне саклау, яклау – һәр кешенең изге бурычы дигән фикер әсәр буенча җемелдәп бара.

Мәдәни яссылыкта, авылларның югалуы милләткә куркыныч яный торган күренеш итеп аңлатыла. Кешенең рухи байлыгы, җан җылысы, күңел юанычы югалу икәнлегенә басым ясала. Мәсәлән, авыл язмышы хакында Ихтыярның «сукыр эчәк сыман кисеп атмакчы булалар аны» диюенә, Зыятдин карт «кешеләрнең бәгырен кисеп ташларга җыеналар» дип җавап кайтара. Мондый бәяләр әсәр эчендә кабатланып бара. Туган җирен, авылын югалтканнарның буш, нигезсез, мәсләксез калуы искәртелә. Авылны югалту – тарихны югалту – акылны югалту чылбыры үстерелә, җиде буын бабайны белмәү белән бәйләп – милләткүләм мәгънә ала.

«Мирас» сүзе – әсәрне аңлау, бәяләү өчен төп ачкыч. Ул башлап әсәрдә әһәмиятле урын тоткан тегермәнгә карата кулланыла, шунда ук мирас – һәр кешенең үзеннән соң эз калдыруы, яшәү мәгънәсе дигән фикер укыла. Әсәрдә һәркемнең мирасы булу ачыклана бара. Тимерхан – авылны торгызган, төзегән, яңарткан, Ихтыяр – яңа шәһәр төзүче һәм шунда ук авылны саклап калуда үз өлешен керткән. Хәтта икенчел пландагы геройларның да «мирасы» аерым вакыйгаларда бик матур уйнатыла. Архитектор Урманов шәһәргә Энҗе тукталышы бүләк итә һ.б.

Совет чоры мирасына, совет идеологиясенә караш мәсьәләсенең турыдан-туры күтәрелүе ягыннан да роман милли әдәбиятта яңа сүз булып кабул ителә. Язучының төп герое Ихтыяр – постсовет чорына күчәчәк буын вәкиле. Аның фәлсәфәсе, дөньяга карашы – асылда постсовет заманыныкы. Роман «без бүген яши торган заманга нинди мирас белән күчтек, постсовет чорында мәйдан тота торганнар нинди шартларда чыныкты, узганнарны ничек бәяләргә?» дигән һәм башка бик күп сораулар хакында уйландыра. Ә инде синтетик характерлы булуы, төрле иҗат агымнарына хас алымнарны уңышлы куллануы ягыннан, ул татар әдәбиятында яңа күренеш хасил итә.

«Милли мәнфәгатьләр Разил Вәлиев тормышының төп мәгънәсен тәшкил итә»[20] дигән сүзләр аның үзфикерле сәясәтче, оста оештыручы буларак эшчәнлегенә генә түгел, бәлки әдәби иҗатына да карый. Әдип тормыш фәлсәфәсе һәм иҗтимагый фәлсәфәнең төрлелеге нигезендә, ачыктан–ачык тәнкыйть яки көлү юлына басмыйча гына, төрле идеологик контекстлар белән уйный һәм уйландыра белә.

Публицистика Р.Вәлиев иҗатының зур бер катламын тәшкил итә. Көн кадагына суккан үткен проблемалы мәкаләләр белән бергә, бу катламда әдәби-публицистик характерлы – милләт-халык язмышы, татар теле һәм әдәбияты, тарих һәм мәдәният, аерым шәхесләрнең мирасы һәм эшчәнлеге турындагы иҗтимагый-фәлсәфи уйланулар белән сугарылган күләмле язмалар, гамьле интервьюлар зур урын алып тора. Күп кенә иҗат портретлары эссе жанрына якыная («Уйлый торган йөрәк» (2001), «Туфрактан яралган Туфан» (2010), «Кунак булып килде, хуҗа булып китте» (2004), «Илаһи моң иясе» (2005) һ.б.)

Р.Вәлиевнең иҗтимагый эшчәнлеге һәм иҗаты турында төрле елларда олы әдипләр, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре – М.Ш. Шәймиев, И.Шакиров, Л.Ошанин, А.Гыйләҗев, Р.Мостафин, М.Мәһдиев, М.Хәсәнов, Н.Фәттах, М.Госманов, М.Галиев, Надир Дәүләт һәм башкалар матбугат аша уңай фикерләр әйттеләр.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

[20] Зәйдулла Р. Дулкын биеклеге // Казан утлары. – 2007. – № 1. – 145 б.

# ВАЕМЛЫ ЙӨРӘК АВАЗЫ

## РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛАГА – 60 ЯШЬ

Шигърият элек-электән сәнгатьнең иң югары, беренчел әһәмияттәге төре булып саналган. Аның әле язу уйлап табылмаган чакта ук яралуы, аерым алганда, әдәбият үсеше өчен бәрәкәтле җирлек әзерләве күпне сөйли. Алай гына түгел, шигърият халыкның фикерләү рәвешенә үтеп кергән, танып белүнең үзгә бер ысулына әйләнгән. Кемдер аны каныбызга көч-дәрт өстәүче корылмалы агымга тиңли икән, мондый гөман кешенең табигый ихтыяҗына  бәйле күренешкә ишарәт кыла. Җисемнең һәрбер кечтеки кисәкчегендә шигърият бар дию дә эстетика тойгысына ышаныч бирә шикелле... Әйе, ошбу сәмави концептны һәрьяклап бәяләргә мөмкин. Һәрхәлдә, төрлечә белдерелгән раслауларда шигъриятнең олуглыгы ачык күренә.

Үзеннән-үзе аңлашыладыр, һәрбер заман шагыйрьләре җәмәгатьчелектә чагыштырмача калкурак урында торган. Алар әдәбият башлангычында да хәлиткеч вазифаны башкарган, гасырлар дәвамында рыцарьларча тезелеп, тарихи сынау вакытында да алдагы сафларга баскан. Борынгы юнаннар шагыйрьне пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәргән. Узган гасырның сиксәненче елларында татар шигъриятенә килгән Ркаил Зәйдулла шушындый бөек миссиягә алынуын барча тирәнлегендә күзаллап җиткердеме икән?! Бүгенгесе күрсәткәнчә, җаваплылыкны, асылда, чамалагандыр.

Күптәннән күзәтеп баруымча, Ркаил Зәйдулла үз-үзенә инде яшьли зур максат куйган, шуңа үҗәтлек белән ирешергә омтылган шәхесләр җөмләсенә керә. Әле сигез яшендә үк ул иҗатка юнәлеш ала. Димәк, егет алдан аяк киенүнең хәерлерәк буласын тоя белгән. Хәтерлим, «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенең әдәбият һәм сәнгать бүлегендә эшләгәндә Чувашстанның Комсомол районы Чичкан авылы мәктәбе укучысыннан хатлар килгәләде. Конверт эчендәге шигырьләр гаҗәпләнерлек дәрәҗәдә җитдилеккә тарта, гүя аларны тәҗрибәле сыйныф җитәкчесе язып биргән. Югыйсә «Яшь ленинчы», «Ялкын» кебек балалар матбугаты бар – ник Ркаил Зәйдуллин тәүге әсәрләрен шушы басмаларга юлламый?! Партия газетасына ияләнүен күрче! Тора-бара аңлашылды: бу «сентименталь малай» уй-хисләрен вундеркиндча кәгазьгә төшерә бит.

Беркем инкяр кылмас, яшьлек елларында чын-чынлап тәҗрибә туплый башлау иҗат әһеленә иртәрәк җитлегергә мөмкинлек бирә. Шәхси карашларны ныгыту өчен дә нәкъ менә шундый зәмин кирәк. Ә тотрыклы инанганлык кыйммәтеннән башка, гомумән, сәнгать эшчәнлеген күзаллап булмый да. Милли гамьнең мөкатдәслеген әле «ваемсыз» мәктәп чорында ук аңлаган Ркаил, әлбәттә, Казан дәүләт университетында үзенең мәсләгенә ярашлы яңа гыйлем офыкларын ача. Җитдилек аңкып торган шигъри әсәрләрен республика көндәлек матбугатында даимән бастырып чыгарырга да җай таба, шулай ук Сибгат Хәким, Нури Арсланов кебек олпат шагыйрьләрдән остазлык дәресләре алырга да өлгерә. Хәтта күпне кичергән классик Хәсән Туфанның өендә чәйләп утыра, беркадәр соңрак хастаханәгә эләккән аксакалның хәлен белергә дә барып килә. Күрешкәндә, Туфан талип белән «Әс-сәлам, Чувашстан!» дип исәнләшә. Барысына да җитешү  һичшиксез эз калдыра. Унҗиде яшендә «Казан утлары» журналында беренче шәлкемен тәкъдим иткән егет инде шигъриятнең шактый катлаулы лиро-эпик төренә кергән поэмалар язарга тотына. Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев та аның «ашкынып үсү»енә чиксез соклануын белдерә һәм Ркаил Зәйдулланың «Кояшлы күзләр» китабындагы  кереш мәкаләдә ихлас күңелдән

ошбу фикерен җиткерә: «Егерме ике яшьлек студентның әйтер сүзләре заманча кыска, саллы, үтемле».

Тәҗрибәле элгәрләребез кабат-кабат искәрткәнчә, шагыйрь булып тумаган кеше андый дәрәҗәгә ирешә алмас. Беркайчан да... Чагыштырып караганда, игътибар үзәгендәге героебыз Ркаил Зәйдулланың вөҗүденә шагыйрьлекнең илаһи оеткысы җитәрлек микъдарда салынган. Бусы аеруча мөһим. Алдарак әйтеп үтелде. Шигърият башка сәнгать төрләренең һәркайсы элементын үзендә туплаган. Димәк, Аллаһның рәхмәте белән мондый талантны күңелендә тамырландырган шәхес иҗат кырының бүтән тармакларында да көчен сынарга сәләтле. «Рух рыцаре»на тиңләнгән затның эчке мөмкинлекләре гаять зур.  Кагыйдәгә әйләнгәнчә, байтак муза тарафдарлары ныклы рәвештә җирдә басып тора, яхшы шагыйрьгә исә иксез-чиксез биеклеккә күтәрелергә туры килә. Шушындый үзгәрәк вазифа. Чынлыкта Ркаил Зәйдуллага да бу нигъмәт насыйп кылынган. Дөрес, «Ташларгамы җанны...» дип башланган шигырендә ышанычка кергән егет тыйнаклык күрсәтә: *«Бик гадәти шул мин – Җир малае...»* Әмма «Каләм турында баллада»сында шагыйребез газамәтле йөкләмәсен таный. Безнең кулыбызга язу коралы тикмәгә генә бирелмәгән ләса.

*Сиңа орыну – бөек җаваплылык!*

Тормыш раслап тора: тыныч холыклы затлардан язучы сирәк чыга. Җанын мамыкка ураган бәндә янып яшәүдән бөтенләй мәхрүм. Моны чынбарлык кистереп әйтә. Кемгәдер гадәти тоелган басынкылык та чын шагыйрьләрнең табигатенә һичничек килешми. Ә менә һәрдаим бимазалаган ваем Ркаил Зәйдуллада артыгы белән бар. Ул туктаусыз көяләнүчән натурасын иҗатында да сиздереп үтә. Мәсәлән, «Булмый елап» исемле шигырьдә балачак еллары искә алына. Алты яшьлек малай кыю адым ясый. *«Мин – иярдә!* – дип аваз сала ошбу нәни җайдак. *– Ат өстендә беренче кат. / Талгын гына аккан каным, уян!»* Күрәсезме, орчык хәтле олан да үз канының уянуын тели. Спарталы кебек кылана. Беркадәр вакыт узганнан соң ул элгәрләренә мөнәсәбәтен белдерә. Анысы «Нигез» дигән әсәрдә: *«А, тынгысыз нәсел... / Шул токымнан – сәер нәселдән мин,  / Кан да шул ук, шул ук – ярсулы!»* Башка рухи халәткә авыша баруын яшүсмер ихластан аңлатып та китә.

*Битараф идем дөньяга,*
*Тыныч иде җаным;*
*Йөрәгем дә болай типми,*
*Кызмый иде каным.*

*Күп йөри алмадым әмма*
*Гамьсез күзләп айны...*
(«Битараф идем...»)

Тынгысызлык... Гадәттә, мондый халәттән чыкмаучы зат үзенә дә, шулай ук башкаларга да тынгылык бирми. Әле дә истә, шактый активлашып киткән студент Ркаил Зәйдулланың «Казан утлары» журналында саллы шәлкеме басылгач, авторны күреп белүче каләмдәшләре арасында яшь шагыйрьнең шушы үзенчәлегенә игътибар итүчеләр булды. «Яратам мин бу малайның шигырьләрен, өметем зур ул егеткә, – дип язды Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин. – Мин аңарда иҗат кешеләренә иң кирәкле сыйфат – тынгысызлыкны күрәм. Җаны тынгысыз аның, яшьлеккә хас бунтарьлыгы да бар. Бик әйбәт!»

Һәрдаим тәкрарланган хакыйкать: язучының осталыгы, ахыр чиктә, аның стиле белән билгеләнә. Каләм әһеленең әдәби өслүбе исә шушы шәхеснең табигатенә турыдан-туры бәйле. Әйе, борынгы Кытай телмәте Деметрий әйтеп калдырганча, сүз сәнгатенең теләсә нинди әсәрендә иҗатчының психик үзенчәлекләре чагылыш таба. Хәер, татарның мәшһүр Тукае да бу хакта үзенчә уйлаган. «Әсәр «эз» булса, – ди ул, – мин аның арысланмы, куянмы эзе икәнен ачык белә алам». Шанлы элгәрләребез дәвамчысы Ркаил Зәйдулланың язганнарында исә аның башкаларныкына охшамаган холык-фигыле ап-ачык ярылып ята. Алардагы мантыйкый чагылманы инде «куян эзе» генә димәссең.

Сүз дә юк, холык буыннар ераклыгыннан ук, кан тирәнлегеннән башлангыч ала. Анасы карынында тибенеп яткан нарасый, һичшиксез, гаиләдә тиктормас олан булып үсәчәк. Эчке табигатьнең калыплашуы өчен, әлбәттә, даим хәрәкәтләнү омтылышы кирәк. Ркаил Зәйдулланың балачак турында сөйләүче шигъри хатирәләрендә холыкфигыльнең аерым рәвешкә керүе бик ачык чагыла. Мәсәлән, «Бабай» дип исемләнгән шигырьдә шактый гыйбрәтле хәл – бер төркем малайларның алма урлавы тасвир ителә. Соңыннан ачыклана: ошбу кызыктырып торган бакча лирик геройның бабасыныкы икән! Иртән әлеге зирәк аксакал оныгына алсу алма суза...

Рәхим итегез, булачак шагыйрьнең прототибын хәтерләтүче әлеге оланкай үзенең күңел катламнарындагы яңа үзенчәлекләрне күрсәтә. *«Никтер шушы кырмыска оясын / Таяк тыгып болгатасы килә...»* Корткычлык гамәленә тарткан ошбу теләк «Вәхши» дигән шигырь ахырында белдерелә. «Көтүче малай» исемле әкият-поэмада исә ул Актырнагы белән... мунчада чабына. Болай кыландырганнан соң, янәсе, эт усаллана төшә. Нәни хуҗа туктап калмый, ныграк өреп торсын өчен аның койрыгын да кисә... Мисаллар байтак җыела. Холкын әкренләп утырта баручы шук-чая героебыз әбисенең үгет-нәсихәтен искә төшергәләп ала. Әнә, «Тау елгасы» әсәрендә дә моны дәлилләгән юллар бар:

*Әби! Әби! Ишетәмсең?*
*Кул болгап кала идең.*
*«Йөрәгең тулып ташса да,*
*Тыйнак бул, – дип, – тыйнак бул».*

.......................................
*Тыйнак булулары кыен,*
*Йөрәгең торса уйнап.*

Төпчеләп карасак, мисал рәвешендә китерелгән шигъри өземтәләр буенча җитлеккән шагыйрьнең халәте рухиясен тоемлап була. Әйе, «Ташларгамы җанны...» дип башланган әсәрдә Ркаил Зәйдулла тикмәгә генә белдермәгән: *«Мин үземә бик тә охшаганмын...»*. Аның язганы да тач үзенә охшый. Безнең татар телендә «холык» сүзенә «фигыль» кәлимәсе кушылу адәми затның психикасындагы эчке бәйләнешләр хакында искәртеп тора. «Фигыль» лексик берәмлегенә исә әүвәл «эш» мәгънәсе салынган. Иҗатны күзаллап әйткәндә, күңел тирәнлекләрендә ни-нәрсә кайнаса, чынлыкта шулар кәгазьгә түгелә. Алты яшендә ярсу атка атланып җилдерткән Ркаил уй-хиснең назым калыбына салмак агуына риза түгел. *«Инде шигыремә кер, яшен!..»* Әстәгъфирулла, «Төнге сабантуй» исемле багышлавында шагыйребез шулай мөрәҗәгать итә. Аңлашылганча, Ркаил Зәйдулланың рухи хәрәкәтчәнлек дәрәҗәсе башкаларныкы янәшәсендә шактый югары күренә. Бу кайнарлыкка ирешкән темперамент язганында ничек чагылмасын, ди!

*Ап-ак кәгазь.*
*Мин шигырьгә бүген*
*Күчермәкче идем ярамны...*

*Яздым-сыздым. Сыздым!*
*Кәгазь хәзер*
*Минем чырай кебек караңгы.*
(«Каралама»)

Күзәтүләр күрсәткәнчә, Ркаил Зәйдулланың шигырь һәм поэмаларында Такташыбызның исеме еш телгә алына. *«Һәммәбездә шул Такташлар каны»*, – ди ул гади генә аталган «Балта осталары» шәлкемендә. «Такташка баш ию исәбем...» – каләмдәш элгәрләре йогынтысыннан котылырга теләмәүче яшь дәвамчы «Койрыклы йолдыз» әсәрендә әнә шундый карарын белдерә. Аннары үзенең «Киләчәккә хат»ында гыйсъянчылык тарафдарына ачыктан-ачык эндәшә: «Сәлам, Такташ!.. / Томан эчендәге киләчәктә / Үз яныңнан урын калдыр син...»

Дөрес аңларга кирәк, Ркаил Зәйдулла тезмә иҗатында Һади Такташка тәкълит кылмый, аның әсәрләре инкыйлаби дәвер белән аваздаш түгел. Хәзерге чорның шагыйренә давыллы еллар җырчысының каләмне иркенлеккә җибәреп язуы, электән килгән гаруз вәзенен заманча үзгәртергә омтылыш ясавы, җанына салынган

тынгысызлык очкынын гыйсъянчы утына әвереләдерә алуы, халкыбыз тәрәккыенә багышланган кыска гомерендә һәртөрле «хулиганлык»лар эшләргә өлгерүе якынрак. Гадәттә, иҗтимагый алгарыш үзәгендә торган әдипне кешелек тормышының рухи прорабына тиңлиләр. Әлеге олуг вазифаны тиешле югарылыкта башкарырга теләсәң, үзеңне мәшһүр элгәрләр варисы итеп тоярга тиешсең. Бу җәһәттән төрек галиме, Эгей университеты профессоры Мостафа Өнәр ныклы буыннар эзлеклелегенең һичшиксез күркәм нәтиҗәләргә илтүен күрсәтеп үтә. «Төрк галәмендә яңарыш һәм җирләшү агымнарының татарлар арасында Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Туфан кебек көчле исемнәрне дөньяга чыгаруы бүгенге татар әдәбияты өчен дә сәламәт бер традицияне мәйданга китерде, – дип язды ул. – Шушы яссылыкта Ркаил Зәйдулланың шигърияте дә, асылда, ошбу зур әдәбиятның язма мирасына үз өлешен өсти».

Әле яңа дәвергә кадәр үк фикер ияләре катгый искәртеп торган: күңел утың янмый икән, синнән яхшы шагыйрь чыкмас. Әлбәттә, күңелдәге ут дигәндә, гамь-ваем күздә тотыладыр. Уйлавымча, таланты күктән бирелгән Ркаил мондый зарурлыкны яшьли аңлый, чөнки ул әлеге ут төшенчәсен шактый еш куллана. *«Янар өчен килдем дөньяга...»; «Очкын бар каләм очында, / Эч тулы гыйсъян утлары...»; «Мин янам, шатланам, газапланам, / Гаҗәп түгел – дөнья бу!..»* Автор «Кил, сөяклем», «Юл», «Мин янам» исемле әсәрләрендә укучысына үзенең «эчке янулы» иҗатчы булуын сиздереп куя. *«Читенрәк икән шашкын җанга /Җир йөзендә янып яшәве...»* Байтак сынауларны кичергән егет, «Күз яше» шигырен язып, әнә шулай көрсенеп ала. Вәләкин Ркаил Зәйдулла барыбер бирешергә җыенмый. Аның «Яна йөрәк...» дип башланган кыйтгасы гомерлек халәткә тугрылык саклау хакында сөйли: *Эчтән ярсыйм, / Эчтән янам. / Тынгы бирми миңа һаман / Элеккедән килгән ярам.*

Гадирәк кимәлдә аңлатсак, яну артында борчылу тора. Иҗатчы күңелендәге һәртөрле сызлану башлыча иҗтимагый мәсьәләләргә тоташа. Алар мөкатдәс милләт гаме булып, йөрәктә төенләнә, кардиограмма язуга әверелгәндәй, кайгыртулы мөһим уй-фикерләр ихтыярсыз ап-ак кәгазьгә агыла. Шагыйрь йөрәгенә уелганны QR-кодка тиңләргә мөмкин. Анда газиз халкыңны кыерсытырга теләгән груһка нәгърә ору да, Аллаһ тарафыннан яралтылган кавемнең хәләл хакын дәгъва итү дә, авыр хәлдән чыгуның әмәлләрен күрсәткән тәкъдим дә тупланыш тапкан. Ваемлы йөрәк авазы... Дөрестән дә, «Җир әйләнә...» дип башланган фәлсәфи шигырендә метафора остасы Ркаил Зәйдулла тулысынча хаклы: *«Йөрәк тирәсендә җыр әйләнә»*. Җырлар... Әмма алар күпчелек очракта моң-зарлы рухтарак килеп чыга. Әйтик, Колшәрифнең соңгы җыры яу кырында түгелгән кайнар каны белән, Муса Җәлилнеке исә «палач балтасына башны тоткан килеш» язылган. Үз-үзенә «Мин кем?» кебек сорауны бирергә яраткан Ркаил Зәйдулла милләтебез юлының элек-электән катлаулы сынаулар аша узуын яхшы күзаллый.

*Сүзләрне тезеп кәгазьгә,*
*Әйтерсең, гаскәр тезелә! –*
*Тартышып яшибез һаман,*
*Хак бар яшәргә безнең дә.*

*Өзелә гомер бу юлда,*
*Гарьлектән үзәк өзелә...*
(«Юл»)

Гәрчә күпләр шагыйрьне ниндидер хыялый затка охшатса да, чын шигърият хәзерге дәвер чынбарлыгыннан читләшеп яши алмый. Каләм әһеле үз чорының гына түгел, әүвәл үз халкының улы булырга тиеш. Димәк, буыннар әманәтен күңел түрендә йөрткән иҗатчы сөекле милләтенә һәрдаим кайгыртучанлык күрсәтергә бурычлы. Төрлесе күзәтелә. Ышанычлы кемсәләр бөтен авыл янганда, белмәмешкә салынгандай, чабата

киндерәсе үрүен дәвам иттерсә... Ошбу гыйбрәтле мисал безгә күптәннән мәгълүм. Кистереп әйткәндә, шушындый дәрәҗәдәге битарафлык әдипләргә бөтенләй ятышмый. Әлбәттә, бер җинаятьтәй күренгән әлеге гамьсезлек Ркаил Зәйдулла табигатенә дә ят. Филология фәннәре докторы, академик Дания Заһидуллина холык-фигыльнең әсәрләрдәге чагылышын бик дөрес билгели. «Ркаил Зәйдулла – заман һәм җәмгыять, милләт һәм кешеләр турында усал рәвештә, әрнеп, аңларга тырышып түгел, ачыктан-ачык гаепләп, «маңгайга бәреп» сөйләүче шагыйрь, – дип искәртте галимә. – Аның тоткан юлы, кыйбласы бер: каләме җәмгыятьне дә, шәхесне дә аямый, турыдан ярып бәяли, кимчелекләрне ача... Шигърияттәге лирик героеннан да кырысрак автор үзендә югарыдан торып фикер белдерерлек көч таба. Ул – хөкемдар».

Аңлашылганча, сәнгатьчә зиһенләүдә гадел хөкемдар булып калу өчен каләм иясе чорның мәдәни биеклегендә торырга тиешле. Аның алгы сафтагы замандашларын борчыган көнүзәк мәсьәләләрне, җәмгыятьтәге беренчел рухи ихтыяҗларны яхшылап белүе лазем. Француз язучысы Оноре де Бальзак әдипне дәүләт кешесе, кайбер очракта аннан да югарырак шәхес итеп күргән. Шулай шул, мондый затларны җәмәгатьчелек вазифасыннан аеру, аларны хадимлектән читләштерү мөмкин түгел. Әле болар гына җитми. «Кеше күңеленең мөһәндисләре»нә тарихчы һәм фәйләсуф кебек белгечләрнең сәләте дә кирәк. Бу әһәмиятле сыйфатлар, шөкер, Ркаил Зәйдуллада бар. Онытмыйк, яхшы шагыйрь таҗын кияргә инсанлык таланты да зарур. Монысына ирешү дә бик җиңелдән бирелми. «Фәрештә» исемле шигырь шушы хакта искәртә: *Кеше булам диеп юлга чыктым... / Тик, һай, авыр кеше булуы.*

Безнең тынгысыз шагыйрьләр җанын һәрдаим әрнеткән иҗтимагый мәсьәләләр турында уйланган чакта рухи символыбызга әверелгән Габдулла Тукайның соңгы сулышынача өзгәләнүе күз алдына килә. Сөекле өммәтебез өчен янып яшәгән зат үз фикерләрен программ рәвештә белдерергә ашыккан: «Китте Казан... Нә дәүләт калды...»; «Вакытында җирне селкеттек... Кая карасаң, анда без фәкыйрь милләтнең бер җире җитмәгәнлеге ачык була!..»; «Мәктәпләрне төзәтмичә, «Тәрәккый!» – дип кычкырырга базып булмый»; «Яшәсен туган тел!.. Яшәсен милләт!»; «Сез үзеңезнең хәлеңезне төзәтергә теләсәңез, хәзер сезгә тырыша торган вакыт тәмам җитте... Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк?»

Хикмәти Хода, узган гасыр башында күтәрелгән ошбу проблемалар бүгенге көндә дә актуаль булып кала. Үзләрен халык улы итеп санаучы каләм әһелләренең барысы да, шул исәптән Ркаил Зәйдулла да, шушы хакта ваемлый лабаса: әсәрләрендә дә, мәкаләләрендә дә, чыгышларында да... Әмма дәүләтчелекне ныгыту, милли мәгарифне торгызу, туган телне саклау ише үзәк мәсьәләләр гомерләрен тулаем олуг максатка багышлаган элгәрләр рухын да борчырлык дәрәҗәдә катлаулана бара. Күпчелек сүзен «усал рәвештә» җиткерергә омтылган Ркаил Зәйдулла хаклы, чөнки милләтнең үзбилгеләнү хокукларын киңәйтүдә алга китеш канәгатьлек уятмый. Әлеге төп стратегик юнәлештән тайпылгалап алулар да күренә. Мөмкинлекләрдән кирәгенчә файдалану җитенкерәми. Безнең йөрәккә кереп оялаган борчылдыру корты чәчәк тузанында казынырга тиеш түгелдер бит. «Төшемдә мин бер төш күрдем...» дип башланган шигырьдә Ркаил Зәйдулла өметсезлек хисенә дә бирелгәләп куя шикелле: *«Кемнәр сизде минем сүздән / Дөнья бераз үзгәргәнен?»* Тик үҗәт холыклы иҗатчы барыбер уйлаганын тукып тора. Безгә насыйп кылынган зарур хокукны чит-ятлар чәчәкле колашада алып килмәс. Исеме куелмаган бер робагыйда шагыйребез дә аумакайлыкны гаепли: *Китә ис, күреп тарихи тарлыкны... / Коллыкка без мәңгегә дип тарыдыкмы? / Бөтен бер ил үз телендә укырга / Мәскәү ханнан көтеп ята ярлыкны.*

Яшәештә әледән-әле расланганча, кайчак йөрәгең авазын хакимият колагына киртләү өчен гади җәмәгать эшлеклесе булу гына җитми, милләт хадименә дәүләт органнарының югары мөнбәреннән аяк терәп чыгыш ясау мөмкинлеге дә кирәк. Бу уңайдан Ркаил Зәйдулланың Татарстан Дәүләт Советы депутаты итеп сайлануы,

аннары Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасына алынуы мантыйкка туры килә. Халыкның рухи-мәдәни ихтыяҗларын нечкәләп белүче мондый шәхесләр җәмгыять тормышындагы җитешсезлекләрне үтемлерәк төстә шәрехләп бирүчән. Ә парламент утырышларында тәҗел күтәрелергә тиешле мәсьәләләр бүгенге заманда туктаусыз ишәю ягына бара күк. Шушындый катлаулы шартларда гафиллек күрсәтү аңлашылмый. Коръәндә төшендереп үтелгәнчә, «Хакыйкатьне яклыйсы урында сүз әйтми торучы бәндә телсез шайтандыр».

*Татар имән сыман беркатлы ул,*
*Тамырларга балта тигәндә,*
*Горурланып аваз бирә кәүсә:*
*– Сабы безнеке, – дип, – имәннән!*
(«Акрын гына карлар төшә өскә...»)

Чынлап та, безнең кавемгә авыр сынаулар бер-бер артлы ишелеп тора. Шагыйребез искәрткәнчә, татар мондый четерекле вакытта беркадәр инфантильлек тә күрсәткәләп ала. Сынаулар бүген дә күп көчне суыра. Шулар арасыннан халкыбызның рухи яшәешенә, этномәдәни тәңгәллеккә караганнары аеруча борчый. Һәркем шаһит, агымдагы чорда милләтебез язмышына турыдан-туры бәйләнгән ана телен, милли мәгарифне саклау мәсьләләре моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә кискенләште. Тотрыклы белем бирү системасын бозу өчен илнең яңа дәверендәниләр генә эшләнмәде: уку-укыту программасыннан милли төбәк компонентын төшереп калдыру, бердәм дәүләт имтиханын русча тапшыруга мәҗбүриләү... Аннары мәктәпләрдә рәсми статустагы татар телен өйрәтүдә, Россия һәм Татарстан конституцияләренә, гамәлдәге кануннарга каршы килеп, төрле-төрле кысрыклау чаралары тормышка ашырыла башлады. БМО тарафыннан дөньяның теләсә кайсы кыйтгасында аңлашырлык 14 тел исемлегенә кертелгән, бәһаләп бетергесез язма мирасның җирлеген тәшкил иткән телне шулай түбәнсетсеннәр әле! *«Коллар без – үзара хан булып кыланабыз, / Үзебез ятлардан телебезне теләнәбез...»* Әйе, «Өзелгән дисбедән» исемле шәлкемнең ошбу шигырендә Ркаил Зәйдулла усал ирониясен дөрес белдерә. Чын инвектива үрнәгедер бу.

Күзәтеп торабыз, Ркаил Зәйдулла милләтнең «җитешмәгән яклар»ын тезмә әсәрләрендә генә түгел, үткен публицистика каләме белән дә кыю рәвештә калкытып күрсәтә. Шагыйрьнең шундый мәкаләләре «Ил» (2000), «Сунар» (2021) һ.б. китапларында туплап бирелгән. Аның иҗтимагый мәсьәләләрне үзәккә алган гамьле язмалары республика көндәлек матбугаты басмаларында да чыгып бара. Хак әйтәләр шул, каләм әһеленең миллилеге көчлерәк булган саен, ул газиз халкының ихтыяҗларын тирәнрәк аңлый. Мондый юнәлештәге эшчәнлектә Ркаил Зәйдулланың фикерләү офыклары тагын да киңәя, табигый интеллекты күпкырлы белгечлеккә хас яңадан-яңа фәһемләү мөмкинлекләрен ача кебек. Тәҗрибәле әдипләр төрттереп искәрткәнчә, бәгъзе авторлар әлеге әдәби жанрда гадәти приказчик биеклегендә генә кала. Юк, ярсу холкын төрле гамәлләрендә сиздерә килгән Ркаил Зәйдулла публицистика өлкәсендә дә үзен җәмәгать эшлеклесе итеп тоя.

Һәммәсе дә мантыйкча: Ркаил Зәйдулла үз талканының коры икәнлеген Татарстан парламенты мөнбәрендә дә раслап тора. Көнүзәк мәсьәләләр уңаеннан ярсып чыгыш ясаган чакта ул ихлас кайгыртучан яклаучы да, шул ук вакытта ташлама ясауларга бармаучан ифрат кырыс гаепләүче дә булып тоела. Кайбер нотыклары исә тоташ катгыйлыкка тарта. Менә бер мисал. Татарстан юбилеена туры килгән 2020 елның 25 июнь – 1 июль көннәрендә Россия Федерациясе Конституциясенә төзәтмәләр кертү буенча илкүләм тавыш бирү үткәрелде. Әлбәттә, бик болгавыр чорда кабул кылынган ошбу Төп Закон яңа күзлектән җентекле рәвештә карап чыгуга мохтаҗ иде. Замана таләбенә бәйле мондый зарури чаралар дөньяның башка алдынгы мәмләкәтләрендә дә

оештырыла. Бездәге федератив конституция төрле-төрле үзгәрешләр кичерде. Вәләкин аерым милләтләрнең хокукларын тарайтуга китергән бериш тәкъдимнәр борыннан бирле гомер сөрүче кавем вәкилләрендә канәгатьсезлек тудырды. Әлеге төзәтмәләрдә үтә таныш тырмага янәдән басу, ягъни милли үзенчәлекләрне әкренләп юу омтылышы сизелә. Әйтик, рус халкын бердәнбер дәүләт оештыручы итеп беркетү электә дәүләт тоткан өммәтләрнең горурлыгына суга бит. Инде күптәннән дәүләт теле саналган рус теленә махсус статус билгеләү дә күп милләтле федератив структураның халыкара масштабта танылган төп принципларына ятышып бетми...

Кыскасы, РФ Конституциясенә теркәлгән бәхәсле өстәмәләрне ТР Дәүләт Советы да хуплады, депутатлар арасыннан Ркаил Зәйдулланың гына каршы шар салырга батырчылыгы җитте. Шагыйребез намусы кушканча тәвәккәлли. Ә милләтләрне кысучы көч тәмам азынган очракта «нацмен»нарны киләчәктә нәрсә көтәчәген күзалларга мөмкин бит. Әнә, авторның «Күпер» исемле әсәреннән инкыйразны хәтерләткән юлларга багыгыз: *Ул ышана – үтәр еллар, / Илдәге һәр халык – һәр! – / Тик урысча гына елар, / Урысча гына көләр.*

Табигый ки, Ркаил Зәйдулла милләт язмышына бәйле мөһим темаларны әдәбиятның лиро-эпик төрләренә кергән поэмаларда да күтәрә. Тынгысыз күңел таләбе буенча ошбу жанрга алынган чакта аның хозурында тагын да киңрәк гомумиләштерү офыклары ачыла. Туктаусыз сыкрап торган милли гамьне «Көтүче малай», «Күпер», «Койрыклы йолдыз», «Матәм» кебек поэмаларда сизмичә мөмкин түгелдер. Менә шуларның соңгысын гына бераз шәрехләп үтәсе килә.

Совет гаскәрләренең чикләнгән контингенты Әфганстанда «тәртип» урнаштырган еллар. Шагыйрь башта ук хак сорау куя: *«Безнең патриотизм хисләренә / Әфган якларында нәрсә калган?»* Поэманың төп герое Мөхәммәтне Татарстанга тутыя табутта кайтаралар. Тома ятим хәлдә үскән егетне икенче бәхетсезлек тәмам гүргә тыга. Бөтен авыл елый. Япь-яшь кызый, бусагага башын бәрә-бәрә, илереп сыктый. Бабасы Әюпнең психикасы бозыла. Ул инде әледән-әле үзалдына сыкрап тиргәнә башлый, соңрак барыбер аң-зиһенендә бәет чыгарырлык көч таба. Беренче һәм соң мәртәбә... Автор исә үткәннәр түренә тарихи экскурслар да ясый. Казан ханлыгын яклап шәһит киткән татар яугирләрен искә алып, безнең кавем кичергән башка сугышларны да үзара чагыштырып карый. Аннары хөкемдардай нәтиҗәсен чыгара. «Солдат чит дәүләттә батырларча һәлак булды. Тик ни өчен? Ни хакына? – дип өзгәләнә Ркаил Зәйдулла әсәрнең чәчмәдә язылган өлешендә. – Йөзләрчә татар егете әфган туфрагына башын салды. Кем җибәрде аларны анда? Һәр халык үз язмышы буенча яшәргә тиеш. Бер ирдә ике җайдак утыра алмый». Һәм каләмдәшебез әлеге мәсьәләгә карашын тезмәдә дә ап-ачык белдергәләп тора.

*Үз атына мәхәббәтле халык*
*Ят дан хакына яуга ялланган...*

***

*Мәшрикътан мәгърипкәчә җирләр*
*Безнең халык белән ашланган.*

***

*Нигә һаман чит илләрне яулап*
*Саклыйбыз соң туган илебезне?*

(«Матәм»)

Күрәбез, «Матәм» исемле поэмадан хәтта иләмәннәрне уйга төшерә торган, дөрес яшәү хакына гыйбрәт алырга чакырган сөземтәләр килеп чыга. Алар байтак. (Бәлки,

кысаларның чикләвен санламаучы автор да бу кадәр нәтиҗәләргә исәп тотмагандыр). Иң әүвәл дөнья хакимнәрен уятырга тиеш сорау туа: иҗтимагый үсеш дәрәҗәсе буенча алдынгы булып саналган бериш дәүләтләр, җиһандар вазифасына керешеп, кайчанга чаклы үзләренең яшәү рәвешен башка илләргә көчләп тагачак? Ирекле-ирексез әмәлдә соцлагерь оештырылды. Аннары еллар дәвамында Вьетнам, Әфганстан, Ирак, Ливия, Сүрия фаҗигале тыкшынуларны кичерде. Хәзер инде кирәкмәс «төсле инкыйлаб»ларны «демократиясез» мәмләкәтләргә импортлау көчәеп бара. Никадәр кан коела. Бу хәттин ашу бит! Аллаһ тигез хокуклы итеп яралткан кавемнәргә жандармча акыл кертергә маташу ниемә хаҗәт? Әйтик, Көнбатыш Саян тауларындагы аулак тарлауда гомер сөреп ятучы ялгызак Агафьяга: «Кала фатирына күченеп кайт, Россия казнасына салым түлә!», – дип, түтәйнең урман ешлыгындагы күркәм алачагына ОМОН белән бәреп кермиләр ләбаса. Табигать иркәсен көчләргә ярамый. Үзе теләгәнчә тереклек кылсын. Шулай ук милли горурлыгын үҗәтләрчә саклап килгән Төньяк Корея да, Яңа Гвинеядагы папуаслар кабиләсе дә кан өне кушканча көн күрсен. Кешелек төрлелекне ярата.

Ничек шулай туры килгән, Ркаил Зәйдулланың әлеге дә баягы «Матәм» поэмасын кабатлап укыган көннәрдә Америка Кушма Штатлары үзләренең гаскәри төркемен Әфганстаннан бөтенләй чыгарып бетерде. 20 ел! Алар шуның кадәр вакыт дәвамында җәмгыятьне «яңача» үзгәртеп кормакчы булды. Гадәттәгечә, үзләрен тиңдәшсез йогынты көче, дөнья кендеге хәлендә тоттылар. Ә нәтиҗә – нуль! Хәер, аяныч нәтиҗәне инде күрмичә мөмкин түгел – халык бихисап корбаннар бирергә мәҗбүр ителде... Әсәрнең буеннан-буена яшен тамырдай үткән лейтмотив уйланучан кешеләрне менә шундый гомумиләштерүләргә этәрә. Ә Ркаил Зәйдулланың ошбу патетик рухлы поэмасы узган гасырның 90 нчы елында ук язылган бит. Иң кыйммәте, авторның астарлы рәвештә әйтергә теләгән гаять мөһим фикерләре бүгенге дөнья җәмәгатьчелегенең карашы белән дә аваздаш яңгырый. Әйе, шагыйрьгә кайчак алдан күрүчәнлек тә, ягъни бераз оракуллык та кирәктер. Катлаулы чорда яшибез. Күпьяклы ялган стандартлар тәхеткә менеп утырды. Инсаният әллә акылыннан язамы дип, ихтыярсыз шикләнеп тә куйгалыйсың. Замананың гайре табигый хәлләрен бик тирәнтен аңлаган Ркаил Зәйдулла «Хәсрәт» һәм «Караңгыда...» шигырьләрендә тикмәгә генә шулай көрсенмидер:

*Бу нинди дөнья булды соң?*
*Бу нинди... нинди... нинди!..*
*Аның белән тураям дип,*
*Мин авыш булдым инде.*

***

*Тәңрем!*
*Бу туң заманда*
*Ник йомшак бәгырь бирдең?..*
*Тәңрем!*
*Бу җәһаләттә*
*Ник шикчел акыл бирдең?*

Сизгәнсездер, югарыда Ркаил Зәйдулланың табигатенә сеңгән байтак җете сыйфатлар ачып күрсәтелде. Шагыйрьнең иҗат өслүбе дә шул хасиятләргә турыдан-туры ялганган. Купшырак сүзләр белән әйткәндә, зиһен тирәнлегендә бөре чыгарган җырлар күңел утырымнары аркылы сөзелеп чыга. Чынбарлык материалын һәркем үзенчә эшкәртә, шәхсиян «темперамент казаны»нда үзенчә кайната, эчтәлек сыгынтысын үзенчә калыпка агыза. *«Туа шигырь – ага сагыш җанымнан...»; «Үтте гүя минем аша / Бар газабы бу галәмнең...»* Күрәбез, «Ә күкләрдә» һәм «Йомылдылар

йолдызларым» исемле әсәрләрдә могҗизалы әверелешне Ркаил Зәйдулла да чагылдырып уза. Шушы җәһәттән аның язу рәвеше дә нәкъ менә насыйп рухиятенә охшап тора.

Игътибар белән карасак, Ркаил Зәйдулланың шигъри сөйләмендәге стиль үзгәлеге әсәрләрнең ритмик нигезендә үк күзгә ташлана. Тезмәдә еш кына иҗекләр саны бозыла, шуларга бәйле рәвештә назымның темпы үзгәрә. Бер үк шигырьдәге рифмалар да кай очракта үлчәмнәрен төрлеләндереп тора. Ниндидер какофония. Әлбәттә, болар каләм әһеленең халәтеннән дә килә. Шигърият кыйммәтләрен сүз тезмәсеннән, формальлектән генә эзләргә ярамый. Тоташ каршылыкларга корылган тормышта да көй дигәннәре әледән-әле даимилеген җуя. Мөһим сүзләрне кирәкле урынга кую буп-буш шомартуга да китерергә мөмкин. Хакыйкатән, тышкы ялтырау иҗатчының холык-фигылен дә, аның уй-фикерләрен дә тоныкландыра ала. Чик-чама хисен санлау хәерле. Шагыйрь өслүбенең «чатаклык» шикелле сиземләнгән билгеләрен әдәбият белгечләре дә үзләренчә күргәли икән. «Ркаил келәймәсе сугылган кайбер шигырьләрнең беренче карашка шактый тупас, усал кебек тоелуы ихтимал, аларның күбесендә ритм-көй булмау да моны көчәйтеп җибәрә, – дип язды Нәҗип Нәкъкаш. – Гүяки ботаклы-сатаклы катыршы каен тактасы, кайсы якка ышкыласаң да, ышкы тимере нәрсәгәдер килеп төртелә. Искәрткәнемчә, беренче карашка шулай. Ә менә тирәнрәк төшеп зиһенләсәң, бу – каләм иясенең көчле бер чарасы бит. Шигырь шуып кына үтеп китми, ул сискәндерә, уйландыра һәм... авторның болай әйтергә хакы барлыгына ышандыра».

Мәсьәләгә шушы яктан якынлашсак, Ркаил Зәйдулланың акрынлап инде калыплашкан язу рәвешендә игътибарны тагын бер аерымлык үзенә тарта. Монысы бериш шигырьләрнең артык катлаулы яки чамасыз серле булып тоелуыннан гыйбарәт. Болары җитешсезлек исәбенә керәме? Бусы бәяләүчегә бәйле. Гомумән, әдәби әсәрләрнең аңлашылып җитмәве электән үк хупланмаган, чынбарлыкта ул талант мөмкинлекләренең чамалы икәнен белдергән. «Кабуснамә»дә искәртелгәнчә, шигырьләр үзең өчен генә түгел, бөтен халыкны истә тотып языла. Алар бернинди мантыйксыз тарызда тезелеп киткән матур сүзләр җыелмасын гына хәтерләтә икән... Озак тәфсилләп тормыйм. Затлы җебе өзелгән мәрҗәннең дә төп гамәли асылы юкка чыга. Шулай пыран-заран килгән муенсаны кеше дикъкатеннән яшереп, барчасын сигез кырлы стаканга тутырсаң гына инде. Бәлки, назымда мондый томанлылык төгәл фикер кытлыгына, үзәктәге шигъри хикмәтне тонык күзаллауга бәйледер. Шигърият тулысынча беленмәгән якка юл алу дип, капылт кырт кисәргә ашыгыр Ркаил Зәйдулла. Шушылай кемнеңдер әйткәнен кабатлар. Янәсе, сәнгатькә сер бик килешә. Каршы төшмим. Әмма монда да чик белү кирәк.

Ай-һай, иҗади хыяллану барыбер эчке мантыйкый халәт сүрүендә, илһамлану белән мантыйк тигезләнеше шартларында барырга тиештер. Күзәтүләр күрсәткәнчә, Ркаил Зәйдулла җыентыкларында «томанлырак» шигырьләр байтак. Һәрхәлдә, андый әсәрләрне кәгазьгә төшерер чакта ошбу таләпне хәтердә яңарту зарур. *«Сүз иярендә / Җилдерик бер тагын да...»* Әле яшь шагыйрь исемен горур йөрткән елларда «Көтүче малай» әкияте авторы шулай язган иде. Лөгатьне кирәкле эзгә кертү алай ук җиңел бирелми. Алар катгый боерык буенча гына җаның теләгән рәвешле сафка басмый. *«Күкрәк куышлыгында яралган гади дә, бергә тезелгәч, сәер дә яңгыраган сүзләрне дөньяга кычкырасым килә,* – ди Ркаил Зәйдулла «Гөләпләр керфеге» парчасында. – *Бер-берсен этә-төртә, сүзләр... ашыга. Шуларны бер тезмәгә салырга сабырлыгым җитми».* Бу уңайдан шагыйрьне юату теләге туа: сабырлык чыганагы беркайчан да саекмасын; «серлелек»кә авышу куркусыз каләмне үтмәсли. Әнә, үз-үзеңә тәнкыйтьчел каравыңны назымыңда да сиздергәнсең: С*әер бер маза кузгала / Күңелем ызанында: / Кирәкмәсне күп яздым, ник / Сүз тапмыйм кирәгенә?(«Үкенү хисе»).*

Шулай бервакыт Александр Блок күнегелгән гадәти тәртиптә язудан туктап

калуы, чөнки әлеге эшне ифрат оста башкаруы хакында көндәлегенә теркәп куйган. Таныш хисләр. Бәлки, тәҗрибә тупларга өлгергән талантлы шагыйрьләр нәкъ менә шундый халәттә әдәбиятның башка жанрларында да көч сынап карарга ният кыладыр. Ишле очракка таянып әйтсәк, андый эзләнүчән каләмнәр чәчмәне якынрак күрә. «Белгечлек»не үзгәртү хәле дөнья күләмендә күзәтелә. Мәсәлән, француз прозасын җиһанга таныткан муза әһелләренең күпчелеге иҗадият үрләрен яулауны Парнас юнәлешеннән башлап җибәргән. Безнең татар әдәбиятында да бу исемлеккә керердәйләр хәтсез. Чәчмәдә шигъри башлангычның гаять әһәмиятле өлеш тәшкил итүен Япония әдипләре дә объектив зарурлык сыйфатында танып бәяли. Прозада назымның дәвамын күрүчеләр дә, бүтән метаморфозаны тоемлаучылар да җитәрлек. Һәрхәлдә, әдәби төрләр арасында Кытай дивары юктыр. Моны Ркаил Зәйдулла да үз мисалында раслый алыр, чөнки ул чәчмә кишәрлегенә чыгуның серләрен яхшы аңлый. «Шагыйрьнең берчак кыйссалар ягына авышуы сүз-ләгать сәнгате өчен бәһаләп бетергесез гамәл, – дип исәпли Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла да. – Ркаил Зәйдулланың мөмкинлекләре зур, ул шәп шагыйрь дә, шәп прозаик та... Лексик хәзинәнең кадерен белүче шагыйрьләр прозада да кыскалыкка, сурәтлелеккә омтыла. Алар чәчмәне шигырь дәрәҗәсенә менгезә. Прозадан тезмәгә күчкән затны тарих хәтерләми, шигырьдән чәчмәгә күчү исә табигый күренеш булып санала».

Дөрестән дә, Ркаил Зәйдулланың чәчмә иҗатында да аның башлангыч тел-өслүбе ачык чагыла. Юк, «Ихласлык» әсәрендә ишарәләп үткәнчә, «Сау булыгыз инде, шигырьләрем!» – дип, ул назымнан бөтенләйгә китмәде ич. Классиклар сүзе белән әйткәндә, каләм иясенең күңелендә тормыш прозасыннан тормыш шигърияты чыгару теләге туган. Мондый олы максатка алынсаң, кимендә ике сәләтең булсын. Мөгаен, Ркаил шуңа төшенгән: шагыйрь гадәти кебек тоелган күренешнең дә үтә кызыклы якларын ачып бирергә мөмкин; шулай ук чәчмәдә дә фикер тирәнлеге бик хаҗәт; җиргә нык басып язылган проза үрнәкләре яшәешкә кирәкле нәрсәләрне күбрәк яктыртып күрсәтә. Чәчмәдә эшләү авыррак диюләре дә, ихтимал, хак сөйләүчеләр раславына туры киләдер.

Менә шундый чынлыкны хәтердә тоткан хәлдә, Ркаил Зәйдулла бер-бер артлы хикәяләр, тарихи повестьлар, романнар яза башлый. Аның чәчмә әсәрләрен туплаган «Татар таҗы» (2004), «Ташка ордым башны» (2008) һ.б. китаплары басылып чыга. Безнең өммәт әдибе күпкырлы булырга тиеш. Бу милли ментальлектән, язмышыбыз ихтыяҗыннан килә. Каләм иркенлеген тулысынча тойган шагыйребез, тезмә-чәчмә кысаларында чикләнмичә, драматургия мәктәбен дә үтәргә тели. Башка сәнгать төренә ныклап тартылган авторның «Казан утлары» журналында (2001) тарихилыгы күренеп торган «Хан һәм шагыйрь» трагедиясе дөнья күрә. Ә Ркаил Зәйдулланың «Саташкан сандугач» пьесасы атаклы режиссёр Марсель Сәлимҗановның игътибарын җәлеп итә, һәм әлеге әсәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уңышлы рәвештә куела да. Аннары «Үлеп ярatty» драмасын да шул ук иҗат коллективы сәхнәләштерде. Гомумән, шагыйрьлектән «азган» драматургның төрле темаларга багышланган дистәгә якын пьесасын Казан, Түбән Кама, Буа, Оренбург шәһәрләрендә эшләп килүче бүтән театрлар да тамашачы хөкеменә тапшырды. Күренә ки, сәхнә сәнгатенә дә ул якорен салды. Өстәп әйтсәк, Ркаил Зәйдулла тәрҗемә өлкәсендә дә шушы «политехнизм» биеклеген сакларга тырыша.

Инде ышанып әйтергә мөмкин, Ркаил Зәйдулла һәммә юнәлештә дә үз максатына маһирларча ирешергә омтыла. Ярсу кальбендә кайнаган уйлары бертөрле калыпка гына сыймый. «Яралгы» әсәрендә аныклап үтелгәнчә, *«Бөек мәгънә эзли... шагыйрь»*. Әлеге бөек мәгънә изге гамьгә тоташа. «Сәер уен» исемле шигырьдәге ошбу мисраглар авторның үзенә дә бик килешеп тора: *«Гасырлардан килгән татар гаме / Йөрәгенә аның сыенды...»* Иҗатчы кәгазенә агылган күпчелек юлларда шушындый мөкатдәс ваем үзәккә куела. Гүя аңа Тукаебыз: *«Һәр кеше күңелен күрмә, милләт авыруына да бак»*, – дип, остазларча кисәтүләр ясый.

Халыкны шәхесләр олылый. Безнең газиз ул-кызларыбыз Габдулла Тукай, Мөхлисә Буби, Хәсән Туфан, Ильяс Алкин, Нәгыймә Айтматова турында махсус әсәрләр язуы да шул ук Ркаил Зәйдулланың барлык әдәби жанрларда да милләт мәнфәгатьләрен башка мотивлардан күпкә өстен итеп санавын дәлилле рәвештә раслый. Сәнгатьнең байтак юнәлешләрен колачлаган каләм җитди йөкне тигез тартырга тырыша. Бу күпкырлы эшчәнлек югары бәяләнде дә. Әйтик, Ркаил Зәйдуллага төрле елларда «Татарстанның халык шагыйре», «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелү, аның әле республикабызның М.Җәлил исемендәге, Татарстан Язучылар берлеге һәм Мәдәният министрлыгының Ф.Хөсни исемендәге премияләренә лаек булуы да шул хакта сөйли. «Яңа татар пьесасы» бәйгесендә дә ул берничә тапкыр җиңүгә иреште, шулай ук Д.Сираҗиев исемен йөрткән мәртәбәле театр бүләген дә алды.

Менә бит, иҗатчы талантының бәрәкәтле төстә тармакланып китүе хезмәтнең әһәмиятен билгеләүдә дә ачык чагыла. Әмма нинди өлкәдә генә иҗтиһат кылмасын, Ркаил Зәйдулла үзенең шагыйрьлеген сиздереп тора. Кайвакыт тезмә әсәрләрен барлап, хисап тотарга да ымсына. «Минем кайбер әйберләр белән хушлашуым» исемле шәлкемдә шигърият үрләрен яулаган шәхеснең халәте күзаллана төсле.

*Китәләр көннәр бер-бер артлы...*
*Һәм вакыттыр, бәлки,*
*Сорау бирергә дә:*

*Мин кем? Нәрсә? Мин ни атлы?..*
*Ни таптым мин җирдә шигырь язарлык?*
*Шигырь язарлык ни югалттым соң?*

Күпмедер үзгәлек өчендер, Ркаил Зәйдулланың «Мәгарә» исемле шигъри китабында (2005) бүлекләр чәчмәдә язылган парча белән ачыла. Автор анда яшь кенә малайның, этисенә ияреп, болынга баруын җентекләп тасвир кыла. Менә ул чытырманлык аша елга буена юнәлә, суда ялгызы йөзгән чакта тәмам төшләнә башлый: кыбырсык олан кара урманда адашып йөри, ничек тә офык киңлегенә чыгарга омтыла... Маҗарага тарыккан тиктормас яшүсмер Ркаилнең мотлак үзен хәтерләтә. Белгәнебезчә, Иван Грозный Казанга илбасарлык походларын барлы-юклы унбиш яшьтә оештырырга керешә. (Ни шайтаныма шул Мөдһишне урынсыз искә төшерергә әле!). Ә шагыйрь булырга хыялланган мәктәп баласы мәркәзгә тәүге тапкыр ундүрт яшендә килә. Соңгысының максатлары игелекле. Аның атаклы Казан дәүләт университетында үзенә кирәкле белем аласы, биредә «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсенә староста сыйфатында җитәкчелек итәсе, «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» газеталары редакциясендә беркадәр каләм чарлыйсы, «Идел», «Гаилә һәм мәктәп» журналларында җаваплы вазифалар башкарасы, төрле жанрларга караган әсәрләрне аерым китаплар рәвешендә бастырасы бар. Аннары инде тәҗрибәле егетне олырак бурычлар алга этәрер.

Асылда тормыш шәфкатьле, адәм баласының яшьли сайлаган юлы аны яңадан-яңа биеклекләргә алып менә. *«Кендек өзеген кысып барам учыма, / Мәңгелеккә ялганасым бар минем...»* Күрәбез, «Кендек» исеме белән аталган дүртьюллыкта шагыйребез шундый амбициясен белдереп куя. Бик хуп, сәнгать әһеле замана югарылыгында торырга да, шулай ук мәңгелекне дә тоярга тиеш. Теге маҗаралы парча тагын искә төшә. Гаҗизлек хәлендә калган малайны күреп, ап-ак сакаллы Хозыр Ильяс эндәшә: «Юлың озак, олан, атла да атла!» Амин, озак барырга язсын. Хозыр галәйһиссәламнең киңәшенә өстәп, шуны да әйтәсе килә: «Шагыйрьлегең һич саекмасын, Ркаил, барысына да ирешерсең».

**Зиннур МАНСУРОВ**



*Г.Тукайның тууына 110 ел тулуга багышланган тантанада. Алдагы рәттә утыралар (сулдан уңга): Фәридә Кудашева, Ислам Әхмәтҗанов, Минтимер Шәймиев, Мостай Кәрим, Василий Лихачев, ..., Әмирхан Еники. 1996 ел.*



*Язучылар белән очрашу. Сулдан уңга: Минтимер Шәймиев, Әмирхан Еники, Ринат Мөхәммәдиев, Гариф Ахунов. Кремль, 1997 ел.*



*Шәүкәт Галиев белән. 2008 ел.*



*Илдар Юзеев белән. 2003 ел.*



*Минтимер Шәймиев (уртада) язучылар хозурында. Сулдан уңга: Фоат Галимуллин, Роберт Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Нурихан Фәттах, Флүс Латыйфи, Туфан Миңнуллин. 2002 ел.*



*Аяз Гыйләҗев белән. 1998 ел.*



*Ркаил Зәйдулла белән. 2019 ел.*



*Татар язучылары белән очрашу. 2008 ел.*

*Сәхифәне* **Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА** *әзерләде.*

# МӘҢГЕЛЕК ТАУ ИЛЕ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Каспий белән Кара диңгез арасына сузылган Кавказ тау сыртларына сыенып яшәүче балкарлар – без казан татарлары өчен тугандаш, кан-кардәш халыкларның берсе. Кабарда-Балкар республикасының Кавказ буйлап, Грузиягә таба сузылган ягыннан Карачай-Черкес республикасы башлана. Балкарлар белән карачайлар, татарлар белән башкортлар шикелле үк үзара якын кардәшләр, бер үк телдә диярлек сөйләшәләр, бары тик икесе ике республикада яшәүләре белән генә аерылалар. Бу – Октябрь инкыйлабыннан соң, СССР дәүләтен төзегәндә, Сталин алып барган милли сәясәтнең ачы җимеше.

Балкарларның «Халык шагыйре» исемен йөрткән күренекле әдипләре әллә ни күп булмаса да, Советлар Союзы вакытында исемнәре бөтен илгә танылган зур шагыйрьләре бар. Шуларның иң күренеклесе – Кайсын Кулиев. Аннан соң Кәрим Отаров килә. Балкар язма әдәбиятына нигез салган Кязим Мечиевның тууына – 2019 елда 160 ел тулды. Журналыбызның бу санында без балкар әдәбиятының бүгенге заман вәкилләре – Кабарда-Балкар һәм Карачай-Черкес республикаларының халык шагыйре, РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Тәнзилә Зумакулова, күренекле остазларының юлын лаеклы дәвам иттерүче Муталип Беппаев белән Әскәр Додуев шигырьләрен тәкъдим итәбез.

**Рафис КОРБАН**



*Тәнзилә Мостафа кызы Зумакулова (1934) – балкар шагыйрәсе, Кабарда-Балкар, Карачай-Черкес республикаларының халык шагыйре, Россия Федерациясенең, Кабарда-Балкар һәм Чувашстан республикаларының Дәүләт премияләре лауреаты.*

Тәнзилә
Зумакулова

# СЕЗ КИЛЕГЕЗ МИҢА КУНАК БУЛЫП...

## Туган йорт учагы

«Туган йортың учагының уты сүнсен!»
Юк шуннан да авыр каргыш минем өчен.

Кем башына килгәндер бу явыз теләк,
Кем беренче әйткәндер бу ләгънәт сүзен?

Кем булган ул зирәк, әмма усал бәндә,
Аңлата һәм аңлый алмыйм хәтта үзем.

Сүнә күрмә, туган йортым учагы, син.
Ут алырга сиңа һәрчак күршем керсен.
Тыным белән кабызырга әзермен мин
Синең утың һичберкайчан сүнмәс өчен.

Мин курыкмыйм үзем өчен, ни булса да,
Сине саклап, мин янарга әзер һәрчак.
Туган йортның җылысын һәм утын саклап,
Каргышларның котын алып янсын учак.

Туган йортның җылысына безне җыеп,
Уты янсын, бәрәңгесе пешсен көлдә.
Ишетелсен бала-чага көлешкәне,
Тирәсендә гәп куерсын туган телдә.

## Ташлар

Йортыбызның байлыгы сез, ташлар!
Сабан да юк бездә, иген дә.
Сез ятасыз хәтта түбәсендә
Без яшәгән сакля-өйнең дә.

Саклагансыз безне җил-давылдан,
Явымнардан саклап торгансыз.
Сездән савыт-саба ясаганнар,
Сез таулыга түшәк булгансыз.

Тау-таш арасында яшәгәннәр
Үзләштергән тормыш хәйләсен:
«Сөт сыгабыз таштан», – дигән сүзнең
Яхшы белә алар мәгънәсен.

Йөрәксез дип, сезне кем әйткәндер?!
Белми, димәк, сезне ул бәндә.
Сез ишелеп хәбәр китергәнсез,
Таулыларга хәтәр килгәндә.

Ышыклыйсыз җәйге челләдән сез,
Җылыткансыз кышкы кичтә сез.
Ач сабыйлар күңелен күрер өчен
Сез бәрәңге булып пешкәнсез.

Сер саклыйсыз, берни сөйләмисез,
Кайгы күрсәгез дә, дәшмисез.
Зиратларның тынычлыгын саклап,
Кабер ташы булып яшисез.

Ник кешегә таш йөрәкле, диләр?
Шундый булыр ирнең сирәге.
Таш йөрәкле кеше булса булыр,
Тик таш түгел ташның йөрәге!

* * *

Туганым күк газиз дускайларым,
Күрегез бер килеп балкарны,
Тауларында, кыя-ташларында
Гөлләр чәчәк аткан якларны.
Гомер буе искә төшерерсез
Бездә кунак булган чакларны!

Чал сакаллы карт та безнең якта
Кунак килсә, бары шат кына.
Ул сиздермәс туры килсәгез дә,
Нинди генә авыр чагына,
Ачык чырай белән каршы ала,
Табынына һәрчак чакыра.

Сез килегез миңа кунак булып,
Әзер булыр һәрчак табыным.
Көннең кайсы сәгате дип тормам,
Шат йөз белән каршы алырмын.
Миндә кунак булган сәгатьләрне
Сез яшәрсез һәрчак сагынып.



*Муталип Азнорон улы Беппаев (1949) – балкар шагыйре, Кабарда-Балкар республикасының халык шагыйре, Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара әдәби премия лауреаты.*

Муталип
Беппаев

# ТАУЛАРЫМ – МИНЕМ ОЧАР КОШЛАРЫМ...

## Хәтер

Әнкәй!
Синең
Нинди сулар
Калган тынып йөзләреңдә...
Уяныр күк алар
Әгәр
Яу кырында ятып калган
Әтиемне искә алып,
Яшьләр тулса күзләреңә.

## Очрашу

Төн уртасы,
Кайтып киләм,
Төне буе көтеп аны.
Тротуарны кайта капшап
Арыган күз карашларым –
Гүя култык таяклары...

## Күзләр, күзләр

Күзләремдә –
синең күзләр.
Синең күздә –
минекеләр.
Кинәт алар
икесе бер
Караш булып кушылдылар.

## Афәт

Бетермичә
Җырлап җырын,
Ташлап суга
Канатларын,
Аккош үлде...
Сагышларга
Салып күлне.

Сискәнделәр,
Тетрәнделәр,
Каушадылар
Төнбоеклар.
Төренеп су
Гөлләренә
Аккош йоклар.

Бу афәттән
Күл соң нишләр?!
(Ә күңелдә
Якты хисләр...)



*Әскәр Таукан улы Додуев (1954) – балкар шагыйре, «Мәңге тау» журналының баш мөхәррире. Карачай-Черкес республикасының халык шагыйре.*

Әскәр
Додуев

# ҖӘҺӘННӘМ БЕЛӘН КУРКЫТМА МИНЕ...

## Бәхеткә юл

Күзләреңнең ни дип кычкырганын
Аңлап булмый күреп кылганың.
Ник алдарга – берни файдасы юк:
Хәтеремдә нәни кулларым.

Мин калдырып кабат үз өемне,
Китеп бардым синнән еракка.
Синнән башка язмыш, тозын сибеп,
Камчы белән кыйный ул якта.

Синең белән күргән михнәтләрем
Йөз мәртәбә миндә яңара.
Менә шулай тырышам мин сине
Хәтеремнән сызып ташларга.
Озын булган саен бәхеткә юл
Кыскарганнан бара кыскара.

## Әле иртәрәк

Җәһәннәм белән куркытма мине,
Күрергә аны әле өлгерәм.
Ни генә кичми адәм башыннан,
Кеше барыбер анда бер керә.

Бу җирдә аны белми яшәсәк,
Һәр кеше булыр иде тазарак.
Җәһәннәм белән кеше куркытма,
Тыныч яшәсен кеше азрак.

Гомер иткәндә кеше бу җирдә,
Кайгы-борчулар күрмичә калмас.
Йөрәккә яра салган кайгылар
Җәһәннәм белән чагыша алмас.

## Чик

Һәрнәрсәнең чиге була.
Таш та упкынга убыла.
Поезд ыргый тимер юлдан,
Каядыр ашкына ул да.

Һәрнәрсәнең чиге була.
Упкын төбендә таш тына.
Поезд да бер туктый барып,
Чапкан ат та туктый арып.

Чикләр белми кеше генә.
Йозак элеп ишегенә,
Чыгып китә ерак юлга.
Карап тормый уңга, сулга.

Гомер буе чабып кеше,
Бары соңгы көндә генә,
Туктап кала, төртелә дә
Килеп кабер түмгәгенә.

*Балкарчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*

# ИДЕЛ-ЧУЛМАН ТӨБӘГЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ: ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕ

## Гарәбстандагы ислам

Гарәбстанда ислам дине тарафдарларының урта гасырларда дәүләт белән идарә итү, икътисад, мәдәният һәм фән өлкәләрендә югары казанышларга ирешүе «мөселман цивилизациясе» дигән төшенчә барлыкка китерә. Урта гасырларда безнең борынгы төрки бабаларыбызның мәдәни һәм көндәлек тормышындагы яңарыш һәм алгарыш та, шиксез, ислам динен кабул итү – мөселман цивилизациясенә кушылу белән бәйле була.

Гарәбстан ярымутравының Мәккә шәһәрендә 40 яшьлек Мөхәммәд пәйгамбәргә (570-632) 610 елда Коръән аятьләре иңә башлау һәм аның яңа динне дәгъватләүгә алынуы дөньяда ислам тәгълиматы һәм хокукы барлыкка килүнең башлангычы дип санала. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең тарафдарлары белән 622 елда Мәдинә шәһәренә күченгәч, мөселманнар җәмгыяте тагын да зурая һәм көчәя.

Мөхәммәд пәйгамбәр кыска гына гомерендә кешенең иманын һәм Аллага мөнәсәбәтен билгеләгән, төгәл ритуаллар тәртибендәге ислам тәгълиматын һәм дин хокукының гомуми нигезләрен булдыра. Үзеннән соң васыять итеп, ул иҗтимагый һәм икътисади үсеш дәрәҗәләре, тормыш һәм хуҗалык итү рәвешләре, телләре һәм гореф-гадәтләре ягыннан бер-берсеннән нык аерылып торган кабилә-халыкларга бер кавемгә берләшү кирәклеге хакында эчке үзаң формалаштырырлык дини күзаллау-концепция калдыра. Ул оештырган мөселман җәмгыятен әле салым һәм финанс системасы, кануннары һәм чиновниклары булган дәүләт дип әйтеп булмас. Мөселманнарның берләшүе дә, нигездә, Мөхәммәд пәйгамбәр шәхесенә бәйле: тирә-яктагы мәҗүси кабиләләрнең аңа биргән тугрылык турындагы антларына нигезләнә. Гарәбстанда яшәгән мәҗүсиләрнең ислам динен кабул итүләре, шулай ук, Мөхәммәд пәйгамбәр төзегән иҗтимагый берләшмәгә керү шарты һәм формасы була.

Исламның Гарәбстан ярымутравында гына калмыйча, дөньякүләм күренешкә әверелүендә, дини дәвамчанлыкны тәэмин итеп һәм үстереп, өммәтне рухландырып, мөселман хокукы доктринасын булдырып, сәяси яктан көчәйтеп һәм мөселманнарны Җир шарында иң алдынгы, белемле һәм югары мәдәниятле цивилизация итеп коруда төп рольне Пәйгамбәр вафатыннан соң идарә иткән Әбүбәкер, Гомәр, Госман һәм Гали хәлиф, шулай ук Өммәвиләр һәм Габбасилар хәлифәтләре җитәкчеләре уйный.

Мөхәммәд пәйгамбәрне дин кардәшләре дини тәгълимат таратучы Остаз һәм җәмәгать намазларын җитәкләүче Рухани, Сәяси җитәкче һәм Баш казый буларак таныйлар *(Большаков О.Г. История халифата. Т.1. Ислам в Аравии. 570-633. М., 1989. С.187, 188)*. Шул сәбәпле аның вафатыннан соң мөселман җәмгыятендә сәяси җитәкче билгеләү мәсьәләсе туа. Бу катлаулы мәсьәлә мөселман җәмгыяте тарафыннан үз кулында дөньяви һәм дини хакимиятне туплаган яңа идарәчене – хәлифне – сайлау юлы белән хәл ителә.

Әйтергә кирәк, хәлифкә хакимият Мөхәммәд пәйгамбәр тарафыннан васыять итеп тапшырылмый. Пәйгамбәрнең үзеннән аермалы буларак, хәлифнең җәмәгать гыйбадәте белән җитәкчелек итүе дә сакраль мәгънәсен югалта, намаз уку тәртибен яхшы белгән һәрбер мөселман башкара торган эш булып китә.

Беренче хәлифне сайлауда катнашкан мөселманнар арасында ике төрле фикер урнаша. Берәүләр Пәйгамбәрнең Гайшә исемле хатынының әтисе, эш-гамәлләре белән халыкта тирән ихтирам казанган Әбүбәкерне сайларга чакыралар, икенчеләре исә

хакимиятне Пәйгамбәрнең кан кардәшенә – аның туганы һәм кияве Али ибне Әбү-Талибка тапшыруны хуплый. Шул рәвешле бүленгән ике төркем берникадәр вакыттан соң мөселман җәмгыятенең сөнниләргә һәм шигыйларга аерылуына сәбәп була.

Исламнан ваз кичкән, без Мөхәммәд пәйгамбәргә ант иттек дип, яңа хәлифне танырга теләмәгән кабиләләргә каршы көрәшеп, беренче хәлиф Әбүбәкер хакимлеген бөтен Гарәбстан ярымутравына тарата. Гомумән, беренче дүрт хәлиф идарә иткән елларда яңа оешып килүче дәүләтнең чикләре тагын да киңәя, исламны күп халыклар кабул итә, диннең төп чыганагы булган Коръән текстлары туплана, системага китерелә башлый һәм Изге китапның бердәнбер текстын булдыруга зур көч сарыф ителә. Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләре җыела, текстларның дөреслеген тикшерү һәм тәртипкә салу юнәлешендә хезмәт башкарыла. Бер үк вакытта, Госман хәлифтән башлап, дәүләттә төрле фетнәләр арта, шул сәбәпле соңгы ике хәлиф дин кардәшләре тарафыннан үтерелә.

*Дәүләттә хакимият Өммәвиләр* (661-750) кулына күчкәч, хәлифләрне халык тарафыннан сайлап кую гамәле юкка чыгарыла, хакимиятне тапшыруның яңа тәртибе урнаша: бу нәселдән һәммәсе 14 кеше тәхеттә утыра. Башкала Күфәдән Дәмәшекъ шәһәренә күчерелә.

Өммәвиләр хәлифәтенең чикләре байлык туплауны максат итеп куйган басып алулар хисабына нык киңәя: Төньяк Африка, Төньяк Һиндстан, хәзерге Испания һәм Португалия җирләре, Төркестан, Сәмәрканд, Урта диңгез утраулары, Сицилия һ.б. мөселманнар кулына күчә. 712 елда гарәпләр Сәмәркандка һәм Харәземгә, бер елдан Чәчкандкә (Ташкент) бәреп керәләр, 714 елда Фирганә үзәненә хуҗа булалар. Шул рәвешле, бу төбәктә ислам дине таралу өчен сәяси һәм хокукый нигез барлыкка килә. Яңа динне җирле кабиләләр арасында таратуда хакимият зур тырышлык куя. 737 елда Азәрбайҗан һәм Әрмәнстан белән идарә итүче Мәрван Хәзәр дәүләтен җиңә, аның яһүд динендәге каһанын исламга китерә.

Мөселманнар басып алынган илләрдә мәҗбүри исламлаштыру белән шөгыльләнмиләр, киресенчә, алар җирле халыкны җәберләмәскә һәм гадел идарә итәргә тырышалар. Яңа динне кавемнәр, нигездә, мөселман булмаган затларга дәүләт тарафыннан салына торган махсус салымнан (хараҗ) котылу өчен кабул итә (хараҗның күләме җыелган уңышның 1/3дән – 2/3 өлешенә кадәр була) *(Махмутов М.И. Мир ислама. Казань, 2006. С. 135, 136).*

Хәлифәттә күпсанлы реформалар уздырыла. Яңа күренешләр дип, илдә почта хезмәтен кертүне, гарәп теленә дәүләт теле статусы бирүне, акча реформасы ясап, Сасанид һәм Византия тәңкәләрен гарәпләр суккан алтын динар һәм көмеш дирһәм белән алыштыруны, салымнарны кешеләрнең матди хәлләреннән чыгып билгели башлауны атарга мөмкин.

Баш күтәргән шигыйларга каршы көрәш вакытында тәхеткә башка династия вәкилләре утыра. *Габбасилар хәлифәтенең* (750-1258) беренче идарәчесе Мөхәммәд пәйгамбәрнең агасының нәсел дәвамчысы Әбү әл-Габбас әс-Сафах була. Габбасилар идарә иткәндә, яңа җирләр яулап алу акрыная, хәлифәттән Испания (Андалузия) һәм Марокко аерылып чыга.

Габбасилар, дәүләт белән идарә итүне камилләштерү максатыннан, Ирандагы хакимият һәм финанс системасын куллана башлыйлар. *(Бартольд В.В. Несколько слов об арийской культуре в Средней Азии // Бартольд В.В. Сочинения. Т. II. Ч.1. М., 1964. С. 328)*. Бу мөселман дәүләтчелегенең тагын да ныгуына китерә.

Габбасилар хәлифәте заманында сөнни мөселман дөньясының тормышында мөһим булачак дүрт мәзһәб формалаша (X–XIII гасырларда – сигез, XVII–XX йөзләрдә – дүрт: Хәнәфиләр, Мәликиләр, Шәфигыйлар, ханбалитлар). VIII гасырның беренче яртысында Көньяк Гыйракта Ногман әбү-Хәнифә (696-767) тарафыннан нигезләнгән мәзһәб тәгълиматы Урта Азиягә, аннан Кече Азиягә, Идел буена, Һиндстанга тарала.

Хәлиф Мансур 762 елда башкаланы Сүриядән Гыйракка – Багдад шәһәренә күчерә,

шул сәбәпле Фарсы култыгы ягындагы җирләр, Иран һәм Һиндстан белән мәдәни һәм икътисади элемтәләр ныгый. Моның мөһим нәтиҗәсе булып, гарәп мәдәниятенең гарәп-бәдәви мәдәнияте генә булудан туктавы, ягъни аның үсешенә төрле мөселман халыклары мәдәниятләренең тәэсире көчәю тора. Һөнәрчелек һәм сәүдә кайнаган шәһәрләрнең саны арту, аларның, үз чиратында, гыйльми һәм мәдәни үзәкләргә әйләнүе хәлифәттә география, тарих, астрономия, медицина өлкәләренә караган күпсанлы хезмәтләр язылуга китерә.

Әйтергә кирәк, беренче вакытта фәнни белемнәр антик чор язма мирасы, шулай ук Иранда һәм Һиндстанда иҗат ителгән хезмәтләрне гарәп теленә тәрҗемә итү аша туплана. Бигрәк тә Мамун хәлиф (813-833) идарә иткән елларда тәрҗемә эше киң җәелә. Юнан (грек) фәлсәфи фикере нигезендә гарәп фәлсәфәсе барлыкка килә, юнан мантыйк фәне (логика) мөселман дин белеме формалашуга зур йогынты ясый. Тәрҗемәләр аша дөньядагы күпчелек белемнәрне туплаган гарәп телен өйрәнүгә ихтыяҗ арта, бу исә, үз чиратында, гарәп теленең төрле күренешләрен фәнни өйрәнүгә сәбәп була. Габбасилар хәлифәте кешелек тарихына фән, мәгариф, фәлсәфә, мәдәниятнең зур тизлектә үсеше белән кереп кала. *(Фильштинский И.М. Арабская литература VIII – IX веков. М., 1978. С.7-8; Бартольд В.В. Культура мусульманства // БартольдВ.В. Сочинения. Т.6. М., 1966. С.163-173)*

Гыйлемнәрнең дәвамчанлыгын тәэмин итү өчен, VIII гасырда Басра, Күфә, Багдад һ.б. шундый зур шәһәрләрдә фарсыча «әнҗемәиданәш», грекча «академия» дип атала торган, яннарында бай китапханәләре булган гыйлем мәҗлесләре һәм фән йортлары төзелә. *(Мәрҗани Ш. «Мөкатдимәтекитабе «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф»тан кыскартылган тәрҗемәләр // Мәрҗани Ш. Сайланма әсәрләр. Казан, 2018. 77 б.)*

Ш.Мәрҗани беренче дүрт хәлиф, Өммәвиләр һәм Габбасилар хәлифәтләре заманында мөселманнар ясаган кайбер ачышларны санап чыга: 800 елда Багдадта беренче аптека ачу, 469–650 елларда беренче җил тегермәне төзү, 660-661 елларда гарәп саннарын, 900–1001 елларда беренче шикәр куллана башлау, көпчәкләрне хәрәкәткә китерә торган механизмнар уйлап чыгару, шул исәптән, 760-761 елларда беренче механик сәгать эшләү, туп, дары, мылтык кебек кораллар уйлап табу, ефәктән, мамыктан, киндер сүсеннән кәгазь җитештерү, диңгез-океаннарда яңа утраулар ачу һ.б. *(Мәрҗани Ш. «Мөкатдимәтекитабе «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхляф»тан кыскартылган тәрҗемәләр // Мәрҗани Ш. Сайланма әсәрләр. Казан, 2018. 78-80 б.)*

Гарәбстаннан читтәрәк ислам цивилизациясенең төбәк вариантлары барлыкка килә һәм мөселман язма телләре формалаша. Аларның уртак яклары дип гарәп графикасын, гарәп һәм фарсы сүзләрен күп куллануны күрсәтергә кирәк. Төрки тел мөселманнарның язма теленә әверелә. XII гасырда миссионерлар исламны тарату өчен дини әсәрләрне төрки телдә яза башлыйлар дип, В.В.Бартольд мисалга Әхмәд Ясәвине китерә. *(Бартольд В.В. Культура мусульманства. С.193).*

Гомумән, методологик яктан караганда, Урта Азиядә, Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урда, Казан ханлыгы һәм соңрак Россиядә яшәгән татарлар тудырган мәдәният дөньякүләм ислам мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып, аны үз казанышлары белән баета.

## Хәзәр каһанлыгында диннәр

VI–XI гасырларда төрки халыкларның Үзәк Азиядә, Себердә һәм Идел буендагы дәүләтчелек тамырлары мәшһүр һуннарга һәм Төрки каһанлыкка барып тоташа. Аның тарихи-мәдәни традицияләрен Уйгыр каһанлыгы, Югары Янәсәйдә (Енисей) Кыргызлар дәүләте, Иртеш буйларында кимаклар һәм кыпчаклар, Азов диңгезе буенча Бөек Болгар дәүләте һәм Хәзәр каһанлыгы, Идел-Чулман төбәгендә Болгар дәүләте дәвам итә.

Көнбатыш Төрки каһанлык хәлсезләнә башлагач, 630 нчы елларда аның җирләрендә

Кара диңгезнең төньяк ярларын, Кавказ тау итәген һәм Каспий үзәнлеген биләгән, халкы ярымкүчмә тормыш алып барган Бөек Болгар дәүләте оеша. 665 елда дәүләтнең җитәкчесе Кубрат вафатыннан соң берничә ел узгач, болгарлар Хәзәр каһанлыгына буйсыналар. Кубратның кайбер уллары мондый вазгыять белән ризалашмыйча, үз кабиләләрен алып, башка төбәкләргә китәләр. Әйтик, Аспарух исемле улы 680 елда Дунай елгасы буена күченеп, биредә Дунай Болгарстаны дәүләтен төзи.

Болгарлар һәм күчмән хәзәрләр тугандаш кавем булып, бер-берсенең телләрен аңлап, көн күрәләр. Аларның хуҗалык рәвеше һәм тормышлары да бер-берсенә охшаш, галимнәр алардан калган матди истәлекләрне Салты-маяк археологик культурасы дип атап йөртәләр *(Дәүләтшин Г.М. Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы. Казан, 1999.31 б.).* Хәзәр каһанлыгындагы кабилә-халыклар берләшмәсендә болгарларның урыны югары була.

Инде билгеләп үткәнчә, хәзерге Россия территориясендә ислам дине таралу гарәпләрнең VIII гасырда Төньяк Кавказга, бу җирләрдәге байлыкка кызыгып ясаган һөҗүмнәре белән бәйле.

Ул заманда сәяси тормышка һәм халыкара мөнәсәбәтләргә диннәрнең йогынтысы гаять зур булу сәбәпле, гарәпләргә бәйлелеккә төшкән Хәзәр каһаны 737 елда ислам динен кабул итә һәм, шул рәвешле, дәүләтнең хәлифәткә буйсынуын таный. Урта гасыр сәяси һәм мәдәни күзлегеннән караганда, каһанның ислам дине кабул итүе Хәзәр дәүләтенең рәсми рәвештә ислам дине кабул итүенә тиң була. Моны Хәзәр дәүләте башкаласы Итилдә гарәп шрифтында, куфи язуы белән гарәп дирһәмнәре сугылу һәм аларны хәзерге археологларның күпләп табулары раслый *(Мухамадиев А.Г. Новый взгляд на историю гуннов, хазар, Великой Булгарии и Золотой Орды. Казань, 2011. С.35)*. Шушы вакыйгадан соң ислам дине төрки кабиләләр арасында тарала башлаган һәм аларның кайберләре исламны кабул иткәннәр дип әйтергә нигез бар. Ләкин Хәзәр каһанлыгында ислам диненең язмышы гарәпләр яулап алган башка җирләрдәге кебек булып чыкмый. Биредә ислам төп дин булып китми: ислам динен кабул итүне үлемнән котылу һәм тәхетен саклау чарасы дип караган каһан, яулап алу куркынычы бетүгә, кабат яһүди диненә кайта.

Йомгаклап әйткәндә, Хәзәр дәүләтендә берничә конфессиональ төркем аерылып тора: хакимиятне үз кулларында тоткан яһүдләр, тәңрегә табынучы мәҗүси төрки күчмәннәр, мөселман төркиләр һәм шәһәрләрдә яшәүче христианнар. Бу хакта X гасыр урталарында гарәп сәяхәтчесе әл-Истаһри каһанлыкның башкаласы булган Сәмәндәрне сурәтләгәндә болай дип яза: «Яһүд динендәге каһанның сараенда якынча 4 мең кеше яши: хәзәр мөселманнары, христианнар, сыннарга табынучылар һәм яһүдиләр; яһүдиләр – азчылыкны, мөселманнар күпчелекне тәшкил итә. Башкалада, шулай ук, яһүди, мөселман, христиан һәм сыннарга табынучыларның мәхкамә эшләрен тикшереп карар чыгаручы җиде хәким бар». *(Большаков О. Ал-Истахри – Ибн Хаукаль // История татар с древнейших времен. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. Казан, 2005. С.747).*

Шушы дәвердә бер төркем болгарлар, Идел елгасы яры буйлап төньякка таба хәрәкәт итеп, Идел-Чулман төбәгенә килеп урнаша. Тарихчылар, археологик казылмаларны һәм каберлекләрне өйрәнеп, болгар кабиләләре бу җирләргә берничә дулкын булып күченгән, дигән фикердә торалар. Гарәпләрнең 737 елгы һөҗүменнән соң бер төркем болгарлар Идел-Чулман буйларына килгән булалар. Күрәсең, бу күченү гарәп баскыннарының үткен кылычыннан котылу һәм исән калу белән бәйледер. Хәзәр каһанлыгында хакимият яһүдләр кулына күчү мәҗүси һәм күчмән менталитетлы төрки кабиләләр җитәкчеләре арасында башта – аерымлану, соңрак килешмәүгә сәбәп була. Яһүдләрнең күчмәннәр арасында үз диннәрен тарату сәясәте далада зур ризасызлык тудыра, бер үк вакытта кайбер мәҗүси кабиләләр яһүди динен кабул итә. Шушы дини каршылык тагын бер төркем болгар кабиләләренең Урта Идел буена күченүенә китерә. Яңа җирләргә соңгы күченү IX гасыр азагы – X йөз башына карый, Хәзәр каһанлыгына

күчмәннәр һөҗүмнәре нәтиҗәсендә илдәге тотрыксызлык белән аңлатыла[1]. *(Хузин Ф.Ш. Булгарский город в X – начале XIII вв. Казань, 2001. С.52-61).*

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

[1] Идел буе Болгар дәүләте (әмирлеге) тарихын өйрәнү илебез тарих фәнендә һәрвакыт диярлек үзәктә булды. Ш.Мәрҗaнинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) исемле хезмәтендәге болгарлар татар халкы оешуының төп нигез ташы дигән фикер бәян ителә. XX гасыр башында татар историографиясе төрки-татар концепциясен алга куеп эшләсә дә, Болгар тарихы Ф. Халиди, М. Рәмзи, Р. Фәхретдин, Г. Әхмәров фәнни эшләрендә дәвам ителде. Совет хакимияте урнашкач, 1920 елларда Болгар дәүләтенә кагылышлы сюжетлар В.В. Бартольд, М.Г. Худяков, В.Ф. Смолин, Г. Гобәйдуллин басмаларында урын алды.
Бөек Ватан сугышыннан соң СССР Фәннәр академиясенең 1946 елда булып узган фәнни сессиясендә рәсми рәвештә казан татарларының килеп чыгышы Идел буе болгарларыннан башлана дигән карар кабул ителде. Бу вакыйга ТАССР һәм РСФСР фәнни үзәкләрендә Болгар тарихын өйрәнүне алгы планга чыгарды. Беренче чиратта, археологларның Болгарның матди истәлекләрен өйрәнүдә искиткеч зур хезмәт куюларын әйтергә кирәк. Болгарлар турында төп хезмәтләрне дә алар язды. Биредә Совет чоры галимнәреннән А.П. Смирнов, Н.Ф. Калинин, В.Ф. Генинг, А.Х. Халиков, Е.П. Казаков, Н.Я. Мерперт, Е.А. Халикова, Р.Г. Фәхретдинов, Ф.Ш. Хуҗин, И.Л. Измайлов исемнәрен атап китү урынлы.
Болгарларың рухи мәдәнияте, Идел-Чулман төбәгендә ислам дине һәм аның җәмгыять тормышына, фән һәм мәгарифкә, көнкүрешкә һәм гореф-гадәтләргә йогынтысын өйрәнгәндә Г.М. Дәүләтшинның фундаменталь хезмәтләре алыштыргысыз чыганак булып тора.

## 2022 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

### МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1443-1444 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**3 февраль** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**27 февраль** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**17 март** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн.

**2 апрель** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**1, 2, 3 май** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**8-9 июль** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**9 июль** – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә.

**10, 11 июль** – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус сүзләр әйтәләр.

**30 июль** – 1444 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**8 август** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**7 октябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне.

*Төзүче-мөхәррир* – **Хаҗи Абдулла ДУБИН**

# ӘЛКИ ӘЛЛӘ ӘЛЛҮКИМЕ?

Әлки авылы халкына бу сәер соравымны 1972 елгы Сабан туена театр белән гастрольгә килеп чыккач биргән идем. Авыл тулы кунак. Гармун тавышлары бер генә мизгелгә дә тынып тормый. Искиткеч матур тавышлы яшьләр аларга кушылып, яңадан-яңа җырлар җырлыйлар. Без алып килгән «Әтиең мин синең!» спектакленә дә билетлар күптән сатылып беткән. Ул вакытларда Әлки авылы клубының тамаша залы кайбер мәдәният йортларыныкыннан да зуррак иде. Хәтта Базарлы Матакта да андагыдай – артистлар җанына май булып ята торган шыгрым тулы залда, алма төшәрлек урын да калмаган аншлагны күрмәдек! Ничек инде минем күңел авыл кадәр авылны иләсләндергән күтәренке рухтан исерми калсын да: «Әлки – Әл көй, Әллүки – Әллү көй, бәллү көй түгелме?» – дигән фантастик фаразлы сорауны бирмәсен?! Әллүкинең сүзләре Тукайныкы икәнен дә беләм, ә бит аның көе – халыкныкы. Тирән мәгънәгә ия бу көй, бәлки, шушындый милли рухлы мәдәниятен саклаган җырлы-моңлы Әлки авылларында тугандыр? Читтә эшләп йөреп, туган авылына кунакка кайткан әлкиләләр арасында ник бер исереп, ямьсезләнеп йөргән кеше күренсен?

Әсхәт Хисмәтне ул чорда әле белми идем. Армия хезмәтем мине шушы авыл егете Дамир белән Мурманск шәһәре аэропортының (безнең хәрби аэродром шунда иде) Килп-яр бистәсендә очраштырды. Әлкинең бөтен гүзәл сыйфатларын үзенә җыйган эре сөякле, гайрәтле, беркайчан да мактанмый, шырланып, кеше көлдерми торган, нинди генә эшкә тотынса да, җиренә җиткереп башкаручы бу уңган егет аркылы миңа әлкиләләрнең тагын бер кызык ягы ачылды. Хезмәттәшләрем Доценко, Сорокопудов, Епишкин, Меликовскийлар бик кыстагач, отпусктан яшереп кенә, берничә шешә «Старка» дигән эчемлек алып килгән идем. Шуларны бушатып, бәйрәм иткәндә, генерал малае Доценко, үзләре белән табынны бүлешмәгәнгәме, мине рәнҗетерлек сүз әйтте. Мин кулыма тоттырган стаканны рәхмәт әйтеп, өстәлгә куйгач, тагы да тозлы-борычлысын өстәде. Шунда Әлки малае Дамир иpләп кенә аны урамга алып чыгып китте. Алар арасында ни булгандыр (өлкән сержантның сер итеп кенә әйткән гайбәтендә Дамир Володяны суккан саен тәгәрәтеп торган), бер Алла белә, әмма тәмам айнып кергән генерал малае миннән гафу үтенгән иде. Дамир турында сүзне озайтмыйм, мәгәр, нәкъ шул авылдашының сыйфатларын төсмерләп, Әсхәтне дә бик якын итә башладым. Аллаһыбыз Әсхәткә зур артистка кирәк булган талантны гына түгел, чын кеше булыр өчен кирәкле сыйфатларны да кызганмый биргән. Яшь артистлар аны аеруча үз итә. Театрда ул биләгән урынга күтәрелү һәм олы хөрмәткә ирешү өчен кешедән чиксез тырышлык та сорала. Ә бит без, элек яшәгән катлаулы чорны бүгенгебез белән чагыштырып, әлеге совет заманына өстенлекне бирсәк тә, анда да бик күп талантларыбыз саташты, юлдан ук язып, бөтенләйгә югалды. Ә менә Әсхәт, затлы авылның затлы гаиләсендә тәрбия күргән әлкиләләрчә, ул чакларда да туктаусыз үсештә булды, бүген дә гөрләтеп яши. Г.Камал театрын аңардан башка күз алдына китерүе дә кыен. Кайсы гына эшне аңа йөкләмәде театр, ул һәрвакыт аны җиренә җиткереп башкарды. Артистларыбызның: «Хәтта мәрхүмнәр дә Әсхәткә бакый дөньяларыннан рәхмәт юллап ятадыр», – диюләре юкка түгел. Театрның кайгыга баткан кешеләре, якыннарының үлеменнән каушап, мәрхүмнәрен соңгы юлга озатып

йөргәндә, барысын да җиренә җиткереп оештыра белүчеләр элек тә күп түгел иде – бүген инде бөтенләй юкка чыгып бара. Әле ярый иман, дин тернәкләнеп килә. Әйе, Әсхәт зур артист булуына карамастан, һич зарланмыйча, кыйммәтле вакытын шушы читен, әмма дә изге эшләрнең берсенә багышлап, тормыш көтә. Өстәвенә бер дигән тамада да бит әле ул безнең. Аның кул астында теләсә кайсы бәйрәмнең онытылмаслык булып узасын белеп, кемнәр генә аны түренә утыртмый?!.

Кабат яраткан Әлкиебезне искә алыйк әле. Беренче килүебездә үк, үзем дә белмичә, Әсхәтнең сәнгать белән җенләнгән гаиләсенә фатирга төшкәнмен. Рәхилә апа белән Әсәдулла абый театр белән саташкан балаларына мине үзләрендә кундырырга рөхсәт биргәннәр. Соңрак та Рәхилә апа: «Әпеш килсә, үзебезгә алып кайтыгыз», – дия торган булган. Әпеш – Рәфкать Бикчәнтәев куйган «Әтиең мин синең» спектаклендә мин башкарган Апуш роле. Безнең әлеге спектакльне әлкилеләр бертуктаусыз алкышлап карадылар. Спектакльдән алган җан рәхәте, Әсхәтләр өенә дә ияреп кайтып, хуҗалар белән бик иркенләп сөйләшеп утырырга мөмкинлек тудырды. Аларның Әсхәтне шулчаклы да яратуы миңа да күчеп, мин инде аны үзебез белән бер табында утырган кебек хис итә башлаган идем. Әлкидән комбайнчы ярдәмчесе булып эшләп киткән Әсхәтнең Казанда төзүче булуын да, эштән бушап торганда, вакытын мәдәният йортының ансамбль концертларында уздырганын да сөйләделәр. Әсхәтнекедәй җанга якын матур тавышка ия сеңлесе абыйсының җырчы булырга хыяллануын да чиште. Кайчандыр Камал театрында Булатны уйнаган артист, композитор һәм шәп җитәкче Мәсгут Имашевның аңа зур киләчәк фаразлаганын да белдем мин бу кичтә. Шулай итеп, бик күп кешенең гомерен ашаган сугышта да сынатмаган Әсәдулла абый һәм таң калырлык шагыйранә күңелле Рәхилә апа гаиләсе, аларның әтием-әнием дип өзелеп торган бала-чагасы белән ике арада бик җиңел генә гомерлек дуслык урнашты.

Габдулла Шамуков, Рәфкать Бикчәнтәев кебек остазларымнан: «Син, Юныс, үзең күргән, үзең белгән тормыш, кешеләр турында яз, чит ил китапларын укып, шуннан алынган ясалма калыпларга безнең кешеләрне бөкләп тыкма, безнең чынбарлыкны кеше аңламаслык итеп укмаштырма, чөнки, чит ил укучысына да җансыз, тамырсыз, ясалма дөнья кызык түгел!» – дигән үгет-нәсихәтләрен еш ишеттем. Һәм менә җирдә нык басып торучы Әсхәт турында язганда да, остазларым өйрәткәнчә, үзем яхшы белгән, минем әсәрләрем буенча куелган спектакльләрдә үзенә генә хас образлар тудырган, инде 36 ел буе бакчам күршесе дә булып торучы, бакчама комсыз кешеләр кул сузганда, мин фәкыйрегезне судка барып яклашып та йөргән Әсхәт Хисмәт турында язам.

Әмма аның төп хезмәте сәхнә түрендә. Ул – меңләгән тамашачының сөеклесе. Мине Марсель абый театрга алганда, Әсхәт инде Камалның танылып килүче артисты иде. Марсель абыйга аны атаклы Мәсгут Имашев үзе алып килә. Марсель абый аңа, үзе укыткан икенче курска ук алып, сәхнә белеме бирә. Театрның баш режиссёры кебек үк, директоры Шамил Закиров та, Әсхәтне, Марсель абыйдан көнләшә-көнләшә, үзенеке итеп күрергә тели. Ничек инде шулай булмасын, Әсхәт өметле артист кына түгел, директорның уң кулы булырлык шәп профком рәисе дә.

Режиссёр Дамир Сиразиев 1981 елны «Алмазбулат»ны куя башлагач: «Кияү Җен итеп кемне күрәсең?» – диде.

Әсхәт уйнаса шәп булыр иде дә, тик куркам, ул, яшь булса да, инде Мирсәет, Җәмил, Ильяс кебек геройларны уйный торган күренекле артист – миндәге бер сүзле Кияү Җенгә алынырмы?

Гаҗәп, Әсхәт алынып кына калмады, Кияү Җеннең онытылмаслык образын тудырды. Артистлар Кияү Җеннең Кәләш Җенгә (Фирдәвес Хәйруллина): «Яратасың да инде биергә!» – дигән сүзләрен, Әсхәт кебек әйтергә тырышып, гел кабатлап йөрделәр. Әмма татар теленең бөтен нечкәлекләрен белгән, музыкаль ишетү сәләте белән дә бүләкләнгән артист, әлеге репликаны мең дә бер төрле итеп тә әйтә ала иде.

һәм менә без Дамир белән, «Ләйсән ире Хәсән»не дә сәхнәләштерә башлагач, кабат Әсхәтне искә төшердек. Дамир бу рольдә башка артистны күзалласа да, мин беренче составка Әсхәтне алырга киңәш иттем. Хәсәннең сүзләрен кыскартырга кирәк була бит, дигәч, киресенчә, син әле Әсхәткә миннән яңа сүзләр дә яздырачаксың, дидем. Һәм шулай булды да. Дамир Әсхәт Хәсәне өчен композитордан хәтта җыр да яздырды. Бу чорда бик үк тулы булмаган залларга уйнаучы спектакльләребез дә бар иде. Ә «Ләйсән ире Хәсән» һәрвакыт тулы залларда узды. «Халык йөрми торган спектакль билетларын «Ләйсән ире Хәсән»дә басып карарга сатып, план үтибез!» – дия иде театрның «бичурасы», инде мәрхүм Шамил Зиннурович. Мондый уңышта төп рольдә уйнаучы артистның да өлеше, һичшиксез, зур була.

Әсхәт Хисмәт комик артистлардан саналмый. Аны милли театрның йөзек кашыннан саналучы җырчы артисты, диләр. Мәгәр, Әсхәт – күпкырлы артист. Камал театрының беренче номерлы комигы Равил Шәрәфи дә кызыгырлык комик образлары да бар аның. Шуларның беренчесе – Гелүс. Репертуарга без Дамир белән бергә бик тырышып, Илдар Юзеевнең «Улыбыз өйләнә, без – аерылышабыз» дигән әсәрен керткән идек. Мәктәп яшеннән чыгарга өлгермәгән Гелүс белән Нәзнинә өйләнешеп йөргәндә, Гелүснең ата-анасы, авызларыннан ана сөте кибәргә дә өлгермәгән бу яшь парны фатирлы итәр өчен, «аерылышып» йөри. Исәпләре – шундый юл белән яңа фатир яулап алу. Кабат, Дамирның яраткан гадәте буенча, кайсы артистка нинди роль бирергә икән дип, киңәшергә керештек. Дамир, Әсхәтнең җырчы икәнен дә искә төшереп, аңа Әбүзәр ролен бирмәкче. Бу уңайдан шундый мөһим нәрсәгә игътибар итик: Илдар Юзеевнең әлеге карт буйдакны үз әсәренә Гелүс белән капма-каршы куеп кертеп җибәрүе зур табыш иде. Өстәвенә, драматург күтәргән фикерне бик калку итеп ача торган Әбүзәр – Миңнурый сәхнәләре дә чын драматург кулы белән язылган. Режиссёрның Миңнурый роленә ихлас һәм гаҗәеп зур талантка ия Зөлфирә Зарипованы алуы да, бик уйлап, алга карап эшләнгән бер эш иде.

– Дамир, Гелүсне Әсхәттән уйнат әле, – дигәч, режиссёрыбыз:

– Минем Гелүс бар инде, – дип җаваплады.

– Беләм, гәүдәсе дә малайларныкы дип мактадың...

– Нәзнинәм дә бар! Алар бер-берсенә бик пар киләләр.

– Пар килүләре Ромео белән Джульеттаны уйнаганда шәп була. Ә инде, төймә борынлы көчек кебек, чәң-чәң килеп торучы Гөрпинә-Аграфиняны, ягъни Нәзнинәне калын җилкәсенә утыртып йөрүче пәһлеван гәүдәле Гелүс – нәкъ менә бүгенге яшьләр арасыннан. Ә Фәритнең Гелүсенә килсәк, укытучы апасына яшерен генә мәхәббәт тотып та, чынлыкта кызлар кулына кагылырга да курыккан малай. Әбүзәр әнә шуның инде үсеп җитеп картая ук башлаган капма-каршысы, – ди драматург. – Ә Әсхәт исә – парта арасында ук кызлар белән үбешеп, инде яшерен җимешләрдән дә авыз итәрлек булып үсеп җиткән зур күсәк. Кечкенә буйлы кызлар Әсхәт Гелүсе кебекләргә ябыша. Ә Фәриткә пар итеп, зур гәүдәле кыз алсаң, отышлырак буласы, рәхәтләнеп көләчәк тамашачың. Ике состав ике төрле мәгънә бирәчәк спектаклеңдә.

Илдар Юзеевнең «Бөркетләр кыяга оялый»сы (бездә, әйткәнемчә, «Улыбыз өйләнә, без – аерылышабыз») худсовет аша бик авырлык белән узган иде, әмма халык аңа ябырылып йөрде. Артистларны режиссёр, вакыт-вакыт бауларга ябыштырып, сәхнә буйлап очырткалап алса да, спектакльнең уңышы Равил Шәрәфи, Зөлфирә Зарипова, Ринат Таҗи, Наилә Гәрәй, Әсхәт кебек, драматург идеясен аңлап, шуны халыкка җиткерер өчен гаҗәеп кызыклы детальләр табып уйнаган артистлар кулында иде.

Дамирның Әсхәт белән Зөлфирәне бергә партнёрлар итәргә омтылуы да «Яшь йөрәкләр» спектаклендә тормышка ашты. Режиссёр Празат Исәнбәт куйган, Рәшит Газиев кебек талант иясе сәхнә бизәлешен иҗат иткән бу үтә милли спектакльгә тиң тамашаны минем әлегәчә күргәнем юк. Чын мәгънәсендә Яңарыш чоры спектакле иде ул. Безнең үтенечне үтәп, 80 яшьлек Габделхәбир хәзрәт белән мөфти Габдулла хәзрәтләр

дә, бу спектакльне камилләштерүгә лаеклы өлеш керттеләр. Спектакльдә укылган догалар да, авыл белән саубуллашучы егетләрнең үз-үзләрен итагатьле тотулары да җанга бик якын иде. Элекке куелышлардагы муллага дигән сәдака акчасын кайнар мич алдында кыздырып, мулла учына салгач, аның үрле-кырлы сикереп алуыннан көлүче җүләрләр юк иде инде анда. Халыкта җиргә мәтәлеп төшә башлаган самолётта бер генә Алласыз кеше дә калмый дигән сүз бар. Монда да үлем эченә китеп баручылар мулланы мыскыл итмиләр. Әмма спектакльнең җитди һәм төп уңышын бу куелышта режиссёрның оста мизансценалары да, рәссамның шәп сәхнә бизәлеше дә түгел, ә Әсхәт белән Зөлфирәнең гүзәл образлары тәэмин итте. Театр белгече Һ.Мәхмүтов сокланып биргән бәяне искә төшерик: «Әсхәт белән Зөлфирә ике саф күңелнең үзара мөнәсәбәтен үтә нечкә, эчкерсез, балаларча тыйнак итеп бирүгә ирешәләр...» Күренекле белгечнең сүзенә тагын тамашачыларның: «Нигә сәхнәдән шундый кәтәнә кешеләрне генә күрсәтеп, аларны үрнәк итеп куясыз?! Безне болай да ватаныбыз СССРда икенче сортлы кешеләр итеп калдырдылар. Без кемнән ким, сәхнәбездә генә булса да, күрсәтегез инде первосортный татарны – үзе кечкенә, үзе хәлсез, төссез кешеләр теләсә кайсы халыкта да бар. Башка милләтләрдә бит аларны милләтнең йөзек кашы итеп тәкъдим итмиләр. Театр, мактаулы исемнәр, дәрәҗәләр алып яшәр өчен дин әһелләрен мыскыл иткән күпме спектакль куйды. Авыллары белән кырып салган ачлык вакытларында байтак хөрмәтле муллаларның авылларны саклап калганын күрсәтегез әле бер...» – дигән сүзләрен өстисе килә.



*Әсхәт Хисмәт К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә Булат ролендә.*

Кыскасы, тамашачының йөрәген яулаган Әсхәтле, Зөлфирәле «Яшь йөрәкләр»ебез аша театрның даны бермә-бер күтәрелде.

Әсхәтнең Булатын күргән, чын ирләр тавышы белән җырлаган җыр-моңын ишеткән тамашачы һәм кулына бу мәкалә килеп кергән укучы нигә бу язманың авторы «Зәңгәр шәл»не һаман телгә алмый икән дип аптырыйдыр. Чыннан да, халык үзенең легендар шәхесләрен онытмый. Тамашачы күңелендә сакланган, театр тарихын бизәп торучы җырчы артистлар күп түгел шул. Әмма мин Әсхәтне әлеге җырчы артистлардан аерып торган, артист халкында бөтенләй дә диярлек очрамаган бер мактаулы ягын да өстәмәкче булам. Марсель абый «Идегәй» трагедиясен куйганда, Аңгысын ролен Әсхәткә бирде. Бик катлаулы эчтәлеккә ия, бөтен театр катнаша торган унике күренешле бу тарихи драманың мәгънәсе тамашачыга барып җитсен өчен нәкъ менә Әсхәтнең Аңгысыны кирәк иде. Ул әсәрдә үзенә бертөрле ачкыч ролен уйный. Әмма төп әйтәсе сүзем, Әсхәтнең бөтен спектакльгә юнәлеш биреп, таркатмый тота алучы шәхси сыйфаты турында. Спектакльне ул режиссёр ярдәмчесенә караганда да шәбрәк белеп, «Әнисәнең сәхнәгә чыгарга вакыты җитте, аңа хәбәр итче; Субра күренеше башланырга тора, сәхнә эшчесе күренми, декорациягә хилафлык килүе мөмкин; әйтегез, күмәк күренешкә чыгарга җыенучылар арасында студент Фәнис юк; Әзһар

абый, өстәге күзәтү мәйданына хәзер үк менә башласаң яхшы булмасмы» кебек бихисап борчылулары Әсхәтне спектакльнең иминлеген, сугышчан рухын саклап торучы, үзенә күрә бер гаскәр башлыгы кебек күрсәтә.

Чын милли җырчы артистлар арасында беренчелек Булат, Хәлил, Батырҗан, Исмәгыйль, Ильяс рольләрен татар тамашачысының җанына үтеп кererлек итеп башкарган Ситдыйк Айдаровка бирелгән дип беләбез. Минем кебек өлкән яшьтәге театр кешеләренең дә Айдаровны сәхнәдә күргәннәре юк. Аның каравы безгә Булат ролен уйнарга опера театрыннан килеп йөргән СССРның халык артисты Азат Аббасовны, артист, композитор һәм җырчы булу белән бергә, сәнгать дөньясында тагы башка күп игелекле эшләр башкарган Мәсгут Имашевны, тумышы белән үк Булат булган Наил Әюповны, шул исәптән театрның тарихында чын Булат булып урын алу бәхетенә ирешкән, өстәвенә «Казан сөлгесе»ндә Ильясны, «Яшь йөрәкләр»дә Хәйретдинне башкарган Әсхәт Хисмәтовны бик күп тапкырлар аягүрә баскан тамашачылар белән бергә алкышлау бәхете насыйп булды. Ходай Тәгалә тарафыннан Әсхәткә бүләк ителгән моңлы бай тавыш аны җырлы рольләрне башкаручы артист итеп санатса да, башта ук әйтеп куйганымча, ул – күпкырлы артист. Аның репертуарында Яңа ел бәйрәмнәренең алыштыргысыз Кыш бабае һәм ничәмә-ничә буын балаларыбызга милли аң өләшүче авыл эте Акбае бар. Аңа кадәр башка зур талантлар тудырган образларда да сынатмады Әсхәт Хисмәт. Әйтик, Марсель абый аңа «Әни килде»дәге Максуд ролен тапшырганда, Габдулла Шамуков кадәрле уйный алмаячак, диделәр. Миндә дә шундыйрак шик туган иде. Әмма Марсель абыйны премьера белән котларга кергәч, «Күрдеңме?!» дип, бер генә сүз әйтте бөек режиссёр. Әсхәтнең бу зур җиңүен башкалар да раслады. «Кара чикмән»дәге Ишәкнең артист репертуарындагы гомер онытылмаслык образлары янәшәсенә теркәлүен дә искә төшерик. Осетин театрының баш режиссёры Хугаев язган «Чёрная бурка» безнең репертуарга авторның М.Сәлимҗановтан үтенүе нәтиҗәсендә килеп керде. Марсель абый әсәрне миннән тәрҗемә иттереп, репетицияләргә дә тотынган иде. Әмма үлем аны бакый дөньяга озаткач, «Кара чикмән» баш режиссёр урынын алган Ф.Бикчәнтәевкә күчте. Ишәк ролен уйнарга тиешле Әсхәт Фәрит Рәфкатович кулына калгач, мин нык кына борчылып куйдым. Чөнки Әсхәт – баш-аягы белән Марсель абыйның яраткан артисты. Театрга яңалыклар кертү белән мавыккан Фәрит үз артистлары беләнрәк эшләргә ярата... Әмма, гаҗәпкә каршы, алар бик тиз уртак тел таптылар. Бер генә репетициясен дә калдырмыйча, яратып, сокланып карап барырга мәҗбүр итте мине бу гаҗәеп спектакльнең дөньяга килүе. Аңгыра дип даны чыккан ишәк урынына бик тә тырыш, хуҗалыктагы бөтен кара эшләрне эшләп баручы, чын татар ишәге дә туды бу гүзәл спектакльдә. Миңа Әсхәт ишәге Кыйканың киреләнеп куюлары да бик ошый иде. Шулай булырга тиеш тә – ачы тире чыкканның ачы теле дә чыга. Киң күңелле күндәм керәшен егете Бәчкене дә тамашачыбыз бик үз итте. Әсхәт Хисмәт тормыш биргән рольләр буенча халык күңеленә кереп урнашкан образларны санап бетереп буламыни бер кечкенә генә мәкаләдә. Шулай да «Җимерелгән бәхет»тәге Дерюгин белән «Өзелгән өмет»тәге Тетеревын һәм «Ханума»дагы грузин Акопын төшереп калдырып булмый; Әсхәтнең дингә каршы аяусыз көрәш барган чорда язылган «Зәңгәр шәл»дәге Ишаны да гаҗәеп килешле. Мин аны соңгы тапкыр караганда, хатадан беркем дә хали түгел дип утырдым. Әсхәт ишаны хатын-кызны артык нык ярата. Без әле әнә үзебез бер хатын белән дә мәш килеп алгалыйбыз. Зарланып та куйгалыйбыз. Ә монда бит алар бишәү. Ишан хәзрәтләре бу кадәр хатын-кыз белән үзенә-үзе җәза да бирә түгелме?! Пычрак күңелле, пычрак җанлы түгел Әсхәтнең ишаны. Бервакыт Нурихан Фәттах тәнкыйть мәкаләсе язып, «Тинчуринның Ишаны пычрак телле», дигән иде. Язучы килеп караган спектакльне хәтерлим – Ишанны ул көнне Шәүкәт Биктимеров уйнамады. Капка артында керә алмый торган Ишан, Галәвигә, күршеләр ишетер дип тә тормыйча, чукрак ишәк, дуңгыз, хайван дип акыра. Бу артист Ишан роленә кереп

кенә килә иде кебек. Аның ишәк, дуңгыз, хайван дигән сүзләре шулчаклы ямьсез булып яңгырый иде, әйтерсең, алар канау кырында сүгенеп утыручы бер исерек авызыннан чыга. Әсхәттә мондый дорфа тон юк. Әсхәтнең уенында мин бик яраткан артистым Хөсәен ага Уразиков чалымнарын да күргәлим. Ишанны ул 60 нчы елларда уйнады. Әсхәтнең аны күрүе икеле, шулай да аның уенында Хөсәен абый чалымнары да бар.

Марсель абый бакый дөньяга күчәрдән элек яраткан артистын Татарстанның халык артисты итәргә өлгерде. Шуннан бирле 19 ел үтте. Бик кызганыч, академия театрының төп артистларыннан саналган артистка Тукай премиясе дә, «Россиянең атказанган артисты» дигән мактаулы исем дә бирелмәде.

Әсхәт Хисмәтне кино артисты дип тә беләбез. Уннарча татар кинофильмнарында уйнап танылды ул. Аны тамашачы эстрада җырчысы итеп тә кабул итә. Әсхәт концертлары һәрчак тулы заллар җыя.

Әсхәт Хисмәт концертына килгән Илһам Шакировның, аны зурлап чәчәк биреп, затлы итеп котлавын күрү бәхете дә тигән иде безгә. Әсхәтнең М.Сәлимҗанов урамындагы дүрт бүлмәле фатирында, берничә көн буе Рәхилә апа һәм Әсәдулла абый белән сөйләшеп, аларның истәлекләрен магнитофон тасмаларына яздырып утырган идем. Әсәдулла абзый гаҗәп тыйнак итеп үзләренең сугыштагы авыр хәлләрдән ничек чыгуын сөйләгәндә, Рәхилә апа истәлекләре тоташ мәхәббәт, моң белән тулы иде. Их, берәр журналда язып чыгарасы иде шуларны, шушы кадәр рухи байлык укучыларга барып җитсен иде.

Әсәдулла абзыйларга Булат кебек оныкларын күрергә дә, аларның уңышларына сөенергә дә насыйп булды. Чыннан да, җыр, моң белән тулы гаиләдә тәрбияләнгән Булатыбыз, бабасы йөргән сукмаклардан барып, ярты Европага татар моңын яңгыратып кайтты. Әлбәттә, монда инде хатыны Рәшидә турында да бер-ике сүз әйтү сорала. Чөнки, Булат һәм аның сеңлесе Илсөярнең теләсә кайсы ата-ана шатланырлык милләт балалары булып үсеп җитүләрендә аның да өлеше бик зур бит. Рәшидәне курчак театрында артистка булып эшләгән чакларыннан ук беләбез. Театрның хөрмәтле, бик талантлы артисткасы булуына да карамастан, ул безнең Камал театрына күчеп килеп, Әсхәт Хисмәткә кияүгә чыкты. Артистка булып эшлисе килгәндер аның да, әмма алга карап, балаларының киләчәге хакына артист талантын корбан итте – гаиләдә берьюлы ике артист булганда, балаларга тиешле тәрбия биреп булмас, диптерме, башка эшкә алынды һәм ялгышмады, аның бу эше дә иҗат белән турыдан-туры бәйле.

Бу мәкалә язылганда, Әсхәт белән зурдан кубып аралашып, туктаусыз очрашып йөрергә мөмкинлек чыкмады. Ул баш-аягы белән театрның яңа куелып ята торган «Сәфәр»енә катнашып, көне-төне репетицияләр ясады. Премьерага бик аз вакыт калганлыктан, мин дә аңа комачауларга батырчылык итмәдем.

Яшь режиссёрның өр-яңа яшь автор белән эшләгән «Сәфәр»ендә Әсхәт Хисмәтнең Шакиры артык күп күренмәсә дә, төп фикерне ачуда мөһим образ булып җитеште. Милләтләрнең башын ашарга чыккан бәлаләр белән тулы заманда татар белән башкорт халкы арасындагы дуслыкның сыналса да, сынмавы кирәклеген ача анда Әсхәтнең тулы канлы образы. Шәт, иншалла, мондый зәһәр сынаулар аша үткән халыкларыбыз арасындагы дуслык яңарып, элеккесеннән дә ныграк булып әйләнеп кайтыр.

**Юныс САФИУЛЛИН,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

*Биектау районы – татар мәдәниятенә, әдәбият-сәнгатенә  бик күп мәшһүр шәхесләр биргән төбәк. Композиторлар Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров; артистлар һәм җырчылар Ситдыйк Айдаров, Галләм Саттаров, Азат Аббасов, Асия Харисова, Клара Хәйретдинова, Рауза Хәбибрахманова, Нариман Гарифуллин; язучылар Галимҗан Мөхәмитшин, Габдулла Шәрәфи, Хәй Вахит, Альберт Хәсәнов, Солтан Шәмси, Ләлә Сабирова, Ирек Сабиров, Рафис Корбан, Зиннур Хөснияр, Алмаз Гыймадиев... Хәсәнгата Габәши, Галимҗан Баруди, бертуган Һади һәм Садри Максудилар, Садретдин Назиров кебек дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, меценатлар...*

*Район Үзәк китапханәсе каршында бу төбәк авылларында яшәүче, күңелләрендә шигырь рухы яшәгән иҗатчыларны бергә туплаган «Каләмдәшләр» әдәби берләшмәсе эшләп килә. Шулар арасыннан берничә талантлы каләм әһеленең иҗат җимешләрен «Казан утлары» укучылары игътибарына тәкъдим итәбез.*

## Кышкы авыл

Урамда кыш... Ап-ак карлар ява,
Бар табигать акка төренә.
Зифа буйлы бөдрә каеннарның
Җиң очлары гына күренә.

Шул ак карга күмелеп авыл йоклый,
Рәхәт табып кышкы айлардан.
Мондый ачы зәһәр суыкларда
Җылы ала алар кайлардан?

Авыл йоклый... Бары буран гына
Өшетергә теләп җаннарны,
Бар көченә котырып, борын чөеп,
Әй туздыра ап-ак карларны!

**Рәзинә ГЫЙМАДИЕВА**
*Мәмдәл.*

## Күңелем Тукай белән сөйләшә

*Сибгат Хәкимгә ияреп*

Дөньяга ямь өстәп язлар җитсә,
Хыял белән өмет берләшә.
Хисләр ташып, кулга каләм алсам,
Күңелем Тукай белән сөйләшә.

Яз кояшы назлы нурын сипсә,
Күгәрченнәр күктә гөрләшә.
Ак кәгазьгә кайнар яшем тамса,
Күңелем Тукай белән сөйләшә.

Яшь йөрәккә дөрләп ялкын тулса,
Каләм белән хисләр көрәшә.
Авырлыклар очрап туктап калсам,
Күңелем Тукай белән сөйләшә.

Апрель җиткәч, сайрар сыерчыклар
«Туган тел»не миңа көйләшә.
Һәр яз киләм шагыйрь һәйкәленә,
Күңелем Тукай белән сөйләшә.

**Алисә СӘГЫЕВА**
*Сая.*

## Өмет уты

Кичкә таба эштән кайтып киләм,
Тирә-якны сарган караңгы.
Шугалакта ялгыз фонарь яна.
Әле дә ярый шул ут бар әле.

Мәктәп уты биш ел элек сүнде,
Клуб уты сүнде бу елны.
Өстәгеләр бераз уйлый микән
Шул утларсыз яшәү кыенны?

Шугалакта ялгыз фонарь яна,
Тирә-якны сарган караңгы.
Тик күнелдә өмет уты сүнми –
Әле дә ярый шул ут бар әле!

**Гомәр ГЫЙНИЯТОВ**
*Суыксу.*

## Йөрәк җылы эзли

Күзге җилләр җылы эзләгәндәй,
Тиле йөрәк көтә җылылык.
Җавап бирмәделәр синең хисләр,
Минем мәхәббәткә торырлык.

Мәхәббәттән йөрәк кайнап торса,
Җылыта хәтта көзге җилләрне.
Салкын карашларың өшеттеләр,
Көзге җилдәй минем хисләрне.

Хисләремнән көлеп йөрер булгач,
Нигә йөрәгемне яуладың?
Хыянәтнең нәрсә икәнлеген,
Еллар үткәч кенә аңладым.

**Диләрә ӘХМӘДУЛЛИНА**
*Сая.*

## Сабырлык

Әйтә иде әнием сабый чакта,
Бу сүз җанга уеп салырлык:
«Авыр чакта, балам, кыен чакта,
Ходай бирсен сиңа сабырлык».

Төрле вакыт булды дөнья булгач,
Азмы-күпме килде авырлык.
Безне дә бит саклап калды һаман
Әнә шушы олы сабырлык.

Үсеп, кеше булу өчен җирдә,
Әти-әнигә без сарылдык,
Түздек, үстек, кеше булыр өчен
Ярдәм итте безгә сабырлык.

Ел артыннан еллар уза торды,
Инде бездән гыйбрәт алырлык,
Һәм әйтерлек: ярый әле бездә
Яши әле, яши сабырлык!

**Гөлнар ИБРАҺИМОВА**
*Каенлык.*

## Сагынганда

Сагынганда хатлар язам сиңа,
Хатлар гына басмый сагышны.
Хатлар алгач, җан кисәгем минем,
Йөзләреңдә синең шатлыкмы?

Хатларымны бизим чәчәкләп
Йөрәгемнән чыккан сүзләрдән.
Үзем язам, үзем сине уйлыйм,
Агыла моң зәңгәр күзләрдән.

Хатлар язам сиңа утырып,
Сагышлардан күңел тулганда.
Сагыну бит ул кайгы түгел,
Сагынырлык кешең булганда.

**Ринат САБИРҖАНОВ**
*Казаклар.*

***

Сүкмәгез көзнең яңгырын,
Туңмагыз җилләрендә.
Туган якны калдырганның
Моң-зар ул иңнәрендә.

Тәрәз артында сызгыра,
Сагындым дия-дия.
Кайтыр идем туган якка
Башларым ия-ия.

Моң булып күз яше тама,
Йөрәк ала талпынып.
Мичкә яккан ак пәрдәле
Җылы өйне сагынып.

Көзге ачы җилгә чыгып,
Кошларны озатыйкчы.
Туган якларга бер кайтып,
Күңелне юатыйкчы.

**Мәнзума СИБГАТУЛЛИНА**
*Биектау*.

***

«Назларыңны бүләк итсәң,
Үлсәм – үкенмәс идем!» –
Өзелеп яратмасам,
Мин болай димәс идем.

Назларыңны татыдым да,
Инде килми үләсе,
Килә сиңа сыенасы,
Онытылып сөясе.

Бераз гына күрми торсам,
Килә кабат күрәсе,
Иңнәреңә үреләсе,
Иренеңнән үбәсе.

Беркемгә дә сөйләмәгән
Серләремне сөйлисе,
Болыннардан чәчәк җыеп,
Чәчләреңә сибәсе.

Сиңа гына хисләремнең
Иң кайнары, иләсе,
«Үлсәм – үкенмәс идем»ем
Булган тукран тәүбәсе.

**Фирая АБДУЛЛИНА,**
*Мәмдәл.*

## Кара күлмәк

Ялгызлык – кара күлмәк,
Күп гомер кигәнемә.
Бәясе чиксез кыйммәт –
Алмаштым сөйгәнемә.

Үлчәмен җилләр алган,
Изүен төннәр уйган.
Тукыма-төймәләре
Оешкан сагыш-уйдан.

«Кулларың тик тормасын!» –
Җиңнәрем сызгандырган.
Ялгызлык караңгысы
Күпләрдән кызгандырган.

Иркенрәк итәк-чабу,
Чикләми адымнарны.
Тик... саксыз кабалану
Бизәми ханымнарны.


«Тегүче» нигә, димен,
Корычтан иткән җөен?
Шартлаган көнен җөйнең
Көтепләр йөргән көем.

Анадан-тума калып,
Атасым килә салып!
Әй, язмыш – оста кырыс! –
Кабатлый: «Ныграк тырыш!»

**Зөһрә ХӘКИМУЛЛИНА**
*Олы Битаман.*

*Шагыйрь Зөлфәтнең тууына – 75 ел*

# АНЫ ӘЛЕ ҺАМАН ЯРАТАЛАР



Әдәби әсәр өчен чын мәгънәсендәге сыналу чоры аны тудырган каләм иясе бакыйлыкка күчкәннән соң башлана. Узган гасырның икенче яртысында туып-үскәннәрнең күңелен әсир иткән шагыйрь Зөлфәтнең (Дөлфәт Госман улы Маликов) иҗаты, өйрәнеп баксак, әнә шул җиз иләкне үтеп, яңа буын яшьләрнең рухи дөньясында да үз урынын тапкан икән. Шагыйрьнең тууына 75 ел тулу уңаеннан тапшырулар әзерләгәндә, бу хәл аермачык чагылыш тапты. Аның композитор Фәрит Хатыйпов белән берлектә иҗат ителгән «Һаман яратам» дигән мәшһүр җырын гына алыйк. Татарстан радиосы фондында аның дистәләгән җырчы тарафыннан башкарылган язмасы саклана. Үз вакытында аны Илһам Шакиров һәм Рәбига Сибгатуллина беренче булып, сәхнәгә алып чыккан. Аннары төрле елларда без җырны Миңгол Галиев, Зилә Сөнгатуллина, Мирсәет Сөнгатуллин, Рөстәм Закиров, Илшат Вәлиев башкаруында ишеттек. Әле бит магнитофон тасмасына язылмыйча калганнары никадәр! Бу җырга мөрәҗәгать итмәгән профессиональ яисә һәвәскәр җырчы булдымы икән? Сәхнәдә генә түгел, «Һаман яратам» туйларда, туган көн мәҗлесләрендә, солдатка озату кичәләрендә һәрчак табын түрендә булды, халык аны үзе җырлады. Һәм менә бу җыр бүген инде әнә шул буын кешеләренең балалары, оныклары телендә.

Шагыйрьне искә алу көннәрендә аңа кагылышлы язмалар янә бер барлап чыгылды. Шигырьләреннән һәм аларга язылган җырлардан әдәби-музыкаль композиция төзелде. Айрат Арсланов һәм Фәннүр Мөхәммәтҗанов укуында әдәби композицияләр эфирга чыкты. «Яфрак төшкән инде җиргә» (Шамил Шәрифуллин музыкасы), «Чатырлар» (Татар халык көе), «Сагынуга дәва юк икән» (Зиннур Гыйбадуллин) кебек җырлар радио концертларында еш яңгырый, чөнки беләбез: халык аларны көтеп ала.

Зөлфәтнең юбилей елын дәвам иттереп, киләчәктә балалар өчен язылган «Мәкерле песи» операсын (Зөлфәт либреттосы, Луиза Хәйретдинова музыкасы) һәм Мәсгудә Шәмсетдинованың «Сөембикә бәете» исемле поэма-композициясен (Зөлфәт шигырьләре) эфирга бирү күздә тотыла. Шулай ук фонд язмалары арасыннан шагыйрьнең тавышы кергән язмаларны ачыклау дәвам итә, төрле әдәби кичәләрдә, Г.Тукайның туган көнендә ел саен үткәрелә торган шигъри митингларда ясаган чыгышлары аерып алына. Ә хәзер исә укучыларыбыз игътибарына без Зөлфәтнең үзе укуында ике шигырен тәкъдим итәбез. Язма 1970 елларга карый. Шулай ук сез биредә шагыйрьнең 1992 елда Шигырь бәйрәмендә ясаган чыгышын ишетерсез.

Әйткәнебезчә, Зөлфәткә кагылышлы аудиоязмаларны эзләү дәвам итә, без шушы эшебез турында аның юбилей елы ахырында журнал укучылар алдында хисап бирербез.

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,*
*тапшыруны тыңлый аласыз.*

# БАЛАЛАРНЫҢ ЯКЫН ДУСТЫ



Танылган язучы, журналист һәм рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Дания Гайнетдинова 1952 елның 2 гыйнварында Теләче районының Олы Тиләҗи авылында дөньяга килгән. Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаганнан соң, хезмәт юлын 1975 елда Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләүдән башлый. Шул елларда республика матбугатында беренче иҗат тәҗрибәләре – шигырьләре, нәсерләре, рецензияләре басыла. 1984 елда Д.Гайнетдинова Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Әдәби фонд оешмасына эшкә күчә. Күренекле әдипләр белән аралашу, иҗат остаханәләре эшендә катнашу яшь каләмнең әдәби осталыгын һәм иҗат активлыгын үстерүгә уңай йогынты ясый.

Шулай да аның иҗат юлының иң зур өлеше Татарстан радиосы белән бәйләнгән. 1991 елда ул балалар һәм яшүсмерләр өчен тапшырулар редакциясенә өлкән мөхәррир булып килә һәм бик тиздән язмышына язылган бер эш булуын аңлап ала. Шул вакыттан бирле Дания ханым «Гөлбакча», «Көмеш кыңгырау», «Сердәшханә», «Язучылар – балаларга», «Табигать дуслары» тапшыруларының алыштыргысыз авторы һәм мөхәррире. Ул биредә радиодраматург буларак та ачылды, аның тарафыннан татар һәм чит ил авторларының әсәрләре буенча дистәләгән радиоспектакльләр эшләнде. 1995 елда балалар өчен иң яхшы радиопостановкаларга Россия күләмендә оештырылган конкурста җиңеп чыкты. Авторның «Яңа ел төнендә», «Тылсым дөньясы», «Әкият иленә сәяхәт» кебек эчтәлекләре белән мавыктыргыч та, маҗаралы да, тәрбияви дә радиоспектакльләре Татарстан радиосы фондында саклана.

Радиода эшләгән елларында Дания Гайнетдинова халык яратып кабул иткән җырлар авторы буларак та танылды. Журнал укучылар игътибарына аның шигырьләреннән һәм аларга иҗат ителгән җырлардан төзелгән радиокомпозиция тәкъдим итәбез. Ходай биргән гомернең һәр мизгеленнән тәм табып, саулыкта-сәламәтлектә иҗат итәргә язсын Сезгә, Дания ханым!

*Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

**РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ «ТАТМЕДИА»ДА**

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов шәһәр һәм район массакүләм матбугат чаралары вәкилләренә 31 яңа автомобиль тапшырды. Автомобильләргә сертификатны «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков кабул итеп алды. Р.Миңнеханов «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында да булып, яңа җиһазларны карады. Анда аны Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев белән комплексның генераль директоры Әнәс Әскәров озатып йөрде. Аннары Президент журналистлар белән әңгәмә үткәрде.

**СӘФӘРОВ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгат Сәфәров «ТАТМЕДИА»да татар телендәге мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашты. Анда сүз киләчәктә хәл итәсе мәсьәләләр турында барды, күпьеллык нәтиҗәле хезмәт өчен бер төркем журналистларга Рәхмәт хатлары тапшырылды.

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НДА КУНАКТА – АТАКЛЫ МАТЕМАТИК**

«Казан утлары» журналы редакциясендә милләттәшебез, атаклы математик, Мәскәү дәүләт университеты профессоры, Ломоносов исемендәге премия лауреаты Иҗат Хак улы Сабитовны кабул иттек. Быел аңа КФУда ике елга бер бирелә торган Лобачевский исемендәге халыкара премия тапшырылды. И.Сабитовның бабасы Сәрвәретдин – Ризаэддин Фәхретдиновның дусты, дин белгече, җәдидче, гуманист, философ, әтисе Хак Сабитов җәлилче Әхмәт Симаевның хезмәттәше булган. Гомере буена татарлар арасында яшәмәсә дә, И.Сабитовның туган телен камил белүе сокландырды. Ул шигырьләр дә яза. Аның сүзләренә язылган җырлар да бар. Очрашуда Иҗат Сабитовның улы Денис та катнашты.

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ – 75 ЯШЬ**

Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевкә 75 яшь тулды. Казандагы «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә яңгыраган котлаулар, шигырьләр, җырлар, әсәрләрдән өзекләр белән үрелеп барган, «Көзге моң» дип аталган әдәби-музыкаль кичә (режиссёры Лима Кустабаева) әдипнең юбилеена багышланды. Бәйрәмдарны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов (ул М.Галиевкә Президентыбыз исеменнән «ТАССР төзелүгә 100 ел» медален тапшырды), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, якташлары, Азнакай шәһәре хакимияте башлыгы Марсель Шәйдуллин җитәкчелегендә зур төркем (М.Шәйдуллин М.Галиевне Азнакай районының мактаулы гражданины итеп игълан итү турындагы карарны ирештерде), «Татнефть» гаммәви акционерлык җәмгыятенең «Рухият» фонды редакторы Рамил Миңнуллин һ.б. котлады. Г.Камал театры артистлары Илдус Әхмәтҗанов, Фәнис Җиһанша, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, яшь шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Гөлүсә Батталова, Фәнил Гыйләҗев, Лилия Гыйбадуллина, Эльмира Җәлилова әдипнең шигырьләрен, әсәрләреннән өзекләр укыдылар. Филүс Каһиров, Рөстәм Насыйбуллин, Резидә Шәрәфиева, Равил Галиев, Алмаз Хәмзин (ул каләмдәшенең юмористик хикәясен дә укыды), Артур Минһаҗев, Рамил Миндияр, Сәйдә Мөхәммәтҗанова юбиляр сүзләренә язылган җырларны башкардылар. «Сәйдәш» мәдәният үзәге бию ансамбленең чыгышы да ямь өстенә ямь булды. Кичәнең башыннан ахырына кадәр сәхнәдә Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» оркестры уйнады.

**ЯҢА КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ**

КФУның филология һәм массакүләм багланышлар институтының Актлар залында язучы, әдәбият галиме, профессор,ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Тәлгат Галиуллинның «Татар әреме» китабын тәкъдим итүгә багышланган чара (сценарий авторы – профессор Нурфия Йосыпова) үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, университетның уку-укыту эшләре буенча проректоры Тимерхан Алишев, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, әдәбият галимнәре Фоат Галимуллин, Әлфәт Закирҗанов чыгыш ясады. Академиклар Дания Заһидуллина, Наил Вәлиев, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, шагыйрә, әдипнең хәләл җефете Фәүзия Солтанның (Галиуллина) видеокотлаулары ирештерелде. Чыгышлар әсәрләрдән

өзекләр уку (Илфак Хафизов), институтның бию ансамле чыгышлары, җыр-музыка белән үрелеп барды. Кичәнең нәзари өлешен – татар әдәбияты кафедрасы мөдире, профессор Флёра Сәйфуллина, сәнгати өлешен К.Тинчурин театры артистлары, Т.Галиуллинның элекке студентлары Резеда Сәлахова белән Артём Пискунов алып бардылар.

## ҖИҢҮЧЕЛӘРЕБЕЗНЕ КОТЛАУ

«ТАТМЕДИА»ның конференцияләр залында ел буена «Казан утлары» журналында барган, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе белән бергә оештырылган «Аһ, туган каумем газиз!» дип аталган ачык әдәби конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булып узды. Тантана алдыннан ТР Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды директоры Нурия Һашимова «Казан утлары» журналы редакциясенең проза бүлеге мөхәррире, язучы Рафис Корбанны юбилее белән котлады. Редакциябезнең шигърият бүлеге мөхәррире, шагыйрь Фәнил Гыйләҗевкә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең Рәхмәт хаты тапшырылды. Аны генераль директор Шамил Садыйков тапшырды. Ул шулай ук уртак проект – «Казан утлары» китапханәсе сериясеннән кечкенә форматтагы кесә китаплары чыгара башлауга бер ел тулуны һәм шушы вакыт эчендә 9 басма дөнья күрүен әйтте. Ул китаплар тупламасын әлеге тантанада катнашкан ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовка бүләк итте. Аннары конкурска йомгак ясалды. «Казан утлары»ның баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин бәйге географиясенең быел тагын да киңәюен әйтеп узды. Аңа Россиянең төрле төбәкләреннән тыш, Төркия, Сүрия кебек чит илләрдән дә әсәрләр килгән. Җиңүчеләргә дипломнарны Марат Әхмәтов һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла тапшырды. Менә алар – җиңүчеләр:

**Повесть номинациясе**

I урын – **Асия Юнысова** («Хатыннар сүрәсе»); II урын – **Айзирәк Гәрәева** («Истанбул малае»); III урын – **Рафига Усманова** («Ярлыкану бәхете»). Кызыксындыру бүләге – **Нурания Гыйльметдинова** («Хакыйкать кыл уртада»), **Фәтхулла Абдуллин** («Чәчкә идек илләрдә»), **Габит Фәрхетдинов** («Җәмнихан балкышы»).

**Хикәя номинациясе**

I урын – **Шәмсия Җиһангирова** («Килен капкасы»); II урын – **Әнвәр Шәрипов** («Мәрсия»); III урын – **Рифә Рахман** («Карга карынын кем белгән»). Кызыксындыру бүләге – **Ифира Хәлимова** («Бер гомеремә – ике дөнья»), **Солтан Шәмси** («Әшрәф баба хөҗрәсе»), **Олеся Умерова** («Яшел күзләр»).

**Шигърият номинациясе**
**(мәктәп укучылары өчен)**

I урын – **Алисә Шакирова**, Теләче, Иске Җөри; II урын – **Динара Фәйзрахманова**, Казан, 177 нче лицей; III урын – **Алия Сәйфетдинова**, Яшел Үзән, Ачасыр. Кызыксындыру бүләге – **Чыңгыз Ханов**, Казан, 185 нче лицей. **Алмаз Рәхимов**, Сарман, Каташ-Каран. **Гүзәл Хәлиуллина**, Сарман, Илексаз.

Тантанада ТР Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев та катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен шагыйрь **Рифат Җамал улы Корбановка (Рифат Җамал)** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

2021 елның 28 ноябрендә 70 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь **Хөсәен Гомәр улы Ягъфәров (Хөсәен Җәгъфәр)** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Тукай районы Иштирәк авылы зиратында җирләнде.

2021 елның 26 ноябрендә 77 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, тәрҗемәче, Г.Державин премиясе лауреаты **Михаил Викторович Тузов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы Архангель зиратында җирләнде.

2021 елның 8 декабрендә 90 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, театр белгече, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның атказанган фән эшлеклесе, Ж.Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреаты **Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казандагы «Курган» зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Буа», повесть А.ХАЛИМА «Песня вернулась», рассказ Р.МУХАМЕТШИНА «Тюльпаны»; стихи Р.ВАЛЕЕВА, Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Н.САФИНОЙ, Г.ЗАЛИЛОВОЙ.*
*«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья К.КАРИМОВА.*
*«Казан утлары» - в моей судьбе»: статья Ф.САДРИЕВА.*
*Литературный конкурс «Майдан - для батыров»: рассказ Р.КУРБАНА «Последний Сабантуй».*
*«Литературная критика»: статьи Л.ГАЛИТЗУЛЛИНОЙ (к 80-летию А.Халима), Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ (к 75-летию Р.Валеева), З.МАНСУРОВА (к 60-летию Р.Зайдуллы).*
*Фотоархив: к 85-летию Государственного Советника РТ, Первого Президента РТ М.Шаймиева.*
*«Литература родственных народов»: стихи Т.ЗУМАКУЛОВОЙ, М.БЕППАЕВА, А.ДОДУЕВА в переводе Р.КУРБАНА.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Искусство»: статья Ю.САФИУЛЛИНА.*
*«Литературные объединения» стихи: Р.ГИМАДИЕВОЙ, А.САГИЕВОЙ, Г.ГИНИЯТОВА, Д.АХМАДУЛЛИНОЙ, Р.САБИРЗЯНОВА, М.СИБГАТУЛЛИНОЙ, Ф.АБДУЛЛИНОЙ, З.ХАКИМУЛЛИНОЙ.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 75-летию Зульфата и 70-летию Д.Гайнутдиновой. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Татарский государственный академический театр оперы и балета им. М.Джалиля. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by F.GIMALTDINOV «Bua», story by A.KHALIM «The song is back», story by R.MUKHAMETSHIN «Tulips»; poems by R.VALEEV, R.ZAYDULLA, N.SAFINA, G.ZALILOVA.*
*«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: article by K.KARIMOV.*
*«Kazan Utlary» is in my destiny»: article by F.SADRIEV.*
*Literary competition «Maidan for the batyrs»: story by R.KURBAN «The last Sabantuy».*
*«Literary criticism»: articles by L.GALITZULLINA (to the 80th anniversary of A.Khalim), D.ZAGIDULLINA (to the 75th anniversary of R.Valeev), Z.MANSUROV (to the 60th anniversary of R.Zaydulla).*
*Photo archive: to the 85th anniversary of M.Shaimiev.*
*«Literature of kindred peoples»: poems by T.ZUMAKULOVA, M.BEPPAEV, A.DODUEV translated by R.KURBAN.*
*«1100 years since the conversion to Islam in the Volga region»: article I.ZAGIDULLIN.*
*«Art»: article by Y.SAFIULLIN.*
*«Literary associations» poetry: by R.GIMADIEVA, A.SAGIEVA, G.GINIYATOVA, D.AKHMADULLINA, R.SABIRZYANOVA, M.SIBGATULLINA, F.ABDULLINA, Z.KHAKIMULLINA.*
*«Priceless voices»: articles to the 75th anniversary of Zulfat and the 70th anniversary of D.Gainutdinova.*
*The heading is conducted by N.AKMAL.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Tatar State Academic Opera and Ballet Theatre named after M.Jalil. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры. *И.Абрамова фотосы.*